


# КАЗАН УТЛАРЫ

4
АПРЕЛЬ
1979

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

4
АПРЕЛЬ
1979

## Бу санда

**В. НУРУЛЛИН. Аккан су юлын табар.** Повесть . 3
**Г. ЛАТЫЙП. Апрель бирде безгә Ленинны.** Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
**Г. РӘХИМ. Кара әле, Тукай, Казаныңа.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 70
**Р. НИЗАМИЕВ. Идел.** Шигырьләр . . . . . . 76
**Р. МИРХӘЙДӘРОВ. Көтеп алынган сәфәр.** Повесть . . . . . . . . . . . . . . . . 82
**Г. АФЗАЛ. Канәгатьсезлек хисе.** Шигырьләр . . 103
**Э. КАСЫЙМОВ. «Ахири» дуслар.** Әкият . . . . 107

ОЧЕРКЛАР

**М. ЗАРИПОВ. Ут бригадиры** . . . . . . . . . 111

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Б. РӘХИМОВА. Идел өсте күк томан.** Шигырьләр 127
**Ф. БӘШИРОВА. Кояшым.** Шигырьләр . . . . 129

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IX СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**М. ХӘСӘНОВ. Социалистик реализм һәм татар совет әдәбияты мәсьәләләре** . . . . . . . 131

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Ш. ХАММАТОВ. «Миллионнарның бәйлә йөрәген...»** . . . . . . . . . . . . . . . . 139

БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

**СИБГАТ ХӘКИМ. Җәлилләр ачкан юлдан** . . . 147
**РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВ. Төп юнәлеш — кешене саклау** . . . . . . . . . . . . . . . . 153
**ЛӘЛӘ ХӘЙДӘРОВА. Кем соң син, замандаш** . 156

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Л. ҖАМАЛЕТДИНОВ. Тукай һәм әдәби әкият** . . 160
**И. КАДЫЙРОВ. Себер татарлары музыкасы** . . 165

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һәм
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. БӘШӘРОВ.** Күңелемә алам яктылык . . . . 174
**Р. НӘБИЕВ.** Матбугатыбызның үсеш юллары . . 176

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Т. МИҢНУЛЛИН.** Вәхшиләр . . . . . . . . . . 179
**КӘШФЕЛЗАДӘ.** Йокысыз төн . . . . . . . . 181
**И. ТУКТАР.** Егет белән кыз . . . . . . . . . . 183

Безнең сафка . . . . . . . . . . . . . . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-63, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Ф. Кадыйрова*

---

Производствога бирелде 6/II-1979 ел. Басарга кул куелды 15/III-1979 ел. ПФ 09007. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83744 экз. Заказ В-441. Бәясе 50 тиен.

---

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

Вакыйф Нуруллин

# АККАН СУ ЮЛЫН ТАБАР

ПОВЕСТЬ

## Сүз башы



Жомга көн иде. Эш сәгате тәмамланып килә. Ә алда ике көн ял. Шимбә көн балыкка барырга планлаштырып торам, якшәмбедә балаларны курчак театрына алып барырга ниятләп куйган идем. Өстәлемдәге кәгазьләрне җыештырып, инде кайтып китәргә дип торганда, газетабызның баш редакторы үз бүлмәсенә чакырып кертте. Хәл-әхвәлне сорашты. Балаларның ничек укуы, хатынның кәефе белән кызыксынды. Инде кайчаннан бирле алты җан (өч бала, хатынның әнисе, хатын белән без икебез) бәләкәй генә ике бүлмәле фатирда чиләнүебезне бик әйбәт белеп торса да, фатир хакында да сораштырды. Тәгаен генә өзеп әйтмәсә дә:

— Да, да, моны онытмаска кирәк, — дип, мине өметләндереп, өстәлендәге календарена нидер язып куйган булды.

Ләкин мин бик яхшы белеп торам: болар берсе дә баш редакторны чынлап торып кызыксындыра торган нәрсәләр түгел. Һәм бу хакта аның миңа беренче кат кына әйтүе дә түгел. Болары аның кереш сүз генә. Төп сүзен ул хәзер әйтәчәк. Әнә ул, һич кирәге булмаса да, өстәлендә яткан алтын каләмле ручкасын алды. Гомерендә беренче тапкыр күргән шикелле итеп, аны әйләндерә-әйләндерә карарга кереште. Димәк, шефның миңа ниндидер йомышы булачак. Андый чакта гел шулай ручкасын бик җентекләп тикшерә ул. Әнә, ниһаять, үзенә кирәкне башлады:

— Бик ашыгыч кына эшләп аласы бер бик мөһим эш килеп чыкты бит әле, иптәш Хәкимов. Дөрес, мин аны берәр бүлек мөдиренә яки берәр сотрудникка да куша алган булыр идем. Ләкин синең редакциядә иң тәҗрибәле, иң оператив журналист булуыңны искә алып, мин аны бу юлы сиңа тапшырырга булдым. Елгырлыгың бар, кешеләр белән уртак тел...

Китте мине мактап, китте мактап — чыдап кына тор! Канатым булса, очып китәр дәрәҗәгә китереп җиткерде бу мине. Шуннан ары түзмәдем:

— Кая барырга кирәк соң, Фәлән Фәләнеч? — дип сораганымны үзем дә сизмичә калдым.

К. районының бер сыер савучысына Хезмәт Герое исеме, бер колхоз председателенә Октябрь Революциясе ордены, бер председателенә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бирелү турында карар кылгән икән дә, безнең шеф мине шуларның берсе — Хезмәт Герое турында очерк язып кайтырга җибәрмәк булган икән.

Кирәк икән — кирәк инде. Мондый чакта балыкка, театрга барасы бар дип вакланып торып булмый. Мин аңа:

— Баруын барырмын, Фәлән Фәләнеч, тик, өйгә сугылып, хатынга әйтеп китәсе булыр бит, — диюдән башка берниндн каршы сүз әйтә алмадым.

Ул шундук машинасын чакыртты да мине өйгә кайтып, хатынга әйтеп китәргә җибәрде. Ә үзе шул арада миңа поездга билет юллый торырга булды:

— Мин барысын да сөйләшеп куярмын, вокзалда депутатлар бүлмәсенә керерсең дә... Хәер, сиңа күп сөйләп торасы юк, үзең дә белерсең инде андый гына нәрсәләрне. Кермәгән тишеге юк, ачмаган ишеге юк, дип тикмәгә генә мактамыйлар бит үзеңне, — дип кул бирен озатып калды.

Дөрес әйтә ул, каһәр. Эшкә тотынсам, кайберәүләр шикелле кактым-суктым гына йөрмим инде анысы. Ничә ел шушы редакциядә эшләп, үземә кушылган бер генә эшне дә җиренә җиткермичә калган чагымны мин үзем, мәсәлән, хәтерләмим. Шулай ук шеф та хәтерләми торгандыр андый нәрсәне. Булмаганны ничек хәтерләмәк кирәк? Белә ул безнең шеф ашыгыч һәм мөһим эшләрне кемгә кушарга!.. Тик шунысы гына миңа бик үк ошап бетми: мактаганда гел ялгызымны гына чакыртып мактый ул. Һәм үзенә кирәк булганда, йомышы төшкәндә генә мактый. Ни була инде алтынга тиң шушы сүзләрен бөтен коллектив катнашында үткәрелә торган редакция җыелышларында яки һәр көн иртән үткәрелә торган планерка вакытларында әйтсә. Ә ул алай итми. Әллә коллектив алдында мактап мине бозудан курка микән?.. Хәер, монысы мәсьәләнең формаль ягы гына инде. Шеф тикле шеф үзе мактагач, кайда һәм кайчан мактаса да, барыбер түгелмени?..

Шеф сүзендә торган, мин өйдән әйләнеп вокзалга барып җиткәнче билет мәсьәләсен хәл итеп куйган иде.

Гадәтем шундый: берәр районга берәр кеше турында материал язарга дип баргач, иң элек район газетасы редакциясенә кереп, аның редакторы яки инде күп еллар шул редакциядә эшләгән берәр әдәби хезмәткәр белән киңәшәм. Чөнки алар үз районнарындагы хезмәт алдынгыларын гына түгел, бөтен бала-чагасына, карт-корысына кадәр бик яхшы белеп торалар. Бу юлы мин күптәнге танышым, инде унбиш ел буена редакциянең авыл хуҗалыгы мөдире булып эшләп килүче Нәҗип Нәбиев янына кердем. Герой турында язу өчен эшне кайдан һәм ничегрәк башлыйм икән дип киңәш сорадым.

Нәҗип башта җәенке кызгылт борыны өстендәге түгәрәк тар кысалы, модасы инде күптән чыккан күзлеген рәтләп куйды. Аннары ике иренен дә алга сузып, аларны сул кулы белән учлап, беркавым уйланып торды. Шуннан соң гына:

— Дөресен әйткәндә, буләкләнүчеләрнең өчесе дә очерк герое булырга лаеклы кешеләр, Хатип дус, — диде. — Өчесе дә, гәҗитчә итеп әйтсәк, заман геройлары. Тормышны әйдәп бара торган кешеләр. Ә син шуларның Герой исеме алганы турында язарга дип атап килгәнсең икән. Үз теләгеңме бу, әллә редакторың шулай куштымы?

— Ул да кушты, үземнең дә ният шундыйрак инде.

Нәҗип сыек зәңгәр күзен бер ноктага төбәп уйланып торды да әйтте:

— Ә минем үземне Вәлиев Булат язмышы ныграк кызыксындыра. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. Синең урында булсам?..

Мин аптырабрак калдым:

— Башкалардан аның кай ягы артык?

Нәҗип миңа күзлек астыннан гына шактый усал итеп карап куйды:

— Туктале, син мәсьәләне шулай кирегә борырга маташма әле. Артыклык-кимлек турында нинди сүз булырга мөмкин бу очракта. Булат агай председатель булып инде егерме дүртенче елын эшли. Әйтергә генә ансат бит егерме дүрт ел дип! Ул егерме тапкыр егерме бишәр сыеры, егерме комбайны, утыздан артык тракторы, утызлап машинасы, тагын әллә никадәр катлаулы техникасы һәм шуларны эшләтүче йөзләрчә кешеләре булган хуҗалык белән идарә итә. Ә бит ул кешеләрнең һәркайсының үз холкы, үз фигыле бар. Икенче төрле итеп әйтсәк, алар һәркайсы үзенә бер шәхес. Менә шуннан үзең чамала инде аның эше ничегрәк икәнен. Шунысын да онытма: бу орден Булат агайның тыныч хезмәттә алган беренче ордены. Егерме дүрт елга бер орден әллә ни күп түгел, әлбәттә. Ләкин ул орденның бәясе бик кыйммәткә төште аңа. Аның урынында башка берәү булса, белмим, түзәр иде микән.Ниләр генә күрмәде дә, ниләр генә кичермәде инде аның башкайлары. Хәтта эш шуңа барып җитте, партбилетыннан мәхрүм калган чаклары булды ул кешенең. Ләкин сынмады да, сынатмады да. Беләсеңме, Хатип, чын мәгънәсендә заманча эш алып бара торган, коммунист исемен йөртергә чын мәгънәсендә лаеклы булган кешеләр турында уйлаганда мин һәр вакыт иң элек шул Булат агайны күз алдыма китерәм.Үзем дә хыялланып куям мин аның хакында берәр шәп очерк язарга иде дип. Ләкин мин инде журналистика факультетын әле яңа гына тәмамлап чыккан һәм бөтен халыкны шаккатырырлык әйберләр язам дип кодрәтләнеп йөрүче яшь фантазер түгел. Үз хәлемне үзем беләм: күпме генә тырышсам да, үзем теләгәнчә һәм Булат агай хезмәтенә лаеклы итеп яза алмаячакмын, әйбәт материалны әрәм генә итәрмен шикелле. Ә менә син шул эшкә алынсаң, мин ышанам, матур гына бер әйбер язып чыгарыр идең. Синең...

— Булды, Нәҗип, артык бер сүз дә әйтмә, булды, ышандырдың! — дидем мин, аның әле һаман хисләнеп дәвам итәргә чамалавын сизеп. — Мин синең ул председательнең янына барырга риза. Тик әйт әле: аны ни өчен партиядән чыгарганнар иде?

— Һо-һо, Хатип, — диде Нәҗип, — катлаулы сорау бирдең син миңа, агай-эне. Бик буталчык һәм озын тарих ул. Дөресен генә әйткәндә, мин аның нечкәлекләрен үзем дә яхшылап белә алганым юк әле. Әйдә, бу мәсьәләдә син мине тинтерәтмә инде. Баргач үзеннән сорашып белерсең. Бәлки әле бер баруда гына эшеңне бетерә дә алмассың. Бәлки тагын берничә тапкыр килергә кирәк булыр!

— Минем алайлар итеп йөрергә ара юк шул, Нәҗип: миңа баруыкайтуы белән нибары ике көн вакыт бирде шеф. Берсекөнгә очерк аның өстәлендә булырга тиеш.

Нәҗип, гадәтенчә, күзлеген рәтләп, иңбашын сикертеп куйды:

— Алай булса, барып йөрүеңнең кирәге дә юк. Бер көндә генә син аннан, белмим, нәрсә генә ала алырсың икән? Алай бик тиз генә ачылып китә торган кеше түгел ул, агай-эне!

Монысы инде җитди сәбәп иде. Журналист өчен аз сүзле кеше белән эш итүдән дә уңайсыз нәрсә юк. Була шундый вакытлар, син аның турында язарга дип төбәп килгән кешеләр үзләренең әлеге шул дәш-

мешлеге аркасында бер якта торып кала, ә син хезмәт нәтиҗәләре ягыннан аңа караганда шактый кайтыш булган бүтән кеше турында язып кайтасың. Чөнки анысы, эше уртачарак кына барса да, рәхәтләнеп, җәелеп сөйли белә, шуның белән синең күңеленне җәлеп итә. Ә менә дәшмеш кешеләр каты чикләвек алар безнең өчен. Ләкин шул ягы бар: әгәр син аларның күңеленә ачкыч таба алсаң — ул чакта өстеңә чикләвекле имән ава инде! Тик, кызганычка каршы, андыйлар алай еш туры килми шул безнең журналист халкына... Әлеге Булат дигәннәре дә шундый ачып булмас сандык түгел микән соң?

— Анысы инде синең үзеңнән тора, егетем, — диде миңа Нәҗип. — Әйтсәм әйтим, мин үзем, танышлыгыбыз инде ун елдан артык булуга да карамастан, аның күңел сандыгын ачтыра алганым юк әле. Әгәр ачтыра алган булсам, ихтимал, тәвәккәлләп үзем дә берәр нәрсә язган булыр идем...

Башта бик нык ымсындырып та соңыннан Нәҗип мине әнә шулай шикләндереп куйгач, көнчелегем кузгалды: «Колхоз председателенең дә телен чиштереп, күңеленә үтеп керә алмагач, нинди журналист димин!» — дип уйлап алдым да «Уңыш» колхозына юл тоттым...

Әмма Нәҗип хаклы булган икән. Мин — академиклардан, космонавтлардан, хәтта чит ил капиталистларыннан интервьюлар алып, әйбәт кенә материаллар язып чыккан кеше — бу юлы Булат агайдан очерк дип әйтмим дә инде, хәтта юньлерәк мәкалә язарлык та мәгълүмат ала алмадым.

— Язасың бик килә икән, әнә, рәхим итеп, үзеңә кирәкле материалларны партком секретареннан, агрономнан, колхозның баш инженерыннан, ферма мөдиреннән, бухгалтериядән алырга мөмкин. Ләкин, зинһар өчен дип әйтәм, мине борчыма! — дип кырт кисте ул.

— Һич югы, үз тормышыгызда булган кайбер хәлләрне генә булса әйтеп күрсәтегез? — дип ялваруымның да нәтиҗәсе булмады.

— Анда сез — журналист халкы өчен кызыклы нәрсә юк. Ә минем өчен гыйбрәтле булганнарын сөйләү файдасыз: сез аларны барыбер газетада бастырмыйсыз. Сезгә бар яктан коеп куйган, гел акыллы гына булган, беркайчан да ялгышмаган, гел дөрес кенә эш иткән кеше кирәк. Шулар турында язарга яратасыз бит сез. Юк, минем тормышым да, эшем дә алай шома бармады, — дип гел ачылмас сандык булып кала бирде.

Булат агай артыннан ике көн йөреп тә, мин ул чакта буш кул белән кайтып китәргә мәҗбүр булдым. Ләкин, шул ук вакытта, үҗәтлегем дә кузгалган иде. «Ничек итсәм итәм, әмма үзем исән чакта шушы председательнең күңел капчыгын чиштереп, төбенә кадәр селектермичә калмыйм!» — дип күңелемә дә беркетеп куйган идем. Кайтып киткән чагымда Булат агайның үзенә дә шул хакта әйтеп киттем. Шул чакны ул үзе дә:

— Сөйләвен анысы сөйләттерә алмассың, энекәш. Әмма, бик тырышсаң, берәр нәрсә яздыра алуың бар, — дип өметләндеребрәк әйтеп куйган иде.

Миңа шул сүзе җитә калды: Казанга кайту белән мин аңа үзенең тәрҗемәи хәлен кыскача гына булса да язып җибәрүен үтенеп, хат яздым. Ул миңа: «Шушы көннәрдә ялга чыгып, санаторийга китәм. Төрле процедуралар белән артык аптыратмасалар, хатын-кызлар киноларга, танцыларга чакырып тинтерәтмәсә, кәеф әйбәт булса, ихтимал, шунда берәр нәрсә маташтырып карармын»,— дип җавап җибәрде. Хаты килгән көнне үк, өенә шалтыратып, кайсы санаторийга барачагын белештем дә, ул санаторийга киткәч, көн аралаш диярлек хат язып, биргән вәгъдәсен үтәвен — үзенең башыннан кичкән хәлләрне язып кайтуын тәкърарлап тордым.

Санаторийдан ул миңа бер хат та язмады. Артык нык сагызланып, бу кешене тәмам туйдырып бетердем бугай инде, дип уйлаган идем мин. Аның миңа берәр нәрсә язып җибәрәчәгенә өметем бөтенләй өзелә язган иде. Ә ул агай мин уйлаганга караганда күп мәртәбәләр эшлеклерәк һәм вәгъдәлерәк булып чыкты: санаторийдан кайтышлый безнең редакциягә үзе кереп, минем өстәлгә калын гына бер папка куйды да:

— Менә, энекәш. Бик аптыраткач, язган булган идем шунда. Үзең карарсың, — диде. — Ярардай урыннары булса, яза торган әйберенә кыстырып җибәрерсең шунда. Ярамый икән — бигайбә. Мин шуннан артык яза да, сөйли дә алачак түгел. Бер шартым бар: үзең укып чыккач, кирәк булган урыннарын күчереп ал да бу язуларымны үземә җибәр. Онык үсеп килә минем. Җәен эти-әниләре белән кунакка кайткан чакта: «Бабай, син яшь чагыңда кайларда булдың, ниләр эшләдең? Председатель булып кайчан эшли башладың? Рәхәтме председатель булып эшләү?» — дип сорашып теңкәгә тиеп бетә. Аңар укырмын мин аны. Мин бу эшкә шул син тыкырдатканга да, санаторийда буш вакыт күп булганга гына, уйнабрак кына тотынган идем. Яза торгач кызып кителде дә егерме өч дәфтәр әйбер сырлап ташладым. Гаҗәп икән язу дигән нәрсә: аның белән бер мавыгып киткәч, иң якын иптәшең белән сөйләшеп, күңеленне бушатып утырган шикелле була икән ул. Егерме ике көн эчендә шушы тамаша әйбер язуыма үзем дә шаккаттым. Күңелем тулган булгандыр, күрәсең. Уйлап чыгарасы түгел бит. Барысы да баштан үткән хәлләр. Узган гомер турында уйлану, элекке хәлләрне бүгенге эшләр белән чагыштырып карау — үзе өчен дә шактый гыйбрәтле икән ул.

Әнә шуларны әйтте дә, мин ни кыстап карасам да, утырып та тормыйча, поездга соңга калам дип, Булат агай ашыгып редакциядән чыгып китте. Мин аның дәфтәрләрен укырга тотындым. Дөресен әйтим, мин ул язмаларны әллә ни зур өмет баглап түгел, болай гына, очерк язар өчен кайбер мәгълүматлар алып булмасмы дип, бит аралаштырак кына укымакчы идем. Ләкин беренче битеннән үк кулъязма минем күңелне үзенә шул тикле әсир итеп алды ки, мин аның бер сүзен дә төшереп калдырмыйча укый башладым. Эш сәгате беткәнче редакциядә, ә эштән соң өйгә кайтып, төне буе укыдым. Укып бетердем дә, кулъязмага үземнән берни дә өстәмичә, Булат агай аны ничек язган булса, нәкъ шул көенчә матбугатта бастырып чыгарырга кирәк дигән фикергә килдем. Чөнки, минем карашымча, берниндн арттыруга да, берниндн киметүгә дә, берниндн шомартуга да мохтаҗ түгел иде ул кулъязма. Яхшыртам дип, шомартам, әдәбиләштерәм дип, аны бозып куюю куркынычы гына бар иде. Шуңа күрә, өтерен дә үзгәртмичә, мин аны журнал редакциясенә илтеп тапшырдым. Анда кулъязманы ошаттылар һәм сезгә, хөрмәтле укучылар, тәкъдим итәргә булдылар.

## БЕРЕНЧЕ ДӘФТӘР

Мине ана карынында ук юк итмәкче булганнар. Җиде айлык чагымда әни, мине төшермәкче булып, эссе мунча парларында утырган. Чоланнан келәткә, келәттән чоланга алтышар потлы капчыклар ташып караган. Әллә нинди үлән төнәтмәләре кайнатып эчкән. Күңеле болганып, һушы китеп, егылып яткан чаклары булган.

Тик мин боларның берсенә дә бирешмәгәнмен. Яралуыма нәкъ тугыз ай тулганда, шалкан шикелле тап-таза, йоп-йомры бер малай булып дөньяга килгәнмен. Килгәнмен дә кычкырып елап җибәргәнмен. Чынында исә бу елау түгел, бәлки:

«Мин яшим!

Мин бу дөньяга яшәр өчен килдем!

Үземнең эземне һәм эшемне калдырып китәр өчен килдем!

Сез миңа тимәгез!

Мин беркемгә дә зыян итмәячәкмен. Мин бары гаделлек өчен генә көрәшәчәкмен!» — дип хәбәр салуым булган.

Ләкин минем бу изге ниятләремне аңламаганнар. Эти дигән кеше (мин ана карынында чакта ук миңа үги эти булган кеше) минем тере булып тууымны өнәмичә: «Шул тамашага чыдап исән калуы гына җитмәгән, туганда ук дөнья сасытып акырып туа бит!» — дип, өйдән чыгып киткән дә каты гына салып кайткан.

Ә энинең үз хәле хәл булган...

Тик кендек әбием — Миңҗамал абыстай гына, бердән, энинең исән-имин котылуына куанып, икенчедән, әрсезләнеп дөньяга килүем өчен мине кызганып, белгән догаларын укыган. Аннары:

«Рас инде дөньяга килгәнсең икән, сау-таза булып үс!

Кешеләргә шәфкатьле, игелекле булып үс!

Бәхетле-тәүфыйклы булып үс!» — дип теләк теләгән. Теләкләре кабул булуына ышанып түгел, болай гына, гадәте буенча гына шулай иткән ул. Ятим баланың бәхетле була алмаганын белмимени ул карчык...

Ләкин мин иң элек кендек әбиемнең әнә шул теләкләрен ишеткәнмен. Ишеткәнмен дә колагыма салып куйганмын. Ә үги эти сүзләрен гел игътибарга да алмаганмын...

Әмма мин этиемә беркайчан да үпкә саклап йөрмәдем. Бишектәге бишкә түрләнә. Минем кем булып үсәчәгемне кайдан белсен ди ул? Соңыннан, үсеп күзгә күренә башлагач, мине иң кадерле кешесе итеп санаячагын, үз улыннан да болайрак якын итәчәген каян белсен ди ул гап-гади бер авыл мужигы... Юк, һич тә үпкәләмим аңа. Үпкәләргә хакым юк. Кем белә: аның урынында булсам, бәлки мин үзем дә нәкъ аның шикелле үк киреләнеп маташкан булыр идем. Кемгә кирәк ди үги бала?..

Шулай ук әниемә дә һичнинди үпкәм юк минем. Кулына ятим бала тотып, кемнең унтугыз яшеннән тол хатын булып каласы килсен? Әле бит аның шунысы да бар: минем әни үз этием белән кавышканда да яратышып кавышмаган. Кавышкач та яратышып тормаганнар. Гомумән «торганнар» яки «тормаганнар» дип авыз тутырып әйтерлек урын да юк анда: җәмгысы унбер ай гына бергә яшәп калганнар. Урлап алып кайткан булган аны эти. Ә минем әни кыз чагында әлеге шул мин кычкырып туганга нервысы кабарып чыгып киткән үги эти — Вәлиулла белән яратышып йөргән булган. Яратышканнар, әмма кавыша алмаганнар. Аларның юлына минем үз этием буласы кеше — Әхмәтша аркылы төшкән: әни Вәлиуллага кияүгә чыгарга йөргән көннәрдә аны үзенә урлап алып кайткан...

Әнә шул хәлләрне белгән көенчә, ничек итеп гаепләмәк кирәк әнине дә, ничек гаепләмәк кирәк этине?.. Әле бит аның шунысы да бар: минем үги эти Вәлиулла белән үз этием Әхмәтша — икесе дә бер ата балалары. Тик аналары гына аерым. Әхмәтшасы ике яшькә олырак. Анысы минем бабайның беренче, аерып җибәргән хатынынан туган бала. Ә Вәлиулласы, ягъни минем үги эти, бабайның яшь хатынынан туган бала. Ата бер булса да, холык һәм кыяфәт башка була боларның. Минем үз этием Әхмәтша гәүдәгә артык зур түгел, әмма бик нык булган. Аның хакында авыл картлары әле булса исләре китеп, тел шартлатып сөйли. Бер вакыт күрше авылдан тегермәннән кайтып килгәндә арбасы күпер төбендәге пычракка батып, аты туктап кала моның. Бер дәшеп карый бу атына, ике дәшеп карый. Аты дер-дер калтырый, җан-фәрманга талпынып-талпынып карый. Ләкин арбаны алып чыгарга көче җитми бичараның. Шуннан соң бу: «Каяле, хайван, читкәрәк китеп тор әле алайса», — дип, атны тугара да, тәртә арасына

үзе кереп, арбаны пычрактан сөйрәп чыгара һәм шул бер хуттан өйгә үк алып кайтып куя... Ә икенче бер чакны каяндыр башка авылдан бер бик дәү үгез килеп, үкереп, сөзмәкче булып, кешеләрне куып йөри башлагач, тагын шул минем әти, кулына хәтта таяк та тотмыйча, теге үгезгә каршы барган да, мөгезеннән каерып алып, җиргә егып та салган. Күрәсең, муены бик нык авырткан булгандыр, күзләре калайланып, берничә минут бөтенләй тора үк алмыйча яткан теге үгез. Тик шуннан ары гына аягына басып, шыпырт кына авылдан чыгып киткән. Картларның әйтүенә караганда, шул көннән соң беркайчан да кеше куркытып йөрмәгән. Киресенчә, ир-ат күрсә үзе шүрли торган булып калган...

Үзе шулай көчле булса да, сабан туйларында көрәшә белмәгән әти. Ә сугышырга туры килгәндә исә тирә-якта аңа каршы торырлык кеше чыкмаган. Сигезәр-унар егетне ут өергән чаклары булган аның. Минем әнине дә әлеге шул көчле булуы, беркемнән дә курыкмавы аркасында урлап алып кайткан ул. «Югыйсә, мин үзем дә алай бик үк төшеп калганнардан түгел идем. Бүтән егет булса, бирешәсе түгел идем, әмма әтиең Әхмәтшага дию пәрие дә каршы тора алмасые», — дип, әни миңа үз авызы белән әйткәне бар... Ә үлеме гел кисәк кенә һәм гел көтмәгәндә килеп чыккан әтинең. Үзебезнең сыерны сатып, Казаннан кайтып барышлый, Шаһгали авылына житәрәк, юлына биш кеше аркылы төшкәннәр моның. Сыер сатканын белеп, алдан әзерләнеп көтеп торганнар булса кирәк. Әтине урап алганнар да акчасын таләп итә башлаганнар. Минем Әхмәтша әти өчен биш кеше пүчтәк кенә бит ул.

— Шулаймы? Сезгә акча кирәкме? Менә сезгә акча! — дигән дә әти тегеләрнең икесен ике кулына алып, чырк иттереп, маңгайга-маңгай китереп бәргән.

Шундук һушсыз булган теге адәм тәгаҗәләре. Өченчесен дә тиз генә тормаслык итеп салып егарга өлгергән әти. Ләкин шул арада аның үзенә дә юлбасарларның берсе арттан килеп пычак кадаган...

Әнә шулай итеп, әти белән әнинең бергә тора башлауларына унбер ай тулар-тулмаста, ә мин әле гел ана карынында, нибары ике ай ярымлык чакта, әни белән без ятим калганбыз. Әнә шуннан соң:

— Гаделлек барыбер бер тантана итәргә — без барыбер кавышырга тиеш идек! Чөнки без бер-беребезне яшьтән үк сөешеп йөрдек! — дип, Вәлиулла агай минем әнигә өйләнгән. Авырлы икәнен белеп: — Син миңа бер балаң белән генә түгел, дүрт балаң булса да барыбер кадерле булыр идең. Мин сине гомер буена яратып кына торырмын! Балаңны да кимсетмәм, бүтәннәрдән дә кимсеттермәм! Тик бергә генә булыйк! — дип ялынып-ялварып өйләнгән.

Өйләнүен өйләнгән, әмма бергә тора башлагач, әле тумас борын ук, мин аңа нигәдер артык булып тоела башлаганмын.

— Я — мин, я — балаң! — дип, әни алдына да мәсьәләне бик кискен итеп китереп куйган ул. Ул заманнарда ир сүзе — закон. Нишләсен бичара әни: үги әтинең сүзен тыңлап, мунча парларында да утырып караган, әллә ничә төрле үлән төнәтмәләрен дә кайнатып эчкән.

Тик мин, инде әйткәнемчә, берничә дә карамыйча, яши һәм үсә биргәнмен, нәкъ тугыз ай тулганда дөньяга килгәнмен.

Шулай да мин үги әтиемә элек тә үпкәләмәдем, хәзер дә үпкә саклап йөрмим. Чөнки ул мине беркайчан да үги итмәде. Берәү үз улын да шулай якын күрмәс иде — шундый яратты ул мине. Миңа башта үз әтием фамилиясен биргән булганнар. Ләкин мин укырга керәсе елны үги әти мине үз фамилиясенә күчерттерде. Шулай итеп, мин Әхмәтшин булып түгел, Вәлиев булып йөри башладым. Мине яратмаса, үз улы итеп санамаса, ул моны шулай эшләр идемени?.. Ә теге чакта — мин туган көнне — чыгып китеп, нык кына эчеп кайтуы миңа ачуланып түгел, мәхәббәтләренә тап төшергәнгә минем әтигә ачуланып эш-

ләнгән эш булган ул. Аның урынында мин булсам да, сез үзегез булсагыз да, мөгаен, шулай иткән булыр идегез...

Ярый, мин үз этием — Әхмәтша турында сүзне шушында тәмамлыйм. Теләсәм дә артыгын сөйли алмас идем. Чөнки мин аны гомеремдә бер тапкыр күргән кеше түгел. Хәтта фоторәсеме дә калмаган аның. Хәзер генә ул адәм баласының туганнан башлап һәр адымын диярлек рәсемгә төшереп баралар. Ә ул чакта паспорт алып читкә китәсе булмаган кеше гомер буена бер тапкыр да фотога төшмәгән...

Минем хикәяткә хәзер тагын бер кеше килеп керә. Анысы Шәрифулла исемле. Миңа шулай ук якын тиешле кеше — үз этием Әхмәтшаның туганнан туган абыйсы ул. Мин моны ни өчен шулай катгый итеп искәртәм? Мин моны шуның өчен шулай эшлим, чөнки алга таба сүз нәкъ әнә шул ике кеше — Вәлиулла белән Шәрифулла хакында булачак. Тагын бер исемне хәтерегезгә салып куюыгызны үтенәм. Ул— Шәйхулла. Анысы Шәрифулла агай малае. Димәк, миңа шулай ук туган тиешле кеше. Ул миннән өч яшькә олы. Ләкин мин аны беркайчан да абый дип йөрмәдем. Ни өчен дигәндә, кече-кечкенәдән, мин белә башлаганнан бирле мине кимсетеп килде ул. Аның хакында алда сүз күп булачак. Ә хәзер мин сезгә Вәлиулла белән Шәрифулла турында сөйләмәк булам.

Бала чакларында да, егет чакларында да үзара дус була алар. Бергә уйныйлар, бергә укыйлар, бер-беренә ярдәм итәләр. Ә менә өйләнешеп, семья корып җибәргәч исә, нинди дер юк кына нәрсә аркасында (хәзер инде мин аны үзем дә өзеп кенә әйтә алмыйм) аралары бозылып китә боларның. Андый хәлләр туган белән туган арасында гына түгел, хәтта бертуган агай-энеләр арасында да булгалый. Тик ул озакка бармый. Һәр ике як та беркавым турсаешып йөриләр дә, үзара сөйләшеп-аңлашып, яңадан элеккечә дус булып яши башлыйлар. Ләкин, ни хикмәттер, минем Вәлиулла эти белән Шәриф агай әлеге шул ачуланышуларыннан соң татулашмыйлар гына түгел, киресенчә, бербәрсен куралмаулары отыры арта. Ә бит икесе дә акыллы, төпле кешеләр үзләре. Нигә тотынсалар — шуны эшли алганнар. Кая барсалар — анда сүзләре үткән. Ул яктан Шәриф агай аеруча елгыр булган. Мин моны шуннан чыгып әйтәм, әле нибары утыз яшендә авыл советы председателе итеп куялар аны. Ул заманда авыл советы председательләренең власть зур. Хәзерге исәп белән исәпләгәндә, авыл советы председателе дә, колхоз председателе дә, партком секретаре да булган ул. Ягъни шулар үти торган вазифаларны бер үзе үтәп барган...

Председатель булып алгач, Шәрифулла агай этине аеруча кысрыклый, кимсетә башлый. Шуңа күрә безнең тормыш алга китә алмый. Ә Шәрифулла агайның эшләре тәгәри генә! Авыл халкына сатарга дип кайтарылган әйберләрне үзләштерә ул, ришвәт ала, шуңа күрә күзгә күренеп баый.

Надан булса да, ул чакта да халык ахмак булмый. Сизәләр моның шухыр-мухыр белән шөгыльләнгәнен. Тик берсе дә башлап сүз әйтми. Куркалар.

Вакыт үз җае белән үтә тора. Авыл җирендә колхозлашу башлана. Бер караганда Шәрифулла агай бу эшне үзе башлап йөрергә тиешле кеше бит инде. Ни өчен дисәң, үзе чеп-чи крестиян малае. Атасы да, бабасы да шул бер сыер белән бер аттан артыгына тиенә алмаган кешеләр. Шулай булгач совет властеның хезмәт халкын яклауны, гади халык тормышын рәтләүне күздә тотып эш итүен хуплап кына яшисе дә, шул халыкка таянып кына эш алып барасы бит. Ә бу — юк! Үз мәнфәгатен кайгырта. Колхоз төзүгә каршы чыга. Шул ук вакытта үзе шуны яшереп калырга да тели. Волкомнан килгән вәкил авыл халкын җыенга чакыртып, колхозлашу мәсьәләсен күтәргәндә, вәкилне яклап сөйләгән була. Ә үзе авыл куштаннарын колхозлашуга каршы сөйләргә

өйрәтеп куйган инде. Коточкыч ул — куштанлык дигән нәрсә. Куштан адәм үзеннән бер баскыч югарырак торган кешегә ярар өчен хәтта газиз анасын сатарга да мөмкин. Кызганычка каршы, хәзер дә җитәрлек әле алар... Шул. Җыелыш башлану белән теге куштаннар бугазларын киерәләр дә: «Безгә колхоз кирәкми! Колхозлашу көчлек эше булырга тиеш түгел!» дип, бүтәннәргә авыз ачарга да ирек бирмиләр. Аптырый да кала волком вәкиле. Шул сүзләрне байлар яисә урта хәлләләр авызыннан ишетсә, ни эшләтәсен белер иде ул... Ә монда өстендәге кырык ямаулы бишмәтеннән башка бете дә булмаган ярлылар каршы чыга. Аларны ни эшләтәсең? Аларны җиңәр өчен тик бер генә чара бар. Ул да булса: колхоз төзү аларның үзләре өчен файдалы булачагына ышандыру. Ә Шәрифулла өеренекеләр аларны бөтенләй кире якка ышандырып куйган инде... Минем Вәлиулла әти колхозлашуны яклап сөйләпсөйләп карый да — файдасы юк. Чөнки Шәрифулла куштаннары аңа авыз ачарга да ирек бирми: «Синең кигән ыштаның белән кәҗә хәтле сыерыңнан башка шайтаның да юк. Сиңа атыңны калхузга илтеп бирәсе түгел. Шулай булгач, монда синең сүзең бөтенләй нәкә дә алынмаска тиеш», — дип кенә җибәрәләр.

Шулай да бер башлысы табыла соңыннан: колхозга керү-кермәү мәсьәләсен гомуми җыелыш җыеп түгел, һәр йорт хуҗасы белән аерымаерым сөйләшеп, кул куйдыртып хәл итәргә тәкъдим кертә. Әнә шул нәрсә ярап куя: икенче көнне, колхозга керергә ризалыкларын белдереп, унсигез кеше гариза яза. Аннары шуларны җыеп колхоз төзиләр, аңа «Таң» дип исем кушалар. Ә колхоз председателе итеп минем Вәлиулла әтине сайлап куялар.

Шәрифулла агай авыл советы председателе булып эшләвен дәвам итә. Шулай итеп, болар икесе бер арбаны тартып бара башлыйлар.

Авылның өч йөз еллык тарихында беренче мәртәбә һәм җыен фәкыйрь-фокарадан төзелгән колхозның хәлләре болай да бик авырлык белән генә барганлыгын чамалау кыен түгелдер дип уйлыйм. Шуның өстенә тагын Шәрифулла агай да, ярдәм итәсе урында, әтигә каршы гел этлек эшләп тора. Куштаннары аркылы халыкны колхоздан чыгарырга өндәү дисеңме, «... колхоз мәллә мескеннәр, гариза биреп кердегез, җаныгызны өтсеннәр», — дип мыскыллы җырлар уйлап чыгарулар дисеңме — барысын да ул оештыра. Ә инде утызынчы елны Сталинның «Уңышлыклардан баш әйләнү» дигән мәкаләсе газетада басылып чыккач исә, шул ук Шәрифулла коткысы белән, инде колхозга керергә өлгергән сиксән ике хуҗалыкның да кырык тугызы, колхоздан чыгаруны сорап, гариза китерә. «Әгәр чыгармыйсың икән, халык дошманы дип үзеңне кулга алабыз» дип янап та куялар әтигә. Әти башта югалып кала. Аннары:

— Җәмәгать, бу мәсьәләне мин генә хәл итә алмыйм. Хәзер иптәш Сталинның үзе белән сөйләшеп карыйм әле, — дип, ватык телефонның «колагын борып», трубканы ала да: — Әлү, әлү, иптәш Сталин, синме? Мине ишетәсеңме? Бу мин идем әле, К. вулысының «Таң» колхозы рәисе Вәлиулла Гатиятуллин. Безнең монда бунт чыгарга тора бит әле, иптәш Сталин. Мена монда минем янга... — дип, юлбашчының үзе белән сөйләшә башлый. Хәлне «аңлатып» биргәч, әйтә бу: — Нишлик, Юсиф Биссарионыч? Ни эшләргә кушасың? Әһә, аңлашылды, Юсиф Биссарионыч, аңлашылды! Значит, колхозны таратырга ярамый дисең. Ә мине тыңламасалар ни кылырга кушасың? Әһә, булды. Төшендем. Значит, әгәренки риза булмаучылар булса, иртәгә тиешле урынга озаттырасың... Ярар, ярар, әйтермен. Аңлатырмын. Башларында азрак кына миләре булса, аңларлар...

Ул шулай саф татарчалатып Сталинның үзе белән «сөйләшеп» торган арада, бик кодрәеп килгән теге «акыллы башлар» шыпын-шыпан

гына идарәдән чыгып сызалар. Язмышы кыл өстендә торган колхоз таркалмыйча кала.

Әмма Шәрифулла агай әтигә хөсетләнүен барыбер туктатмый, тәки әтине председательлектән төшерттерә. Моны ул кеше кулы белән эшли. Авыл куштаннарының берсен Октябрь бәйрәме көнне әйбәт кенә итеп эчертә дә, кичен урамда ялгызын туры китереп, әтигә бәйләнергә куша. Мин үземнең Әхмәтша әтиемнең ниндирәк булганын әйткән идем инде. Вәлиулла әти дә шактый таза иде. Минем буй — йөз дә сиксән алты сантиметр. Ә Вәлиулла әти миннән озынрак иде. Димәк, йөз дә туксаннар чамасы булып чыга. Баһадир диярлек ук булмаса да, безнең халык өчен хәйран буй инде бу. Хәер, мәсьәлә буйда гына да түгел. Буйга колга булып та, көч-куәткә килгәндә бернигә ярамый торган кешеләр бар. Ләкин ул яктан да сыната торганнардан түгел иде минем әти. Үзе башлап берәүгә дә кагылмас, ну инде үзенә кагылсалар — баш иеп тормаган! Теге кичне Шәрифулла агай коткысы белән килеп бәйләнгән адәмгә аеруча каты эләктергән. Аның нык ук кызмача икәнен күреп, башта яхшылык белән генә: «Кит, абзый, юкка мәтәшеп йөрмә. Салган икәнсең, бар, кайт та йокла!» — дип, эшне зурга җибәрмичә генә аерылып китмәкче булган ул. Әмма теге бәндә: «Әһә, син әле шулаймы? Безнең ише гади халык белән сөйләшергә теләмисеңме?» — фәлән дә фәсмәтән дип, чәер урынына ябышкан. Әти ачуланмыйча ипләп кенә китеп баргач, артыннан куып җитеп, яңагына ук чәпегән.

Менә шуннан соң әти дә кызып киткән дә, каерылып торып, тегенә берне сылаган. Шундый чибәр сылаган — агаең бер ярты сәгать гел дә һушын югалтып яткан. Ә Шәрифулла, моның шулай буласын алдан ук белеп, ике куштаны белән урамның аргы ягында карап-көтеп торган икән. Әти, теге кешене кызганып, ни эшләргә белмичә торган арада, болар өчәүләп әти янына киләләр дә, Шәрифулла агай әйтә:

— Нишләвең бу, Вәлиулла? Үзең тәртип сакларга тиешле кеше, үзең кеше кыйнап йөрисең! — ди.

— Болай булгач, өстеңнән акт төзергә туры килә. Әйдә, авыл сәвитенә барыйк әле, — ди.

## ИКЕНЧЕ ДӘФТӘР

Күрәсең, моңарчы җыелып килгән бөтен ачуы берьюлы кузгалгандыр инде: алдын-артын уйлап тормый безнең әти, шунда бер хуттан, тегеләрнең өчесен өч якка чәчеп ташлый да өйгә кайтып китә...

Әнә шул көннән соң ул беркайчан да председатель булмый инде. Шәрифулла агай төннәләтеп милиция чакыртып китерә дә әтине районга озаттыра. Аннары әтине эшеннән алалар, алты айга утыртып куялар. Аның урынына, председатель булып, Шәрифулла агай кала.

Утыз икенче ел иде бу. Ул чакта миңа җиде яшь. Әти төрмәдән чыккач сөйләшкән сүзләребез бүген дә истә әле. Кайтып керү белән мине күтәреп алып сөйде дә, куанычыннан килгән күз яшьләрен сөртеп:

— Син минем кайда булганны беләсеңме, улым? — диде.

— Беләм, әти: төрмәдә идең син, шулаймы?

— Әйе, улым, кызганычка каршы, шунда идем шул. Мине ни өчен утыртканнарын да беләсеңме?

— Сугышып кешеләр кыйнаган өчен. Берсенең тешен сугып төшергән өчен, Шәрифулла абыйның кабыргасын сындырган өчен утыртканнар сине, шулаймы?

— Шулай, улым. Сугышмаска кирәк иде миңа ул чакта. Сабыр итәргә кирәк иде. Ялгыштым мин. Ә син беркайчан да кеше белән сугышма, улым, яме! Сугышу җүнлегә алып бармый ул. Сугышып түгел, акыл белән җиңәргә өйрәнергә кирәк бу тормышта. Аңладыңмы, улым?

— Юк, аңламадым. Акылның нинди көче булсын аның? Аның белән Шәйхигә каршы ничек сугып була ди?

— Нинди Шәйхи ул, улым?
— Нинди булсын, шул сине төрмәгә утырттырган Шәрифулла абый малае Шәйхулла инде.
— Әллә сине кимсетәме ул малай?
— Очраган саен кыйнамый калмый. Ә минем аңа каршы торырга көчем җитми. Миннән олы бит ул. Ә син акыл белән җиңәргә кирәк дисең. Бар, җиңеп кара син аны!
Үзенең фәлсәфәсе миңа бик үк барып җитмәвенә күңеле төште бугай: калын кара кашларын җыерып, эти беркавым уйланып торды. Аннары сорады:
— Ә ни өчен кыйный соң ул сине?
— Әтиең өчен, — ди. — Әтиең минем әтиемнең кабыргасын сындырган өчен, — ди. — Кайчакта ни өчен икәнен әйтеп тормыйча да тәпәли.
— Ярар, мин кайткач кыйнамас инде, улым, курыкма.
— Куркуын моңарчы да курыкмый идем мин аннан. Үзен кыйный алмаганга хурланам гына мин. Ә син тагын прсидәтел буласыңмы, эти?
Эти бу мәсьәләне күптән хәл итеп куйган иде булса кирәк, шундук җавап бирде:
— Юк, улым, бүтән беркайчан да прсидәтел булмыйм инде мин.
— Ник, эти?
— Сәбәпләре күп аның, улым.
— Берсен генә булса да әйт әле шуларның, эти?
— Берсе шул: җитәкче булып эшли алмыйм мин.
— Ник эшли алмыйсың, эти?
— Бердән, белемем аз. Икенчедән, андый эшкә сәләтем юк минем. Ә менә син шушы үзебезнең колхозда прсидәтел булып эшләсәң шәп булыр иде. Эшли алырсыңмы икән, улым?
— Белмим шул, эти, син булдыра алмаганны мин ничек эшләрмен икән анда?
— Әйбәт укысаң, акылың булса, булдырырсың, улым.
— Ярар, тырышып карармын, алайса...
Эти кайткач, Шәйхи, чыннан да, мине кыйнаудан туктады.
Тик эти генә үзенең теләге гамәлгә ашканны күрә алмады. Тирләгән килеш салкын җирдә ятып, салкын тидереп авырый башлады да утыз дүртенче елның апрелендә, кыр казлары, сыерчыклар, тургайлар кайткан җылы, матур көннәрнең берендә үлеп китте...
Без әни белән тагын, бу юлы инде бөтенләйгә, ятим калдык.
Әй, әтинең үләсе көннәрдәге ул тилмерүле, ул сагыш-моң тулы карашлары!.. Ул инде ябыгуның чигенә чыккан: тире белән сөяккә генә калган. Зур гәүдәле кеше ябыкса бигрәк кызганыч була икән. Аяк-куллары чамасыз нык озынаеп киткән шикелле күренә. Әгәр урыныннан кисәгрәк кузгалса, бөтенләй таралып китәр шикелле тоела. Ә иң кызганычы — аның сулыш алганын карап тору. Шундый авырлык белән, шундый көчәнеп сулый — һәр сулышы инде моңысы соңгы сулыш булыр шикелле... Әйтәм бит, үзәкләр өзелә иде шундый чакларда. Сәламәт чагында аны күргән кешегә хәзер күрсәтсәң — мәңге таный торган түгел. Мае сызганлыктан, күз алмалары эчкә баткан. Күз карашлары тоныкланган, яңаклар ябышкан. Ә үзе, бичара, гел акылында. Гел сөйләшергә тели. Яныннан бер дә җибәрәсе килми иде мине. Ә минем урамга уйнарга чыгасым килә. Бер чыккач, онтылып, озак-озак кайтмый йөргән чакларым да була. Хәзерге акылым булса, мин аның яныннан бер генә минутка да китмәс идем дә бит, ни хәл итәсең, ул чакта бала булганмын шул. Сине яраткан, синең белән ирләрчә сөйләшкән, сиңа акыл биргән, сине гел яхшылыкка гына өйрәткән әтиең янында утыруның минуты гына түгел, секунды да әйтеп бетергесез зур бәхет булганын тик соңыннан, ул үлгәч кенә аңладым...

Инде әйткәнемчә, үзе сулышын бик авырлык белән генә ала, ә үзе һаман өметен өзми, һаман терелермен дип ышана иде ул. «Менә мин терелгәч...» дип әллә ниләр эшләргә планнар корып ята иде. Күп иде аның эшлисе эшләре: абзар артындагы бәрәңге җиренең бер өлешен койма белән бүлеп алып, җиләк-җимеш бакчасы ясарга да, шунда уңышны өч-дүрт мәртәбә күбрәк бирә торган яңа төр бодай орлыгы китереп чыгарырга да, өй кыегына ике сыерчык оясы ясап куярга да хыяллана иде ул. Каршы як күршеләрнең өй кыегындагы тишеккә оя корып йөргән сыерчыкларны карап ятканда килгән иде аның башына сыерчык оясы ясау уе.

— Кара инде, ә, — дип исе китеп сөйләнеп ятты ул, сыерчыкларның җан-фәрман тырышып салам-солам, мамык-мунчала кисәкләре ташыганын күреп. — Кырыкка җитеп, шул кошларга бер оя ясап куярга да башка килмәгән бит, ә!..

Хәле шәптән булмаса да, урында ятуны бер дә яратмый, тәрәзәдән дөньяга карап утырасы килә иде. Ә утырып торырлык хәле юк. Шуңа без аны ястык-мендәр белән урап, карават башына сөяп утыртып куябыз. Ул шуннан чишмә тавына карап торыр иде дә:

— Их, улым, хәлем булып шул тауга менәсе иде бер. Менәсе иде дә кычкырып җырлап җибәрәсе иде!—дип гаҗизләнеп әйтеп куяр иде...

Үләргә бер көн кала гына ничектер тынып-тынычланып калды ул. Дөнья хәлләре белән кызыксынудан туктады дип әйтмәс идем. Просто сөйләшерлек хәле булмаганга гына сөйләшмәде бугай. Ләкин, ничек кенә булмасын, үләсен белеп үлде ул.

Әни, гадәттәгечә, колхоз эшендә иде. Көндезге унберләрдә әти мине ым кагып кына үз янына чакырып китерде дә әйтте:

— Хәлем авырайды, улым, — диде. — Әнкәңне... алып кайтырга... кирәк булыр. Дөнья эшен... белеп... булмый. Бәлки мин... сез кайтып житкәнче... түзә дә алмам. Әгәр алай-болай булып куйсам... Әниеңә әйт: әти диген, сине яраттым... дип әйтте диген. Сиңа беркайчан да хыянәт... итмәдем... дип әйтте диген. Минем белән мең бәхил... дип әйтте диген... Авырыксынмыйча... елдан артык мине тәрбия кылганы өчен... бик зур... рәхмәт, дип... әйтте диген. Үзеңә дә... рәхмәт, улым... Бала гына булсаң да... гел янымда... булдың... Әйткән... сүземне... тыңладың... Гел шулай... акыллы... бул... яме, улым! Сиңа соңгы васыятем... шул: авылны, туган җирне.. ташлап китмә. Минем хыялларны... беләсең... Аларны син гамәлгә... ашырырга тырыш... Озак... яшә. Минем өчен дә... яшә... яме, улым! Әниеңә... әйтеп... калдырасы... тагын бер... сүзем бар: миннән соң кияүгә... чыкмаса... әйбәтрәк булыр... иде. Ул... бүтән кеше... белән... тора... башласа... мин тыныч ята... алмам анда... Ярар, бар инде, улым. Тизрәк... алып...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады: кинәт бөтен гәүдәсе белән бер жыерылып, бер сузылып куйды да телдән язды...

Мин әнине алып кайтканда, әтинең тәне суынып та өлгергән иде инде. Шулай да миңа ул бөтенләй үк үлмәгәндер, сулышы ачылып киткәндер дә иркенләп, рәхәтләнеп, тирән йокыга талгандыр шикелле генә тоелган иде. Йокысы туйгач уяныр да, сәламәт чагындагы шикелле итеп, мине күтәреп алып сөяр, син дә үсеп җитәсең бит инде, улым, дип куаныр, көләр кебек иде.

Шуңа күрә мин башта кайгырмадым да, еламадым да. Әнинең тавыш-тынсыз гына яшь коюы, күрше-күләннең, туган-тумачаларның безне кызганып елавы миңа хәтта бераз сәеррәк тә булып күренде. Ә икенче көнне иртән әтине ак кәфенгә төреп зиратка алып баргач һәм аңа дип казылган кабер янына килгәч исә кинәт күз алдым караңгыланып, дөньядагы бар нәрсә кара гына булып күренә башлады. Аннары күздән тыелгысыз рәвештә яшь ага башлады...

Мин атна буе миңгерәүләнеп, өнемә килә алмыйча йөрдем. Әнә шул көннәрдә мин, этиемнең васыятен үтәп, авылда калырга, ул тормышка ашыра алмаган хыялларны тормышка ашырырга дип ант иттем.

Антны итүен иттем, тик авылда ныклап төпләнгәнче байтак еллар чит җирләрдә йөрергә туры килде миңа.

Белмим, үз башы җиткәндерме, әллә эти шулай киңәш итеп калдырганмы, әни мине, авылда дүрт класс тәмамлагач, Бохарайдагы рус мәктәбенә укырга бирде. ТБУМны[1] шунда тәмамлагач, врач булуымны теләде. Моңа этинең урын өстендә озак ятып үлүе сәбәп булды, ахрысы.

— Врач караса, үләсе түгел иде атаң. Авылда врач булмаганга гына үлде ул, — дия иде әни миңа. — Син врач булсаң, үзең дә авырмассың, авырып китсәм мине дә терелтерсең, — дип тә бик еш әйтә иде.

Әни сүзен тыңламыйча ярамый, чөнки этинең анаң сүзен тыңла дигән васыяте бар. Шуның өстенә ФАШы[2] да әллә кайда түгел, үзебезнең район үзәгендә генә. Тоттым да тәвәккәлләп кердем мин шунда укырга.

Ярты елдан артык әйбәт кенә укыган да идем инде. Ләкин бер көнне, чаңгы шуганда егылып, аякны сындырдым да, башта озак кына больницада, аннары өйдә ятып, иптәшләремнән артта калдым. (Аякны беренчесендә дөрес утыртмаганнар, шуңа яңадан гипсларга туры килде). Аннары килеп, укып чыкканнан соң врач түгел, фельдшер гына буласы икәнен белгәч, үземнең дә укырга күңел сүрелгән, әнине, авылны да сагынган идем. Больницадан чыккач укырга барып тормадым...

Әйткән идем микән, минем әни Зәңгәр күл дигән авылда туып үскән. Аның энесе Нәкыйп абый ул елларда шунда хисапчы булып эшли иде. Мин ФАШны ташлап кайтканны ишеткәч, бер көнне безгә килде дә мине Казанга хисапчылар курсына укырга барырга үгетли башлады бу. Нәкъ шул чорда гына колхозларга хисапчылар курсына кешеләр җибәрергә разнарядка килгән булган икән. Минем үземнең барырга әллә ни дәртем юк иде югын. Тик әни дә, Нәкыйп абый да: «Күтәреп эшлисе эш түгел, чут төймәсе тартып, идарәдә генә утырасы. Аннары кеше арасында дәрәҗәле дә эш», — дип, бик нык үгетләгәч, риза булдым. Укый башлагач ошап та китте бу миңа.

Бер еллык курс иде ул. Без аны кырык беренче елның маенда тәмамладык. Мин эшкә үзебезнең авылга, һич югында, үз районыбызның берәр авылына кайтырмын дип ниятләп йөргән идем. Минем ният белән артык санашып тормадылар. Син анда түгел, син бүтән җиргә кирәк, диделәр дә, мине Кама урман хуҗалыгы карамагындагы бәләкәй генә артелгә хисапчы итеп җибәрделәр. Дуга, тугым бөгә, чана ясый торган артел иде ул. Эшчеләре күп түгел: җәмгысы егерме дүрт кеше. Бөтен артелгә бер ат. Әмма шул бәләкәй артел дә тиздән күзгә күренеп кими башлады: артел эшчеләрен берәм-берәм сугышка алырга керештеләр. Кырык икенче елның мартында бөтен артеленә без нибары өч җан гына калган идек инде: бер аягын гражданнар сугышында өздереп кайткан ат караучы Госман агай белән «Очкын» исемле карт алаша да, өченчесе — мин. Әллә урман хуҗалыгында безне оныттылар, әллә безнең белән хәбәрләшеп торырга вакытлары булмады, бер ай үтте, икенчесенә китте, тик безгә бернинди күрсәтмә бирүче дә, эш хакы җибәрүче дә юк иде. Бу ни хикмәт икән дип бер көнне үзем конторага барсам — ишегендә йозак. Контора хезмәткәрләрен дә фронтка алып

[1] ТБУМ — тулы булмаган урта (җидееллык) мәктәп.
[2] ФАШ — фельдшеро-акушерская школа, ягъни фельдшер-акушерлар мәктәбе.

бетергәннәр икән дә, хуҗалыкның эше гел тукталып ук калган булып чыкты. Нишләргә хәзер? Уйладым-уйладым да «Очкын»ны күрше колхозга илтеп тапшырдым. Госман агайга үз җаен үзе карарга куштым. Әртилнең печатен, акча кәгазьләрен Казанга республика әртилләр идарәсенә илтеп бирдем. Аннары Зәңгәр күлгә кайтып Нәкыйп абый урынына (ул сугышка алынган иде) хисапчы булып эшли генә башлаган идем — үземне дә армиягә алдылар.

Сарапулда ике ай укытып, сержант итеп чыгардылар да туп-туры фронтка озаттылар мине. Артиллериягә эләктем, үзебезнең генералыбыз Фатих Булатов дивизиясенә. Хәзер ничектер, әмма ул чорларда, ай-һай, гаярь кеше иде ул. Бер-ике тапкыр миңа аның үзен күрергә дә туры килде. Ул полкка киләсе булганда, ни әйтер икән дип, дер калтырап тора идек... Кырык өчтә Гомельне азат итү өчен көрәшкәндә аеруча шәп сугышты безнең дивизия. Шуның өчен аңа Гомель дивизиясе дигән исем бирелде. Командирларга, солдатларга да орден һәм медальләрне кызганмадылар. Миңа да шул чакта Дан ордены бирделәр. Камалышта калган дошман бер урында фронтны өзеп кача башлаган вакытта безнең расчет немецларның өч танкысын сафтан чыгарган иде. Шунда мин үзем дә каты контузия алдым. Айга якын госпитальдә яттым. Аннан чыкканда да колак юньләп ишетми иде әле. Шуңа мине тылга озатып, радио төзәтү эшенә өйрәттеләр. Кырык дүртнең башында, колак инде ишетә башлагач — тагын фронтка. Ничек итсәм иттем, тик барыбер үзебезнең частька кайттым. Бу юлы инде артиллерист итеп түгел, радист-разведчик итеп билгеләделәр. Монысы инде хәтәррәк: монда пехотадан артта түгел, монда пехотадан алда булырга, артиллеристларга кая атарга, кайчан атарга икәнен билгеләп-әйтеп торырга кирәк иде.

Минем отделениедә дүрт рация, сигез радист. Үзең өчен генә түгел, алар өчен дә кайгырырга туры килә. Әтинең минем өчен дә яшә дип васыять әйтеп калдыруы кабул булгандырмы, үземнең бәхет булдымы икән — Бобруйскины азат иткәндә дә, Жлобинны алганда да, Слонимны дошманнан арындырганда да ник бер пуля яки снаряд кыйпылчыгы тиеп карасын ичмасам. Аннары Нарев елгасын кичү. Һай, ул чактагы мәхшәр әле хәзер дә төшләргә кереп йөдәтә. Гадәттәгечә, безне, радист-разведчикларны, елганың аргы ягына — әле яңа гына безнекеләр яулап алган Ружан плацдармына чыгардылар. Бик бәләкәй иде ул плацдарм. Безнең андагы сугышчылар да санаулы гына иде. Корал ягы да чамалы. Немецлар ахмак түгел. Бeләләр безнең хәлнең мөшкел икәнен. Ярдәмгә яңа көч килеп җиткәнче безне ярдан елгага этеп төшерер өчен, җан тырмашып ашкыналар. Бер вакыт шундый итеп китереп кыстылар — безгә я бирелергә, я үләргә генә кирәк. Бүтән чара юк. Бирелү турында уйламыйбыз инде анысы. Шул ук вакытта исән калырга да һичнинди җай күренми. Нишләргә хәзер? Иптәшләр белән киңәштек тә: «Үләргә икән — үләргә, тик дошманның үзен дә юк итеп үләргә»,— дип, рация аша утны үз өстебезгә яудыра башлауларын сорадык. Бер снаряд төшкән урынга икенче тапкыр меңнән бере генә төшәргә мөмкин дип әйткәннәрен ишеткәнем булса да, бик ук ышанып җитми идем. Ә менә шул көнне ышандым. Мең генә снаряд атмаганнардыр ул чакта безнең плацдармга. Тик берсе дә, бәхетебезгә каршы, без яткан снаряд чокырына туры килмәде. Шулай итеп, үзебез дә исән калдык, плацдармыбызны да кулдан ычкындырмадык. Шул эш өчен миңа тагын бер орден — Кызыл Йолдыз ордены бирделәр.

Сугышны мин Германиянең Эрфрут шәһәре тирәсендә тәмамладым. Аннары бүтән артиллерия бригадасына күчерделәр, утыз биш солдат биреп, шуларны ике ай эчендә радист итеп чыгарырга куштылар. Тотындым мин бу эшкә. Солдатларны да укытам, үзем дә өйрәнәм. Бер заман шундый мавыгып киттем мин бу эш белән, хәтта төннәрен класс-

ка кереп, төрле системадагы рацияләрне сүтеп-җыеп карый торган булдым. Ә аларга кытлык юк: трофей рацияләр — дөнья! Һәр яңа төр радиоаппаратның схемасын алып, шуның серенә төшенү күңелгә рәхәтлек, канәгатьлек бирә.

Армиядән кайткач та шул радио белән бәйләнгән берәр эшкә урнашырга кирәк булыр дип йөргән идем. Мин дигәнчә барып чыкмады. Теге солдатларны укытып чыгаргач мине, хисапчы итеп, штабка күчереп утырттылар.

Штабта мин кырык бишнең июленнән алып кырык алтының дүртенче апреленә, ягъни демобилизацияләнеп, өйгә кайтып киткәнгә кадәр эшләдем. Хисап эшен яратып эшләдем дип әйтә алмыйм, кушканга, кирәк булганга эшләдем.

Тагын Шәрифулла агайлар токымы белән бәйләнеш китә хәзер. Мин кайтып төшкәндә ул агай инде колхоз председателе түгел. Эчү белән артык мавыгу аркасында ашказанын бозган да, бик каты авырып ята. Ә аның урынына өченче ел фронттан кайткан улы Шәйхуллаһы куйганнар иде. Әйтергә онытканмын: мин армиядән старшина чины белән кайттым. Ә Шәйхи ул яктан арырак киткән: лейтенант иде. Монда ул чынлап та лаек иде, минемчә. Сынының хәрбиләрчә төз-спайлыгы дисеңме, йөреш-торышы дисеңме, төс-битнең чибәрлеге дисеңме — барысы да килгән, барысы да нәкъ менә шул офицер булыр өчен генә яратылган шикелле иде. Буйга әллә ни түгел түгелен. Уртачарак кына.

### ӨЧЕНЧЕ ДӘФТӘР

Әмма башкасына тел тидерерлек түгел иде аның. Монысы — хак. Чибәрлекне дә биргән инде үзенә: атасыныкы шикелле калын кара каш. Хатын-кызның һушын ала торган зур һәм чак кына кәкрерәк борын. Очкынланып торган җете кара күзләр. Дулкын-дулкын булып бөдрәләнгән кап-кара чәч. Ул урамнан үтеп барган чакта ирләре сугыштан кайтмый калган хатыннар, сөйгән егетләре бөтен Европа кырына сибелеп калганлыктан, кияүсез йөрергә мәҗбүр булган сазау кызлар каерылып-каерылып аның артыннан карап кала торганнар иде. Шул Шәйхи белән бер генә тапкыр бергә булсам, үлсәм дә үкенмәс идем, дип әйтүче хатын-кызлар да бар дип сөйлиләр иде ул елларда...

Ә Шәйхи дәрәҗәсен белеп кенә йөри. Чөнки сизә: кайсы гына йортка барып керсә дә — аны борып чыгармыйлар. Председательгә йомышы төшми торган кеше буламыни? Фронттан кайтканына ике елдан артса да, ул әле хәрби киемен салмаган иде. Өстендә яшел диагональ офицер кителе белән кесәләре бүтилкәләндереп тегелгән күе зәңгәр төстәге бик шәп галифе чалбар. Башта — козырегы ялт-йолт итеп тора торган фуражка. Хәтта йолдызы да алынмаган. Гимнастеркасын портупей белән буып йөри. Наганы булмаса да, кобурасы тагылган. Әгәр аның кем икәнен белмәсәң, я районның милиция начальнигы, яки авылга кайткан кадровый офицер дип уйларга мөмкин.

Холкы да сабыр-салмакланган. Күп сөйләшми. Кешене тыңлап тора да, бер-ике сүз белән җавап биреп куя. Әйтсә — бетте. Гел ул дигәнчә генә була. Шулай булырга тиеш. Югыйсә, эшең хөрти: ул яратмаганнар рәтенә керәсең. Анда эләккән кешегә — көн юк.

Хезмәт көне иң аз төшә торган эш — шуларга.

Урман кисәргә разнарядка килсә — шуларны җибәрәләр.

Торфка яки Казанга һөнәр училищесына кешеләр җибәрергә кирәк булганда — иң элек шулар семьясыннан берәрсен яздыралар.

Колхозның чыгымчы атларын — шулар җигә...

Мин кайтканда колхоз хисапчысы булып дүрт кенә класс белемле, исәп-хисап эше белән һичнинди алыш-биреше булмаган бер чибәр тол хатын эшли иде. Шәйхи белән бик тату, аңлашып эшлиләр. Халык аны

Шәйхинең ун кулы дип йөри иде. Шуңа мин үз һөнәрем буенча эшләү хакында сүз дә кузгатып тормадым. Үзем сорап, тимерче ярдәмчесе булып эшли башладым. Көндез тимерлектә булам. Сука калаклары таптыйбыз, сугу һәм җилгәрү машиналарын ремонтлыйбыз, тырма тешләре ясыйбыз, тугым кыршаулыйбыз. Авыл халкының да йомышы өзелеп тормый. Кайсы сынган чалгысын, кайсы сынган сәнәген ялгатырга, кайсы тишек казанын, тишек самаварын, тишек чиләк-чүмечен яматырга алып килә. Минем шеф — тимерче Сагир абзый, гәзитчә итеп әйтсәк, үз эшенең остасы. Утлыкта күмер янып торса, кулында чүкече белән тимер тота торган келәшчәсе булса, ни телисең шуны — коя да куя! Шул осталыгы аркасында дәрәҗә дә зур иде аның. Һәм ул үзенең дәрәҗәсен бик яхшы белә: вәкарь белән генә сөйләшә, урамнан барганда бер дә ашыкмыйча, гәүдәне шәм шикелле төз тотып атлап бара, үзенә сәлам бирүчеләр белән баш кагып кына исәнләшеп үтә. Хәтта председатель Шәйхигә дә бер дә алай баш иеп тормый, киресенчә, тегенең үзен баш иеп сөйләшергә мәҗбүр итә. Чөнки ул Шәйхисез яши ала, ә Шәйхи ансыз — юк! Колхозда ул елларда тимерче кирәк булмый торган берәр минут булды микән?..

Үзен шулай шактый һавалы тотса да, бер дә нәфесле һәм хөсетле түгел: эшләгән эше өчен хезмәт хакын беркайчан да үзе куймый, кем ни китерсә — шуңа, кем күпме китерсә — шуңа канәгать. Ә тормыш хәле авыррак булган тол хатыннардан, карт-карчыклардан гел берни дә алмый. Китергән әйберләрен дә, минем исәнлеккә кичен бер дога кылырсың дип, кире биреп җибәрә. Әмма шул кешенең бер хикмәтле гадәте бар: моны ул үзләре гадел булган кешеләргә карата гына шулай эшли. Ә инде бик үк саф күңелле булмаган, хәйләкәр һәм саран кешеләрнең гозерен тегеләр алтын таулары вәгъдә итсәләр дә тыңламый.

— Андыйларны җенем сөйми. Эшләрен эшләргә кулым үк бармый! — ди торган иде.

Ул мине дә шулай үзе шикелле итәргә тырыша: җае чыккан саен акыл биреп, шул хакта искәртеп тора торган иде. Аның тырышлыгы бөтенләй үк эзсез калмады булса кирәк: теге яки бу кешегә, теге яки бу мәсьәләгә карата мөнәсәбәтемне ачыклар алдыннан мин әле хәзер дә еш кына, бу очракта Сагир агай ничек эшләр иде икән? дип күңелемнән аның белән сөйләшеп-киңәшеп алам... Ул инде бу дөньяда күптән юк. Әйбәт кешеләр нигәдер аз гомерле булалар шул. Ә менә алар эшләгән яхшылыклар, алар әйтеп калдырган гыйбрәтле сүзләр, алар өйрәтеп калдырган әйбәт гадәтләр саклана...

Бер уйласаң шаклар катарлык инде: моннан нибары утыз еллар элекке колхоз хәлләрен бүгенгесе белән чагыштырып карый торган да түгел! Ул чакта колхозның сабан-тырмасын, чәчкеч-ургычын, җилгәргечен һәм сугу машиналарын төзәтүләрне әйткән дә юк инде, хәтта колхозда эшли торган МТС тракторларын ремонтлауга тикле шул бер тимерче белән аның ярдәмчесе җилкәсенә төшә торган иде. Ул еллардагы тимерче — токарь да, слесарь да, механик та иде. Хәзер шул вазифаларның һәркайсын аерым кешеләр, шуның өчен махсус укыган кешеләр башкара. Алай да эш күп дип зарланалар әле... Дөрес, теге елларда колхозның техникасы да әллә ни зур түгел иде. Бүгенге көндә безнең утызлап тракторыбыз бар. Ул чакта бөтен бер МТСында да нибары егермеләп кенә иде. Аларны да ашык-пошык кына салкын алачыкларда ремонтлыйлар, шуңа күбесе ремонттан кайтышлый ук ватылып кала иде. Төзекләренең дә куәте күпме генә инде. Ә бүген безнең машина-трактор паркындагы ремонт мастерскоенда гына да биш төрле цех даими эшләп тора. Ул цехлар барысы да кышын пар белән җылытыла. Һәр цехта үзенә кирәкле станоклар һәм җайланмалар. Кирәк булганда тракторыңны да, машинаңны һәм комбайныңны да ялт итте-

реп тиешле җиргә күтәреп куя торган күтәрү кранына тикле бар. Әйтәм бит, сугыштан соңгы еллар белән чагыштырганда, хәзер колхозда эшләү — ял ул. Инде килеп, хезмәт хакын карагыз. Теге елларда колхозның бар техникасын бер үзе төзәтеп торган, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләгән тимерчегә иң күп дигәндә көненә өч хезмәт көне язалар, ә бер хезмәт көненә нибары биш-алты йөз грамм ашлык тия иде. Ә менә узган елны безнең механизаторларның уртача айлык хезмәт хакы — ике йөз дә егерме бер сум чыкты. Бозау караучыларныкы — йөз дә туксан өч, сыер савучыларныкы — йөз дә җитмеш җиде сум илле өч тиен, төзүчеләрнеке — йөз дә алтмыш биш, шоферларныкы — йөз дә җитмеш өч сум. Шуның янына аларның үз савым сыерлары, үз бәрәңге бакчалары бар бит әле. Иренми икән, яшелчәсен утырта ала...

Бер узган елны гына да колхоз тугыз йөз сиксән мең сум саф табыш алды. Ә теге елларда бу турыда хыялланучы да, ихтимал, булмагандыр. Иң зур хыялыбыз — тамак туйганчы ашарлык икмәк алу иде ул чакларда. Әмма барыбер эшли идек. Хәзергегә караганда күп артык эшли идек. Хәзер колхозда туксан процент эш машина белән эшләнә. Язгы чәчү яки урак өсте чорын исәпкә алмаганда, колхозда көнгә сигез сәгатьтән артык эшләүче юк дияргә була хәзер. Шулай да ялындырыбрак кына йөриләр әле. Бар, көндез бер эштә эшләп кайткан колхозчыны, теге еллардагыча, төнлә ат яки үз сыерын җиктереп заготзернога ашлык илтергә җибәреп кара син хәзер!.. Яисә көндез фермада эшләгән кешеләрне төнлә ашлык сугарга кушып кара!.. Сөйләшеп тә тормаячак алар синең белән. Көненә утыз сум түлим дисәң дә бармаячак. Ә теге елларда түләве дә ташка үлчим генә, шулай да зарланучы, ризасызлык белдерүче юк иде. Чөнки һәркем белә: сугыш илгә коточкыч зур каза китерде, шуның җимерекләрен торгызырга кирәк иде. Ә бүгенге көндә бер безнең авыл халкының гына да саклык кассасында егерме җиде «Волга» автомобиле алырлык акчасы ята. Менә кая китте эшләр!.. Ә мин тимерче ярдәмчесе булып эшләгән елны авыл халкыныкы белән бөтен колхоз кассасын кушып исәпләсәң дә бер машина алырлык акча таба алмас идең.

... Шулай итеп, көндез тимерлектә эшлим, иртә-кич сугыш елларында тузган каралты-кураны рәтлим. Аннары әти васыять итеп калдырган җиләк-җимеш бакчасына тотындым. Үзем дә канәгать шушы тормышымнан, әни дә. Ул бичара минем шулай хезмәт көне яхшы төшә торган (ә ул чакта, инде әйткәнемчә, иң күп хезмәт көнен тимерчегә язалар иде) җирдә эшләвемә куанып бетә алмый...

Тик анда иркенләп эшләргә туры килмәде миңа. Башта әти белән Шәрифулла агайның юлы үзара кисешкән булса, хәзер, бер дә көтмәгәндә, Шәйхи белән минем юллар очрашты. Шулай итеп очраштык без аның белән, икебезгә бер авылда яшәү турында уйларга да ярамый иде хәзер. Бу юлы мин китәргә тиеш булдым. Ләкин җиңелеп түгел, җиңеп. Ничек кенә җиңеп әле!..

Буй-бәдәнгә этиемә тартым икәнлегемне әйткән идем. Инде алтынчы дистәне башлаган булсам да, көч-куәткә дә, шөкер, зарланырлыгым юк икән әле. Мин моны менә нәрсәдән чыгып әйтәм. Узган ел шулай инде армия хезмәтендә булып кайтсалар да, ни аллага, ни муллага дигәндәй, колхозда да эшләмичә, әти-әниләренә дә бер тиенлек ярдәм күрсәтмичә, ат ялы кадәр чәч үстереп, гитара чиртеп, әти-әниләре эшләп тапкан акчага ашап-эчеп, юашрак егетләрне кимсетеп, кыз-кыркынны бимазалап йөри торган өч сөрхәнтәй белән «сөйләшеп» алырга туры килде миңа. «Һәр заманның була үзенә күрә сволочы, каһәр суккыры», — дип, Һади Такташ бик дөрес әйткән икән. Мондый эшлексезләр әлек шәһәрдә генә була дип сөйлиләр, авыл җирендә андый хәлнең булганы да юк, булыр дип күз алдына китерү дә кыен иде. Ә соңгы

елларда, анә, бер безнең авылда гына да өчәү килеп чыкты болар. Сүз дә юк, колхоз аларга калмаган. Алардан башка да эшкә кеше җитәрлек бездә. Әмма начар гадәт йогышлы була бит ул. Моңарчы үз эшләрендә әйбәт кенә эшләп йөргән кайбер яшь-җилкенчәкләр дә, тегеләрдән күреп, шаляй-валяйракка әйләнә башлады. Ә сүз әйтсәң, җаваплары әзер.

— Шулай инде ул, Булат абый, эшләгән кешенеке күренә, безне бик тиз күрәсез, ә бер дә эшсез йөри торган фәлән-фәләннәрне күрмисез! — диләр.

Сизәм, алга таба болай дәвам итә алмый. Тиеш түгел болай дәвам итәргә. Югыйсә, акрынлап бөтен колхоз яшьләрен бозып бетерергә мөмкин теге хәерсезләр. Үзләрен чакыртып сөйләшеп карадым, юк, ыжлап та бирмиләр.

— Без институтка керергә әзерләнәбез. Эшләп әзерләнеп булмый аңа. Син безне борчыма инде, абзый кеше, — дип кенә җибәрделәр.

Әти-әниләрен дәштереп сөйләшүнең дә нәтиҗәсе чыкмады. Беләсезме ни дип җавап бирде алары:

— Син, Булат, — диләр, — ул малайларга бәйләнеп маташма инде. Үзебез чиләнгәне дә җиткән заманында. Ичмаса, балаларыбыз тормышның рәхәтен күрсен. Алардан башка да калхузның эше тукталып тормый бит әле. Аннары, әнә, гәҗит-журналларда да, радиолардан да «укырга кирәк», «укыган кешеләр кирәк» дип көн саен язып та, әйтеп тә торалар. Әйдә, тимә, укысыннар, әзерләнсеннәр!..

Ярый, монысы өченче ел булган хәл. Анысы шулай узды. Теге сөрхәнтәйләр Казанга барып имтихан да биреп карадылар. Ләкин берсе дә институтка үтмәде. Үтәргә тиеш тә түгел. Чөнки аларның үтмәячәге, укырдан йөрмәүләре алдан ук билгеле иде.

Шуннан соң боларның әти-әниләре азрак уйланыр, гел шулай трай тибеп йөрергә ярамаганын аңларлар да, идарәгә килеп, малайларына үзләре эш сорарлар дип көткән идем. Килделәр, килмиләрме соң? Киресенчә: «Эшкә кушарга теләп, прсидәтел Булат балаларның гайрәтен чигереп, нирбысын бозып бетерде. Шуңа гына укырга керә алмый кайттылар балаларыбыз!» — дип, мине гаепләп сөйләгәннәр әле...

Хуш, мин артык горур кеше түгел. Аннары, башка мең төрле вазифалардан тыш, халыкны дөрес юлга әйдәү дә шул ук колхоз председателе вазифасына керә бит. Имтиханнарын бирә алмыйча кайтканнан соң ни үзләре, ни әти-әниләре минем янга килмәгәч, тагын чакыртып алырга туры килде тегеләрне. Башта әти-әниләрен дәштердем. Бу юлы да барысы бер авыздан улларын яклап чыктылар:

— Узган ел житәрлек хәзерләнә алмады балаларыбыз. Бу ел әйбәтләп хәзерләнәбез дә эбизәтельне киләсе елны укырга керәбез дип сүз бирделәр. Әйдә, тимә инде син аларга прсидәтел. Безнең семьялардан да берәр укыган кеше чыгарга тиештер бит инде,— диделәр.

Я, шуннан соң аларга ничек каршы сүз әйтмәк кирәк?.. Шулай да теге сөрхәнтәйләрнең үзләрен дә чакырттым. Туктале, мин әйтәм, әтиәниләре зурлап укыган кешеләр түгел, алар бөтен нәрсәне аңлап та бетермәскә мөмкин, үзләре ни уйлыйлар икән бу шайтаннар. Ни әйтсәң дә, ун ел совет мәктәбендә укыган, өлгергәнлек аттестаты алып чыккан егетләр бит. Бәлки, мин әйтәм, боларына бераз акыл кереп кайткандыр.

Өч тапкыр чакыртканнан ары, ниһаять, килделәр. Һәркайсының өстендә бу елларда модага кергән тез башлары ямаулы, балаклары чачаклы-чуклы джинси кәчтүн-чалбар. Өчесенең дә авызда сигарет. Өчесендә дә чылгыйлары асылынып торган мыек. Чәчне инде әйткән дә юк. Артларыннан караганда хатын-кызмы, ир-атмы икәннәрен аера торган да түгел.

— Я, — мин әйтәм боларга, — барып кайттыгызмы, егетләр?

— Барып кайттык, — диләр, үзләре мыек асларыннан гына елмаешалар.

— Инде ни эшләргә уйлыйбыз соң, егетләр? — мин әйтәм. — Колхозда берәр эшкә урнашабызмы, механизаторлыккамы укырга китәсезме? Кайсын телисез — шунысын сайларга мөмкин.

— Ә без әле эшкә урнашырга да, укырга китәргә дә ашыкмыйбыз, — ди боларның берсе, араларында башлык булып йөри торган Салих исемлесе. — Без институтка укырга керергә әзерләнәбез быел.

— Әзерләнеп тә, кереп тә карадыгыз бит инде, егетләр! — мин әйтәм.

— Һы, — ди әлеге шул Салих дигәне, астыртын елмаеп. — Анысы аның болай гына, тәртибен белер өчен разведкага барып карау гына иде. Ә менә киләсе елда без инде чынлап керергә дип, яхшылап әзерләнеп барачакбыз...

Шуннан соң ни дип әйтәсең инде аларга?..

Тагын йөри башлады болар тырай тибеп. Көн аралаш диярлек авылдан унбиш чакрымдагы тимер юл станциясенә барып, шунда килгән-киткән кеше арасында ышкынып, җае чыкса берәр йомшак күңелле авыл агаена ярты алдырып, кәефләнеп тә кайталар. Тора-бара әлеге шул станциядә ачыграк авызлы кешеләрнең кесәләрен чистарткалыйлар икән дигән имеш-мимешләр дә ишетелә башлады. Имеш-мимешләр дә бөтенләй үк нигезсез булмаган булса кирәк, бер-ике тапкыр милициягә дә эләккән болар. Инде ни эшләргә? Болай дәвам итәргә тиеш түгел ич инде. Яхшыга алып бармаячак бу нәрсә егетләрне. Авыл советы председателе ир-ат булып, ул катырак тотынса, ихтимал, тыя да алган булыр иде үзләрен. Ләкин безнең председатель — хатын-кыз. Аның да кыюсызы. Мәсьәләне конкрет алып хәл итә алмый торганы. Үзе ул болай әйбәт кеше. Әмма житәкче булу өчен коры әйбәтлек кенә житеп бетми шул. Аның өчен тәвәккәллек, тоткан жирендән өзә алу да кирәк. Ә бу алай булдыра алмый. Холкы андый түгел... Партоешма секретаребыз ул яктан ут уйната торган кеше иде дә, тик ул өйдә юк, аның бер айга укырга киткән чагы иде. Комсомоллар белән сөйләшеп караган идем, тегеләрнең берсе дә комсомол түгел, взносларын түләмәгәнлектән, инде әллә кайчан комсомолдан төшеп калганнар булып чыкты. Шуннан соң колхозның идарә утырышын жыйнап, шул утырышка дәштердем мин боларны. Колхоз эшенә йөрмәсәләр дә, колхозда туып-үскән булгач, колхоз члены санала бит әле алар. Хуш. Идарә утырышында иртәгәдән үк эшли башларга, әгәр эшли башламыйлар икән, бүтән кискенрәк чара кулланырга дип карар чыгардык.

Карар чыгаруын чыгардык, тик барыбер без дигәнчә эшләмәде теге пәри комалаган нәрсәләр. Икенче көнне үк лесхозга барганнар да, шунда эшкә урнашып, хезмәт кенәгәләре алып кайтканнар. Барып-кайтып йөргән була башлады болар. Лесхозга шалтыратып белешкән идем, анда да киндердермиләр икән: бер көн эшлиләр, ике көн — юк...

Хәзерге заманда районга да, станциягә дә юл өзелми: көн саен колхоздан машиналар йөреп кенә тора. Ә лесхоз нәкъ район юлы өстендә. Барганда да, кайтканда да шул безнең колхоз машиналарына утырып йөри тегеләр. Машина кызганыч түгел, йөрсәләр йөрерләр иде. Ләкин колхозны ташлап киткән кешеләр, председательне төп башына утырттык, дип көлүчеләр бит алар. Әнә шунысына ачу чыкты минем. Карап-карап тордым да, тукта әле, яшь кенә башлары белән артык акыллы булып, этиләре булырлык кешедән көлмәсеннәр әле дип, шоферларга тегеләрне утыртып йөртмәскә куштым. Кем кушты дисәләр, председатель кушты дип әйтерсез дидем. Шулай дип әйткән болар тегеләргә.

— Ярар, — дигәннәр тегеләр, — алайга китсә, без дә берәр чарасын табарбыз. Председательгә әйтегез, әгәр шул сүзеннән кире кайтмаса — безгә үпкәләмәсен! — дигәннәр.

Шуннан соң атна-ун көн үткәч районнан кайтып килә идем, күрәм, лесхоз турында юл өстенә басып тора болар. Юлның нәкъ уртасында. Мин килгәнне белеп, мине көтеп торганнар. Күрәләтә кеше таптап китеп булмый ич инде. Ә әйләнеп үтү минем холыкка хас нәрсә түгел. Шулай булгач, бу өч зәхмәт өчен генә ничек итеп үз холкыма үзем хыянәт итим ди инде? Туктаттым машинаны. Көтәм. Сүз әрәм итеп башта үзем дәшәсем килми. Болар да тора. Болар да башлап бәйләнергә җөрьәт итмиләр.

## ДҮРТЕНЧЕ ДӘФТӘР

Кесәдән сигаретны алып кабыздым да тартам. Күрәм, пышын-пышын гына нидер сөйләшәләр. Минем нервларның ныклыгын сыныйлар. Сынагыз, мин әйтәм, сынагыз. Күп сынадылар инде минем нервларны. Әмма моңарчы берешкән юк иде әле. Сезгә генә ничек тә түзәрмен, дим. Халәт шундый: чак кына ул-бу була башласа, үземә-үзем хисап биреп тора алмаячакмын. Я — алар, я — мин!..

Башта тегеләрнең нервлары биреште. Араларыннан берсе, әлеге шул Салих исемлесе, машинаның уң ягыннан килеп ишекне ачты да:

— Чык әле монда, агай, сөйләшәсе сүз бар, — ди.

— Мин моннан да бик әйбәт ишетәм.

— Юк, син курыкма, идарәдәге шикелле батыр бул. Чыгып сөйләш! — ди бу. Ә авызыннан аракы мичкәсе исләре килә. Очсызлы кызыл аракы исе. Иң тәмсез ис. Мин аны читкә кагып, шунда выжлатып үтеп тә китә ала идем, әлбәттә. Ләкин бу миңа соңыннан кыйммәткә төшәчәк иде. Шул өч маңка, председательнең өнен алдык дип, очраган бер кешегә мактанып йөриячәкләр иде. Шуңа машинадан төшәргә туры килде.

— Я, нәрсә әйтмәкче буласыз?

Атаманнары Салих, каршыма килеп, теш арасыннан гына:

— Син ник безгә каныгасың, прсидәтел? — ди. — Ник син безне машинага утыртып йөртмәскә әйттең?

— Бөтен сөйләр сүзегез шушы гына идеме? — дидем мин. Тегеләрнең кыяр-кыймас кына сүз башлауларына ачуым чыкты. Алар мине машинадан төшмәс, куркып качар дип уйлаганнар, ә хәзер югалыбрак калганнар иде.

— Безнеңме? — дип чәчрәп чыкты арада иң кечкенәсе, Мәхмүт дигәне. — Юк, болар гына түгел әле әйтәсе сүзләр! — Ул куен кесәсеннән пычак чыгарды. — Менә моны күрәсеңме, прсидәтел?

Мин дәшмәдем. Мыскыллы карап, елмаеп кына куйдым. Ә үзем пружина: теге кизәнә башлауга тибеп егарга торам.

— Карале,— ди бу,— эшне зурга җибәрмик, прсидәтел: иртәгедән син шоферларыңа безне утыртып йөри башларга рөхсәт бир. Ә бүген безне үзең белән утыртып алып кайтасың. Тик шунысын искәртеп куябыз: кайткач алай-болай тавышланып йөрисе түгел! Югыйсә, хәлең мөшкел булачак.

— Беттеме сүзегез? — мин әйтәм. Ә үземнең бөтен тән калтырый. Тегеләрдән куркудан түгел. Нәфрәттән, ачудан!

— Хәзергә бетте, — ди атаманнары.

— Алайса менә болай, егетләр: мин ике сөйләшә торган кеше түгел. Колхозга кайтып эшли башламыйсыз икән, машина дип авыз да ачмагыз! Куркытырга җыенмагыз! Сезнең ишеләрне генә...

Мин сүземне әйтеп бетерергә дә өлгермәдем, теге кечкенәсе, кадамакчы булып, пычагы белән миңа ыргылды. Ялт кына читкә тайпыл-

дым да секунд эчендә пычаклы кулын каптырып, пычагын каерып алдым. Шунда бер очтан үзен тибеп тә ектым. Анысының эше шуның белән бетте: касыгын тотып бөгәрләнеп барып төште.

Бу хәл шундый тиз арада булып алды, теге икесе миңа ябышырга өлгерә алмыйча да калдылар. Ә хәзер эш узган: пычак минем кулда инде.

— Я, — дим тегеләргә, — башыгыз ике булса, килегез хәзер минем янга. Их, аналарыгыздан шәрә туган нәрсәләр!..

Ажгырып өсләренә ыргылган идем, артларына да карамыйча өтәләнеп, кар ерып, икесе ике якка сыпырттылар гына! Ә теге эчен тотып бөгәрләнеп ятканын, кызганып, машинага салдым да авылга алып кайттым.

Юлда кайтышлый әлеге шул әрәмтамаклар, аларны китереп чыгарган сәбәпләр турында уйлана торгач бер фикер килде минем башка: менә шушындый калай этәчләргә юл куеп, җәмгыятебезнең киләчәгенә зыян китерәбез түгелме икән без? Тормышыбыз әйбәт хәзер, бер баланы гына туйдырып торырга була дип, инде егермегә җиткәч тә эшләтмичә, эшкә өйрәтмичә асрап яту кая алып барып чыгарыр икән безнең ул балаларны? Ә бит безнең эшләрне дәвам итәргә һәм безгә караганда яхшырак дәвам итәргә тиешле кешеләр алар.

Шунсыз җәмгыятьтә үсеш юк.

Шунсыз тормыш алга бара алмый. Ә безнең, шагыйрь Гамил Афзал әйтмешли, өф-өф итеп үстергән, юньле-башлы белем алмаган, яшьтән нинди дә булса берәр һөнәргә өйрәнмәгән ул балаларыбыз ничек итеп башкара алыр икән үз өсләренә төшкән шул тарихи миссияне?.. Менә мәсьәләнең кай ягы уйландыра мине. Менә мәсьәләнең кайсы ягы сискәндерә. Шәһәр халкы өчен җавап бирә алмыйм, әмма авылда илле яшьлек эти-әниләре утын ярганда, терлек асларын чистартканда янсә кар көрәгәндә өйләрендә гармун уйнап яки соңгы елларда бер чиргә әйләнеп киткән шул гитараны чиртеп утырган әзмәвердәй егетләрне очрату бер дә читен түгел хәзер...

Явыз ният белән кумәк һөҗүм иткәннәре өчен, тегеләрне җавапка тарттырырга да була иде. Ни әйтсәң дә райсовет депутаты да бит әле мин. Әмма башта үзләре, аннары эти-әниләре килеп ялынгач, кызгандым. Тик өчесенә дә колхозга кайтып эшли башларга дип катгый шарт куйдым. Шулай итеп дөрес эшләдем дип уйлыйм. Судлашып йөрүнең файдасы тияр идеме, зыяны күбрәк булыр идеме — анысын әйтү кыен. Ә менә мәсьәләне тыныч юл белән хәл итү һәр ике як өчен дә начар булмады. Мин дә үз дигәнемә ирештем, тегеләр дә тәртә арасына керде. Күз тимәсен, хәзер колхозда ару гына эшләп йөриләр. Берсе төзүчеләр бригадасында. Берсе, курста укып кайтып, шофер булды. Берсе механизатор — «Беларусь»та эшли.

... Әйе, көч белән тартышырга калганда хәзер дә алай махы бирдем юк әле анысы. Ә кырык җиденче елда, бөтен Европаны җәяүләп айкап кайткан егерме ике яшьлек егет чагымда, көч тә, тәвәккәллек тә бик күпкә артык иде. Ул чакта нәкъ шул тәвәккәллегем белән алдырдым да бугай инде. Югыйсә, чибәрлек алай шаккатмалы түгел минем. Ләкин адәм баласына шул нәрсә хас: ул, үзе чибәр булмаса да, чибәрне ярата, чибәргә омтыла. Гомумән, адәм баласы үзендә булмаган сыйфатларга ирешергә тырыша. Мин дә үзем алай әллә кем түгеллекне артык уйлап тормадым, авылыбызның иң чибәр бер кызына гашыйк булдым бит, әй! Күрше кызы иде ул. Кап-кара күзле, куе кара чәчле, йомры гәүдәле, малайларча җитез һәм гаҗәеп сөйкемле бер кыз иде. Миннән ике яшькә олырак. Башта мин аны үземнең бертуган апам шикелле күреп яраттым. Чөнки минем апа-абыйларым юк. Аның да энесе юк. Шуңа ул да мине энесе шикелле күрә иде булса кирәк: гел үзе белән ияртеп йөри, зуррак малайлар кимсетә башласа, мине яклап сугышуга кадәр

барып җитә. Бик кыю һәм тәвәккәл кыз иде ул. Әмма, үсә барган саен, аның ул кыюлыгы кими, ә матурлыгы арта барды. Элек нечкә булган сыйракларына ит кунып, йомрыланды. Элек ап-ак булган бит алмалары алсуланды... Мин сугыштан кайтканда ул инде зифа буйлы, нечкә билле, йомры күкрәкле гаҗәеп бер сылуга әйләнгән иде.

Ул шулай чибәрләнә һәм миннән ерагая барган саен, минем аны яратуым да үзгәрә барды. Хәзер мин аны бертуган апам шикелле итеп түгел, миңа бөтенләй таныш булмаган, әмма миңа дөньядагы бар кешедән, хәтта әниемнән дә якынрак булган кыз кеше итеп ярата идем. Яратуын яратам, әмма ул хакта кызның үзенә әйтергә йөрәгем җитми. Һәй, кая ул әйтү! Мин хәтта аны яратуыма үземнән үзем оялып йөрим. Шуңа аңа берни сиздермәскә тырышам. Шул ук вакытта сиздерәсе дә килә. Сиздергәнне сиздермичә генә сиздерәсе килә. Бер уйласаң, гаҗәеп инде бу мәхәббәт дигән нәрсә. Үзе чакыра, үзе кача, чыкмый чакырган җиргә, дип җырлыйлармы әле? Күрәсең, бер миңа гына түгел, башкаларга да хастыр әнә шундый каршылыклы хисләр. Каршылыклы, әмма иң татлы, иң яшерен һәм иң изге хисләр. Бүтәннәр ничектер, әмма минем үземнең шуннан бүтән беркайчан да андый һуштан яздырырлык тылсымлы хисләрне татыганым булмады. Гел Айсылу апагызга тугрылыклы булып кына яшәлде дисәм, хакыйкатькә хилафлык иткән булыр идем. Яшереп торуның кирәге юк, кешедән яшерсәң дә, үзеңнән яшерү мөмкин түгел, булды бер гөнаһка кергән чак. Махсус рәвештә эстәп йөреп түгел, әлбәттә. Бер дә көтмәгән-уйламаганда кинәт кенә килеп чыга икән андый хәл. Тоймый да каласың икән... Ләкин шунысын кистереп әйтә алам: беркайчан да, беркемне дә Айсылуымны яраткан шикелле итеп өзелеп ярата алмадым. Баштан гына хур кызы булып тоела икән ул чит хатын-кыз. Ә яшьтән сөйгән яр, чын мәхәббәт — бөтенләй башка. Ул гел тансык, гел саф, гел кадерле һәм гел яңа була икән...

Мин Айсылу апагызны әнә шулай өзелеп яратуымны, ул яратуым гомер буена барачагын, әгәр мин аның белән кавыша алмасам, дөньяда иң бәхетсез кеше булачагымны әлеге шул кырык җиденче елда сугыштан кайткач аңладым.

Аңлавын аңладым. Ләкин шуны Айсылу апагызга да аңлатасы, аңлатасы гына түгел, аны шуңа инандырасы да бар бит әле. Ә ул инде тәмам өлгергән — егерме дүрт яшьлек чибәр кыз. Яныңнан үтеп киткәндә һушсыз калдыра. Аннары килеп, халык арасында абруе да зур — укытучы! Мин башта сугышта, аннары армия хезмәтендә йөргән елларда унны бетереп, үзебезнең авылда укыта башлаган. Ә укытучының абруе ул чакта югары иде. Хәзер генә ул, кемгә карама — урта белемле дә, югары белемле. Ул чакта авылда җиде класс бетергәннәре дә санаулы гына иде. Ә Айсылу инде читтән торып педучилище тәмамлап килә. Авылда аңа гашыйк булмаган берәр егет булды микән ул елларда? Юктыр. Үзебезнең авыл егетләреннән тыш, күрше авыл егетләре, роно инспекторы, финагент, райкомол секретаре, райкомның оештыру бүлеге мөдире — барысы да аңа гашыйк, барысы да аның белән берничә авыз сүз сөйләшер өчен генә дә, юк йомышларын бар итеп, безнең авылга сугылып китәргә тырыша иде. Әле ярый, бәхеткә каршы, Айсылу берсенә бер капланып төшми. Бөтенесенә дә, русча итеп әйткәндә, от ворот — поворот биреп бара иде. «Иде» дип кистереп әйткәч тә, бу кеше шуларның барысын да үзе күреп торган икән дип уйларга кирәкми. Аның өчен карап-ияреп йөрү мәҗбүри түгел. Авыл җирендә берни дә яшерә алмыйсың. Анда кемнең кая басканына хәтле көне-сәгате белән белеп-ишетеп торалар! Моның шулай булуы начар түгел, минемчә. Әнә шул бер-берсенең хәлен күреп-белеп тору әхлакый бозыклыкка юл куймый. Шуңа күрә дә авыл җирендә гаилә низаглары, аерылышулар шәһәр җирендәгегә караганда бик күпкә ким. Чөнки авыл кешеләрен

«халык ни әйтер», «кешеләрдән әйбәт түгел» дигән фикер тотып, тыеп килә... Шәһәр тормышы ул яктан бөтенләй башка. Анда күрше йорттаниләр булганын гына түгел, күрше фатирда ниләр булганын да, хәтта кайчакта анда кемнәр яшәгәнен дә белмиләр. Ә авыл җирендә иртән түбән очта булган хәл кичке якта бөтен авылга мәгълүм булмыйча калмый...

Әйе, Айсылу хәзергә каты тора торуын. Ләкин, ничек кенә дисәң дә, ул да адәм баласы бит. Ялгышып китеп, тегеләрнең берәрсенә аның да күзе төшеп куймас дип кем өзеп кенә әйтә ала? Чынлап торып яратмасалар да, тасма телле егетләргә кияүгә китеп барган кызлар азмыни бу дөньяда? Анысы аның әле анысы. Минем өчен тагын бер бик хәтәр бер кеше бар иде ул чакта. Тегеләр арасында анысының мөмкинлекләре бик күпкә артык иде. Сүз әлеге дә баягы шул Шәйхи турында бара, әлбәттә. Инде әйтеп киткән идем: төс-битнең бер генә килмәгән җире дә юк моның. Үзе офицер. Ә ул чакта офицерларның дәрәҗәсе кызлар арасында мондый егетләрнекенә караганда өч-дүрт мәртәбә артык иде. Аннары килеп, Шәйхинең тел дә бик хәтәр шома. Ныклап тотынса, ташны эретергә мөмкин. Җыр белән биюгә дә авылда беренче иде ул. Минем үземдә исә ни тегесе, ни монысы юк. Күңелем белән биим дә, җырлыйм да. Бер дә кешедән ким түгел. Хәтта күңелем белән башкалардан әйбәтрәк җырлыйм, башкалардан шәбрәк биим дә түгел микән әле. Ләкин кычкырып, кеше ишетерлек итеп җырларга да, кеше алдында биергә дә, үтер, булдыра алмыйм Йөрәгем җитми. Үзем генә чагымда биеп карыйм — була. Ә мәнә кирәк чакта, кеше алдында — юк...

Әйе, үзем кичен клубта, аулак өйләрдә җырлый да, бии дә алмыйм. Ә күңел, каһәрең, аңа карап тормый, авылның иң чибәр кызын — Айсылуны ярата. Гел аңа гына омтыла. Гел шуны гына сөя. Ә аны, үзегезгә мәгълүм, Шәйхи дә күзләп йөри. Кая инде ул яктан миңа Шәйхи белән тартышырга? Алда әйтеп үткән өстенлекләреннән тыш, Шәйхинең миңа караганда тагын бер отышлы ягы бар: Айсылуны ул мин бөтенләй якын да бара алмаган җирләрдә дә күрә ала. Хәзер генә ул укытучысы да, сыер савучысы, тракторчысы да — барысы бергә киносын карый. Барысы бергә культура йортына җыелып, уйный-җырлый, концертын, спектаклен куя да, карый да. Әгәр кемнең кем икәнен алдан белеп тормасаң, киеменә карап кына кайсы укытучы, кайсы сыер савучы икәнен бөтенләй аера да алмыйсың: бар да чәчәк кебек булып киенеп йөри. Моның шулай булуы бик әйбәт, әлбәттә. Чөнки алар барысы да шул ук адәм баласы бит. Шулай булгач, нигә киемнәре белән үк бер-берсеннән аерылып торырга тиеш ди әле алар... Ә без яшь чакта эшләр башкачарак иде. Укытучылар бүтәннәргә караганда затлырак киенә. Чөнки алар акчага эшли иде. Аннары алар клубларга, аулак өйләргә дә гел түгел, бәйрәм-сәйрәмнәрдә генә, концертларда катнашасы булганда, репетицияләргә генә килә. Ә Шәйхи — председатель. Аның барысына да хакы бар: тели икән, Айсылуны мәктәпкә дәрес вакытында барып та күрә ала, теләсә — идарәгә чакыртып та сөйләшә ала. Аннары аның әрсезлек тә җитеп ашкан. Ә мин нәрсә?.. Башкасы турында әйткән дә юк инде, хәтта Айсылу белән икәүдән-икәү генә калган чакларыбызда да сөйләшер сүз таба алмыйча коелыплар төшәм. Әгәр аңа яратуымны әйтсәм, кимсетермен, хәтерен калдырырмын да, ул мине гел кыралмый ук башлар шикелле тоела. Әмма, шул ук вакытта, ул минем күңелемне аңлый да шикелле. Күз карашымнан аңлыйдыр, шуннан аңларга тиеш дип уйлыйм. Мәхәббәт сүзсез дә аңлашырга тиеш шикелле тоела миңа. Ләкин мин бу уйларымның дөресме-түгелме икәнен тәгаен белмим. Шуңа, бәлки мин ялгыша торганмындыр дип, шикләнәм дә. Бәлки мин гел юкка алданып йөри торганмын, бәлки Айсылу инде күптән Шәйхи белән йөри торгандыр дигән хәвефле уй һич баш-

тан чыкмый. Төннәр буе шул хакта уйланып, йоклый алмыйча ятам. Андый чакларда үземә-үзем сүз бирәм: иртәгә ничек тә Айсылуны туры китерәм дә, туп-туры барысын да әйтәм дә бирәм, дим. Җитте, дим. Ниндидер могҗиза булганын көтеп, гел болай билгесезлектә яшәгәнче, ичмаса, барысын да белеп торуың хәерле, дим. Югыйсә, уйлый-уйлый тилегә сабышып китүең дә бик ихтимал, дим... Ә икенче көнне, үзен күргәч: «Нихәл, Айсылу, укытып буламы?» яки «Нихәл, Айсылу, судан кайтып килешмени?» дигәннән бүтән берни әйтә алмыйм...

Ә Шәйхи әйтә иде булса кирәк. Айсылу өйләрендә ялгызы гына калган чакларда, чебеш алып китәргә йөргән тилгән шикелле, алар өе турыннан да бик еш узгалый башлады бу. Колхозга мотоцикл да алып җибәргәч, тизлеге дә артты. Халык та:

— Шәйхи Айсылуга өйләнергә чамалый икән. Тик көз кереп, сугым суя башлаган, каз өмәләре башланган чакны гына көтәләр икән,— дип сөйли башлады.

Дөрес, Айсылу үзе Шәйхи-тилгәнгә алай бик үк мөкиббән шикелле түгел түгелен. Үзләренә су китергәндә безгә дә су кертә ул. Әнисе Асылбикә апай да минем әни янына көн саен диярлек кереп йөри. Шунда Айсылу хакында сүз чыга да, Асылбикә апай:

— Әй, Гайниҗамал, кыз үстерүләр дә бик читен хәл икән! — дип көрсенеп куя. — Башта тугыз ай буенда күтәреп йөрисең. Аннары ике елга якын күкрәк сөтеңне имезәсең. Исәя төшкәч, кеше янында кеше төсле булсын дип, үзең киясен аңа кидерәсең. Үзең ашыйсын аңа ашатасың. Инде үсеп буйга җитте дигәч ул-бу булмагае дип, һаман шуның өчен җан атасың. Ә хәзер менә, нинди бәндәгә тап булыр икән дип, ут йотып торырга кирәк. Син теләгәнне ул ошатмый. Үзе ошатканны ул сиңа әйтми икән шул, малай җаным. Миңа калса, прсидәтел Шәйхулланың бер генә килмәгән җире жук кана да, нишләтәсең аны, кыз үзе өнәп бетерми шул.

«Әй, зобани хатын, — дип, Айсылуның әнисен чын-чынлап орышып куям андый чакларда. — Авызыңнан җил алсын бу кофер сүзләрне. — Ә Айсылу өчен куанам. — Молодец! — дим аңа күңелемнән. — Шәйхуллага кызыкмыйча бик дөрес эшлисең. Син бүтән беркемне дә түгел, тик мине генә сөй, Айсылу, яме! Чөнки мин үзем тик сине генә сөям...»

Мин шулай уйлыйм уйлавын да, кыз үзе бу мәсьәләгә ничек карыйдыр — анысын белгән юк. Кем белә, бәлки ул мине гел дә яратмыйдыр. Бәлки бөтенләй бүтән кешедер аның күңелендә. Суны ул безгә нигез күрше итеп кенә кертә торган булуы да бик ихтимал бит. Менә шунысы сыздыра йөрәк маен. Ягымлы, җылы карашы бар инде барын. Әмма бер җылы карашка ышанып кына ничек тынычланмак кирәк? Бәлки ул бүтән егетләргә дә шулай ягымлы карыйдыр. Кыскасы, Айсылу мине генә яратадыр дип, авыз ачып йөрергә һич ярамый. Нидер эшләргә, ниндидер чара күрергә кирәк иде бу мәсьәләдә.

Уйладым-уйладым да, бер көнне Айсылу безгә су керткәндә, ишегалдында туктатып, әйттем мин моңа:

— Айсылу,— дидем,— Шәйхи синең тирәдә бик еш кайнаша башлады бу араларда. Аның тасма теленә ышана күрмә, яме!

## БИШЕНЧЕ ДӘФТӘР

Я, шуннан ул ни дип җавап бирде дип уйлыйсыз? Бер генә сүз әйтте ул миңа. Әмма берәгәйле итеп әйтте:

— Юләр! — диде. Аннары, чиләкләрен безнең кисмәккә бушатып, тагын суга төшеп китте. Ә мин миңгерәп калдым: ни дип әйтмәк бул-

ды икән ул кызый бу сүзе белән? «Шул лыгырдык Шәйхигә ник ышаныйм мин, юләр», — дип әйтүе булды микән? Әллә: «Ә нигә мин аңа ышанмаска тиеш ди әле, юләр?» — диюе идеме икән? Яки: «Синең ни эшең бар миндә, юләр», — дип әйтүе булды микән? Төрлечә уйларга урын калдырырлык итеп әйтте бит, бәхетле булгыры. Котны алырлык итеп әйтте!..

Судан әйләнеп кайтуын көтеп тордым мин моның. Көтеп тордым да:

— Баягы сүзеңне ничек дип аңларга кушасың, Айсылу? — дидем.

Ике дә уйлап тормады бу. Кычкырып көлеп куйды да:

— Шуны да аңламагач, нинди егет син, Булат?! — диде.

Бүгенгедәй хәтеремдә: өченче ноябрь иде бу. Җирләр туңган булса да, көн әллә ни салкын түгел. Күктә бер болыт әсәре юк. Якты, кояшлы иде. Айсылуның әлеге җавабын ишеткәч, кинәт дөнья салкынаеп, кояшның нуры сүнеп киткән шикелле булды. Әйе, ул кыз хаклы. Мин, егет кеше, юләр булып йөрергә тиеш түгел. Мәсьәләне мин үзем ачыкларга тиеш идем. Ә аны тик кыюлык, тәвәккәллек белән генә ачыклап булачак иде.

Әнә шул кичне мин Айсылуны урлап алып кайтырга план кордым.

Планнарны, шөкер, корып була. Шәп итеп, зур итеп, перспективалы итеп корабыз без аларны. Ә менә ул шәп планнарны тормышка ашыра башлагач исә, әллә каян, әллә нинди көтелмәгән хәлләр килеп чыга да, аларның байтагы үтәлеп җитми, шул план хәлендә генә кала. Күп булды инде андый үтәлмәгән планнар минем гомердә. Хәзер димим, элеккерәк елларда. Планнар өстән бирелә торган заманнарда. Хәзер без планнарны үзебез төзибез. Мөмкинлекләребездән чыгып, көчебездән килердәй булуын искә алып. Хәзер ул яктан эшләр бөтенләй башкача. Ике агроном, ике зоотехник, алты-җиде бухгалтер, экономист эшли бүген бер безнең колхозда гына да. Барысы да үз тармаклары буенча югары белемле кешеләр. Ә теге елларда бөтен колхозына бер председатель дә, булса — бер агроном, булмаса — ул да юк иде. Шулай булгач, корган планың шәп булып кына кая бара аласың?.

Башта ук әйтәм, минем Айсылуны урлау планым да үтәлмичә калды. Ни өчен дигәндә, мин урлап алып кайтасы көнне Айсылу кичен урамга гел чыкмады ук. Чыкканын күрми калыр дияр идем, күрми калырга урын юк: кич күз бәйләнә башлаганнан алып төнге уникегә тикле сагалап тордым мин аны. Өйләрендә ут шуңарчы янды. Әнисе Асылбикә апа комганын тотып, мыдыр-мыдыр укына-укына, өч тапкыр ишегалларына чыгып, тәһарәт алып керде. Утларын сүндерер алдыннан Айсылу үзе дә һава алып кереп китте. Әмма капкаларын ачып урамга чыкмады. Шулай булгач, ничек урлыйсың инде аны? Өйләренә кереп, әнисе алдында кычкыртып алып чыгып китеп булмый бит кешене!..

Икенче кичне чыгуын чыккан да иде. Бәйрәм концертына репетиция ясарга клубка барды анысында. Тик барыбер урлап булмады. Репетиция бүлмәсеннән чыгышлый ук Шәйхи эләктереп алды үзен. Күзен тозландырып, алдан ук шунда кереп, көтеп утырган икән, хәерсез! Бәйләнешкә китсә, мин, һичшиксез, тәгәрәтер идем аны. Малай чакта гына, миннән олы булганга гына җиңә иде ул мине. Хәзер — эш башка. Хәзер ул миңа түгел, мин аңа кәҗә догасы укыта алырлык булган идем инде. Ләкин бит, алайга китсә, тавыш-гаугага кубачак. Ул чакта, билгеле, председатель хаклы булачак. Ә мин Айсылу алдында да, авыл халкы алдында да көлкегә генә калачак идем. Аннары килеп, Айсылуны озатырга өметләнүчеләр бер мин генә түгел, тагын икәү иде. Кайтырга чыккан булып, алар да Шәйхи белән Айсылу артыннан иярел барган иде. Тик кыз беребезгә дә тәтемәде. Шәйхи аны капка төпләренә тикле озатып куйды. Анда да тиз генә кертеп җибәрмәде — унбиш-егерме минутлап сөйләштереп тотты. Ул тагын да тотмакчы иде әле. «Әни сизенсә

ару түгел, аннары иртәгә көнгә дәресләргә дә әзерләнәсем бар», — дип, Айсылу кыбырсый башлагач кына җибәрергә мәҗбүр булды...

Беләм, кеше сүзен тыңлап, шымчылык итеп йөрү егетлек түгел, әлбәттә. Ләкин ул чакта минем шуннан башка чарам юк иде шул. Аннары килеп, мин аларны махсус рәвештә яннарына барып түгел, үзебезнең капка төбеннән генә тыңлап тордым. Шуңа күрә әллә ни гөнаһ эшләдем дип ул чакта да санамадым, хәзер дә ул эшне алай гөнаһ дип өстемә аласым килми. Ни өчен дигәндә, шул чакта аларның ни сөйләшкәнен чамалап калмаган булсам, Айсылу апагыздан колак каккан идем. Шәйхинең Айсылуга: «Сузма, бәгырем. Әйдә, Октябрь бәйрәменә кавышыйк!» — дигәнен мин шул кечне үз колагым белән ишеттем. Әгәр ишетмәгән булсам...

Айсылу аңа кырт кистереп кенә ризалык бирмәде бирүен. Шул ук вакытта тәкъдимен катгый рәвештә кире дә какмады:

— Бигрәк куырасың инде, председатель. Мин бит әле сине бик аз беләм, — диде ул аңа. Ләкин моны бит ризалык билгесе дип аңларга да була иде. Кыз баланың кайсысы, ярар, мин риза дип торыр икән инде? Өзелеп сөйгән ярына да элек-электән ялындырыбрак кына чыккан бит безнең кызлар. Эчләрендә корыч эретерлек кайнар хисләре ташып торса да, тыштан аны сиздермәскә тырышкан алар. Ләкин, кызганычка каршы, аларның шул күркәм сыйфаты соңгы елларда күзгә күренеп кими башлады шул.

Безнең заманда модасы чыкмаган иде ул сыйфатның. Ир-атларның баһадирдайлары сугыш кырларында ятып калган, авылда күзгә күренердәйләре бармак белән генә санарлык. Ләкин безнең заман кызлары, хәзерге кайбер яшь-җилкенчәкләр шикелле, «тизрәк чыгып калыйм әле алучысы барында» дип, мәсьәләгә алай җиңел генә карамый иде.

Озын сүзнең кыскасы шул: Айсылуның Шәйхигә биргән җавабы ризалык билгесе шикеллерәк тоелды миңа. Шуңа күрә, егет кешегә болай әрсезләнү бик үк килешеп бетмәсә дә, бәйрәм арасында, үзенә сиздермичә генә, гел Айсылуны күзәтеп йөрергә булдым.

Җидесе көнне кич авыл укытучылары, бер ялгыз карчык өендә ашсу әзерләп, бәйрәм кичәнә җыелдылар. Чакырулы булгандырмы, үзе темсенеп килгәндерме, анда Шәйхи дә бар иде. Гомеремдә онытасым юк: әллә нинди салкын, бик зәһәр җилле кич булды ул. Көндез тын гына, кояшлы гына торган иде. Кояш баер алдыннан кинәт кенә төньяктан аксыл-кара болытлар килеп чыкты да, бөтен күк йөзен каплап алды. Алмагачларның коелып бетми калган яфракларын йолкып-йолкып җил исте. Аннары ишеп карлы-бозлы яңгыр коя башлады... Шәйхиләр, Айсылулар өйдә. Җылыда. Рәхәтләнеп сыйланып, уйнап-җырлап утыралар. Ә мин — урамда. Алар бәйрәм итә торган өйгә каршы йортның келәтенә ышыкланып торам. Өстә — солдаттан киеп кайткан шинель. Аякта — кирза итек. Башта — солдат бүреге. Фронтта чакта, шушы киемнәрне кигән килеш, кыш көне кар өстендә ятып йоклаган чаклар булды. Анда әллә ни тундырмый торган иде. Ә монда!.. Шундый туңам, тешкә-теш тидереп булмый. Арлы-бирле йөреп тә, физзарядка ясап та карыйм. Барыбер файдасы юк. Җил мине үтәли тишеп исәдер шикелле. Ә өйдәгеләрнең миндә гаме юк. Сиптерәләр биеп. Прәме өйләре селкенеп, ишелердәй булып китә...

Инде үләм, инде бетәм дип торганда, ниһаять, болардан ике укытучы — тарихчы аксак Роберт белән әле быел гына Арча педучилищесын тәмамлап килгән математик Әзһәр килеп чыктылар да, сөйләшә-сөйләшә, бик ашыгып, түбән очка таба китеп бардылар. Җил бик каты искәнлектән, барлык сүзләрен дә аерманчык ишетә алмадым. Ишетелгән кадәресеннән шуны аңладым: ниндидер ат җигү турында сөйләшеп киттеләр алар. Бу хәл минем инде кайчаннан гел бер төрле булган халәтемә шундук үзгәреш кертеп җибәрде. «Нинди ат җигеп йөрү икән ул

шушы эт чыкмаслык яңгырлы төндә? Кемгә кирәк икән ул ат? Аның белән кая бармак, ни эшләмәк булалар икән?» Күңелне шушы сораулар биләп алды. Миңа эссе булып китте. Югыйсә, түнүга чыдый алмыйча кайтып китәр хәлгә җитеп килә идем инде. Ә хәзер прәме аркадан тирләр бәреп чыкты...

Тегеләрнең ат җигеп килгәннәрен күтәргә булдым. Күңел сизенә: әгәр кайтып китсәм, нәкъ менә шушы кара төндә ниндидер хәвефле эш эшләнер шикелле. Ә ялгыз карчык өендәге мәҗлеснең түгәрәкләнер чамасы күренми генә түгел, киресенчә, анда эшләр кызганнан-кыза бара. Их, шунда кереп ун гына минут торып чыгасы иде бер!.. Хәер, нигә ун минут? Бер минуты да бик җитәр иде. Миңа тик Айсылуны күрү һәм үзем аңа күренеп чыгу гына кирәк. Дөньяда мин дә бар икәнен исенә төшерү өчен генә кирәк бу миңа. Ләкин күктән таш ява башласа да, алар янына керәсем юк. Нинди йөз белән барып кермәк кирәк ди кеше мәҗлесенә?..

Мин шулай ут йотып торганда теге укытучылар колхозның нәсел айгырын тарантаска җигеп алып килделәр.

— Син шушында атны саклап торып тор. Мин хәзер кереп Шәйхигә әйтәм дә... — дип, Роберты өйгә кереп китмәкче иде, Әзһәр аны җиңеннән тотып туктатты:

— Карале, анда кайткач Шәйхи әллә салдыра, әллә юк. Син, бар, миңа берәр стакан алып чыгып бир әле, яме! Бик туңдыра башлады, — диде ул.

— Әйтмәсәң дә беләм, агай-эне! Шуны да белмәскә, син мине кем дип беләсең? — диде аңа Роберт. Титаклап, өйгә кереп китте. Күп тә тормады, бер кулына шешә, икенчесенә йодрык кадәр ит тотып, әйләнеп тә чыкты. Мин боларны бик белеп әйтәм: тәрәзәдән төшкән ут яктысында барысы да күренеп тора иде.

— Сорап та тормадым Шәйхидән, шешәсе белән үк алып чыгып киттем, — диде Роберт, мактанып.

— Шуңа да башың җитмәсә, хайван булыр идең син! — диде Әзһәре, бер дә исе китмичә генә. — Үзебез өчен йөрмибез бит, Шәйхи өчен йөрибез. Шуның аркасында мин бүген үземнең Сәрвиям янына бара да алмыйча калдым. Я, ничек анда эшләр? Кайчан алып чыгалар?

— Шәйхи әйтә, сабыр итегез, егетләр, бераз күтәргә туры килер, ди. Кызның кайтыр исәбе юк әле, ди. Но әзер булып торырга кушты. «Кәҗә ябаргамы», «Йолдыз санарга»мы туры килеп, өйалдына апчыксам, миңа булышырга килерсез, дип калды.

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә берәр стакан эчтеләр дә:

— Озаграк күтәргә туры килсә, монысының да кирәге чыгып куюы бар, — дип, Роберт калган аракыны шешәсе белән Әзһәргә бирде.

Үзе тагын өйгә кереп китте. Әзһәр шешәне тарантас башына тыгып куйды. Ләкин шундук кире алды:

— Әй, моның нәрсәсен калдырып торасың. Я айнып бетәр, — дип, үзалдына мыгырданып голт-голт итеп эчте. Тагын бераз калмаганмы дип булса кирәк, шешәне тәрәзәдән төшкән ут яктысына тотып карады. Буш икәнен үз күзе белән күреп ышангач, әллә кеше барын сизеп инде, шешәсен урамның бу ягына, мин шыгаеп басып торган келәткә таба томырды. Чак кына тайпылып калдым. Эләксә — харап иде эшләр. Келәт бүрәнәсенә бәрелеп, шешә көл булды.

Нишләргә хәзер? Алар өчәү. Мин берүзем. Белгән бит Шәйхине дә кемнәрне ярдәмче итеп алырга. Берсе дә минем хәлне аңлардай кеше түгел. Роберты кече-кечкенәдән куштан, игелексез бәндә булды. Кечекечкенәдән мин аны өнәмәдем. Ул шуны белә, шуңа ул да мине өнәми иде. Әзһәрен мин әле аз беләм. Ләкин аның да иманы юк икәнлеге көн кебек ачык: юньле адәм кешегә кыз урлашырга риза буламыни? Әгәр ышанычлы булса, мин хәзер аның янына барыр идем дә, хәлне аңлатып

биреп, Шәйхигә алып кайтасы кызны үзебезгә генә алып кайту турында сөйләшеп карар идем. Анысына ук риза булмый икән, һич югы, Айсылуны бүгенгә урламый торырга күндерер идем. Бүген урламасалар, иртәгә күз күрер иде анда. Мин үзем дә гел болай ачык авыз булып йөрмәм, Айсылуга мәхәббәтемне ничек тә аңлатыр идем. Ә бу Әзһәргә тел әрәм итеп торудан файда булмаячак. Ахмакка гына калуың бар иде.

Тагын байтак вакыт үтте. Хәзер мин туңмыйм. Кая анда туңу! Киресенчә, җәйге челләдәге шикелле эссе иде миңа хәзер. Җил һаман котырына, боз катыш эре яңгыр һаман ява. Җиргә төшү белән ул ялтырап бозлавыкка әверелә бара: бөтен урам шугалакка әйләнгән иде инде. Авыл йортларында утлар да сүнеп бетте диярлек. Әмма мәҗлестәгеләрнең кайтыр чамалары сизелми. Аруын үзләре дә арды бугай инде: җырларының рәте калмады. Тавышлары дыңгырдык юлдан барган арба шикелле: бер бик хәтәр көчәеп китә, бер, гайрәте кайтып, акрынлый. Бер көйне башлыйлар да, аны онытып, икенчесенә күчеп китәләр...

Ат саклап капка төбендә торган Әзһәрнең дә түземе бетә башлады булса кирәк. Башта, эчкән шәпкә, тарантастан алып; өстенә кожан киеп, капка ышыгында арлы-бирле хәйран күңелле генә мыгырданып-җырлап йөргән иде. Аннары тарантасына менеп, тыныч кына оеп утырып торды. Ә хәзер, әнә, тагын арлы-бирле йөри. Үзе өзлексез сүгенә. Русчалатып та, татарчалатып та. Үзен дә сүгә, мәҗлестәгеләрне дә. Робертны да, Шәйхине дә. Шәйхигә бигрәк тә каты эләгә:

— Җаны юк микәнни ул анасын саткан нәрсәнең! Кайчаннан бирле капка төбендә, шушы салкында кеше аны көтеп торганны белми микәнни, иман тактасын...— ди. — Ачуымны чыгарсалар, ташлап кайтып китәргә дә күп алмам мин,— дип тә гайрәтләнеп куйгалый. Әмма кайтып китми үзе. Китәме соң? Председательгә иртәгә үк йомышы төшәчәген белә иң ул. Аның бу сүгенү-сукрануларын үзен юату өчен генә ләбаса...

Ниһаять, төнге беренче киткәч, башта өйдән кемнәрдер ишегалдына чыкты. Аннары үзәк өзгеч итеп илереп:

— Нишлисез сез, кабахәтләр? Җибәрегез! Җибәрегез дим! — дип кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелде. Аннары капка ачылып китте дә, әлеге шул кычкырган-тартышкан кызны күтәреп алып чыгып, тарантаска сала башладылар.

Ул — Айсылу иде.

Гаҗәп икән бу кеше дигәнең. Шуңарчы минем башта бернинди дә конкрет фикер юк. Нидер эшләргә һәм Айсылуны коткарып калырга кирәк икәнен беләм. Тик ничек коткарырга — анысы ачык түгел иде миңа. Ә менә хәзер, тегеләр Айсылуны алып китәргә дип тарантаска салгач һәм, атларын борып, чаптырып китеп барганда исә, ни эшләвемне үзем дә белештермичә, атылып килеп җиттем дә каракларның ат башыннан тотып алдым.

Шәйхи Айсылуны ычкындырмаска азаплана, ә ярдәмчеләре каушап калган иде бугай, нишләргә белмичә аптырап торалар. Шәйхи сүгенеп:

— Ни көтеп торасыз инде, фәлән дә фәсмәтәннәр, тотыгыз да изегез измәсен,— дип кычкыргач кына икесе дә ике яктан килеп миңа ябыштылар.

Ә мин моңа күңелем белән күптән әзер идем инде. Башта берсен, аннары икенчесен селтәп ыргыттым. Тарантастан суырып төшереп, Шәйхине дә салып екмакчы идем — өлгерә алмыйча калдым. Мин тегеләр белән мәтәвекләнгән арада ул, атын чаптырып, китеп барды. Айсылуның: «Җибәр, Шәйхи, җибәр, паразит! Мин барыбер синеке булачак кеше түгел!» — дип ачыргаланып кычкыруы гына ишетелеп калды.

Артларыннан чабудан мәгънә юк: колхозның гел ашап кына яткан нәсел айгыры артыннан җәяүләп ничек җитмәк кирәк? Ә Шәйхи кызны

күрше авыл ягына таба алып китте. Бездә элек-электән килгән гадәт бар: урлаган төнне кызны егетнең өенә алып кайтмыйлар. Сизенеп алып, кызның әти-әниләре, туган-тумачалары килеп алып китмәсен өчен шулай эшләнә бу. Шуңа күрә кыз урларга әзерләнгән егет башта кызны алып кайтырга берәр туганы, яисә берәр ышанычлы кешесе белән фатир сөйләшеп куя. Шәйхи, күрәсең, фатирны Аланда сөйләшеп куйган булгандыр...

Әнә шулай күрә торып колак кактым мин Айсылудан. Ахмак түгел диегез инде мине. Шунда ат башыннан тотып торган арада камыт бауларын гына кисәсе бит. Безнең татарның шулай инде ул: акылы арттарак калып йөри аның. Хәзер үз-үзеңне орышып торудан файда юк, ни дә булса эшләргә кирәк иде. Тоттым да җәяүләп Аланга киттем мин. Алан — зур авыл. Шәйхи кызны кайсы йортка алып кайтканын бер алла үзе генә белә. Барып та тапмыйча кайтуың бик мөмкин иде.

Ләкин минем бүтән чарам юк. Айсылуны коткарсам тик үзем генә коткара алам. Бу эштә миңа беркем дә ярдәм итмәячәк иде.

Мин Аланга барып кергәндә, сәгать инде төнге ике тулып килә. Башка көннәрдә бу вакытта халык күптән йоклап беткән булыр иде. Ләкин бүген, бәйрәм төнендә, утызлап йортта ут бар. Миңа тиз генә әнә шул ут янган өйләрне тикшерергә кирәк, Шәйхи белән Айсылу шуларның берсендә булырга тиеш иде...

Бөтенләй үк бәхетсез түгел икәнмен: бишенче йортта ук таптым мин тегеләрне. Пәрдәсе ябылып бетмәгән тәрәзәдән карап, Шәйхинең анда икәнен үз күзем белән күргәч, капкаларына барсам — капка бикле. Ә капкалары урыс капка. Башка вакытта булса, тотып атабыз дисәләр дә, мөгаен, менә алмас идем мин ул капка өстенә. Ләкин бу юлы, белмим, андый көч һәм җитезлек каян килгәндер, шул биек капка өстенә менеп, ишегалларына сикереп төшкәнемне тоймый да калдым. Куркып китте булса кирәк, тугарып тарантасына бәйләп куелган «Аҗаган», ашавыннан туктап калып, поры-ы-ыххх иттереп пошкырып җибәрде.

## АЛТЫНЧЫ ДӘФТӘР

Мин ажгырып тегеләрнең өенә барып кергәндә, хуҗа хатын самавар әзерләп йөри. Айсылу, өстендәге пальтосын да салмаган килеш, кече якта пышык-пышык елап утыра, ә Шәйхи аның каршына баскан да юатырга азаплана иде. Килеп кергән хутка Шәйхине изүеннән каптырып алып, йодрыгымны ияк астына терәдем:

— Сугып үтеримме шушында?

Күктән иңгәндәй, кинәт кенә аның каршында пәйда булуым шул кадәр нык тәэсир иткән иде булса кирәк, Шәйхи гел телсез үк калды. Куркудан аның хәтта күзләре калайланган иде.

Мөгаен, мине күрү шатлыгыннандыр, Айсылу да башта ни диярга белмичә шаккатып торды. Аннары, елап утырган җиреннән кубып:

— Булат! Зинһар коткар, җаным, шушы кабахәттән! Зинһар, дип әйтәм, коткара күр?! — дип, миңа килеп сыенды.

Ләкин минем аның белән сөйләшеп торырга вакыт юк. Миңа башта Шәйхи белән эшне бетерергә кирәк иде. Шәйхи белән ике арада сугыш китсә, берәребезнең йодрыгы аңа да тимәсен өчен, Айсылуны бер кулым белән читкәрәк кактым да:

— Я, әйт, нишләтим сине, Шәйхи? Менә шушы урында сугып тынсыз итимме? — дидем.

Шәйхинең йөзе мин изүеннән алганда сөттәй агарып калган иде, ә хәзер чигәләр шикелле кып-кызыл булып бүртенеп чыкты. Ул, миннән ычкынмакчы булып:

— Кит әле моннан! Кешене үңәчләргә ни хакың бар синең? Беләсеңме сиңа моның өчен нәрсә булачагын?! — дип кычкыра-кычкыра тарткалаша башлады.

Эшнең яхшыга бармавын сизенеп, хуҗа хатын да:

— Нишләвегез бу, оланнар? Алланы бар дип белсәгез, зинһар, минем өемдә бәйләнешә күрмәгез! Туктагыз! Әтү хәзер үк урамга чыгып каравыл кычкырам да, бөтен авыл халкын җыям! — дип, еларга җитешеп, арабызга килеп керде.

Ул апа хаклы, җиде төн уртасында гауга чыгарып, сугышып яту бер дә килешә торган нәрсә түгел иде. Шуңа күрә Шәйхигә сугып, кул пычратып тормаска булдым. Ялт итеп, тез белән бер генә тапкыр арт шәрифләренә тибеп куйдым да:

— Бар, ишегалдына чык та «Аҗаганны» тарантаска җигә тор! Тик, кара аны, мин чыкмыйча беркая да китмә! — дип чыгарып җибәрдем.

Үзем әле һаман елавыннан туктый алмыйча боегып басып торган Айсылу янына килеп, аны иңеннән йомшак кына кочып алдым:

— Курыкма, Айсылу! Беркемнән дә курыкма! Мин барында сине бирәү дә кимсетә алмас!

Кыз сизелер-сизелмәс кенә, әмма бик якын итеп елмаеп, башын минем күкрәккә куйды:

— Рәхмәт, Булат. Мең рәхмәт сиңа, яме!

Аның әнә шулай үз итеп миңа сыенуын һәм кайнар сулышын тойгач, күз алларым әлҗе-мөлҗеләнеп, башларым әйләнеп китте. Миңа шундый рәхәт, шундый рәхәт — Айсылуны шулай сыендырган килеш, гомер буе басып торырга да әзер идем. Ләкин озаклап торырга ара юк, Шәйхинең безне калдырып кайтып китүе мөмкин иде. Ә мин аны, кучер итеп, ат тоттырып, Айсылу белән икебезне авылга алып кайтып куйдырмакчы булган идем.

Ләкин без ишегалдына чыкканда, Шәйхидән җилләр искән: ул «Аҗаганны» җигеп тормаган, атланып кына чыгып сызган иде...

Нишләргә? Җиде төн уртасында кыз баланы җәяүләп җиде чакрым җиргә алып чыгып китү әйбәт эш булмаячак. Шулай ук аның үзен генә калдырып китәргә дә һич ярамый: әйләнеп килеп, Шәйхинең тагын бәйләнүе мөмкин иде.

— Рөхсәт итсәгез, без сездә генә кунып китәр идек, абыстай, — дидем мин, безгә ияреп чыккан хуҗа хатынга.

Әйтерсең шушындый сүз буласын белеп, җавабын алдан ук әзерләп торган:

— Җук-җук-җук-җук! — диде теге апа, гөлт итеп кабынып. — Калмыйсыз! Калдыраммы соң! Шәйхуллага да шул прсидәтел кеше булганга гына ризалык биргән булганыем мин — карт җүләр. Алла сакласын, калдыраммы соң? Картаеп барган көнемдә сезнең аркада әллә ниткән бәлаләргә тарып, төрмәгә кереп утырыр хәлем җук әле монда! Барыгыз, бар-бар! Хәзер үк чыгып китегез!..

Шулай итеп, безгә җәяүләп кайтырга чыгудан башка чара калмады. Яңгыр инде туктаган. Җил дә тыйлыга төшкән. Ләкин бик нык салкынайткан иде. Мин Аланга килгәндә дөнья дөм караңгы, күзгә төртсәң дә күренмәс иде. Болытлар арасыннан ай күренгәләп торганлыктан, хәзер алай ук караңгы түгел. Ай инде тулы диярлек. Ул миңа нигәдер яңа гына мичтән чыккан хуш исле кайнар калач булып күренә. Үрелеп алып, шул калачтан бер телем кисеп, Айсылуга ашатасы килә иде. Җил безгә каршы исә, ә ай безнең белән бергә җилгә һәм болытларга каршы бара: юл яктыртып, безне озата килә шикелле иде. Юл читендәге әрем һәм үлән сабаклары тоташтан боз белән капланган. Болытлардан арынып, ай яктыртып куйган чакларда алар алтын белән йөгертелгән тылсымлы чәчәкләргә охшыйлар. Сабакларының бер-беренә орынып чылтырашып куюы — сабантуй көннәрендәге кыңгыраулар чыңы булып

ишетелә. Айсылу белән безгә бернинди җил дә, суык та куркыныч түгел. Чөнки без кулга-кул тотышып, шул кулларыбыз аша бер-беребезнең йөрәк җылысын тоеп, Айсылуның Шәйхидән котылуына куанып, бер-беребезне табышканга сөенешеп кайтабыз...

Айсылулар капка төбенә кайтып җиткәч тә, шактый гомер сөйләшеп тордык әле без. Мин аны шул төнне үк үзебезгә алып кайтырга ниятләгән идем. Ләкин ул уемны кызның үзенә әйтергә йөрәгем җитмәде.

Аның белән без тугызынчы ноябрьда кавыштык. Минем әни әле һаман авырып ята иде. Ул көнне дә, гадәтенчә, Айсылу безгә су китерергә керде. Бер көянтә су алып кайтып, икенчесенә барырга чыкканын ишегалдында көтеп тордым да:

— Минем сиңа әйтәсе сүзем бар иде, Айсылу, чак кына туктап тор әле? — дидем.

— Әйтеп кара, күрше.

— Шәйхи турында әйтмәкче идем мин сиңа. Бер каныкса, каныга торган кеше ул. Сакланыбрак йөр син аннан, яме. Тагын берәр этлек китереп чыгармасын.

— Үзем дә шуннан куркам шул, Булат. «Шул Айсылуны кулыма төшермәсәм, исемем Шәйхи булмасын!» дип әйтә икән.

—Ә син курыкма аннан, Айсылу. Беләсеңме, аннан котылу өчен без ни эшлибез? Әйдә, менә болай...

Шуннан артыгын әйтергә тагын кодрәтем җитмәде.

— Нишлибез? Нигә әйтеп бетермисең? — диде Айсылу, бик нык кызыксынып.

Бу миңа рух кертеп җибәрде.

— Син бит инде, — дидем мин аңа, — безнең үз кызыбыз шикелле, Айсылу: су да китерәсең, икмәген дә салып бирәсең... Әллә бүгеннән алып... бездә генә тора башлыйсыңмы?

— Ничек? — ди бу. Үзе, оялып, аска караган. — Өйләнешепме, болай гынамы?

— Үзең ничек телисең, шулай булыр. Тик бездә генә тора башла.

— Син аны хәзер генә шулай дип әйтәсең, Булат. Иртәгә үк, синеңчә түгел, минемчә яшик, дип даулый башлаячаксың!

Мин аптырабрак калдым. Чыннан да, гел ул дигәнчә генә яшәп булмас бит ул, әй. Кайчакларда мин дигәнчә эшләргә дә кирәк булыр. Хәзер сүз биреп тә, соңыннан сүземдә тормасам — егетлек булмас иде.

— Ярар алайса, — дидем мин аңа, байтак уйланып, баш ватып торганнан соң менә мондый фикергә килеп: — Гел синеңчә генә булмый торган булса, кайчакларда минемчә дә булгалар, яме. Ә күп вакытта без һәр нәрсәне киңәшеп, икебезнең дә ризалык белән эшләрбез. Мин сине кечкенә чактан бирле яратам инде, Айсылу. Тик әйтергә генә йөрәгем җитми иде моңарчы.

— Анысын мин үзем дә сизеп йөрим, Булат. Ләкин әле генә үзең: «Син безнең үз кызыбыз шикелле», диден бит. Син дә миңа үз туганым кебек. Шулай булгач, килешеп бетәр микән соң?

Бу инде Айсылуның мин риза дип әйтүе белән бер иде!

— Һәй, Айсылу! — дидем мин, куанычымнан күккә ашардай булып. — Ничек кенә килешер әле! Без синең белән беләсеңме, ничек итеп яшәрбез? Без синең белән шундый матур итеп, шундый бәхетле, шундый тату булып яшәрбез — бөтен дөнья халкы сокланыр!..

Безнең кавышуга әниләребез дә куанышып бетә алмады. Ә Айсылу белән мин — дөньядагы иң бәхетле кешеләр идек. Бер-беребезне хәтта күз карашыбыздан ук аңлыйбыз. Үзем тимерлектә тимерче ярдәмчесе булып эшләвемне дәвам итәм. Ул — мәктәптә. Кич эштән кайтканда, бер-беребезне ун ел күрми торган шикелле сагынышып кайтабыз...

Лəкин ул бəхетле көннəр санаулы гына булган икəн шул. Өйлəнешеп тора башлавыбызга атна-ун көн дигəндə, Шəйхи авылга гайбəт таратты: имеш, Булат аннан калган хатын белəн тора. Имеш, Айсылу Шəйхигə кадəр үк инде «тотылган» кыз булган. Имеш, ул аны шуна күрə Аланда ташлап кайтып киткəн.

Менə кай тарафларга борылып китте эшлəр! Мин үзем боларның бөтенесе дə нахак сүз икəнен, безгə үч итеп, Шəйхи уйлап чыгарган нəрсə икəнен бик яхшы белəм. Моның шулай икəнен Айсылу үзе дə белə. Лəкин халык белми бит аны. Шулай булгач, бар, туктатып кара син бер таралган гайбəтне!.. Хəер, мин үзем гайбəтенə дə түзəр идем əле. Лəкин Айсылуга бик авырга туры килде. Минем шикелле гади колхозчы гына түгел, укытучы кеше бит ул. Тəрбияче кеше. Ə ямьсез даны чыккан тəрбиячегə балалар ничек караганын сөйлəп тормасам да чамалыйсыз булыр. Шəйхи тараткан теге нахак сүз бик тиз арада мəктəп балаларына да барып ирешкəн иде. Əнə шунысына түзə алмады Айсылу. Бер көнне мəктəптəн кайтты да:

— Инде үзем укыта торган балаларга тикле ниндидер бер җинаятьчегə караган шикелле итеп карый башлады. Телəсəң нишлəт, Булат, мин мəктəпкə бүтəн бармыйм! — дип кырт кисте.

Бу очракта аны тыңламыйча мөмкин түгел иде. Шул ук көнне кич тəвəккəллек өчен бер «кечкенə»не төшердем дə, идарəдəн кайтканын капка төплəрендə көтеп алып:

— Менə бу сиңа минем өстəн көлеп йөргəнең өчен булыр! Ə менə монысы Айсылу өчен! — дип, башта Шəйхине тотып ярдым. Аннары, өйгə кайтып, Айсылуга юлга əзерлəнергə куштым.

Безнең өй Айсылуларныкына караганда зуррак, арурак иде. Əбине үзебезгə дəшеп кертеп, аны белəн янəшə утырттым да:

— Без иртəн иртүк читкə чыгып китəргə булдык. Бу хакта ике сөйлəшү юк — мəсьəлə хəл ителгəн. Ə сезгə менə нəрсə кинəш итəм: икегезгə аерым-аерым тормыш алып бару авыр булыр. Шуңа күрə, əби, син безгə күчеп кер дə, аны белəн бергə яши торырсыз! — дидем.

Ə иртəгесен, кеше-кара күзенə артык чалынып тормас өчен, иртəнге сəгать дүрттə үк Айсылу белəн авылдан чыгып киттек.

Китүен киттек. Тик басу капкасын чыгуга башка уй төште: кая барырга? Ни Айсылуның, ни минем паспортыбыз юк. Ни Казанда, ни бүтəн берəр шəһəрдə беребезнең бер туган-тумачабыз юк. Тимер юл станциясенə барып, кай тарафка билет алу мəсьəлəсе алга килеп баскач:

— Нишлибез инде, Булат? Бигрəк тə бəхетсез икəн башкайларыбыз, — дип, Айсылу елап ук җибəрде.

Үземнең хəл дə аныкыннан артык түгел. Лəкин миңа сер бирергə ярамый, чөнки мин — ир кеше. Миңа аны да, үземне дə өметлəндерергə, юатырга кирəк.

— Юк өчен хафаланма, акыллым, — дим мин Айсылуга. — Без бүген җир шарында иң бай, иң бəхетле кешелəр! Чөнки безнең бу дөньядагы барлык кешелəрнекеннəн дə көчлерəк мəхəббəтебез бар. Бүген торыр урыныбыз, барыр җиребез юк икəн — төкер син аңа! Икебез дə сау-сəламəт. Икебез дə эштəн курыкмыйбыз. Ə эшлəгəн кешегə эше дə, торыр урын да булыр. Бүтəн телəсə нəрсəне табып була, Айсылу, тик чын мəхəббəтне табу гына авыр. Ə ул инде безнең бар һəм без бүтəн телəсə кемгə караганда да бəхетлерəк!

Айсылуым азрак тынычлангандай булды: елавыннан туктап, кулъяулыгы белəн күз яшьлəрен сөртте. Аннары əйтə бу миңа:

— Мин шулай икəнен үзем дə белəм, Булат, — ди. — Лəкин менə хəзергесе кыен бит əле! Кая барабыз инде без? Шуңа аптырап елавым бу, — ди.

Үзенең шушы рәхимсез, ләкин хаклы соравы белән тагын стенага китереп терәде ул мине! Чөнки ни эшләргә, кая барырга төшлегебезне мин үзем дә белми идем бит әле.

— Безме,— дидем мин, үзем дә тәмам аптырап.— Без ни эшлибезме? Безме?.. Әһә, без хәзер синең белән менә болай итәбез аны...

Шулай сөйләнә-сөйләнә, билет кассасына таба киттем. Шунда барышлый башка бер конкрет уй килде. Заманында минем белән укыган бер классташ узган җәйдә Кемероводан кунакка кайткан иде. «Шахтыда эшлим, акчаны көрәп алам. Җидешәр мең төшкән айлар була. Биштән беркайчан да ким чыкмый. Ә сезнең монда эшләр мактарлык түгел. Хезмәт көнең ярыйсы да, ләкин ипигә ягып ашап булмый бит аны. Ятма монда чиләнеп. Әйдә, киттек минем белән шахтыга», — дип бик кыстаган иде. Ул чакта минем авылдан китәргә уйда да юк. «Бөтенебез дә читкә китә башласа, кем үстерер ул икмәкне дә, кем туйдырыр сез-эшче халыкны?» — дип, мин аның үзен ачуланган идем. Шунда ул: «Ярар, ярар, син алай бик артык илдарланма. Дөнья бу, иптәш, минем сүзләрне хәтереңә алып куй әле», — дип, үзенең адресын әйтеп киткән иде. Йорт номеры ук хәтеремдә калмаган, әмма ул әйткән урамның исеме хәтеремдә. Урамын белгәч, йортын ничек тә табармын әле, дип уйлап алдым да:

— Кемеровога кадәр ике билет бирегезче? — дип, кассирга акча суздым.

Үз язмышын тулысынча минем карамакка тапшырган Айсылу актан да, карадан да бер сүз дәшмәде.

Теге классташның Кемерово дигәне Кемерово үзе ук түгел, шәһәр тирәсендәге шахтерлар поселогы икән. Адреслар бюросыннан адресын алып, эзләп таптым мин моны. Авылга кайткан чагында, фатирым да бик шәп, дип сөйләгән иде ул. Асылда алай ук түгел икән. Агач баракта унбиш квадрат метрлы, бер тәрәзәле бер бүлмә. Дөрес, утын әзерләп, мичен ягып азапланасы түгел — пар белән җылытыла. Аш-суны да гомуми кухняда керосинкада гына пешерәләр. Әмма, шулай булуга да карамастан, биш кешелек семья өчен (өч балалары бар) алай шаккатмалы фатир түгел иде ул. Инде менә Айсылу белән мин дә килеп төшкәч, шул унбиш метрга без җиде җан булдык. Башта икебезгә дә эш, аннары паспортлар юллаганчы, айдан артык вакыт үтеп китте.

Ләкин хуҗалар безгә ялгыш та караңгы чырай күрсәтмәде. Киресенчә, без, фатир алып, алардан китеп барганда, чын-чынлап борчылып, сезнең белән яшәү күңелле иде әле, юкка китәсез, дип калдылар. Уйлап карасаң, гаҗәеп инде бу кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр. Кайчакта туган белән туган (мәсәлән, Шәйхи белән мине генә алып карыйк), бергә яшәү дип әйтмим дә инде, хәтта аерым яшәп тә тыныша алмыйлар, ә кайчакта бер-береңә бөтенләй чыбык очы да булмаган кешеләр бәләкәй генә бүлмәдә дә дус булып, берсенең уңышы өчен икенчесе куанып яшиләр.

Мине шахта идарәсенә бухгалтер итеп алдылар. Мин ул турыда уйламаган идем. Шахтага төшәргә иде минем исәп. Ләкин кадрлар бүлегендә минем сугышка кадәр бухгалтерлар курсын бетергән булуымны белеп алгач, шахта идарәсе начальнигына җибәрделәр дә, мине шул ук көнне идарәнең баш бухгалтеры урынбасары итеп билгеләделәр. Ниндидер әкеш-мәкешләрен фаш итеп, мин килер алдыннан гына бухгалтериянең берничә кешесен кайсын эшеннән алганнар, кайсын утыртып ук куйганнар икән. Ул елларда андый хәлләр шактый очрый торган иде. Ни өчен дигәндә, сугыш әле яңа тәмамланган, кадрлар җитми, белгечләр аз. Шуннан файдаланып, төрле аферистлар, төрле юллар белән алдашып, шундый акча тирәсендәге эшкә урнашалар да, бераз эшләгәч, я төрмәгә барып керәләр, яки эштән куылалар. Күп кенә акча урлап, качып китүчеләре дә булгалый иде... Махсус курс та үткән

булгач, мине күтәреп алган шикелле иттеләр. Хәтта баш бухгалтер итеп тә куймакчылар иде. Үзем каршы килдем. Җаваплылыгы зур, эше катлаулы, ә минем тәҗрибә аз, дидем. Айсылуга да укыту эшенә урнашырга мөмкин иде. Русча укыту кыен булыр дип, риза булмады. Кадрлар бүлегенә эшкә урнашты. Мин беренче тапкыр хезмәт хакы алган көнгә туры китереп, төзүчеләр гомуми торагында икебезгә егерме метрлы якты бер бүлмә бирделәр. Шулай итеп, без, әле кайчан гына ни эшебез, ни барыр җиребез, ни фатирыбыз булмаган кешеләр, эшле дә, ул заман өчен менә дигән тораклы да булдык. Шул бүлмәгә күчкән көнне Айсылуым тагын бер тапкыр елады. Ләкин бу юлы ул: «Синең станциядә әйткән сүзләрең рас килде бит, Булат. Мәхәббәт булганда бүтәне табыла икән аның!» — дип шатланып елады.

Кырык сигезенче елның унтугызынчы гыйнварында Айсылу малай алып кайтты. Болай да тулы булган бәхетебез гел

## ҖИДЕНЧЕ ДӘФТӘР

дә түгәрәкләнеп китте. Малайга Наил дип исем куштык. Баланы бер яшькә кадәр Айсылу үзе тәрбия итәргә сөйләштек тә, ул эшеннән чыкты.

Дәрәҗәсе зур булса да, баш бухгалтер урынбасарының эш хакы шахта җире өчен алай искитмәле түгел — иске акча белән 1050 сум гына иде. Шуңа күрә мин, идарә житәкчесе җибәрәсе килмәсә дә, ул эшне ташлап, шахтага төшәргә булдым. Дөрес, әлеге мең дә илле сум безгә ашарга-эчәргә һәм гадәти генә тормыш алып барырга җитәр иде. Ләкин авылда безнең икебезгә ике әниебез бар. Минеке, гел авырыштырып торганлыктан, бөтенләй диярлек эшли алмый. Аңа ярдәм итәргә кирәк иде. Әби болай нык ныгын. Ләкин аның үзен генә аерып калдыру килешми бит иде. Аннары мине монда чакырып китергән шахтер классташым да:

— Шушы баһадирдай гәүдәң белән чут төймәсе тартып утыру ни пычагыма ул сиңа? Әйдә, төш минем янга забойга, рәхәтләнеп эшләрсең, уч тутырып акчасын алырсың! — дип бик үгетләгән иде.

Забойда күмер чабу җиңел эш дисәм — ялган булыр иде. Юк, җиңел түгел анда. Кешедән калышмыйм, норманы арттырып үтим дисәң икән, чынлап торып тир түгеп эшләргә кирәк. Ләкин тир түкмичә, тырышмыйча гына кайда уңышка ирешеп була икән соң?.. Ә мин эштән курыкмыйм. Авылда көннәр буе чүкеч сугып эшләгән егет бит. Һәрхәлдә, шахтада күмер чабу тимерлектә эшләүдән дә авыр тоелмады миңа. Хәтта җиңелрәк тә түгел иде микән әле. Ник дисәң, тимерлектә без бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшлибез, ә монда сигез сәгатьтән ары теләсәң дә эшли алмыйсың. Рөхсәт итмиләр. Монысы — бер. Инде килеп, хезмәт хакы мәсьәләсен дә онытырга ярамый. Тимерлектә мин көненә өч хезмәт көне эшләсәм дә, кило да сигез йөз грамм ашлык алам. Аны да ел ахырында гына. Уңыш ярыйсы булып, колхоз икмәк планын арттырып үтәгән тәкъдирдә генә. Уңыш әйбәт булмаса, өч йөз-дүрт йөз грамм белән дә каласың. Ә монда алтышар мең тәңкә акча алган чаклар була торган иде минем. Тагын шунысы да бар: забойда эшләп минем җаның тыныч. Отчет сораучы да юк. Статьяда каралмаган нәрсәләргә, финанс тәртибен бозып, шул ук вакытта законга сыя торган да булырлык итеп, акча табу юлларын эзләп баш ватасы да түгел. Эшләмәгән кеше генә белми, бухгалтерның эше бик четерекле аның. Начальствога да ярарга кирәк, әшен дә тәртиптә булырга тиеш. Әгәр инде ревизия килеп, алай-болай законга туры килеп бетми торган эшләреңне ачса, җавабын начальство түгел, син бирәсең. Ә забойда — ике кулыңа бер эш. Сменаң беттеме — син аның хакында уйлап та карамыйсың. Ә сменада мин алай сер бирмим. Ай саен нормамны арттырып үтәп барам. Исемем алдынгылар рәтендә.

Рәсемем — Почет тактасында. Эшне әйбәт эшләгәч, иптәшләр арасында да, начальство каршында да авторитет бар. Өч ел эшләгәч, үз идарәбездә җиңүче булып чыккан өчен бүләк итеп, минә дигән фатир бирделәр. Какраз икенче малаебыз Шамил туган чак иде бу. Фатир дигәнем гади фатир гына түгел. Өч бүлмәле аерым таш йорт. Пар белән җылытыла. Кайнар суы да, салкын суы да үзендә. Ваннасы, туалеты да шунда. Бүлмәләре һәркайсы ат чаптырырлык. Ә өй каршында — бакча. Тик анысы каралмаган. Миңа кадәр яшәгән хуҗаларның җиләк-җимеш, яшелчә үстерүгә хиреслеге булмаган булса кирәк. «Ярар, җәйгә чыгыйк әле, гөл итәрмен мин бу бакчаны», — дип планлаштырып куйган идем мин. Алма агачлары, чәчәкләр, карлыган, кыяр, суган шикелле яшелчәләр утыртып җибәрергә иде исәп. Айсылу да: «Авылны сагынып, саргаеп үләргә житешкән идем. Болай булгач, бераз юаныч була икән миңа. Җәйгә чыккач, әниләрне дә апкилербез дә, бергәләп кинәнеп яшәрбез шушында», — дип канатланып йөри башлаган иде. Шул хакта әйтеп, әни белән әбигә хат та язган иде... Әмма без дигәнчә барып чыкмады. Озакламый әбидән минә мондый җавап килеп төште: «Зур фатир бирүләре анысы әйбәт булган. Әмма аягым-кулым исән булып, үземне-үзем йөртә алган чагымда авылдан беркая да китмим, балалар. Кодагый да, чит-ят җирләргә илтеп калдырыр хәлем җук сөягемне, ди. Хәле дә көннән-көн авырая бара. Хәзер инде тышка да үз аягы белән чыга алмый башлады. Сезне бик сагына. Авыруым да шул балаларны сагынудан бугай, ди. Әйтеп җаз әле, кайта алмаслар микән. Алар кайтса, терелеп китәр ием төсле, ди».

Дөресен генә әйткәндә, үзем читтә булсам да, күңелем гел авылда иде минем. Әнине сагынам! Авылны сагынам! Барыннан да бигрәк, әтинең васыяте өстемдә тора. Шул исемә төшкән минутларда миңа коточкыч оят булып китә. Мин үземне җинаятьче дип хис итә башлыйм. Тик анда Шәйхи һаман әле председатель булганга гына кайтмыйча торырга мәҗбүр идем. Эшләр болайга киткәч, Шәйхи дип торып булмый иде инде. Әбидән хат килгәннең икенче көнендә үк Айсылу да, мин дә эштән җибәрүләрен үтенеп гариза бирдек. Чөнки әни шундый авыр хәлдә яткач, бер әбигә генә ышанып тору һич тә ярамый иде.

Теләсә кем теләсә ни әйтсен, әмма мин бер нәрсәгә ышанам: берәр төрле көтелмәгән хәл килеп чыгасы булганда, адәм баласының күңеле шуны алдан сизенә икән бит, әй. Сизенә — и бетте китте! Моның шулай булуына мин әле сугышта йөргәндә үк игътибар иткән идем. Бер бик әйбәт дустым бар иде минем. Рус егете. Туланыкы. Арыслandай батыр, юлбарыстай җитез. Ул телгә осталыгын әйтәсе дә юк инде. Берәр нәрсә сөйли башласа, тыңлаучыларның барысын да авызына каратып кына тота. Иң читен вакытларда да аһ ормый, күңелен төшерми. Киресенчә, төшенкелеккә бирелгән кешеләрне үзе юата торган иде. Минә шул кеше бер тапкыр сугышка керер алдыннан кинәт кенә үзгәрде дә куйды. Бөтенләй сөйләшмәс булды. Тынгысызланып-борсаланып, арлы-бирле йөренә башлады. «Ни булды сиңа, Коля, туганнарыңнан күңелсез хәбәр килдеме әллә?» — дип сорадым мин аннан, аптырагач. «Юк, берниндн дә хәбәр алмадым, просто эти белән әни искә төштеләр дә үзләрен күреп киләсе килеп китте әле», — ди бу. Ә бераздан үзе минем янга килде дә: «Сержант, син минем өй адресын беләсеңме?» — диде. «Беләм, ә нигә алай дип сорыйсың әле?» — дигәч, ничектер бик тә сагышлы, бик тә моңсу итеп үзалдына елмайгандай итеп куйды да, тагын шул, «болай гына» дию белән чикләнде... Әйтәм бит, күңеле нидер сизенде аның. Нидер әйтергә тели иде ул миңа. Ләкин өзеп кенә берни дә әйтә алмый иде...

Шул көнге сугышта Коля үлеп калды. Хәвеф буласың сизенгән икән аның күңеле.

Минем шахтадан шулай тиз генә китәргә карар кылуым да нигездә

энә шул сизенүгә бәйле иде. Югыйсә, шундый шәп особнякны, шундый күп акча төшә торган эшне алай ансат кына ташлап кайтып китәр идеммени! Күңелем алгысыды минем ул вакытта. Тәкатьсез булып, туган якка, әни янына кайтасым килә башлады. Сәбәбе соңыннан ачыкланды: бик белеп ашкынган икән күңел. Тагын бер генә көн соңарсак та, әнине күрмичә каласы булганмын икән. Ә без әни әле исән чакта, әмма инде хәл эчендә яткан вакытта кайтып җиттек. Миңа да, Айсылуга да бәхиллеген биреп, кайтып җитүебезгә сөенеп китте ул бу дөньядан.

— Рәхмәт, балаларым! Күрми үлсәм, күңелем китек буласые. Хәзер инде тынычланып китәм, — дип, үзе әйтеп китте...

Ярый, кайтып авылда тора башладык, шулай итеп. Шәйхи әле һаман колхоз председателе. Ул инде бер хатын алып аерып, икенчесенә өйләнгән. Икенче секретарьның кияүдән кайткан кызын алган. Хатыны мәктәптә тарих укыта. Аңа урын кирәк булгач, Әзһәрне бүтән мәктәпкә күчергәннәр. Шәйхинең хәзер кикриге шиңгән. Хатыны бик чая нәрсә икән. Әйткән вакытыннан Шәйхи биш кенә минутка соң кайтса да, өйдә сафура бураннары куптара, ди. Ләкин кайсы председательнең вакытында өенә кайтканы бар икән? Әллә нинди көтелмәгән мәшәкатьләр чыгып тора бит колхоз эшендә. Шуның өстенә тагын Шәйхи үзе дә сөттән ак, судан пакь кеше түгел. Иске гадәтен куып, «уҗымга чыкалавын»да дәвам иттерә икән... Кыскасы, без кайтканда ул инде, тыштан сер бирмәсә дә, элекке Шәйхи түгел иде. Кочак җәеп үк каршы алмаса да, миңа алай дошманы карашын сиздермәде. Әйтерсең безнең арада берни булмаган...

Кайтып берәр ай авылда торгач, декретка чыккан мәктәп бухгалтеры урынына вакытлыча эшкә кердем. Ә аннары җирле советларга чираттагы сайлаулар килеп җитте дә, мине авыл советы председателе итеп сайлап куйдылар. Шулай итеп, Шәйхи белән без, нәкъ әтиләребез шикелле, ике тәкә башы, янә бер казанда кайный башладык. Күңеленнән, белмим, нәрсә уйлагандыр, әмма тыштан Шәйхи бу юлы да аңымоны белгертмәде. Ихтимал, ике арабызда булган хәлләрне дөрес аңлагандыр, ачу саклап йөрми торгандыр, дип уйлаган идем. Әмма яманлык канына бер сеңгән кеше шуннан тәки мантый алмый булса кирәк. Эчендәге агуы барыбер бәреп чыкты тегенең. Соңыннан, байтак еллар узгач бәреп чыкты. Ә мин авыл советы председателе булып эшли башлаган илле алтынчы елда ул әле берни дә сиздермәде. Хәтта минем белән дуслашырга да нияте юк түгел иде аның. Тик мин үзем салкын булганга, теге чактагы кабахәт гайбәтен кичерә алмаганга гына якынаеп китә алмадык. Эш мәсьәләсенә килгәндә, мин һәр вакыт хәл кадәренчә аңа ярдәм итәргә тырыштым. Чөнки шәхси мөнәсәбәтләрне җәмәгать эшендәге мөнәсәбәтләргә күчерүне мин ир-ат заты өчен түбәнлек дип саныйм...

Шәйхи дә тырышмады дип әйтмәс идем. Колхозны терн әкләндерергә ул да тырышты. Райком да аңа карата аеруча игътибарлы иде. Әйтик, кайбер колхозларда бер машина да булмаган ул елларда безнең колхозның ике машинасы бар. Бүтәннәрдә бер-ике комбайн булса, бездә инде өч комбайн эшли иде.

Ләкин колхоз барыбер телгә алып сөйләрлек котая алмады. Уңышны ел саен күршеләребездән аз ала идек. Икмәк йөкләмәсен көч-хәл белән тутырсак та, ит йөкләмәсен сиксән-туксан проценттан арттыры булмый. Моның хикмәте шунда, колхозчылар белән мөнәсәбәте шәптән түгел иде Шәйхинең. Дорфа иде ул аларга карата. Күрәсең, взвод командиры булып йөргән чагыннан калган гадәтедер: приказ тонында сөйләшергә бик ярата, бар нәрсә дә гел ул әйткәнчә генә булырга тиеш дип саный иде. Үзенең авторитетын күтәрергә тырышып, шул кадәргә барып җитте ки, бер вакыт кабинетына зур келәм алып кайттырып

җәйдерде дә үз янына йомыш белән килгән колхозчыларның аяк киемнәрен ишек төбендә салдырттырып кына кертә башлады. Ә халык сизгер ул. Эшең алга бармаганны кабинетыңа келәм җәеп кенә каплап булмый аннан. Бик нык инанып, егерме өч еллык тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: әгәр халык синең сүзеңне тыңласын, сине хөрмәт итсен дисең икән, әгәр ул син кушканны эшләсен дисең икән, иң әлек син үзең шул гади халык шикелле гади бул. Кеше күңеле пыяла, нык орынсаң уала, диләр безнең якта. Бик дөрес әйтәләр. Кешенең күңелен табар өчен кайчакта бер җылы сүз дә җитә. Әгәр син үзеңнән өлкән агайга яки апайга башлап сәлам бирәсең икән, аннан синең дәрәҗәң һич кенә дә кимеми. Әгәр районга барышлыйммы, кайтышлыйммы юлда очраган авыл кешесен атыңа яки машинаңа утыртып алып кайтасың икән — шулай отасың гына.

Ә менә безнең Шәйхи нигәдер халык белән якынаюны өнәми иде. Әйтик, хатыны Казаннан кайтасы булса, ул станциягә каршыларга бара. Аның хатыны белән бер үк вагонда безнең авылның тагын бер-ике кеше кайткан. Шунда Шәйхи үзенең хатынын атына утыртып алып кайтып китә, ә тегеләрне алмый. Мин моны шуннан беләм, авыл советы председателе булып эшли башлагач, әнә шул хәлләргә дучар булган кешеләр, әйтсәк тә, Шәйхи безне тыңламый, ичмаса, син әйтеп кара үзенә, дип зар елап килә торганнар иде. Ә Шәйхинең бу мәсьәләдә үз фәлсәфәсе:

— Төкер син шулар сүзенә! Бер нәрсәне аңла: житәкче белән аның кул астындагы кешеләр арасында билгеле бер дистанция булырга тиеш. Колхозчы белән колхоз председателе икесе бер арбага утырып йөри башласалар, кая китә ул? — дип кенә җибәрә. Үзенең шул сүзенә дәлил итеп: — Әнә, райком секретаре үз машинасына колхоз председательләрен утыртып йөрми бит! — дип тә өстәп куя иде.

Колхоз милкенә үз милке шикелле итеп карый торган гадәте юк түгел иде аның. Гурнәчә шикелле итеп, колачлы нарат бүрәнәләрдән алты почмаклы йорт салдырып куйган. Түбәсе — күгәрми торган, цинкланган калай. Өйнең эче штукатурлап обойланган, тышы такта белән тышланган. Капкалар, тәрәз йөзлекләре — бары да бик әйбәтләп бизәкләп эшләнгән. Күз явыңны алырлык итеп буялган. Ишегалдында гади авыл кешесенең өенә алыштыргысыз зур ак мунча... Дөрес, бүгенге көн күзлегеннән караганда, монда искитәрлек берни юк. Мисал итеп алсак, минем бүгенге үз өем дә алай ким-хур түгел. Дүрт бүлмә. Шул дүрт бүлмәдә ындыр табагы-ындыр табагы хәтле биш келәм. Ишегалдында гына мунча. Анысы да ике бүлмәле. Берсе кер юар өчен, икенчесе юыну-чабыну өчен. Суын да ташып торасы юк. Колонкадан туп-туры мунчага кертелгән. Әмма, шул ук вакытта, теге чактагы Шәйхи өе белән бүгенге минем өй арасында зур гына аерма да бар. Ул үз йортын колхоз чутыннан, балта осталарына бер тиен түләмичә салдырган. Ә мин, төзү материалларыннан тыш, тик төзүчеләрнең үзләренә генә дә өч мең ярым сум хәләл акчамны түләп эшләттем. Аннары шунысы да бар: минем өй авылдагы бүтән өйләрдән бер дә алай аерылып тормый. Хәзерге заман өчен гадәти өй ул. Бездә хәзер минекеннән яхшырак өйләр дә күп инде. Ә Шәйхинең өе ул чакта бөтен авылга бер булып балкып утыра. Аның колхоз чутыннан салынганын халык бик яхшы белә. Күзенә терәп әйтмәсәләр дә, үзе югында аны «алпут» дип, «хан» дип атыйлар иде...

Адәм баласы бер кыек юлга басса, аннан тиз генә борылып чыга алмый икән ул. Киресенчә, һаман арырак, тайгаклыккарак баруын дәвам итә икән. Җитмәсә әле, ул үзен хаклы дип тә саный икән. Моны мин әлеге шул Шәйхи мисалыннан чыгып әйтәм. Потлап кына, кирәгенчә генә алып кайтса ни булган инде аңа? Икмәкнең алтын бәясе тора торган чаклары бит! Шәһәр халкы, чана тартып, авылга кием-са-

лымга алыштырырга ризык эзләп кайта торган, ә авыл халкы үзе черек бәрәңге белән диярлек җан асрый торган заманнар!.. Ә Шәйхи уйлап та бирми. Колхоз икмәге әйтерсең аның шәхси байлыгы. Үзем дә сизәм моның мутлануын. Халык та сөйли. Үз күзем белән күрдем дип килеп тә әйтәләр. Әмма моңарчы да мөнәсәбәтләр киеренке булганга күрә, аяк терәп сөйләшә алмыйм. Бергә эшлисе бит. Болай да бик холыксыз кеше, аннары тагын да ныграк канығыр шикелле. Кайчакларда әйтеп карыйм каравын. Тик ул аңа игътибар итми.

— Теле кычыткан гайбәтчеләр сүзе генә ул. Мин барысын да законлы эшлим! — дип кенә җибәрә.

Тора-бара икмәкне олаулап ук үзләштерә башлады бу. Шуннан соң мин дә түзеп тора алмадым. Чәкәләштем моның белән. Какраз җае да чыккан иде. Бер дә бер көнне күрше колхозның тегермәнчесе Хисмәтулла агай минем янга авыл советына килеп керде дә:

— Прсидәтелегезнең кыланышлары кырга сыймый башлады бит, Булат энем, — диде. Аның борын яфраклары күпергән, сулышын еш-еш ала, вак-төяк эш белән генә йөрмәгәнлеге кыяфәтенә чыккан иде.

— Нишләгән ул? — мин әйтәм.

— Өченче көн сезнең калхуз безнең тегермәндә өч тонна бодай тарттырганмы?

Бу мәсьәләдән мин хәбәрдар түгел идем. Тегеңә өзеп кенә җавап бирә алмадым:

— Шуннан? — дип кенә сорап куйдым.

— Шуннан менә болай, алайса, — дип элеп алып китте Хисмәтулла агаң. — Әнә шул бер машина онны Шәйхиегез кичә калага илттереп саттырды. Нәбирнәкә акчасын колхозга бирмәгәндер ул аның. Нәбирнәкә үз кесәсенә салып куйгандыр. Күңелем сизенә, нәбирнәкә шулай итте ул аны!

— Син моны нәрсәдән чыгып әйтәсең, Хисмәтулла агай? Тегермәндә боерыксыз гына тарттырдымы әллә онны?

— Анысы бар барын. Ну бик шикле күренә. Менә карале. — Ул кесәсеннән боерык кәгазе алып бирде. Анда тегермәнгә өч тонна бодай озатылуы язылган иде. Ләкин ул боерыкта мин шикләнерлек нәрсә тапмадым. Колхоз печате сугылган, колхоз председателенең имзасы куелган иде аңа.

— Анысы шулаен шулай, олан, — диде тегермәнче. — Ну минем менә нәрсәдә шигем бар: бу кәгазь идарәдәге төп кенәгәгә, хисапчы кенәгәсенә теркәлде микән соң? Теркәлмәгәндер күк тоела миңа. Ни өчен дисәң, бүтән чакта калхуз ашлыгын тартырга китергәндә үзегезнең авыл кешеләре китерә, завхуз үзе дә килеп китә торган иде. Ә монысын сезнең калхузга убуркага килгән кала машинасы белән кала кешеләре китерде. Тарткач та, шулар машинасы белән илтеп сатып кайттылар. Шәйхи үзе килеп, ни эшләргә икәнен әйтеп-тикшереп торды. Онны да бик вак итеп тарттырды. Бүтән чакта алай тикшеренеп йөрми торганые ул.

Хисмәт агайның бу сүзләренә, бер караганда, ышанырга да була: ул елны, чыннан да, дәүләткә икмәк тапшыру чорында безнең колхозга булышырга шәһәрдән килгәннәр иде. Ләкин...

— Алар машинасы белән тегермәнгә ашлык илтергә ясә тегермәннән он алып кайтырга ярамый дигән сүз түгел әле бу, Хисмәтулла агай, — дидем мин, тегенең сүзенә бик ук кушылып бетә алмыйча.

— Әй, энем, энем, — диде тегермәнче агай, миңа бик нык хәтере калып. — Нужәли син минем сүземә дә ышанмыйсың инде, ә? Знамы, андый закун жук ул. Рәхмәт ул кала кешеләренә! Кем килсә дә кире борып җибәрмәделәр: машиналары белән утын ташып, ярты авыл халкын кышлык утынлы итте ул җегетләр. Мин үзем дә, напримир, бер келәтлек агач алып кайтып калдым шулар машинасы белән. Ну бит,

сүз ул хакта түгел. Бөтенләй башка әйбер хакында бара монда сүз. Мин бит синнән әнә шул кала кешеләре тарткан калхуз оны калхузга керемгә алынды микән, шуны беләсие дип сорыйм. Мин үзем, напри-мир, берни дә белмәгән атлы булып, шыпырт кына завхузыгыздан со-рашып караганыем, ул әйтә: «Минем кала кешеләренә он тарттырганым юк!» ди. Менә шуңа күрә әйтәм мин сиңа, әллә әйбәтләбрәк үзең тик-шереп карыйсынмы дип. Түлке, матри, мине бу эшкә

## СИГЕЗЕНЧЕ ДӘФТӘР

катыштырасы булма! Шәйхи мин әйткәнне белә калса — желегемне корытыр. Шундый бәндә ул...

Хисмәтулла агай хаклы булып чыкты: ул әйткән өч тонна бодай оны ни завхозда, ни колхоз хисапчысы кенәгәсендә керемгә алынмаган иде.

Эшне зурга җибәргәнче, Шәйхинең үзе белән сөйләшеп карарга булдым. Башта мине ишетергә дә теләмәде теге:

— Ул ниткән нахак бәла тагын? Андый эшне эшләргә син мине кем дип беләсең? — дип, бик хәтәр җикеренеп маташты. Әмма мин аңа Хисмәтулла агай биреп калдырган боерык кәгазен күрсәткәч, чи-ертсә кан бәрергә торган кара кучкыл-кызыл йөзе кәфен шикелле ага-рып китте. Иреннәре дерелди, куллары калтырый башлады.

— Тәки каптыргансың икән, ә? — ди бу миңа.— Беләм, синең миңа Айсылу аркасында үчең бар инде. Минем язмыш хәзер синең кулда. Теләсә ни эшләтә аласың. Ну шулай да үтермә инде син мине, Булат. Бу юлга калдыр. Балам хакына калдыр!

Баласы турында дөрес әйтә: аерган хатынныннан туган биш яшьлек кызы бар аның. Яшь хатын аны болай да яратмый. Шәйхисез калса, гел дә көн күрсәтәчәк түгел ул аңа.

— Ярый, Шәйхулла, — мин әйтәм, — син үзең әшәке булсаң да, миннән булсын яхшылык. Мондый кыек эшләрең беренче генә түгел икәнен дә беләм. Миңа кылган этлекләрең дә бик хәтердә. Балаң кыз-ганыч. Шуңа калдырам. Тик өч шарт белән.

— Әйт кенә, барысына да риза! — ди бу, этәләнеп.

— Беренчедән, — мин әйтәм, — теге чакта нахак хәбәр таратып безне авылдан чыгып китәргә мәҗбүр иткәнең өчен, өйгә килеп, Айсы-лудан минем алда гафу үтенәсең! Икенчедән, колхоз милкенә бүтән беркайчан да кагылмыйсың! Өченчедән, бер дә юкка миңа каныгула-рыңны бетерәсең. Килештекме?

— Мин килешәсе дә, тик он тарттырган боерык кәгазе синдә бит, Булат. Аның белән син мине теләсәң кайчан каптыра аласың ич.

— Ә син каптырмаслык итеп эшләрсең!

— Сүз биргәнмен икәнмен, анысыннан эш калмас. Син дә минем шартны үтә: ташла җыртып шул боерык кәгазен!..

— Менә карап тор! — Тегенең күңеле булсын дип, шунда күз ал-дында шырпы сызып яндырдым боерык кәгазен.

Шәйхи дә сүзендә торды: шул сәгатендә үк безгә барып, Айсылудан гафу үтенде. Ә менә шуннан соң!..

Әле дә күз алдымда: ул көнне иртән бик җилләде. Аннары дөньяны тоташ кара болыт каплады да, төш турында ишелеп яңгыр ора башла-ды. Менә шул көнне, әнә шул орып торган яңгыр вакытында, бик тиз барып җитәргә кушып, миңа райкомнан телефонограмма килде. Ниш-лисең? Ашыгыч чакыралар икән, димәк, сәбәбе җитдидер, вак-төяк эш өчен генә мондый көндә борчып тормаслар иде дип, авыл советы аты-на атландым да, киттем чыгып районга. Мин барып җиткәндә таран-таска җигелгән «Аҗаган» райком каршындагы атлар бәйли торган

урынга бәйләп куелган иде инде. Яңгыр шундый нык ява, хәтта шул шәп айгырның да гайрәтен сүндергән: ул да бөкшәеп, башын иеп тора.

Миңа беренче секретарь янына керергә куштылар. Анда ул Шәйхи белән утыра иде. Белмим, кем ничектер, ләкин минем үземнең кайбер сыналмышларым бар. Мәсәлән, сул күзем тартса — шатлыкка була. Ә уңы тарта икән — ниндидер бер күңелсезлек килеп чыгасын көт тә тор. Ул көнне иртән торганнан бирле уң күзем тарта иде минем. Инде менә беренче секретарь янында Шәйхи дә утырганын күргәч, мине ниндидер күңелсезлек көткәненә тамчы да шигем калмады. Рас беренче секретарь шулай бик ашыгыч чакыртып китергән икән, рәхмәт әйтергә түгел инде ул.

— Я, — диде секретарь, килеп кергәч исәнләшүемә гел дә игътибар итмичә. — Аңлатып бир әле, Вәлиев: нигә дип каныгасың син иптәш Шәрифуллинга? Нигә тыныч кына эшләргә ирек бирмисең син аңа?

Мин телсез калдым. Бүтән теләсә нинди явызлыкны көтәргә була иде Шәйхидән, әмма мондый ук әшәкелеккә барып җитәр дип башыма да китермәгән идем. Соң әле кайчан гына үзе килеп, аяк астыма ятып дип әйтерлек үзен коткаруны сорап ялварган һәм бүтән беркайчан да минем өстән нахак сөйләп йөрмәскә сүз биргән кеше иде ләбаса ул...

Минем дә җен ачуларым чыкты хәзер.

— Нигә каныгыйм мин аңар, Гали Даутович? — дидем мин секретарьга. — Сез моны каян чыгып әйтәсез?

Ул миңа бер биткә язылган кәгазь сузды:

— Мә, укы, эшеннән азат итүне сорап гариза язуга китереп җиткергәнсең кешене!

Гариза, чыннан да, Шәйхи кулы белән, үзен председательлектән азат итүне сорап язылган иде.

Мин аның гаризасына күз генә йөртеп чыктым. Өстәлгә куйдым да әйттем Гали Даутовичка:

— Ул гариза язганга минем ни гаебем бар икән соң?

Секретарь миңа, нигә син, башыңны юләргә салып, кыланып утырасың, дигән шикелле итеп сөзеп карады:

— Ә син гаризаны ахырына кадәр үк укып чык башта!

Тегенең гаризасын яңадан кулга алып укый башлаган идем, чәчләрем үрә торды! «Миңа ярдәм итәсе урында, — дип язылган иде анда, — авыл советы председателе Вәлиев Б., минем эшкә аяк чалып, мине терроризировать итеп килә». Ярый әле, Шәйхидән ераграк, өстәлнең икенче башында утырам, югыйсә, тәки очып кунган булыр идем.

Шулай да нәфрәтем тышка бәреп чыкты:

— Ничек итеп аяк чалам соң мин сиңа, Шәйхи?

— Синме, — ди бу. Шуны гына көтеп торгандай, урыныннан очынып ук купты. — Син миңа ничек аяк чаласыңмы? Колхозның бер машина онын сатып, акчасын үзләштергәнсең дип, кем миңа нахак бәла ягып йөри соң?

Әнә кая борып җибәргән иде эшне Шәйхи! Күрәсең, үз холкыннан чыгып алай иткәндер: кичерәм дип сүз бирсә дә, сүзендә тормас, барыбер бер китереп чыгарыр дип шикләнгәндер. Шуңа мин аның үзен буяп калдырыйм дип уйлагандыр...

Әнә шул чакта мин теге боерык кәгазен яндырып никадәр зур ялгышлык эшләвемә үкенеп бетә алмадым. Ләкин үкенүдән ни файда? Шәйхинең колхоз онын урлап сатканын расларлык дәлилем дә, аның белән вакланып йөрергә теләгем дә юк иде минем. Шулай да секретарьга эшнең ничек булганын сөйләп бирдем.

— Коммунист буларак, мин тик дөресен генә сөйлəдем. Әгәр чын коммунист икән — Шәйхи үзе дә эшләгән эшен танырга тиеш! — дип тә өстәп куйдым соңыннан.

Секретарь икеләнебрәк калды: кайсыгызга ышаныйм, дигән шикелле итеп, әле Шәйхигә, әле миңа карап торды.

— Алдаша ул, Гали Даутович, диде Шәйхи, аның сораулы карашына түзә алмыйча, аягүрә басып.— Күзгә карап алдаша. Сезнең алда да ялганлап торгач, мин аның белән бүтән бер көн дә эшләячәк түгел.

Инде минем дә түземем чигенә җиткән иде!

— Алайга китсә, мин дә аның белән эшләргә теләмим! — дип, мин дә ду куптым.

Сүз күп, тарткалашу нык булды ул көнне. Миңа шунысы ошады: Гали Даутович башта миңа бик каты тотынган булса да, Шәйхинең кем икәнен чамалады булса кирәк, ахырдан шактый йомшарды. Корырак кеше булса да, дөреслекне табарга тырыша торган иде ул. Бу юлы да, кем әйтмешли, алтын урталыкка алып чыкты безне.

— Күреп торам, моннан соң сез, чыннан да, бер коллективта эшли алачак кешеләр түгел, — диде ул. — Ләкин мин берегезне дә эштән җибәрергә җыенмыйм. Сезнең кебек кадрлар белән алай шаяра алмыйбыз без. Әлегә житәрлек зур эш майтарганыгыз булмаса да, фронтовиклар бит сез. Менә болай итәбез аны...

«Болай итүе» шул булды: Шәйхи үз урынында «Таң» колхозында калды. Ә мине күршедәге «Трактор» колхозына председатель итеп сайладылар.

Үзенә кадәр эшләгән кешене яманлау егетлек түгел, әлбәттә. Ләкин бу очракта миңа кадәр «Трактор»ны җитәкләгән иптәшнең телгә алып мактарлыгы юк иде шул. Эчүгә сабышып, атналар буена «авырып» ятканы өчен алганнар иде аны эшеннән. Бүтәне турында әйтеп тә тормыйм, председатель җигеп йөргән айгыр белән тимерхут арбадан башка, адәм рәтле аты да, арбасы да юк иде колхозның. Дөрес, зур колхоз түгел иде ул. Бар җире мең дә ике йөз гектар булып, шуның чәчүлек мәйданы нибары җиде йөз дә җитмеш өч гектар гына иде. Колхозчылары начар яшәми үзенең. Җәен колхоз эшендә кылт-мылт, элен-салын йөргән булалар да, кар төшү белән авылның юньлерәк ир-атлары Чиләбе, Свердловск якларына итек басарга, балта эшенә чыгып китә. Ә председатель дәшми. Шуңа дәшми, чөнки тикшерә башласалар, ул үзе гаепле булып чыгачак: тегеләргә, «колхозда артык эш көче булуы сәбәпле, идарә рөхсәте белән китте», дип үзе кул куеп, үзе печать сугып рөхсәт кәгазе биргән. Ул кәгазьне аннан аек чагында түгел, бәлки эчертеп, халыкча итеп әйтсәк, «майлап» алганнар. Шулай булгач, кемгә үпкәләсен дә, кемгә жалоба белән барсын ул?.. Шуңа күрә Пәрәү авылы халкы тик үз мәнфәгатен генә кайгыртып яши. Башка авыллар белән чагыштырганда тазарак яши. Чөнки ул мал-туарын җәен колхоз кырында көтүдә йөртә. Колхоз кырыннан кышлык печән чаба, егерме биш сотый бәрәңгесен утырта. Кыш керүгә коралын кулына тота да читкә кәсепкә чыгып китеп, язга кесә тутырып акча эшләп кайта. Ә колхоз эше тора бирә.

Мин килеп эшли башлаганда да Пәрәүнең кулына балта тота белә торган (ә анда балта тота белмәгән кешене син таба да алмыйсың) ир-атлары барысы да диярлек Урал ягына китеп таралышып беткән. Авыл мәет озаткандагыдай тынып, моңсуланып калган иде. Хет утыр да ела: атларга дип калдырылган фураж яңа ел башына да җитәрлек түгел. Терлек фермасындагы хәлләр аннан да яманрак: иртән дә — салам, көндез дә — салам, кич тә — шул ук салам! Печән дигән нәрсәнең әсәре дә юк. Ә бит әле алда башланмаган салкын кыш бар! Сыерлар бозаулыйсы, сарыклар бәрәнлисе бар. Кыскасы, шул: каптым мин килеп Пәрәүгә. Шәйхи-явыз аркасында каптым. Ә ул минем мөшкел хәлне күреп, шуңа куанып, тагын да кукраебрак йөри. Минем белән очрашкан чакларында, болай да янган йөрәккә тоз сибеп:

— Ну, Вәлиев, ничек соң эшләр? Кайчан минем «Таң»ны куып җитәсең инде? — дип авызын ерып китә.

Ә «Таң»ның хәле «Трактор» белән чагыштырганда — во! Аларның атларына фураж җитәрлек. Шәйхинең кулы каты: ул шабашниклыкка артык ирек куймый. Кәсепкә чыгарга рөхсәтне җәен колхозның иң җаваплы эшендә һәм иң тырышып эшләгән кешеләргә генә бирә. Хәзергечә итеп әйтсәк, шабашниклыктан да мораль һәм материаль кызыксындыру юлы белән файдалана. Аннары килеп, бабасы райком секретаре булуның да файдасы юк түгел. Колхозның хаҗәте бетеп торамыни аның? Ә кирәк нәрсә колхозга район аша кайтарыла. Менә шул чакта Шәйхи бер дә читтә онытылып калмый.

Яңа комбайннар кайтса — иң элек аңа!

Трактор яки чәчкечләр кайтса — аңа!

Ремонт вакытында да аның трактор-комбайннары беренчеләр рәтендә ремонтлана. Һәм башкалар, һәм башкалар...

Ә шулай да хикмәт бабаң кем булуда гына түгел. Хикмәт председательнең үзендә, аның эшкә мөнәсәбәтендә, минемчә. Мин моны шуннан чыгып әйтәм: бабасы күпме генә ярдәм итмәсен, үзе никадәр генә әрсез булмасын, Шәйхинең «Таң»ы, эше иң әйбәт барган чакларында да, район хуҗалыклары арасында тугызынчы урыннан югары күтәрелгәне булмады. Әмма ул безнең «Трактор» белән чагыштырганда шактый алда. Безнекенең соңгы өч ел эчендә беркайчан да арттан санаганда өченче урыннан өскәрәк менә алганы юк һәм менәр чамасы да күренми иде.

Ләкин бу дөньяда яшәүнең бөтен кызыгы, бөтен мәгънәсе дә әнә шул булмастай күренгән нәрсәләрне булдырырга тырышу бит инде. Яшереп торуның кирәге юк, узган эш, «Трактор»да председатель булып эшли башлаганда ук алдагы бер-ике ел эчендә Шәйхи колхозын узып китәргә дигән ният белән тотындым мин.

Тотынуын тотындым, тик моңа ничек ирешергә? Төннәр буе йокламыйча, шул хакта баш ватып ятам. Шәйхинең мыскыллы карашын күрмәс өчен, аның чәнечкеле сүзләрен ишетмәс өчен, сүнәр-сүнмәс кенә барган «Трактор»ны ныклап кабызып җибәреп, гөрләтеп эшләтә башлыйсы килә иде минем.

Шунсыз җаным тынычланачак түгел!

Шунсыз мин үземне-үзем хөрмәт итәчәк түгел!

Шунсыз миңа яшәүнең яме, ашауның тәме булмаячак! Кемгәдер аркаланып кына түгел, бәлки гаделлек белән, тырыш хезмәт белән дә максатка ирешеп булуын, шулай булырга тиешлеген расларга тели идем мин. Үзем өчен расларга тели идем. Бөтен уем, бөтен хыялым шул иде ул көннәрдә...

Тик хыял белән чынбарлык икесе ике нәрсә шул. Хыял белән эш итү җиңелрәк. Аның белән теләгәнчә идарә итеп була. Ә чынбарлык белән алай җиңел кылана алмыйсың. Аны үзгәртеп булмый. Ул гел бар. Ул гел күз алдында. Әйтик, әлеге фуражсыз кыш чыгарга тиешле атлар. Ошыймы алар сиңа, ошамыймы, ләкни син аларны ашатырга, язын колхоз җирен сөрерлек итеп кышлатырга тиешсең. Чөнки алар булмаса — хана! Язгы чәчү чәчелмичә калачак. Ә коры салам белән генә кыш чыксалар (чыга алсалар әле!), алардан ни көтәсең? Сыерлар да бер салам белән генә түзмәячәк. Аларның бозаулыйсы, аннары бозау имезәсе бар. Шул ук сыерлар дәүләткә сөт тә бирергә тиеш бит әле... Ичмаса, киңәш-табыш белән ярдәм итәрдәй кешесе дә юк иде авылда. Картлары — карт. Тел шартлатып, бот чабып торудан башкага ярамый. Яшьләре — яшь. Акыллы сүз әйтә алмый. Ә эш майтарырдай, акыл бирердәй ир-егетләр кәсепкә таралышып беткән. Идарә члennарының да ныклап таянырдайлары юк. Ферма мөдире — беренче группа инвалиды. Аның талканы коры. Чак кына катырак сүз әйттең

исә: «Сүз тыңлап эшләп йөргәнгә рәхмәт әйт. Югыйсә, мин иртәгәдән үк фермаңа бөтенләй бармаска могу! — дип кенә җибәрә.— Мин сезнең хезмәт көненә бирелә торган ике йөз илле грамм чи арышыгызга калмаган. Шөкер, хөкүмәт пенсиясен түләп тора, базымда бәрәңгем бар, җәй йөргән бозавым суеп элеп куелган»,— дип тә өстәп куя. Келәтендә ашлыгы бар икәнен генә әйтми. Ә бар. Чөнки Пәрәүдә урып-җыю чорында икмәк чәлдерү дигән нәрсә бар иде әле ул чакта. Завхозның шулай ук мактарлык җире юк. Анысы да шул миңа кадәр эшләгән председатель сыңары. Бер эздән йөргәннәр. Бергәләп тә ашаганнар колхоз икмәген, аерым-аерым да. Ә «салуын» гел бергә салганнар. Мин килеп эшли башлагач та ташламады ул бу начар гадәтен. Әмма шунысын әйтми булмый: салганда миңа күрсәтеп салмый — курка. Кирәк чагында эзли башласаң, гел табып ук булмый. Дөрес, анысы эш ташлау белән куркыта алмый. Анысы инвалид түгел. Пенсиясе килеп тормый. Ләкин көн аралаш исерек булып, үз вазифасын тиешенчә алып бара алмагач, миңа аннан ни мәгънә?..

Партоешма секретаре болай ярыйсы гына кеше үзе. Мәктәп директоры ул. Итәгатьле. Акыллы. Әмма — хатын-кыз. Ире сугышта һәлак булып калган. Бер үзенә дүрт бала. Аның колхозда эшләгән эше атнаун көнгә бер тапкыр фермага барып, ферма эшчеләре белән әңгәмә үткәреп кайтудан, айга бер тапкыр стена газетасы чыгару, айга бер тапкыр партия җыелышы үткәрүдән әллә ни уза алмый. Кулыннан килмәгәннән дә, теләмәгәннән дә түгел бу. Шуннан башкасына аның вакыты җитми. Җидееллык мәктәпләрдә завхоз штаты каралмаган. Гомуми җитәкчелек итүдән һәм дәресләр алып барудан тыш, директорга хуҗалык эшләре артыннан да үзенә йөрергә туры килә. Җәйгә чыкса — утын, мәктәпкә ремонт хәстәрен күрәсе. Кышын — ягу-җылыту, йөз процентлы өлгереш өчен кайгыртасы. Ә бит аның әле үз йортҗирен, үз семьясын карыйсы да бар. Инде шулар өстенә колхозның партоешма секретаре вазифасын да китереп йөкләгәч, ул, бичара, кайсына гына өлгерә алсын да кайсын гына җиренә җиткереп эшләп бетерсен?..

Ә көннәр, поезд вагоннары кебек, бер-беренә тагылып, туктаусыз үтеп тора. Колхозда хәлләр кыенлашканнан-кыенлаша бара... «Ни эшләргә?» Көндез дә башта шул уй, төнлә дә. Уйладым-уйладым да, бүтән чара таба алмагач, колхозчыларны гомуми җыелышка җыеп, алар белән киңәш-табыш итеп карарга булдым. Киңәш дигәнем шул:

## ТУГЫЗЫНЧЫ ДӘФТӘР

киләсе көзгә тикле әҗәткә халыктан бәрәңге сорап карарга исәп. Йөз дә сиксән ике хуҗалык Пәрәүдә. Йорт башыннан икешәр центнер гына җыйганда да өч йөз дә алтмыш центнерлап әйбер җыелырга тиеш. Халыкта бәрәңге бар — уңыш әйбәт булды. Икмәк тә сорап карарга ният юк түгел. Дөрес, колхоз хезмәт көненә әллә ни кинәндермәгән: сигезәр йөз грамм исәбеннән генә бүлеп биргән. Әмма халыкта икмәк бар. Бигрәк тә атлы эштә эшләгән кешеләрдә. Бу авылда урак өстендә атлы эштә эшләгән кешенең буш кайтмавы бөтен тирә-якка билгеле. Бөтенесендә дә түгел, әмма бар икмәк. Шуңа анысын йорт башыннан фәлән хәтле дип куеп булмас. Ә запасы булганнарыннан сорап карау зыян итмәскә тиеш.

Җыйналды халык. Һәр йорттан үк булмаса да, кеше күп килгән иде. Җыелышны парторг ачып җибәргәч, үзем сүз алып, безнең эшләр менә шулайрак тора, иптәшләр, дип колхоз малларының хәлен аңлатып бирдем. Әйбәтләп, тын да алмыйча тыңладылар. Тәвәккәлләп, бәрәңге мәсьәләсен дә кузгаттым. Анысыннан соң ду кубып каршы

килерләр дип курыккан идем. Тып-тын утыра бирәләр. Селкенеп карaучысы да, пышылдап сүз әйтүчесе дә юк. Күзләрен тәгәрәтеп мина текәлгәннәр дә, тик утыралар. Бик яхшы сизеп торам: сүзсез генә мине шелтәләүләре бу. «Акылың алтын икән, прсидәтел. Кем синә киләсе көздә әллә буласы, әллә юкка кыш өстеннән икешәр ситнырлык бәрәнге бирсен?» — диюләре... Бу четерекле хәлдән чыгарга кирәк бит инде. Теләсәң ничек кенә түгел, ниятләп куйганча чыгарга кирәк! Шунсыз ярамый. Бу җыелыш — бу авылда мин председатель булгач җыйган беренче җыелыш: теге, мине сайлау җыелышын иске председатель җыйган иде. Шушы җыелышта халыкны ышандыра алмыйча калсам, киләчәктә минем алар алдында дәрәҗәм сукыр бер тиенлек тә булмаячак...

Сүз алып сөйли башлаучы булмасмы дип көткәндә, әнә шул рәвешле уйланып алдым да әйтәм мин боларга:

— Ярый, алайса, иптәшләр, — дим. — Дәшми тору ризалык билгесе, диләр. Сезнең шушылай дәшми утыруыгызны да идарә тәкъдименә ризалык билгесе дип санарбыз да, тәкъдим бертавыштан кабул ителде дип карарга кер...

Сүземне әйтеп бетерергә өлгермәдем:

— Мин әйтеп карыйм әле? — дип, арткы рәтләрнең берсеннән бер кеше күтәрелде.

Колхоз фермасына су ташучы Хәмзә карт иде ул.

— Рәхим ит, Хәмзә агай! — мин әйтәм.

— Алайса, менә болай инде, Булат улым, — ди теге. — Кемнәрдер бәлки дәшми торуны ризалык биру дип саный торганнардыр. Анысына минем бер каршы сүзем дә жук. Җаны теләгән җылан ите ашаган ди. Анысын үзләре беләдер шунда. Әмма дә ләкин пртакул җаза торган кызга берүк әйтеп куй: минем дәшми торганны ризалык билгесе дип терки күрмәсен ул анда! Бүтәннәр ничектер, мин анысын белмим, тик мин үзем ике ситныр түгел, ике кадак бәрәнге дә бирә алмыйм бүгенгесе көндә. Үзебезгә дә бик такы-токы гына ул. Ышанмыйсыз икән, өйгә килеп, тикшереп карый аласыз!

Барып йөрисе юк: семьясы алты җан. Фәкыйрьлеге кыяфәтеннән үк күренеп тора иде Хәмзә агайның. Аңа каршы сүз әйтергә тырышу — болай да дөрләп торган утка бензин сибү белән бер булачак иде.

Колхозга ярдәм итә алмауларын әйтеп, шул арада тагын берничә кеше торып сөйләде. Алары да очын-очка чак-чак кына ялгап бара торган зур семьялы кешеләр. Әмма аларга карап кына нәтиҗә чыгарырга ярамый. Мәсьәләне катырак, конкретрак куярга кирәк иде.

— Яхшы,— дидем мин, тегеләр үз сүзләрен әйтеп бетергәч,— менә сез, әле сөйләгән иптәшләр, бер пот та бәрәңге бирә алмыйбыз, дисез. Ышанам. Артык бәрәңгегез юктыр да. Семьяларыгыз зур. Ләкин колхозда сездән башка да йөз дә житмештән артык хуҗалык бар бит әле. Һич тә шикләнмичә әйтәм: аларның икешәр центнер гына әҗәт биреп торырлык хәлләре бар.

Бу юлы авылның иң таза тормышлы кешесе — мич чыгаручы Сәлах агай сүз алды. Ул үзе колхоз эшенә йөрми. Инвалид. Карап торышка болай таза гына. Әмма сугышта контузияләнгәннән соң чукрак булып калган. Дөрес, аның турында халык арасында, юри шулай кылана ул, бер дә чукрак түгел, үзенә кирәкне бик шәп ишетә, эшләмичә пенсия алыр өчен генә, янадан сугыш чыга калса, сугышка бармас өчен генә шулай мәтәштереп йөри ул, дигән сүзләр дә ишетелгәли. Ләкин кеше сүзенә карап кына берни эшләп булмый, чөнки тегенең инвалидлык документы бар.

Әнә шул Сәлах агай, колхозда эшли алмаса да, дөресрәге, эшләргә теләмәсә дә, бер көн дә эшсез тормый: кешеләргә мич тә чыгара, бүтән эшләрен дә эшли. Сүз әйтер хәлем юк, шәп мичче, яңа йорт

житкергән кешеләр, мичләрен аңа чыгартыр өчен, хәтта күрше районнардан килеп алалар үзен. Шул кадәр атаклы. Әмма хезмәт хакын да шәп каера: бүтән мич чыгаручыларга караганда ике-өч мәртәбә артык ала. Берсе инде армия хезмәтеннән кайтып өйләнгән, икенчесе алдагы елда барачак ике малае бар. Алары да, әтиләренә охшап, эшкә бик уңган. Тик берсе дә кышын колхозда эшләми. Ул елны да кәсепкә чыгып киткәннәр иде. Менә шул агай торып басты да әйтә миңа:

— Син, Булат энем, — ди, — кешеләрне алай хәллегә дә, хәлсезгә дә аерып карама. Калхуз шуның өчен дә калхуз инде ул — бай да, ярлы да юк анда. И һәм булырга тиеш тә түгел. Имынны шул бөтен кеше дә бертигез булсын дип төзелгән дә инде ул калхуз дигән нәрсә, — ди. — Рас шулай икән, рас калхузга бәрәңге бирергә дип карар чыгарасыз икән, — ди, — ул чакта моржа башыннан икешәр ситныр бирергә дип чыгарырга кирәк аны. Шулай булган тәкъдирдә мин риза. Хет бүген үк килеп алып китегез минем ике ситныр бәрәңгемне! — ди. — Әмма ләкин, шулай булмый торган булса, бигайбә, мин дә бирә алмыйм. Минем дә артып торган малым юк! — ди.

Мин аңа ни дип әйтергә дә өлгермәдем, тагын бер шуныңише «дипломат» агай торып басты. Анысы тегүче. Гомер буе бүрек тегеп кәсеп иткән. Ике центнер гына түгел, теләсә унике центнер да биреп торырлык рәте бар. Ә ул нишли дисез? Ә ул әйтә миңа:

— Әз генә булса да оят дип атала торган нәрсә бармы безнең бу идарәдә, әллә бөтенләй оныттыгызмы инде аны? — ди. — Алдагы елларда алган әҗәтләрегез түләнмәгән, тагын нинди әҗәт сорау була ди инде бу? Минем инде калхуздан тугыз ситныр бәрәңге аласым бар. Ә сез тагын сорыйсыз. Килешә торган эшме инде шушы, я? — ди.

Ул шуны әйткән генә иде, җыелыштагылар:

— Бик дөрес. Иң элек калган әҗәтләрен түләсеннәр, шунсыз беребез бер кадак бәрәңге бирмибез! — дип ду купты. Алар сүзе дә хак булып чыкты: колхоз инде өч ел рәттән кышын әҗәткә дип бәрәңге җыя да, көзен түләмичә килә икән...

Менә шуннан соң ышандырып кара син колхозчыны!

Ә бит миңа аларны ышандырырга кирәк! Шуннан әйтәм мин боларга:

— Курыкмагыз, иптәшләр, — дим, — колхоз сезгә бурычлы булып калмас. Алган әҗәт түләнергә тиеш. Киләсе көз, кемгә күпме тиеш, барысын да кайтарып бирербез. Ләкин сез дә идарәнең үтенечен аяк астына салмагыз инде. Колхоз бер минеке генә түгел. Сәлах агай дөрес әйтте: бөтенебезнеке ул. Ничек тә кара җиргә исән-сау аяк басырыйк инде ферма малларын. Әйдәгез, иптәшләр, йорт саен икешәр центнер бәрәңге арттырыйк. Кем дә кем шуңа риза — кул күтәрүләрен сорыйм.

Бер кул да күтәрелмәде.

— Башта элек алган әҗәтләрегезне түләп күрсәтегез әле. Аннары сөйләшербез, — дип тик утыралар. Нишләргә хәзер? Әгәр мин бүген сүземне үткәрә алмыйм икән, миңа бер генә юл: гариза язып, председательлектән китү генә калачак. Ләкин бу инде егетлек булмаячак.

Мин шулай ут йотып, гаҗиз булып торганда Сәлах агай янә сүз сорап алды:

— Элекке заманда әҗәткә биреп торган өчен әҗәт алган кешедән ул әҗәтен прутсинт белән түләтү гадәте барые. Әйтик, бер хәллерәк кеше бер ярлырак крәстиянгә кыш көне бер пот икмәк биреп торса, көзен, игеннәр өлгергәч, ул бер потны крәстиян тегеңә пот ярым итеп кайтара торганые. Бәлки безнең идарә дә шулай итеп карар, ә? Алай булган тәкъдирдә — мин берүзем өч ситныр бәрәңге биреп торырга риза булырыем, — ди бу.

Җыелыштагыларның башкалары да элеп алды моның тәкъдимен. Алар да:

— Шулай булганда без дә риза! — диешә башлады. Минем үземнең дә эчкә җылы кереп китте хәзер. Дөрес, үз семьяңнан үзең процент алу килешә торган нәрсә түгел инде. Ләкин менә бу конкрет очракта, мәсьәләне башкача хәл итү мөмкин булмаганда, Сәлах агай куйган шартны кабул итмичә дә беркая барып булмый иде. Тегенең тәкъдимен тәвәкәлләп тавышка куйдым. Җыелыштагыларның күпчелеге, ризалык белдереп, кул күтәрде...

Әлбәттә, хәзер, колхозның бүгенге мөмкинлегеннән чыгып карагандa, бик вак булып күренә бу хәлләр. Хәтта бераз көлке дә булып күренә. Мәсәлән, безнең колхоз быел, дәүләт планын үтәгәннән тыш, фуражга гына да 8 320 центнер бәрәңге салды. Әмма бу безнең колхозның терлек азык балансында бер дә алай зур роль уйный торган нәрсә түгел. Десерт сыманрак кына ул безнең терлекләр өчен. Ә теге елны аның бер центнеры да дөнья бәясе иде безгә...

Инде әйткәнемчә, мин башта күп дигәндә дә өч йөз дә алтмыш центнер җыйный алсак, бик әйбәт булыр иде дип тотынган идем. Ә без дүрт йөз дә тугыз центнер бәрәңге җыйдык ул чакта. Ни өчен дигәндә, бер центнерга бер ярым итеп түләнәчәген белгәч, «кирәк булса, без артыграк та биреп тора алабыз, калхуз үзебезнеке ләбаса» дигән булып, үзләре теләп, өчәр, хәтта дүртәр центнер бирүчеләр булды...

Икмәк әҗәте мәсьәләсен мәҗбүри түгел, ихтыяри итеп куйган идем шул җыелышта. Көзен центнерга центнер ярым итеп кайтарасы булгач, анысын бирүчеләр дә байтак табылды: йөз центнердан артык икмәк җыйналды.

Мин моны ни өчен шушылай тәфсилләп сөйлим? Мин моны шуңа күрә җентекләп сөйлим, чөнки бу минем «Трактор» «руленә» утыргач беренче җиңүем иде. Уңышлы үткән шул «бәрәңге һәм икмәк операциясе» минем тормышымда зур борылыш моменты булды: үз-үземә дә, кешеләргә дә ышанычымны арттырды, ары таба председатель булып эшләргә рух, дәрт бирде.

Шулай да бу «операция» кайберәүләрнең эченә тигән булып чыкты бит, әй. Көзен бәрәңге алырга керешеп, колхозчыларга әҗәтне кайтара башлаган көннәрнең берсендә ашыгыч кына районга чакырттылар. Бюро буласы икән дә шуңа дәштергәннәр иде. Чиратым җиткәч керттеләр. Гали Даутович түрдә, «Т» хәрефе башында берүзе утыра. «Т»-ның гәүдәсен тәшкил иткән өч өстәлнең як-ягына бюро членнары тезелешкән. Бүлмә тып-тын. Унлап кешенең барысы да, фоторәсемдәге шикелле җансыз калып, миңа текәлгән. Моңарчы бер тапкыр да бюрода булганым юк иде. Шуңа күрә, ни эшләргә дә белмичә, ишек төбендә туктап калдым. «Якынрак килегез!» — диде Гали Даутович, «Т»ның бу башындагы буш урынга ымлап. Килдем. Минем ише чакырылган кешеләр утырыр өчен куелгандыр инде бу дип, шул урындыкка утырмакчы идем, секретарь, каты гына итеп, басып торырга кушты. Аннары, «башладык» дигәнне аңлатып, оештыру бүлеге мөдиренә ым какты. Мөдир минем өстән райком исеменә хат килгәнлеген, ул хатта минем кышын колхозчылардан колхозга әҗәткә алып торган бәрәңге белән ашлыкны бер центнерга центнер ярым итеп кайтаруым турында язылганлыгын әйтте дә:

— Без бу сигналны тикшердек. Факт расланды, — диде.

— Кем кушты сиңа, Вәлиев, колхоз милке белән башбаштаклык итәргә? — диде Гали Даутович, гадәттә булмаганча кискен итеп.

Мин килеп кергәндә бюро членнары барсы да тын гына, шомлы гына каршы алгач, әллә берәр төрле законсыз эш эшләп ташладым микән дип шикләнгән идем. Ә хәзер, мәсьәләнең «бәрәңге белән ик-

мәк операциясе»нә кайтып калганлыгын белеп алгач, эчкә җан кереп китте:

— Ә минем бернинди башбаштаклык та иткәнем юк, Гали Даутович! Колхозчыларның гомуми җыелышы чыгарган карар нигезендә эшләнгән эш ул! — дидем.

Мин моны курыкмыйча әйттем. Председатель булып эшләвемә күп булмаса да, колхозчыларның колхоз милкенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә мондый гына карар чыгарырга хокуклары бар икәнен белә идем.

Мин җебеп калмагач, секретарь да бик алай күтәрелеп бәрелми хәзер. «Сез соң ни карадыгыз мәсьәләне бюрога әзерләгәндә», дигән сыман итеп, оештыру бүлеге мөдиренә дә текә генә итеп бер карап куйды бу. Әмма сүзеннән кайтырга исәбе юк үзенең. Аның да хәле аңлашыла. Бюро тикле бюрога кешене чакыртып китергәч, ничек инде бер дә чара күрмичә генә кайтарып җибәрмәк кирәк?

— Син алай гомуми җыелышка гына сылтама! — ди бу миңа, каш астыннан гына карап. — Карарның төрлесен чыгарырга була аның. Без сине башка колхозларның колхозчыларына начар үрнәк бирә торган, шәхси милекчелеккә юл куя торган карарны нигә чыгардың дип чакырттык. Синең шуңа ни дип җавап бирүеңне ишетер өчен, алга таба председатель булып эшли алу-алмавың мәсьәләсен хәл итәр өчен чакырттык без сине монда!

Үземнең беренче тапкыр гына утыру булса да, бюроларда байтак булган өлкән председательләрдән ишетеп беләм: мондый чакта акланырга тырышу кирәкми. Гаепле булсаң да, гаепсез булсаң да, хата миндә, иптәшләр, кичерегез, бүтән андый ялгышны кабатламаска сүз бирәм, диюдән дә яхшысы юк дигәннәр иде алар. Дөрес әйткәннәр икән, мине дә кичерделәр. Шелтәсен бирделәр бирүен. Әмма әйттеләр, председатель булып әле күптән түгел генә эшли башлавыңны искә алып, шелтә бирү белән чикләнәбез, әгәр тагын шундый берәр «мөгез» чыгара калсаң, үзеңә үпкәләрсең, диделәр.

Аларның юравы юш килде: озак та үтмәде, миңа, чыннан да, тагын кызарырга туры килде. Ул хакта сүз алдарак булыр. Ә хәзер шул елны минем тарафтан ясалган «атлар операциясе» турында әйтеп үтәсем килә.

Ул бичара атларның хәле бик мөшкел иде. Әгәр берәр әмәлен табып, фураж мәсьәләсен хәл итмәсәң, язгы чәчүдә эшкә ярамау гына түгел, аңарчы гел үлеп бетүләре дә бик мөмкин иде. Ни эшлим икән, эшләр менә шулай-шулай бит, дип райкомнан ярдәм сорап караган идем — ник авыз ачканыма үкенеп бетә алмадым. «Әле кыш уртасы да узып китмәгән, ә син инде фураж бетте дип килеп җиткәнсең. Ничек оят түгел синә. Әнә күршең Шәрифуллиннан үрнәк ал: җирләрегез бер төсле үк, аның фуражы да, бүтән курмылары да җитәрлек»,— дип, икенче секретарь башта шыбыр тиргә батырганчы тиргәде. Аннары: «Бар, бүтән мондый сораулар белән баш катырып килеп йөрисе булма. Ярыл, ләкин җаен тап. Син шуның өчен председатель итеп сайланган бит. Кара аны, бер генә атың үлә калса да, башың белән җавап бирергә туры киләчәк!» — дип чыгарып җибәрде.

Райкомнан чыктым да, урам уртасында басып уйга калдым: нишләргә? Кая барып бәрелергә хәзер? Каян табарга ул атларга азык?.. Ни кылырга да белмичә гаҗиз булып торган чагымда, берәү артымнан килеп аркама кагылды да:

— Нихәл, сержант Вәлиев! Нигә болай боегып торасың? — диде.

Күтәрелеп карасам — фронтта минем белән бер взводта сугышып йөргән дустым Александр Леонов икән. Ул чагында ябык кына, чандыр гына бер егет иде. Ә хәзер шундый тулып-тазарып киткән, үзе дәшмәгән булса — танырлык та түгел. Фронтта без аның белән сигез

ай чамасы бергә булдык. Аннары, кырык дүртнең августында, немецлар белән бер бик каты сугыш вакытында, сул иңбашы каты яраланып, аны госпитальгә озатканнар иде. Шуннан соң ул сугышка яраклык булмаган. Авылларына кайтып, бригадир булып эшли башлаган. Анда бераз эшләгәч, райкомга инструктор итеп алганнар. Ике елдан бүлек мөдире итеп күтәргәннәр. Ә аннары Агачлык спирт заводына директор итеп билгеләгәннәр дә, инде менә дүртенче елын шунда эшли икән.

— Синең эшләр зарланырлык түгел, алай булгач. Ә менә минем хәлләр бик ямаи, Саша, — дип, мин аңа атлар мәсьәләсен сөйләп бирдем.

— Да-а-а, — ди бу, минем хәлгә кереп. Сәламәт кулы белән колак яфрагын тотып беркавым уйланып тора. Шуннан соң әйтә миңа: — Тыңла әле, Булат, — ди, — син миңа заводка утын ташырга биш баш ат биреп тора алмассыңмы?

— Алуын алам, Саша, — мин әйтәм, — тик бик ябык шул алар.

— Анысы өчен кайгырма,— ди теге.— Барда ашатып атна-ун көн эчендә эшкә яраклык, унбиш көн дигәндә бия күрсә ярсый башларлык итәм мин синең ул атларыңны.

— Алай була торган булса, бишне генә түгел унны, туксанны алсаң да сүзем юк, — мин әйтәм.

— Ашыкма син, Булат,— ди бу миңа.— Ашыкма, дустым. Башта мине тыңлап бетер.

## УНЫНЧЫ ДӘФТӘР

Хәтерлисеңме, сугышта син мине бервакыт үлемнән коткарып калган идең? — ди.

— Хәтерлим, — мин әйтәм.

Әйе, булган иде андый хәл. Бер бик хәтәр сугыш вакытында безнең Казанка елгасы шикелләрәк суны ашыгыч кына кичкән чакта (ашыкмый хәл юк, чөнки ул чагында без дошманны түгел, дошман безне чигенергә мәҗбүр иткән иде), менә шул суны бик ашыгыч кына кичкәндә, тобага туры килеп, бата башлады бит шушы Саша. Бүтән бар яктан уңган егет үзе, ә йөзә белми икән. Прәме күз алдында батып бара. Ә үзе ярдәм сорап кычкырмый. Кычкырса, дошман атып үтерәсен белә: фашист прәме үкчәгә басып килә бит безнең. Кычкыруын кычкырмый бу, әмма кул ишарәләре белән, коткар, Булат, зинһар үлемгә ташлап китмә дигәнне аңлата. Ә күзләре шундый инәлеп, шундый ялварып-өметләнеп карый — түзә торган түгел. Нишләргә хәзер? Суда озак маташсам, үзем дә дошман кулына эләгәм. Калдырып китәр идең, үз агай-энең шикелле якын булган, сиңа шундый ялварулы итеп карап ярдәм көткән кешене ничек ташлап китмәк кирәк? Ул арада Саша инде бөтенләй батып китте. Ул төшеп киткән турыдан вак-вак куыклар гына чыгып калды. Шул чакта мин ни эшләдем дисез?.. «Их, беткән баш беткән, барыбер бер үләсе, күрә торып иптәшеңне батырып калдырып, аннары гомер буена үкенеп-өзгәләнеп яшәгәнче, ичмаса, үлсәм дә тыныч күңел белән үләрмен», — дип уйлап алдым да, чумдым мин теге баткан тобага...

Сез инде шундый ашыгыч чакта, әллә кайчан суга сикерәсе урында, ничек шулай уйланып-икеләнеп тора алдың, дип гаҗәпләнеп калгансыздыр, шулаймы? Ләкин шуны онытмагыз: сөйләгәндә генә шушылай озак сөйләнә ул. Ә теге уйлар ул чакта минем баштан секундның меңнән бере эчендә үтеп китте... Ничек шулай җайлы туры килгәндер, анысына хәзер дә шаккатам: шул бер чумудан эләктереп алдым бит Сашаны. Эләктердем дә сөйрәп ярга алып чыктым. Гомеребез бетмәгән икән: безнең иптәшләрнең берсе минем суда мәтәвекләнеп ятканны

күреп алган да, яр башындагы агачлар артында посып, автоматтан атып, мин Сашаны су буеннан ярга алып менгәнче немецларны тоткарлап торган иде...

Әнә шул вакыйганы әйтүе иде хәзер Сашаның.

— Ул чакта тоба төбенә батып баруым исемә төшкәндә әле хәзер дә җаным өшеп, тәннәрем чымырдап куя. Син булмасаң, беткән иде. Булат дус, баш! Шул вакытлар искә төшкән саен сине рәхмәт хисләре белән искә алам, — диде ул, минем аркамнан кагып. Аннары, өзелеп калган сүзне ялгап, атлар мәсьәләсенә күчте. — Ә ул мәсьәләне болай сөйләшербез: син заводка биш баш атыңны җибәрерсең, ә мин синең колхозга көн саен ун мичкә барда биреп барачакмын. Ризамы шуңа? — ди.

— Мин биш куллап риза да бит, Саша, — мин әйтәм, — минем аркада үзеңә кыен туры килмәсме соң? Араларыбыз унҗиде чакрым гына булса да, икебез ике өлкә (ул Киров өлкәсенә карый торган завод директоры иде) кешеләре бит без. Барда үзегезнең өлкә колхозларына да кирәктер ич.

— Анысы өчен борчылма, — ди бу миңа, сүз озайтып торырга урын калдырмаслык итеп. — Икебез ике өлкәдә яшәсәк тә, шул бер үк Советлар Союзы инде ул. Раз эшлим дип әйткәнмен икән — эшлим инде мин аны! Бушка түгел бит! Заводка утын ташырга ат кирәк бит,—ди.

Сүзендә торды Саша: яз җитеп, юллар өзелгәнгә тикле көн саен ун мичкә барда биреп килде безнең «Трактор»га. Ә барда дигән нәрсә ат дигән хайван өчен солыдан бер генә дә ким түгел икән ул. Парландырып шул барда белән болгатып бирсәң, солы саламын әйтмим дә инде, хәтта арыш саламының да бөртеген дә калдырмыйча ашап бетерә икән ат.

Саша дөрес әйткән: барда ташып ашата башлагач, атна-ун көн эчендә тернәкләнеп китте безнең малкайлар. Ә язгы чәчүгә чыгар алдыннан алар инде гайрәтләнеп кешнәшә үк башлаганнар иде.

Шул елны язгы чәчүне безнең «Трактор» Шәйхинең «Таң»ыннан бер көнгә алдан төгәлләде. Ул заман өчен бер көнгә генә алдан тәмамлау әллә ни зур җиңү саналмый, чөнки язгы чәчү кампаниясе егерме бишәр көнгә, берәр айга сузыла. Кайбер алдынгырак хуҗалыклар чәчүләрен безнекеише фәкыйрь колхозларга караганда унар көн алдан бетерәләр иде. Хәзер генә ул чәчү срогын көнләп түгел, сәгатьләпминутлап алдан билгеләп куябыз. Бу ел, мәсәлән, безнең колхоз язгы чәчүне биш көн ярымда тәмам итте. Алай да районда без беренче түгел, бишенче урынга гына чыга алдык әле. Әнә кая китте хәзер эшләр!..

Ә шулай да ул-елны мин чәчүне Шәйхидән бер көн алдан тәмамлауга бик нык куандым. Чөнки, председатель булгач, минем аны беренче тапкыр җиңүем иде!.. Тагын шунысы кызык: чәчүне уңышлы тәмамлавыбызны райкомның икенче секретаре да үзенең шәхси уңышы сыманрак кабул иткән иде. Мин моны менә нәрсәдән чыгып әйтәм: сводкадан карап, безнең колхозның чәчүе төгәлләнгәнен күргән дә шалтырата бу миңа:

— Ну, вот, әйткән идем бит мин сиңа булмаган фуражны райкомнан сорап йөрмә, үзең җай тап дип. Чәчүне әйбәт кенә башкарып чыккансың ич. Молодец, понимаешь, сүзне тыңлагансың! — ди.

Аның бу сүзләрендә мине мактаудан бигрәк үзен мактау күбрәк иде шикелле.

Хәзер инде мине күргән саен мыскыллы елмаерга ярата торган Шәйхинең дә авызы ябылды. Ул миңа хәзер көнләшеп, кара янып карый башлады. Минем дә җан бар. Минем дә аны бер кытыклап алырга ният юк түгел. Төрттереп алырлык сәбәпләре дә бар: сыерлары нә-

селле маллар булса да, колхозы дәүләткә сөт тапшыру буенча бездән артта бара; язгы чәчү өстендә өч аты егылып үлде; яңа тишелеп чыккан бодай кырын билчән басып килә. Әйтәм бит, теләсәң аның да ачуын китерерлек сәбәпләр байтак. Әмма иртәрәк иде әле. Көз житеп, игеннәрне жыйнап алганны көтәргә кирәк иде. Дөнья бу, кайчакта кырлары янәшә торган ике колхозның берсенекенә гел дә кагылмыйча, икенчесенекен бетереп боз сугып киткән хәлләрне дә беләбез. Ә көзгә әле ерак: яңа тишелеп чыккан игеннәрнең үсеп тупсага утырасы, баш чыгарасы, серкә очырасы, орлыкланасы бар аңарчы. Кыскасы, шул: шайтан күңелне ничек кенә итеп вәсвәсәләндереп тормасын, Шәйхигә тел тидерергә ярамый иде әле...

Ихтимал, председатель булып яңарак эшли башлаганга күрәдер, ул елдагы хәлләр күңелдә аеруча нык уелып калган. Шул җәйдә мин үзем өчен дә, колхоз эше өчен дә бик мөһим тагын бер «операция» ясап ташладым.

Анысы «шабашниклар операциясе» иде. Кыш киясе тунны жәен тегеп куй, ди халык. Мин дә шулайрак итәргә булдым. Кар төшү белән авылдан Урал якларына сибелгән теге кәсепчеләрне санап карыйм — иллегә якын жыйнала болар. Иллегә якын! Тегенди-мондый гына түгел, орса өрлек сындырырлык ир-егетләр ләбаса!.. Миңа кадәр чыгып киткәннәр иде, алты ай йөреп, май башларында гына кайттылар. Сүз әйтә алмыйм, күбесе кайту белән колхоз эшенә тотынды: кая кушсаң — шунда баралар, ни кушсаң — шуны үтиләр. Ләкин бөтенесе дә түгел. Арада элен-салын, эттем-төрттем генә йөргәннәре дә бар. Ә дүртесе бөтенләй эшкә чыкмый боларның. Чакыртып сөйләшеп тә карадым, ыжлап та бирмиләр. Берсе әйтә:

— Бик эшләрием дә, прсидәтел, минем спитсиәлнес буенча эш юк шул сездә: ташчы бит мин, — ди. Икенчесе әйтә:

— Минем шкатур спитсиәлнесенә дә эш таба алмыйсың инде син, — ди. Үзләре мыек астыннан гына көләләр: синең ише акыллы башларны күргән бар, янәсе. Ә икесе һөнәрләрен әйтеп торуны да кирәк тапмый. Алары бөтенләй алып узып:

— Карале, юк нәрсә белән үзеңнең дә башыңны ватып, безнең дә нирбыга тиеп маташма әле, Вәлиев! — диләр. — Синең шикелле тырышып караучылар булды инде. Тик берсе дә берни үзгәртә алмады. Алар китә барды, ә калхуз әле һаман исән, гел шул фәкыйрь килеш яши бирә. Курыкма, без эшләмәгәннән генә таркалмаячак ул. Син тырышканнан гына алга да бармас. Әйдә, лутчы киттек безнең белән бер тынычрак жиргә дә, бер иркенләп, кешеләрчә сөйләшеп утырыйк әле ичмаса! — диләр.

Ә бит алар да нәкъ минем шикелле үк тап-таза ир-атлар, югыйсә. Минем кебек үк алар да совет мәктәбендә укыган. Бер үк елганың суын эчеп үскәнбез. Бер үк телдә сөйләшәбез. Бер үк радионы тыңлыйбыз. Бер үк китаплар укыйбыз. Бер үк киноларны карыйбыз. Ә колхоз эшенә мөнәсәбәтләребез — жир белән күк. Аларның үз фәлсәфәсе, минем үз фәлсәфәм. Хикмәте кайда моның? Каян, нигә шулай килеп чыга бу?..

Тегеләрнең кыланышына женем чыгып, туздырып ташларга да уйлап алган идем. Әмма шул чак Гали Даутович күз алдыма килде дә тыелып калдым. Аның бераз корырак, гел үзен генә хаклы саный торган, боеру тоны беләнрәк эш итә торган кеше икәнен әйтеп киткән идем инде. Ул якларын бик үк өнәп бетерми идем мин аның. Әмма шул кешенең минем өчен үрнәк булырлык бер әйбәт сыйфаты бар: ачуы никадәр нык килгән чагында да ярсып китми, үзен-үзе контрольдән ычкындырмый иде ул. Ә бит аның эше минекенә караганда бик күпкә катлаулырак. Районда егерме ике колхоз гына бар. Жиде совхоз. Әллә ничә бүтән төр оешма. Ә ул шуларның барысына да жаваплы. Кай-

сысының эше артка калса да, иң элек аннан сорыйлар. Ләкин ул нинди генә хәлдә дә сабырлыгын җуймый иде. Дөрес, эчтән кыза: тешен бик каты кысканлыктан, яңак сөякләре уйнаклый. Тик ул беркайчан да җикеренми. Гаебең бар икән, бюрога чакырта да, я шелтә бирдереп җибәрә, яки эшеңнән азат иттерә. Әмма, кабатлап әйтәм, беркайчан да чыгырыннан чыгып китми үзе. Беләм, болай эшләү аңа җиңел түгел. Ләкин, шул ук вакытта, миңа калса, моның уңай ягы да бар. Әнә шул тыелып, уйланып һәм башкаларның да фикерен тыңлап утырганда ул, бердән, суына-сүрелә, икенчедән, тикшерелә торган мәсьәлә буенча дөрес фикергә килә. Мин аның әнә шул сыйфатына кызыгам. Үземнең дә аның шикелле буласым килә. Четерекле хәлләр килеп чыгып, менә шартлыйм, менә шартлыйм дип торган чакларда аны искә төшерәм дә, үземне кулга алып, тыелып кала торган идем...

Тегеләрнең кара мыеклысы, һөнәрен дә әйтмичә, күзгә карап авыз ерып торганга җен ачуым чыгып, эчемдә тәмуг уты кайнаса да, тыштан тыныч кына итеп:

— Ярый, алай булгач. Барыгыз, кайтыгыз. Мәсьәләне колхозчыларның гомуми җыелышында хәл итәргә туры килер, — дип, тегеләрне чыгарып җибәрдем.

Җыелыш җыеп шул дүрт тыңлаусызны колхоздан чыгарып ташларга иде исәп. Шунсыз булмый. Шунсыз колхозда тәртип урнаштыру мөмкин түгел. Берәрсе син кушкан эшкә бармыйча калып, аны чакыртып сөйләшә башласаң: «Әнә, кайберәүләр бөтенләй дә эшкә йөрми бит әле, аларны күрмисең, мин бер көн эшкә чыкмый калганмын икән, дөнья харап булган шикелле итеп, идарәгә үк чакырттыргансың», — дип авыз ачарга да ирек бирмиләр. Мисалга шул дүрт сөкәтнең исемен атыйлар. Дөрес итәләр. Чөнки, чынлап та, тегеләре дә колхозчы санала, колхоз җирендә яши бит. Ләкин читтә акча сугып йөри. Болары бер караңгыдан икенче караңгыга тикле колхозда бил бөгә. Җитмәсә шул эшләүчеләрен еш кына орышырга туры килә әле...

Анысы шулай. Әмма тегеләрне колхоздан чыгару җиңел булмаячак. Монысын мин алдан ук сизеп тора идем. Авыл халкының холкын беләм: берәр кешегә катырак хөкем, кискенрәк чара кулланырга кирәк булганда, гәрчә ул кеше шул хөкемгә артыгы белән лаек булса да, авыл халкы барыбер аны кызгана. Эшне ничек тә зурга җибәрмичә, йолып калдыру ягын карый.

Бу юлы да шулай килеп чыгуы бик мөмкин. Шуңа күрә алдан берәр төрле чарасын күрергә кирәк иде.

Уйладым-уйладым да, шушы авылда туып үскән, тормыш тәҗрибәсе минекенә караганда күпкә артык булган парторг Мәдхия апа белән киңәшеп карарга булдым. Мәдхия апаның ул көннәрдә эше бик тыгыз — мәктәпкә ремонт ясыйлар иде. Шуңа аны идарәгә дәштереп тормадым, янына үзем бардым.

Мин барганда ул, ремонтчылар, укытучылар, җыештыручылар белән бергәләп, җиң сызганып эшләп йөри иде. Читкәрәк дәшеп алдым да планымны сөйләп бирдем.

— Дөрес уйлыйсың, — диде Мәдхия апа. — Шунсыз безнең хуҗалыкта тәртип булмаячак. Тик менә тегеләрне колхоздан чыгарырга халык риза булыр микән соң?

— Белмим шул, Мәдхия апа. Шуңа киңәшкә дип килдем дә инде сезнең янга.

Ул бераз уйлап торды да:

— Менә болай итеп карарга кирәк булыр, Булат, — диде. — Бу мәсьәләне без әлеге дүрт кешегә генә кайтарып калдырмыйк. Киңрәк куйыйк без аны.

— Башкача тагын ничек куясың аны?

— Анымы? Авылдан инде әллә кайчан киткән һәм колхоз белән бернинди дә алыш-биреше булмаган кешеләр байтак бездә. Алар инде күптән төрлесе төрле җирдә төпләнеп калган. Кайсы заводта, кайсы шахтада эшли. Кайсы нефть чыгаруда. Ләкин алар барысы да бүгенге көнгә кадәр колхозчылар исемлегендә йөри. Ә бит болай булырга тиеш түгел. Авылда яши торган, колхозда эшли торган кешеләр генә колхоз членнары булып саналырга тиеш. Җыелышта әнә шул фактически инде күптән колхоздан чыккан кешеләрне формаль яктан да колхоздан чыгару мәсьәләсен куярга кирәк. Шул исемлеккә тегеләрне дә теркәргә. Шулай эшләгәндә законлы да булыр, халыкның да тешенә артык тимичә генә үтеп китәр.

Идарәгә кайтып санатып караган идем, колхоздан кендекләре өзелгән кешеләр утыз сигез җан булып чыкты. Шуларга әлеге дүрт акыллы башны да кушкач, кырык икегә житте болар.

Җыелышта докладны үзем ясадым. Башта колхоз хәлләренең гомуми торышы турында сөйләдем. Аннары алда торган эшлисе эшләргә тукталып, аларны уңышлы итеп башкарып чыгу өчен барлык колхозчыларның да тырышып эшләве кирәк икәнлеген әйттем.

— Ләкин, иптәшләр, — дидем шуннан соң, төп мәсьәләгә күчеп, — кайберләрегез колхоз эшенә бик салкын, хәтта, мин әйтер идем, төкереп карый, — дидем. Теге дүрт сөрхәнтәйнең исемнәрен атадым. — Менә шундый, — дидем аннары, — исеме колхозчылар исемлегендә булып та, җисеме белән тик үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып йөрүчеләр халыкка начар үрнәк күрсәтә. Шуңа күрә идарәнең колхозчылар исемлеген яңадан барлап чыгарга, анда тик чын мәгънәсендә колхозда эшләүчеләрне генә калдырырга кирәк булыр.

— Бик дөрес!

— Күптән шулай кирәгие! — дип кычкырышты халык, мине хуплап.

— Алайса, сүзне озынга сузмыйк, иптәшләр, колхозда эшләмәгән кешеләрнең исемлеген укыйк, — дидем мин. — Исемлекне уку өчен сүз партоешма секретаре Мәдхия Хәмитовага бирелә!..

— Я, кемдә нинди фикерләр, тәкъдимнәр бар исемлеккә карата?

— Әйтәсен әйттек бит инде! — дип җавап бирделәр. — Тагын нәрсәсен тикшереп торасың аның?

— Яхшы. Алайса, тавышка куябыз. Кем дә кем шушы исемлеккә кергән кешеләрне колхоздан чыгарырга кирәк дип саный — кулларыгызны күтәрүне сорыйм.

Барысы да кул күтәрде. Теге тыңлаусызларның үзләрен дә чакырткан идек җыелышка. Уен эш кенә дип карыйлар иде, ахрысы, тәкәббер генә елмаешып, хәтта алар да кул күтәрде.

Ә инде иртәгесен, җыелыш карары нигезендә, аларның мал-туарын колхоз көтүенә чыгарырга ярамавын, бәрәңге бакчалары, агач бакчалары өчен шактый гына налог түләргә кирәк булачагын аңлатып биргәч, корт чаккандай кыбырсына башлады болар. Башта, яклау эзләп, авыл советына күрше авылга (Пәрәүдә авыл советы юк иде) чапты болар. Анда, барысы да дөрес эшләнгән, без берничек тә ярдәм итә алмыйбыз, дигән җавапны алгач, районга, прокуратурага жалоба белән барганнар. Тиздән, мине чакырып, прокурордан язу килде. Закон сагында торучы кешегә каршы килеп булмый, бардым. Белмим, чыннан да, мине гаепле дип санагандырмы, прокурор мине бик хәтәр каршы алды. Килеп керергә өлгермәдем:

— Фәлән-фәлән кешеләрне колхоздан чыгаруың дөресме, Вәлиев? — ди бу миңа.

— Дөрес! — мин әйтәм.

— Ни эшләгәнеңне үзең аңлыйсыңмы син? — ди бу. — Моның өчен нәрсә булачагын беләсеңме? — Ул моны шундый итеп әйтте, әйтерсең мин кеше үтергән! Шуннан минем дә йон кабарып китте дә, әйтәм мин тегеңә:

## УНБЕРЕНЧЕ ДӘФТӘР

— Сез, иптәш Әхмәдуллин, минем белән алай төксе сөйләшмәгез. Беренчедән, мин генә эшләгән эш түгел ул. Гомуми җыелышта халык хәл иткән аны. Икенчедән, ул белеп, колхоз уставы нигезендә эшләнгән. Өченчедән, — мин әйтәм, — әгәр без ялгышканбыз икән — җавабын үзебез бирербез. Тиешле булса, җәзасын да алырбыз.

Шулай дидем дә, минем бүтән әйтер сүзем юк, сау булыгыз, дип кайтып киттем. Башка бу турыда сүз булмады. Колхоздан чыгарылган теге дүрт акыллы баш, күрмәгәнен күрсәтәбез әле без ул прсидәтелгә дип, бик гайрәтләнеп йөрсәләр дә, прокурор мине бүтән чакырмады. Күрәсең, хаклык безнең якта икәнен ул да аңлаган иде булса кирәк.

Шулай итеп, тагын бер мәртәбә нервыны бозып алдылар. Әнә шул вакыйгадан соң үзем өчен янә бер мөһим ачыш — хаклыкны да көрәшсез генә яулап булмый, аның өчен дә көрәшергә туры килә икән дигән нәтиҗә ясадым. Ә аңарчы дөреслекне яулап торасы юк, ул болай да шар ярылып ята бит дип сабыйларча ышанып йөргән идем. Монысы бер. Икенчедән, әнә шул чакта кәсепчеләргә каршы көрәштәге тәвәккәллегем соңыннан үзем өчен бик әһәмиятле җиңүгә әйләнде. Районда гына түгел, Казанга барып та «каптыра» алмагач, кикрикләре шиңде теге акыллы башларның. Хәзер мин алар артыннан түгел, алар минем арттан йөгерә башлады. Колхозның кадерен колхоз члены булган кеше генә белми аның. Дөресрәге, ул аның хакында бөтенләй уйламый. Чөнки ул аңа ияләнгән, аның өчен ул гадәти хәл, норма. Ә менә коллективтан чыгарылып, шәхси хуҗалык алып бара башлагач, колхоз милкенең шырпысына да кагылырга хакың булмагач, һәр нәрсәне бер ялгызың гына хәл итәргә тиеш була башлагач, ай-һай, уйландыра икән ул.

Теге дүрт сөрхәнтәй дә бик тиз аңладылар моның шулай икәнен. Эш сорап үзләре килә башлады. Ә мин әйтәм, бирә алмыйм сезгә эш, хакым юк, дим. Эшне биргән тәкъдирдә дә колхозчыларга биргән кебек гади итеп түгел, читтән килеп ялланганнар белән эш иткән шикелле, договор төзеп кенә бирергә мөмкин булыр иде, дим. Ләкин хәзергә алай да итә алмыйм, чөнки сезгә хезмәт көне кирәкми, сез аңа риза түгел, сез акчага гына эшлисез, ә без акчалата түли алмыйбыз, дим. Еламыйлар гына тегеләр:

— Без ничек түләсәң дә риза, тик безгә эш кенә бир дә, терлекләребезне көтүгә чыгарырга, кирәк булганда колхоз атын җигеп торырга, бозауларыбызны болынга арканларга рөхсәт ит? — диләр. Мин аларның хәлен аңлыйм. Хәтта мин аларны кызганам да. Колхозда эш бетәсе түгел. Эшен дә бик бирәсе: бер кешене бишкә-буләргә әзер торган чак бит. Шулай да каты торам тегеләргә. Ни өчен дисәң, бүтән вакытта кәсепкә йөрүләрен гел дә онытырасым килә. Алар туктаса, бүтәннәр дә йөрмәячәк. Шуңа каты торам. Беләм, колхозсыз яши алачак кешеләр түгел болар. Үлсә үлә, тик авылда үлә. Чөнки алар җаны, рухы белән авылга береккән. Чөнки дүртесе дә эш ярата. Ул эш аларга рухи канәгатьләнү бирә. Аларның өйләре — авылда иң яхшы өйләр. Капка-коймалар бизәкләп-буяп эшләнгән — ярты чакрымнан балкып тора. Дүртесендә дә мунча. Дүртесенең дә менә дигән алма бакчалары

бар. Шуларны ничек ташлап чыгып китә ди алар. Китми. Ялкау кеше генә, кулыннан юньле эш килми торган кеше генә чит җиргә ансат чыгып китә ул. (Мин монда югары уку йортларына, техникумнарга укырга китүчеләрне кертмим, алар — башка статья). Чөнки аның авылда кызганыр нәрсәсе юк. Сәләмә генә өе дә, булса, бер сыерыннан башка, нәрсәсе бар аның? Ике дөнья, бер моржа да, уртасында бер тишек кенә аңа. Шуңа авылны ташлап китү берни тормый. Җае чыкса, хәтта сөенә-сөенә китә әле. Имеш, ул шәһәр җирендә рәхәтрәк, культуралырак яшәячәк. Торыр урын дип тә кайгырасы түгел: эшче халыкка тулай торак һәр вакыт әзер. Ә инде, юлы уңып, квартирага да тиенсә, җәннәтнең дә җәннәте булачак. Чөнки аны кош сайравы, кырларда иген үсүе, чишмәләр чылтыравы, тургай, сандугачлар җыры, язын алмагачларның чәчәк атуы — берсе дә кызыксындырмый. Ул үз эшеннән ләззәт ала белми, шуңа өй турында бакча ясамый, каралты-курасын юньләп карамый. Бүген тамагы тук, өсте бөтен булса — шул бик җиткән аңа. Бу нилектән шулай килә торгандыр, анысын әйтә алмыйм. Ләкин мин андый кешеләрне бик үк өнәп бетермим. Әзерне, җиңел табыла торганны эзләүчеләр алар. Бәхет эзләүчеләр. Яшь чакта, дөнья корыр вакытта, кеше корганны, әзерне эзләп йөриләр-йөриләр дә, инде вакыт уткәч, көч-дәрт киткәч, их, үтте гомер чит җирләрдә, их, авылга кайтып, алачык хәтле генә булса да бер куыш салып, рәхәтләнеп, туйганчы авыл һавасын суласы иде, дип офтанып утыралар.

Зәңгәр күлмәгем юарга
Зәңгәр күлләр тапмадым.
Килсә, бәхет үзе килсен,
Мин эзләдем, тапмадым,

— дип, әле һаман да үзләренең ялкаулыкларын акларга тырышып, җырлап та куйгалыйлар. Ә бәхет ул эзләп кенә табыла торган нәрсә түгел. Тир түгеп эшләп, тырышып кына табып була аны. Эзләп кенә табыла торган булса, аны иң элек шул «летуннар» табар иде. Мин андыйларны күптәннән күзәтеп киләм: берсенең дә алай һуш китәрлек бәхеткә ирешкәне юк әле. Элеккерәк елларда Урал арьягы өлкәләренә язылып киткән иде алар. Вербовка белән. Анда да әллә кайда түгел, колхозда эшләргә. Бер елны Пәрәүдән берьюлы биш семья язылды. Бишесенең дә ир-атлары батырып эш эшли торган түгел. Өйләре өсләренә ишелергә тора. Яңаны җиткерү турында уйлыйсы да юк — кесәләре такыр. Өчесенең хәтта сыер да юк. Ярый, язылып чыгып китте болар. Ник киттеләр? Чөнки юлны дәүләт түли. Барып урнашкач, өй салырга да дәүләт ссуда бирә, сыер-сарыклар бирә. Хуш. Киткәннәренә бер-ике ай үткәч, хатлары килә башлады тегеләрнең. Өй салырга дәүләт, чыннан да, мул итеп акча биргән. Теләгән кешеләргә сыерын да, танасын да, сарыкларын да биргәннәр. Урманы өскә авып тора, телисең икән клуб хәтле итеп салырга була өйне, дип язалар. Шулай булуы бер дә гаҗәп түгел. Рас вәгъдә итеп кешеләрне алып киткән икән, безнең дәүләт вәгъдәсен үтәмичә калмый инде ул. Ләкин бит акча дигән нәрсә өй түгел әле ул. Өйне аны үз хезмәтеңне куеп, яки кеше яллап җиткерергә кирәк. Аннары бер ссуда белән генә гомер торып булмый, эшләргә, акча табарга кирәк. Дәүләт синең өчен эшли алмый. Киресенчә, син аңа эшләргә тиешсең. Шуңа шул кадәр акча түгеп алып киткән бит ул сине. Ә безнең теге иптәшләр эш мәсьәләсенә килгәндә алай атлыгып тора торганнар түгел. Шул. Анда барып та әллә ни котая алмады болар. Дәүләт биргән акчаны туздырып, үзләренең бар булган мөлкәтләрен юкка чыгарып, дүртесе китүләренә ике ел тулмас борын ук әйләнеп кайтты. Бишенчесе дә калмас иде дә, анысы шундагы колхозга завхоз булып урнашкан булганга күрә генә калган. «Җылы» урынны ярата торган адәм иде ул. Үзебездә эшләгән чагында, идарә тирәсенә берәр

эшкә алсаң икән, дип миңа да сүз катып караганы булды. Ләкин минем гадәт шундый: андый җиргә урнашырга кеше үзе темсенеп йөрсә — якын да китермим мин аны. Чөнки үзенә файда эзләп йөри торган бәндә була ул. Урал аръягындагы колхозда завхоз булып калган теге кеше дә шундый булып чыкты ахырында: колхоз милкен үзләштергән өчен алты елга утыртып куйганнар иде аны.

Әйтәм бит, күңел биреп, намус белән, тир чыгарып эшләмисең икән, хет син җәһәннәмнең тишегенә барып кер — анда да таба алмыйсың бәхетеңне. Андый «бәхет эзләүчеләрне» шактый күрдем мин үз гомеремдә. Мисалга бер дә әллә кая барып торасы түгел. Үзебезнең КамАЗны гына алыйк. Сүз дә юк, кирәкле төзелеш, газеталарда язганча итеп әйтсәк, гасыр төзелеше ул. Әнә шул төзелешкә иң элек авыл җиреннән кемнәр китте? Әлеге дә баягы, бәхетне эшләп түгел, эзләп табарга теләүчеләр, күп акча артыннан куарга ярата торган «летуннар» китте анда. Мин моны үзебезнең колхоздан киткән кешеләр мисалыннан чыгып әйтәм. КамАЗ төзелеше башланган елны бер безнең колхоздан гына да унҗиде кеше киткән иде шунда. (Мин монда әле һөнәр сайларга, һөнәргә өйрәнергә өлгермәгән, семья кормаган яшь-җилкенчәкләрне алмыйм. Яңа, зур төзелешләрдә нәкъ әнә шундый яшьләр эшләргә, шунда алар үзләренә ошаган һөнәрне үзләштерергә, шунда бәхетләрен табып, семья корып, шунда төпләнеп калырга тиешле дип саныйм мин. Ә менә бу конкрет очракта мин инде семья корган, бала-чагалары булган, әмма һаман ни семьясын, ни колхозны кинәндерерлек эш майтара алмаган ир-атларны күздә тотып сүз алып барам.) Әйе, безнең колхоздан унҗиде кеше китте алар КамАЗга. Әллә ашыкмыйсызмы, егетләр, дип караган идем, колакларына да элмәделәр. Көләләр әле җитмәсә үземнән:

— Тота алмыйсың безне, прсидәтел. КамАЗга китәргә теләүчеләрне тотарга хакың юк! — диләр. — Ә син артык кайгырма безнең өчен. Бер-ике елдан кайтабыз без. Барыбыз да «Жигули» алып, авылга кунакка кайтабыз, туры килгәндә үзеңне дә утыртып йөрербез, — диләр. Әй, сөйләшкән булалар үзара, әй, хисләнешәләр. Имеш, анда аена сигезәр йөз сум акча төшереп була. Имеш, анда эшләүчеләргә ике ел эчендә мәскәүчә төзелгән уникешәр катлы йортларда фатир бирәләр.

Китте болар шулай итеп. Ләкин киткәннәренә ел да тулмас борын әйләнеп кайттылар да шыпырт кына колхозда эшли башладылар. Ни өчен шулай тиз әйләнеп кайтканнармы? Чөнки берсе дә юньләп һөнәргә өйрәнмәгән. Берсе дә батырып эш эшләмәгән. Шуңа күрә боларга үзләре өметләнгән фатир да, аена сигезәр йөз сум акча да тәтемәгән. Колхозда да кинәндерә торган җирдә түгел алар: җыен вак-төяк эштә йөргән булалар шунда...

Ә теге елны колхоздан чыгарылган дүрт кеше — алар ул яктан бөтенләй башка. Эштән курыкмый иде алар. Нәрсәгә тотынсалар да яратып, умырттырып эшлиләр. Эшләгән эшләрен коеп куялар. Шуңа күрә эшләгән эшләре өчен түләүне дә тиешенчә таләп итәләр. Ә колхозның ул елларда һәркемгә хезмәтенчә түли алырлык хәле юк иде әле. Тегеләр читкә чыгып әйбәт кенә акча төшереп кайталар да, колхозда эленке-салынкы гына йөриләр...

Мин үзем колхозчыларны өч төргә бүлеп карыйм. Беренче төр — үзенә кушылган эшне чын-чынлап яратып, тәм табып, җиренә җиткереп эшли торган кешеләр. Мин аларны **алтын куллар** дип йөрим. Икенче төр — үзенә кушылган эшне зарланмый-сукранмый гына эшли, башкалардан артка да калмый, алга да чәчрәп чыкмый торган кешеләр. Алар колхозда — күпчелек. Алар — колхозның төп йөген тартып баручылар. Андыйларны мин **оста куллар** дип атыйм. Ә өченче төргә әнә теге, ни аллага, ни муллага дигәндәй, ни колхозга, ни семьялары-

на игелек күрсәтми торган, даими эшләре, яраткан һөнәрләре булмаган, әмма тел белән тегермән тартып йөрүче коры куык, буш бугазларны кертәм. Аларны мин **агач куллар** дип атыйм. Алар күп түгел. Әмма бар. Әлбәттә, бөтенләй булмасалар гел дә шәп булыр иде. Ни өчен дигәндә, кайда гына эшләсәләр дә гел зарлана, гел кемнедер гаепли, гел үзләрен хаксызга кимсетелгәнгә саный алалар. Үзләре юньләп эшләмәү өстенә, әлеге күпчелек тәшкил иткән **оста куллар** эшенә дә сүлпәнлек кертәләр.

Минем өчен иң кадерлеләре—**алтын куллар.** Кайда гына эшләсәләр дә, алар эшләгән җирдә һәр вакыт тәртип. Үзләре сүлпәнлеккә, халтурага юл куймау гына түгел, башкаларга да аннан-моннан гына эшләргә ирек бирми алар. Андыйлар белән эшләгәндә **оста куллар** тагын да тырышыбрак эшли. Чөнки адәм баласына көнчелек (мин монда бары тик яхшы мәгънәдәге көнчелек турында әйтәм), мин бүтәннәрдән киммени, нигә мин башкалардан калышырга тиеш әле дип, бүтәннәрдән уздырып җибәрергә омтылу дигән нәрсә хас. Моның шулай булуы әйбәт тә. Югыйсә, бу тормышта торгынлык килеп чыгар, алга, яхшыракка, яңага омтылыш булмас иде. Бу дөньяда һәркемнең бүтәннәрдән чак кына өстенрәк буласы, аерылыбрак торасы, алдынгырак буласы килә. Әгәр сабан туенда көрәшкә чыккан ике кешенең икесе дә үзе җиңүче булып калырга омтылмаса, шуңа ирешергә тырышмаса, ул көрәшнең кызыгы да, кирәге дә булмас иде. Эш — шулай ук көрәш.

Аның спорттан аермасы шунда гына: спорт ярышлары меңләгән тамашачылар күз алдында үткәрелә. Ә эш тамашачыларсыз эшләнә. Ләкин барыбер тамашачыларны — син эшләгән эшне күрәчәк, аңа бәя бирәчәк кешеләрне күздә тотып эшләнә. Ярыш дигән нәрсә әнә шуннан килеп чыга.

...Әлеге мин әйткән **алтын куллар,** гәрчә үзләре бу хакта уйламасалар да, эштә ярыш (көрәш дип атарга да була — аермасын күрмим) оештыручы алар. Менә шул **алтын кулларның** дүртесе, инде әйткәнемчә, эшсез йөри иде. Шуна мин аларга бик каты тотындым. Шуңа күрә колхоздан чыгарттырдым мин аларны. «Ни кушсаң, шуны эшләрбез, Булат туган. Беркайчан да сүзеңә каршы килмәбез! Кәсепкә чыгуыбызны да ташларбыз!» — дип үзләре бик ялынгач кына бераз миһербаным килде. Шулай да бөтенләй үк чишелеп китмәдем, әйттем мин боларга:

— Колхозга алу турында сүз булуы мөмкин түгел, — дидем. — Ул турыда авызыгызны да ачмагыз. Бер чыгарып, бер кертеп йөрергә колхоз ул сезгә үзгынчылар йорты түгел. Ну, ярар, терлекләрегезне, хайваннар хакын хаклап, көтүгә йөртә башларга рөхсәт итәм. Ләкин бер шарт белән: колхозга бик шәп итеп тегермән салып бирәсез!

Югыйсә, авыл тулы балта остасы, ә авылда тегермән салучысы юк. «Без аны сала белмибез», — дигән булып, бераү дә бу эшкә алынырга теләми. Ә халык интегә. Ярты капчык бодае өчен дә я арба тартып, я ат җигеп, тегермәнгә күрше авылларга йөрергә мәҗбүр. Колхозга да бик кыен иде тегермәнсез. Күпме фураж гына тартырга кирәк ел әйләнәсендә? Аннары килеп, башка авыл тегермәне — башка авыл тегермәне инде ул. Аларда тәртип катгый куелган: үз авылыннан килгән кешеләрнең ашлыгын тартып бетермичә торып, синекен кәүшәгә салдырмый алар. Була шундый вакытлар, бер капчык он тартыр өчен кайбер кешеләр тегермәнгә өчәр көн, берәр атна рәттән барып йөрергә мәҗбүр була. Әнә шул нәрсә минем күңелне бик нык тырный иде. Шулай булмый хәле юк, чөнки синең иң кирәкле эштә эшли торган колхозчың, сиңа иң кирәк чагында гына тегермәнгә китеп бара да ике кулсыз итә. Озын сүзнең кыскасы шул: яңа уңыш өлгергәнче ничек итеп булса да әйбәт кенә бер электр тегермәне салып куярга кирәк иде кол-

хозга. Ә теге эшсез ята торган дүрт «дизертир» тотынса, бу эшне җиренә җиткереп чыгачакларына шигем юк. Тегермән генә түгел, тегермәннән болайракларын салган кешеләр иде алар.

Шулай да зур эш иде бу, җаваплы эш иде. Алар өчен дә, колхоз өчен дә. Шуна мин, риза булырлармы икән дип, шикләнеп тора идем. Күңелем дөрес сизенгән икән. Бер дә алай капланып төшмәде болар минем тәкъдимгә. Үз дәрәҗәләрен белә, каһәрләр. Шулай булуы гаҗәп тә түгел: минем ише генә председательләрне аз күргәнмени алар? Аннары, әгәр инде эш зурга китеп, колхоздан чыгарылган килеш калганда да әллә ни куркасы юк бит ул **алтын кулларга**. Тота да семьясын икенче бер колхозга алып китеп, шунда урнаша. Гариза гына бирсеннәр, аларны теләсә кайсы колхозга член итеп алачаклар. Анысын да уйлыйм. Ләкин йомшаклык та күрсәтәсе килми. Йомшаклыгыңны сизеп алсалар, хәзер башкача сөйләшә башлаячак алар.

— Я, — мин әйтәм, тегеләр әле һаман бер-берсенә карашып дәшми торгач, — сузмагыз, әйтегез сүзегезне! Минем сездән башка да эшләрем бетәсе түгел, — дим.

Юк, килешергә ашыкмыйлар.

— Бераз гына киңәш-табыш итеп алыйк әле, — дип, идарә болдырына чыгып, байтак кына сөйләшеп керделәр. Аннары арада иң остасы, Мөсәгыйт исемлесе, әйтә миңа:

— Без риза, председател, тегермән салып бирергә, — ди. — Ну безнең ике шартыбыз булыр сиңа. Иң элек безгә ярдәмгә тагын өч кеше бирәсең. Дүртебез генә алына алмыйбыз бу эшкә. Булдыра алмаганнан или анда теләмәгәннән түгел. Ну дүртәү генә алына алмыйбыз. Ни өчен дисәң, тегермән биек, кимендә ике катлы йорт биеклегендә булырга тиеш. Ә синең безгә биреп торырга күтәрү краның юк. Тагын ким дигәндә дә өч кеше кирәк булыр безгә ярдәмгә. Монысы — бер. Икенчесе шул: без мондый зур эшне синең хезмәт көненә эшли алмыйбыз. Акчалата түләргә кирәк булачак безгә. Күп сорамыйбыз, җиде кеше эшлибез икән, борын башына берәр мең бирәсең, шуңа өстәп бер меңнән мәгәричкә саласың да бөтенесе буладыр шалкан бәясе—сигез мең тәңкә[1] акча. Ашау-эчү, сүз дә юк, колхоз чутыннан, — ди.

Райкин әйтмешли, менә шундый кроксворд китереп куйды болар минем алга. Әлбәттә, колхозның бүгенге мөмкинлегеннән чыгып карaганда, бер дә алай искитәрлек нәрсә юк монда. Тегермән хәтле тегермән (ә без аны зур итеп, вак он — крупчатка — да тарта торган итеп эшләтмәкче идек) салдыру өчен иске акча белән сигез мең сум хезмәт хакы гел пүчтәк ул. Хәзер шундый тегермән өчен яңа акча белән биш-алты мең түләргә кирәк булыр иде. Алты почмаклы гап-гади авыл өен салдырган өчен дә икешәр мең, ике мең ярымшар ала хәзер балта осталары. Анысына да ялындырыбрак кына килешәләр әле. Шулайга китте хәзер эшләр. Ләкин теге елларда тегермән салганга хәзерге акча белән сигез йөз сум түләү безнең колхоз өчен бик зур нәрсә иде.

Нишләргә хәзер теге шайтаннар белән? Булмый, дияргәме? Уйладым-уйладым да:

— Менә болай итәбез, егетләр, — дидем мин боларга. — Мин сезгә ярдәмгә өч кенә түгел, тагын биш кеше бирәм. Ашау колхоз исәбеннән булыр. Буравын шул тугыз кеше бурыйсыз. Ә мүккә күтәрүен бөтен авыл ир-атларын җыйнап, өмә ясап күтәрербез.

Юк, ашыкмый тегеләр «була» диярго.

— Ә хезмәт хакына акча кая? — диләр барысы да бер авыздан.

---

[1] Сүз иске акча турында бара.— Автор.

— Анысы инде, егетләр, колхоз баегач булыр, — мин әйтәм. — Хәзер хезмәт көненә генә эшләп торырга туры килә.

Өч көн йөрде тегеләр риза булмыйча.

**УНИКЕНЧЕ ДӘФТӘР**

Минем дә бирешергә исәп юк. Терлекләрен көтүгә чыгартмыйм. Болынга арканларга да рөхсәт итмим. Урманга алып барып, үзләре көтәргә мәҗбүр терлекләрен...

Күрәсең, өйләрендә семьялары тынгылык бирмәгәндер, түзмәде болар. Дүртенче көнне иртүк үзләре минем янга идарәгә килделәр дә:

— Без риза хезмәт көненә эшләргә. Ул тегермән бөтен авыл халкы өчен дип төзелә бит. Акчасы булмаса да, савабы булыр. Шуңа дип кенә ризалашуыбыз бу, — диделәр. Шундук кул сугышып, шул ук көнне эшкә дә керештеләр.

Андый осталар алынганда эш бармыймы соң? Егерме ике көн эчендә менә дигән тегермәнле булдык без ул елны...

Шул ук вакытта тегеләрне колхоздан чыгарып торуның бүтән кәсепчеләр өчен дә гыйбрәте зур булды. Ул елны идарә рөхсәтеннән башка бер кеше дә кәсепкә чыгып китмәде. Ә тегеләр, янадан колхозга кабул ителеп, һәммәсе төзүчеләр бригадасына беркетелде. Берсе әле хәзер дә төзүчеләр бригадиры булып эшләп йөри. Өчесе инде пенсиядә...

Ул елны икмәк тә ару гына булды безнең. Алдан чәчеп калуның файдасы тиде: арышны Шәйхигә караганда центнер ярым чамасы, бодайны бер дә җиде центнер артыграк алдык. Ләкин мин аңа ул елны да, «я, ничек, «Трактор» белән бүтән тартышмыйсыңмы инде» дип әйтә алмадым. Әйтергә ярамый иде. Чөнки мин ул елны районга мәгълүмат биргән чакта уртача уңышны нәкъ Шәйхинеке хәтле генә итеп күрсәтеп, артыгы хакында артык шауламаска булдым. Бу хакта тик завхоз белән хисапчы гына белә иде. Әйтергә оныткансын, теге эчкече завхозны эшеннән чыгарып, аның урынына белеме әллә ни булмаса да, эчмәсә эчми торган кеше булыр дип, яшь кенә бер тол хатынны куйган идем. «Куйган идем» дигәндә аптырамагыз. Андый эшне формаль яктан идарә утырышында хәл итсәләр дә, фактически соңгы сүз председательнеке була. Мин моның әллә ни гаебе дә юктыр дип уйлыйм. Әнә, дәүләт башына яңа премьер-министрлар килгәч, яңа кабинет төзеп, кабинетларына үзләре мәгъкуль күргән булдыклы кешеләрне җыялар һәм аларга беркем дә бер сүз әйтми. Колхоз председателе шулай ук үз колхозының премьер-министры бит инде ул. Шулай булгач, монда бер дә алай шаккатарлык нәрсә юктыр дип саныйм. Ә менә күпме уңыш алганны дөрес күрсәтмәү мәсьәләсенә килгәндә, мин ул чакта әйбәт эшләгәнмен дип әйтә алмыйм. Шул ук вакытта әллә ни зур җинаять дип тә санамыйм мин аны. Дәүләткә икмәк тапшыру планы үтәлгән. Хәтта арттырып, йөз дә тугыз процент итеп үтәлгән иде. Шуннан артканын үзебезгә калдырсак та ярый торгандыр дип уйлаган идем. Заводларда, әнә, планнарын йөз дә тугыз түгел, йөз бөтен уннан бер процент итеп үтәсәләр дә, мактап газеталарга язып чыгалар, радиодан сөйлиләр. Директорыннан башлап җыештыручысына тикле ишеп премиясен ала...

Премия дигәннән искә төште: ул чакта без колхозда премия бирелергә мөмкин булыр дип күз алдыбызга да китерә алмый идек. Ә хәзер?.. Бер уйласаң, әллә ни гомер дә узмаган. Нибары ун-унбиш ел. Крестьян тормышы өчен ун-унбиш ел бик аз бит ул. Ничә йөз еллар буена җир сөреп, иген игеп килгән бит безнең бабайлар. Ләкин эшләре әллә ни алга китә алмаган. Гел шул сука да тырма, китмән дә кө-

рәк белән эш иткәннәр. Ә соңгы ун-унбиш ел эчендә ничек үзгәрде колхозлар? Әле кайчан гына авыл белән шәһәр арасында аерма бетәргә тиеш, шәһәр уңайлыклары авылда да булырга тиеш, дип сөйләгән кешеләрне тилегә үк санамасак та, акылга бик үк тулы түгел, ахрысы, бу дип, эчтән генә көлә торган идек. Ә бүген кара әнә. Авыл агаеның газы — өендә. Су — капка төбендә яки торба белән өенә үк кертелгән. Телевизорын карап, бөтен дөнья хәлләрен шәһәр халкы белән бергә үк күреп-белеп бара. Керен машина белән юа. Ишегалдында — мунчасы. Аны да утын белән түгел, күбесе газ белән генә яга хәзер. Ни өчен дигәндә, бездә хәзер газны баллонлап ташыйсы түгел — торба буйлап туп-туры өйгә килә. Колхозчының хезмәт хакы шәһәр эшчесенекеннән һич тә ким түгел. Хәер, анысын бер әйтеп киттем бугай инде. Бүгенгесе көндә безнең колхозга караган өч авылда дүрт йөз житмеш алты хуҗалык исәпләнә. Шуларның илле икесенең үз «Жигули»ы бар. Ягъни тугыз йортның берсе — машиналы. Әле тагын илле дүрт «Жигули» алырлык акчалары бар кассада. Кайсы чират килеп җитмәгәннән, кайсы үзләре теләмәгәннән генә алмыйча торалар. Менә кая китте авыл халкының эшләре соңгы ун-унбиш ел арасында! Я, кем әйтә ала хәзер крестьян тормышы белән эшче тормышы арасында сизелерлек аерма бар дип?.. Хәер, аерма барын бар. Әйтик, хезмәт хакы эшченекеннән һич тә ким булмау өстенә, колхозчының егерме биш сотый бәрәңге бакчасы, сыеры, сарыклары, кош-корты бар. Иренмәгәне үзенә кирәк булган кадәр җиләк-җимеш үстерә. Ә өй каршында алма бакчасы булмаган хуҗалык гел юк бездә. Авыл советы аша махсус карар чыгартып, мәҗбүр итеп эшләттек аларын.

Мактана дип әйтсәгез әйтерсез, бакча, агач саятыннан сүз кузгалгач, тагын бер нәрсәне искәртеп китми кала алмыйм. Шәһәр җирендә парк дигән нәрсә элек-электән булган. Уйладым-уйладым да, туктале, мин әйтәм, нигә ул тик шәһәрдә генә булырга тиеш. Нигә авылда да ясап карамаска шуны? Авыл советы депутатлары, идарә члennары һәм партоешма белән бергәләп киңәштек тә, без дә үзебезнең колхозда парк ясарга булдык. Чәчүлек җир дә әрәм итәсе булмады. Авыл читендә чокыр-чакырлы, ни юньле үлән үсми, ни бүтән файдалы бирәр эшкә ярамый торган дүрт гектарлап урын бар иде. Шуны бульдозерлар белән кумдерәсен кумдердек, тигезлисен тигезләттек тә, алтмыш сигезенче елның Октябрь бәйрәме көннәрендә бөтен колхоз белән өмә ясап, агач утырттык. Үзебезнең якларда үсә торганнарын: юкә, каен, имән, өрәңге һәм чыршы. Чыршыны сигез рәт итеп паркның читенә утыртып чыктык. Ә бүтән агачларны һәркайсын аерым аллеялап. Тизрәк күзгә күренсен дип, шактый зурларны, өчәр-дүртәр метр биеклегендәгеләрне утырттык. Хутланып китә алырлар микән дип шикләнебрәк тә йөргән идем. Киттеләр. Кайберләрен генә алмаштырып утыртырга туры килде. Хәйран үсеп, тәмам урманга әйләнеп киләләр инде. Үссеннәр әйдә. Без китәрбез. Ә менә без утырткан шул агачлар тагын бик күп еллар яшәп, тирә-якка матурлык биреп, балаларыбызга, оныкларыбызга бездән калган җанлы һәйкәл булып торыр. Ә бу инде кечкенә нәрсә түгел!..

Премиядән башланган сүз әнә кайларга алып кереп китте. Нишләтсәң аны? Күңелдәгеп әйтмичә ничек үтеп китәсең? Әйе, ул елларда премия турында уйлаган да юк инде, шелтә бирмәсәләр бик әйбәт дип, шунысына да куанып йөри идек. Ә менә хәзер исә премия алу түгел, премия алмыйча калу гаҗәпкә әйләнеп бара. Сыер савучы йөкләмәсен арттырып үти икән, ана — премия. Тракторчы нормасын арттырган булса — премия. Комбайнчыга — шулай ук премия. Аерым колхозчыларга гына түгел, колхозларның үзләренә дә бирелә бит ул хәзер. Әле менә шушы араларда гына районнан шалтыратып, Мәскәүгә җибәрү өчен документлар әзерләп китерергә куштылар. Ит җитештерү бу-

енча безнең колхоз республикада беренче урынга чыккан икән дә шуңа аны РСФСР Министрлар Советы премиясенә тәкъдим итәргә булганнар. Өченче ел бер премия алган идек инде. Анысын үзебезнең Министрлар Советы бирде. Сөрү җирләренең һәр йөз гектарыннан уртача егерме бер мең сум табыш алуга ирешкән өчен. Премиясе — ике мең сум иде. Министерствога барып, безнең акча болай да житәрлек, сез ул премияне акчалата бирмәгез, машина кирәк безгә дип, бер йөк машинасы юллап кайттым.

Безнең өйнең зал идәненә җәелгән келәм дә сатып алган әйбер түгел. Премия итеп бирелгән әйбер ул. Бодайдан югары уңыш алган өчен... Бүләктән киткәч, анысын да әйтим инде: миңа хәтта «Волга» да бүләк иттеләр. Колхоз машинасы иде ул. Әле гел яңа диярлек, нибары егерме өч мең километр җир үткән иде. Миңа илле яшь тулган елны колхозчылар шул машинаны миңа бүләк итеп бирделәр. Зурлап, гомуми җыелыш җыеп, җыелыш карары нигезендә бирделәр. Кирәкми миңа мондый зур бүләк дип, мин бүләк өчен эшләмәдем, иптәшләр, дип тә караган идем. Ләкин авыз да ачтырмадылар. «Син әйткәндә без каршы килмибез бит. Син дә безнең теләккә каршы килмә! Сиңа ул машина бик тиеш!» — дип, мәҗбүри бирделәр. Мин үземне алай юккабарга балавыз сыга торган артык нечкә күңелле кеше дип әйтмәс идем. Егет булып кына житкәннән бирле тик ике генә тапкыр елаганымны хәтерлим мин.

Берсе житмеш беренче елда председательлектән алып, партиядән чыгарырга иткән чакта булды.

Икенчесе, әлеге шул миңа «Волга» бүләк иткән җыелышта.

Беренчесендә дөньяда гаделсезлек өстен чыкканга көенеп елаган идем.

Икенчесендә эшләгән эшемнең халык тарафыннан шулай ихтирам ителүенә сөенеп еладым. Сиңа машина тикле машина бүләк иткәннәр икән, димәк, сиңа ышаналар, сине үз итәләр, синең тырышлыгыңны күрәләр дигән сүз бит ул. Ә халык хөрмәтен, халык рәхмәтен казанудан да зуррак тагын нәрсә бар бу дөньяда?..

Менә шулайга әйләнде эшләре Булат абзагызның. Ләкин, кабатлап әйтәм, бу хәзер шулай. Ә аңарчы, ай-һай, күп чиләнергә туры килде аңа!

...Теге елны планнан артык икмәкне яшереп калдырганны тәки сизделәр бит, әй. Өч кешегә мәгълүм булган серне беркайчан да саклап калып булмавы хакында ишеткәнем бар иде. Шуны искәртеп, завхозны да, хисапчыны да кисәтеп тә куйган идем. «Шту син, прсидәтел, шту син! Курыкма, бездән сүз чыкмас!» — дип икесе дә беравыздан сүз дә биргән булганнар иде. Ләкин, атна-ун көн дә узмады, мине фаш иттеләр. Алдан әйтеп-нитеп тормыйча гына районнан комиссия килеп төште дә, бар булган икмәкне үлчәтеп, биш йөз центнердан артык икмәгебезне таптылар. Артык дигәч тә, чыннан да, артык булган икән дип уйларга кирәкми. Берничә йөз баш савым сыеры, меңләгән сарыгы, йөзгә якын аты булган хуҗалыкта артык икмәк була димени? Колхоз малларына фураж итеп ашатырбыз дип тора идем мин аны. Нәтиҗәсе барып чыкмады, «артык» икмәгебезне алып Шәйхигә бирделәр. Чөнки ул, планын арттырып үтәр өчен, фуражга тиешле ашлыгын да дәүләткә тапшырып бетергән булып чыкты. Шунысы кызык: ул чакта, икмәген яшереп калдырган дип, бюрога чакыртып, миңа каты шелтә бирделәр, ә Шәйхине, планын арттырып, йөз дә унбер процент итеп үтәде дип, район газетасында мактап язып чыктылар. Ул, хәйләкәр төлке, моның барысын да алдан уйлап эшләгән икән.

— Кара көздән фуражсыз калдырамы соң дәүләт, ярдәм итәсен белдем мин аның, — дип соңыннан үзе әйтте. — Менә

шулай була ул артык акыллы булырга тырышсаң — дип миннән көлеп тә йөрде. Аннары шунысы да мәгълүм булды: безнең «артык» икмәк булуын да районга шул ук Шәйхи җиткергән иде. Ә аңа безнең завхоз «тишкән» булган. Әйтеп киттем бугай, тол хатын иде ул. Ачыктан-ачык йөрмәсә дә, җае чыкканда ир-атны, бигрәк тә начальствоны, алай читкә какмый. Инициативаны хәтта үзе күрсәтә торган иде. Узган эш, бер тапкыр минем дә уразаны ычкындыртты ул шайтан кавеменнән яралган җан. Хәйран чибәр нәрсә иде. Гел үбешеп-сөешеп торыр өчен генә яралган шикелле юеш-юка иреннәр. Дугаланып торган нечкә кыйгач каш. Озын керфекле зәп-зәңгәр күзләр. Ап-ак нәфис муен. Һәрчак елмаеп, ир-ат күңелен җилкендереп тора торган магнитлы-нурлы йөз. Тыгыз булып кабарып торган күкрәкләр. Шөпшәнеке шикелле нечкә, сыгылмалы сылу бил. Ә аякларының ни кадәр матур, ни кадәр төгәл итеп яратылганын аңлатыр өчен хәтта сүз дә таба алмыйм. Озын сүзнең кыскасы шул: килмәгән җире юк иде аның. Ул урамнан үтеп барган чагында аның артыннан авыз ачып, тел шартлатып карап калмаган ир-ат, белмим, булды микән...

Әнә шул чибәр нәрсә бер дә бер көнне: «Булат абый, бер тавыгым йомыркасын кешегә сала башлаган. Һич кенә дә биздереп булмый. Әйдәле, шуны гына суеп бир әле, зинһар», — дип, өйләренә алып керде.

Җир йөзендә шушы хатын-кыз кавеменнән дә хәйләкәррәк зат юктыр, билләһи. Галия исемле иде ул. Хуш, шуннан нишләде дип уйлыйсыз инде Галия апагыз?

«Әйдәле, менә монда ябып куйганыем мин аны», — дип келәтенә алып керде бу мине. Ә келәттә өстәл. Өстәл өстенә менә диган итеп табын әзерләнгән. Бер пешкән тавык белән бер «савыты» да шунда. Бер җамыяк бал. Кош теле. Мин, юләр, әле һаман берни аңышмыйм.

— Кунаклар көтә идеңме әллә, Галия, ник шул тикле әзерләндең? — дип торган булам. — Кая, суясы тавыгыңны тизрәк суйыйк та, минем кырга, тракторчылар янына барасым бар, дим. Чынлап та шунда барасым бар. Ә Галия апагыз шундый ягымлы, шундый матур, шундый мәгънәле итеп елмайган да, мәк чәчәге шикелле кызарып, тик басып тора. — Ни булды сиңа, Галия? — дим, аның нигә шулай кинәт сүзсез-ягымлы булып калуына гаҗәпләнеп. — Нигә болай аптырап өнсезләнеп калдың?

Шуннан әйтә бу миңа:

— Менә шушы тавыкны «суярга» дәштем мин сине, Булат, — ди, өстәлдәге әзер тавык итенә ымлап. — Әйдәле, утырыйк әле табын янына. Киләсе бер кемем дә юк. Икебезгә дип әзерләнгән табын бу, — ди. Шулай диде дә, мин аны-моны абайларга өлгергәнче, башын иңемә салып, сулкылдап елап та җибәрде. Ә үзе сулышын еш-еш ала. Үзе шул арада: — Минем бүтән бер кешем дә юк бит. Ялгыз башыма бигрәкләр чиген, Булат. Шуңа менә сиңа дәштем, — дип, йомшак кына итеп колагыма пышылдый. Сулышы шундый кайнар, шундый кайнар, мин сиңайтим, эчендә җаны булган ир-атның теләсә кайсын хисләндерә, теләсә кайсын исертә, теләсә кайсының дөньясын онытыра торган илаһи сулыш. Аның ул сулышына, аның тәненең кайнарлыгына битараф калу — җинаять булыр иде...

Соңыннан, инде эш узгач: «Кеше түгел син, Булат! Ахмак син, Булат. Хыянәтче син, Булат! Хатын-кызның сиңа күзе төшкән дип, шулай юләрләнергә ярамый иде сиңа, Булат!» — дип үземне-үзем эт итеп сүгеп йөрдем. Чөнки минем бу гөнаһымны бөтен авыл халкы, бөтен дөнья халкы белә торгандыр шикелле иде. Айсылу апагыз өйгә кайтып кергәнне дә көтеп тормас, капка төбенә үк чыгып каршы алыр да: «Их, син, адәм актыгы! Шулмыни синең мине яратуың? Кая синең намусың? Ике бала атасы, ир уртасы кеше бит инде син! Шулай итеп

мине дә, үзеңне дә адәм хурлыгына калдырып йөриләрмени? Уф, чыдый алмыйм бу хурлыкка, башкайларымны юк итәм!» — дип такмаклый-такмаклый көлле пумала белән тукмар төсле тоелган иде. Әгәр бу юлы тавышсыз-тынсыз гына үтеп китсә, андый эшкә гомеремдә дә бүтән бәйләнмәскә дип антлар итеп куйдым. Әмма аны бозмыйча саклау җиңел булды дип әйтә алмыйм. Дөнья булгач, әллә нинди көтелмәгән хәлләр килеп чыга икән ул. Әле менә күптән дә түгел, җитмеш алтынчы елда гына...

Язгы чәчүне тәмамлап, колхозның эшләре бераз җиңеләйгәч, көньякка санаторийга барган идем. Ашказаны бик үк шәптән түгел минем. Шуны ремонтлатырга. Инде дөнья мәшәкатьләреннән котылдым, егерме дүрт тәүлек буена рәхәтләнеп, үзем теләгәнчә яшим әле бер тынычлап дип, ашыкмыйча гына, режим саклап, врач кушканча гына яши башладым тегендә. Тиешле процедураның берсен дә калдырмыйм. Коллектив экскурсияләренә дә барам. Бер грамм салмыйм. Хатын-кызга күтәрелеп тә карамыйм. Буш вакыт булганда китап укыйм. Яки рәхәтләнеп йоклыйм. Югыйсә, безнең председатель халкына бүтән чакта алай бик эләкми ул йокы дигән нәрсә. Кичтән уникесез урынга ята алмыйсың. Дөнья хәлләреннән бөтенләй үк бихәбәр булып калмас өчен, газета-журналларын да, китапларын да укырга, телевизорын да караштыргалап барырга туры килә. Халык бик укымышлы хәзер. Чак кына йомшак ягыңны сизеп алдымы, шундук сиңа бүтәнчәрәк карый башлый. Аның белән аяк терәп сөйләшер өчен, заман сулышын тоеп, заман белән бер аяктан атлап барырга син просто мәҗбүр. Югыйсә, артка каласың. Югыйсә, сине таптап китәчәкләр. Бүгенге көн председателе булып эшләү читтән карап торганда гына ансат, читтән караганда гына рәхәт булып күренә ул. Утырып йөрергә җиңел машинаң булу, акыллы киңәш биреп, юл күрсәтеп бара торган партком секретаре булу, урынбасарың булу, хуҗалыкның төрле тармакларында эш алып бару өчен югары белемле кадрларың булу, сүз дә юк, бик әйбәт һәм бик мөһим нәрсәләр. Аларның председательгә ярдәме әйтеп бетергесез зур. Алардан башка бүгенге көндә хуҗалыкны алып барып та булмас иде. Ләкин председательнең эше белгечләргә акыл биреп, алар эшләгәнне күзәтеп, тикшереп тору белән генә чикләнми шул. Алар белән җитәкчелек итәр өчен, ул тармактагы хәлләрне иң элек председатель үзе бик яхшы белеп торырга тиеш. Ә белер өчен укырга, өйрәнергә кирәк. Юк, һич тә җиңел түгел бүгенге председательнең эше. Ул бер үзе, ә аның ни эшләгәнен мең кеше күреп тора. Чак кына шунда ялгышлык җибәр — сиңа инде ышаныч какшый. Үзеңә үк әйтмәсәләр дә, мыек астыннан гына елмаеп йөриләр. Җае чыккач шуны искәртеп, чеметеп тә куйгалыйлар. Ә кайберләре хәтта синең өстән я гәҗиткә яки югары органнарга язып җибәрә. Моның өчен аларны гаепләп тә булмый. Рас сиңа ышанып шундый зур эшне тапшырганнар икән, рәхим итеп, син аны тиешенчә алып бар.

Безнең бу заман шундый заман, сиңа бер көн эчендә генә дә әллә кемнәр белән очрашырга, әллә кемнәр белән бәйләнешкә керергә туры килә. Артистлар ай саен диярлек килми калмый. Алар белән сөйләшеп утырмыйча булмый — үпкәлиләр. Ә сөйләшә башласаң, алар үзләре уйнаган рольләр турында гәп кузгаталар. Минем фәлән спектакльдә уйнаганны күрдеңме, фәлән җырны җырлаганны тыңлаганың бармы дип төпчен башлыйлар. Андый нәрсәләргә вакыт бик калмый шул,

## УНӨЧЕНЧЕ ДӘФТӘР

эш бик күп, дип әйтсәң, әй, абзыкаем, алай ярамый, заманнан артта калма, син җитәкче кеше бит, дип вәгазь укый башлыйлар. Менә шуңа күрә, алар алдында бөтенләй үк томана булып утырмас өчен, яңа

спектакльләрне дә карап, яңа җырларны да тыңлаштыргалап барырга туры килә.

Аннары хәзер язучылары да авылларга еш йөри башлады. Алары инде махсус рәвештә атап, синең белән сөйләшергә, колхоз хәлләрен өйрәнеп кайтырга дип килә. Һәм, әлбәттә, әдәбият, әдәби әсәрләр хакында да сүз булмый калмый. Алар синең әдәбияттан башка да мең төрле эшең булуы белән исәпләшеп тормый, минем фәлән исемле китап чыккан иде, аны укыдыңмы, дип аяк терәп сорый. Укыганың булмаса: «Ну, иптәш председатель, алай ярамый бит инде житәкче кешегә! Син дә укымагач, колхозчыларың ничек укысын инде?! Син аларга үрнәк күрсәтергә тиешле кеше ләбаса. Укырга кирәк, укырга! Һич югы, минем фәлән китапны! Соңгы елларда безнең язучылар язган әйберләр арасында иң әйбәте булып санала ул», — дип, үпкә катыш киңәш тә биреп китәләр. Әнә шуңа күрә, яңа чыккан китапларны да караштыргалап барырга туры килә. Ә иртән, сәгать биштән дә соңга калмыйча, син инде аяк өстендә булырга тиеш. Безнең хәзерге беренче секретарь Азат Миңнуллович алай озак йоклый торган кеше түгел. Безгә дә җәелергә ирек бирми. Көн аралаш диярлек иртәнге алтыда ук үзе шалтыратып, хәлне белеп торырга ярата. Ул шалтыратканда эш урынында булмый кара... Хәер, хикмәт анда гына да түгел. Авыл халкы үзе үк шуннан ары йокларга ирек бирми. Әле таң яралган гына була, ә идарәдә сине инде төрлесе-төрле йомыш белән килгән берничә кеше көтеп тора анда... Артистлардан, язучылардан тыш, көтмәгәндә генә килеп чыга торган журналист халкы да бар бит әле. Колхоз алдынгылар рәтендә булгач, соңгы елларда безгә аеруча еш килә башлады алар. Шуңа киләләр, чөнки безгә тимер юл якын. Ә тимер юл станциясеннән колхоз үзәгенә, асфальт ук булмаса да, чуер таш түшәп салынган олы юл килә. Үзебез салган юл. Колхозың турында, үзең турында, колхозчыларың турында газета-журналларда мактап язганны уку күңелле хәл, әлбәттә. Ә безнең хакта соңгы вакытларда гел мактап кына диярлек язалар. Чөнки дәүләткә сөт сату буенча да, иген үстерү буенча да, ит сату буенча да республика колхозлары арасында алдынгыларның берсе — безнең колхоз. Без үстергән нәселле таналар еш кына Мәскәүгә Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә җибәреләә һәм я диплом, яки бүләк бирелә аларга. Шуңа күрә аларның бәясе дә гади таналар белән чагыштырганда бер ярым-ике тапкыр кыйммәтрәк. Алар шуңа лаек. Чөнки алар сыер булгач та сөтне, гадәти сыерларга караганда, күп артык бирә. Моның шулай икәнен колхоз председательләре бик әйбәт белә. Шуңа безнең таналарны алырга алдан ук гариза биреп куялар. Ә соңгы биш-алты ел эчендә агрономыбыз Фәгыйть Фәтхуллинның тырышлыгы белән югары сортлы чәчүлек бодай үстереп тә сата башладык. Елына уртача сигезәр йөз мең сум саф табыш алып килә икән колхоз, ул акча күктән төшми, әнә шул нәселле таналар, сортлы чәчүлек бодайлар үстереп сатудан килә инде ул. Ә аларны үстерү алай җиңел генә эшләнә торган эш түгел. Артыңны кояш кыздыра башлаганчы йоклап ятсаң ирешеп булмый аңа. Иртәнге дүрттән торып аягыңны киенсәң дә таманга гына килә әле...

Ә журналистлар район газетасыннан колхозларда эш барышы турындагы сводканы карый да, безнең колхоз өстәге урыннарның берсендә торганын күреп, әһә, менә кая барырга кирәк икән, дип безгә килә. Килә дә, иртәгә яки берсекөнгә материал газетада басылып чыгарга тиеш, дип я бухгалтериядән, яки синең үзеңнән сораштырып, язгы чәчүгә әзерлек чоры булса — чәчүгә әзерлек турында, урак өсте булса — урып-җыюның барышы турында мәгълүматлар ала, бер-ике алдынгы кешенең фамилиясен блокнотына теркәп куя да, кешеләрнең үзләрен күреп-сөйләшеп тә тормыйча, арт ягына ут капкандай ашыгып, китеп тә бара. Вәгъдәләрендә тора үзләре. Килеп китүләренә ике-

өч көн дигәндә, чыннан да, газетада я хәйран зур гына мәкалә, янсә очерк бастырып чыгаралар. Ләкин шунысы хикмәт: анда алар үзләре гомер күргәне булмаган сыер савучы яки механизатор турында сөйләп кенә калмыйлар, бәлки ул сыер савучының яки механизаторның «үз авызыннан» да әллә ни кадәрле сүз сөйләтәләр! Аларның язмасында саннар да, канатлы сүзләр дә, колхозның һәм колхозчыларның экономик хәлен күрсәтә торган фактлар да җитәрлек була. Тик җанлы кешеләр генә булмый анда. Ә бит журналистның төп бурычы, минемчә, нәкъ менә шуларны күрсәтеп бирү булырга тиеш. Аның язган әйберсе укучыларны ышандырырлык, укучыларны дулкынландырырлык, хисләндерерлек булырга тиеш дип уйлыйм мин. Ә алай итеп язар өчен журналист кеше үзе күтәреп чыгарга тиешле мәсьәләне җентекләп өйрәнергә, үзе язарга алынган кешеләрнең холыкларын һәм аларның эшләрен биш бармагы шикелле белергә тиеш. Кызганычка каршы, безнең журналистлар язган мәкаләләр дә, очерклар да, репортажлар да чамасыз озынга сузылган гап-гади информациядән әллә ни уза алмый. Һәрхәлдә, авыл хуҗалыгы мәсьәләләре хакында яза торган журналистларыбыз арасында бүгенге көндә мин русларның шул темага яза торган Юрий Черниченко, мәрхүм Георгий Радов кебек журналистлары белән рәттән куярлык кешеләрне атый алмыйм. Безнең журналистлар мәсьәләнең асылына үтеп керү турында артык баш ватып тормый, булган фактны әйтеп-теркәп чыгу белән генә чикләнә. Мәсәлән, моннан җиде-сигез ел элек без колхозда биш йөз тонна сыйдырышлы ашлама склады салган идек. Кырда, тау өстендәге бик әйбәт бер тигез урында эшләдек без аны. Ашлама җиргә я язын, яки көзен кертелергә тиеш. Ничә ел сынап килгәнем бар, трактор белән яки махсус машина белән сиптерүгә караганда, ашламаны җиргә самолеттан сиптерү әйбәтрәк. Мин монда чәчелгән игенне тукландыру турында сүз алып барам. Чөнки бу эшне җир юеш вакытта, ашлама җиргә, күп дигәндә, ике, өч көн эчендә сеңеп бетәрлек чакта эшләп калырга кирәк. Җир коры чакта аңа ашлама сибү — ашламаны җилгә очыру ул. Ә җир юеш вакытта җиргә машина бөтенләй керә үк алмый, тракторны кертергә була булуын, ләкин ул чакта аның зыяны файдасыннан артып китә: трактор көпчәкләре чәчелгән игеннең егерме процентын диярлек таптап бетерә.

Ләкин бит җир юеш вакытта самолет та әллә кая бара алмый диярсез инде сез. Дөрес. Менә шуңа күрә дә теге склад янына мин үзебезчә әйткәндә, самолет килеп куна алырлык юл, русча әйтсәк, посадочная полоса ясаттым. Ә халык аны аэродром дип кенә атап йөртә. Безнең ул аэродромнан хәзер күрше колхозлар да файдалана. Шул хакта безнең журналистлар үзебезнең республика матбугатында гына түгел, хәтта үзәк газеталарда да язып чыктылар. Яңалык дип, мактап яздылар. Мактарлыгы да бар: хәзер безнең ашламаның бер граммы да югалмый, вакытында тиешле җиренә индерелеп килә. Ләкин шул ашлама склады белән шул аэродромның ничек төзелүен, аларны төзетер өчен күпме нерв бозарга, күпме сүз ишетергә туры килгәнен әлеге журналистларның хет берсе белә микән?

«Төзелде» яки «төзедек» дип әйтүе генә ансат ул. Башта идарә членнары да, район начальствосы да складны нигә япан кырга төзергә, нигә аны авыл янына, ашлык амбарлары белән рәттән төземәскә, ашламасы да кул астында булыр иде, дип җанга тиделәр. Ә авылның чокырда утыруы, язын-көзен авылдан кырга чыгып йөрүләре үзе бер бәлагә әверелүе хакында уйлап та карамыйлар. Чөнки шулай гадәтләнелгән, гомердән шулай килгән — нигә баш ватып, яңачарак, бүтәнчәрәк уйлап торырга?.. Анысына, ниһаять, тегеләрен дә, боларын да ышандырып, складны кырга төзегәч, аэродром мәсьәләсендә бәхәс китте. «Бердән, — диләр, — аны төзер өчен акча тотарга кирәк. Икен-

чедән, колхозның никадәр сөрү җире елына нибары биш-алты көн эшләячәк самолет өчен әрәм китәчәк. Өченчедән, әнә бүтән колхозлар аэродромсыз да яшәп киләләр бит әле, шулай булгач, нигә гел безгә генә андый зур мәшәкатьләр кузгатып йөрергә? Инде алай трактор белән сиптергәндә җир бик бозыла дисең икән, без аны кулдан, тубал белән дә чәчеп бирербез», — диләр..: Хәзер алар барысы да, җае чыкса да, җае чыкмаса да «безнең аэродром», «колхоз аэродромы» дип горурланып сөйлиләр. Узган ел авылның бер кешесенә кинәт кенә катлаулы операция ясарга кирәк булып, Казаннан санитар самолет чакыртырга туры килгәч һәм ул кеше нәкъ менә шул үзебездә аэродром булу аркасында гына үлемнән коткарып калынгач, аеруча үсеп китте аэродромның дәрәҗәсе. Ләкин бит аңарчы күпме чәч агартырга туры килде миңа!..

Ашлама димәктән, узган ел без үзебезнең кырларга ике йөз тоннага якын минераль ашлама керттек. Азмы бу, күпме бу? Безнең җирләрнең хаҗәтеннән чыгып караганда, күп түгел. Тагын йөз тонна булса да, бер дә артык булмас иде әле. Ә районның бүтән колхозлары белән чагыштырып караганда, бу — күп. Ни өчен? Чөнки ашламалар кирәк булганга караганда әлегә бик күпкә ким кайта. Мәсәлән, әлеге шул узган елны районның бер генә колхозына да утыз биш-кырык тоннадан артык ашлама эләкмәде. Район разнарядкасы буенча, безгә дә утыз биш тонна гына билгеләнгән иде ул. Ләкин мин аны, инде әйткәнемчә, ике йөз тоннага якын итеп кайтарттым һәм барысын да тиешле вакытында тиешле җиренә индерттем. Бер яктан караганда, дөрес, бик үк гаделлек белән эшләнгән эш түгел бу. Ни өчен дигәндә, күктән төшмәгән, үзебезнең район колхозларына дип кайтартылган ашлама исәбеннән алынган бит инде ул. Димәк, кайсыдыр колхозларга тиешле булганы да тулысы белән эләкмәгән. Әйтәм бит, бу яктан килеп исәп иткәндә мәсьәлә шактый четреклегә әйләнеп китә. Ә менә шул нәрсәне икенче ягыннан чыгып караганда, алай артык искитәрлек урын да калмый. Әйтик, ничек килеп эләккән миңа ул ике йөз тонна ашлама да, нигә тиешле колхозларына барып ирешә алмый калган? Хикмәт шунда, теге колхозлар үзләренә тиешле ашламаларын вакытында килеп алмаган. Ә тимер юлчылар хәзер мәсьәләне катгый куя: станциягә килеп туктаганнан соң, вагон билгеле бер вакытта, әйтик, унике яки егерме дүрт сәгать эчендә бушатылган булырга тиеш. Бушатылмаса, товар кайсы оешмага килгән, шул оешмадан штраф алына. Дөрес эшләнә. Вагонны бит аны тик торсын өчен түгел, йөк ташу өчен, гел хәрәкәттә булсын өчен ясыйлар. Ә менә кайбер колхоз председательләре үзләренә атап кайтартылган вагоннарны бушатырга вакытында кеше дә, транспорт та җибәрми. Яки кешесе белән транспорты булса да, колхозга алып кайтырга юлы булмый. Ә мин станция начальнигы белән алдан ук сөйләшеп куйган: әгәр әнә шундый «яна» торган ашламалар була калганда, ул миңа хәбәр итә. Андый чакта мин инде эшне озакка сузмыйм. Чөнки мине язгы юл өзеге дә, көзге пычраклар да, кышкы бураннар да куркытмый. Станциядән авылга кадәр, асфальт ук булмаса да, юл бар дип әйттем инде. Аны салдыру шулай ук җиңел булмады. «Нигә ул кадәр тыпырчынырга? Моңарчы яшәдек бит әле. Моннан ары да яши торырбыз. Расхут чыгарып, көч түгеп мәшәкатьләнмик. Дәүләт төзеп бирер әле», — дип карышып маташучы «акыллы башлар» да байтак булды үз заманында...

Ахыры журналыбызның бишенче санында.

## Галимҗан Латыйп

### Апрель бирде безгә Ленинны

Мең сигез йөз җитмешенче елның
күкләрендә зәңгәр кош юлы.
Ал таңнарны бизәп йолдыз янды,
ә җир иде һаман борчулы.

Себер киткәннәрне этап белән
әйдәделәр ерак җирләргә.
Сәерерәк караш ташлады яз
богау кидерелгән ирләргә:

Кошлар кайта туган якларына,
оя корыр өчен яңадан;
аерылып туган җирләреннән,
болар кая китеп баралар?..

Чылдыр-чылдыр килә богау чыңы,
шундый авыр куллар, аяклар.
Юл буенда каторжаннар җыры,
атлы сакчы килә як-яктан.

Россиянең кырларында ул чак
агач сука,
агач тырмалар.
Елның-елы
еллар ябык килгән,
елның-елы иген уңмаган.

Кая барсаң нужа,
ач эт кебек,
чинап-чинап арттан ияргән.
Бер сискәнеп куйгандыр бу дөнья,
яңа аваз салган көйләрдән.

Якты күкрәү булып килде Ленин,
апрель белән акты кар суы.
Онтылмас җыр булып керде җанга
елгаларның тулып ташуы.

...Килә җырлар кошлар канатында,
кояш нурларына төренеп,
була язлар,
була шундый язлар,
төшләреңә синең керерлек.

Күге аяз,
ә кояшы биек
булгандыр бу язгы иртәнең.
Белде микән апрель бу минутта
җиргә кемне бүләк иткәнен?!

## Гәрәй Рәхим

### Кара әле, Тукай, Казаныңа

Шигырь бәйрәме көнне шагыйрьнең һәйкәленә карап.

Син дөньядан киткән көндәгедәй
Бүген тагын таллар бөредә...
Кара әле, Тукай, Казаныңа,
Ул бит сиңа яхшы күренә.

Синең күзләр күрмәде дә кебек
Яфракларның шытып чыкканын.
Рәхәтләнеп җырламый да калдың
Кушлавычның көмеш чыкларын.

Татарыңның авыр хәсрәтеннән
Син сызландың, сыкрап еладың.
Котырганда ләкин кара көчләр,
Син бер мескен булып тормадың.

Гел якага-яка алыштың син,
Рәхимсезлек белән сугыштың.
Шигъри күктә камчың уйнап торды,
Өзелсә дә соңгы сулышың...

...Син дөньядан киткән көндәгедәй
Бүген тагын таллар бөредә.
Кара әле, Тукай, Казаныңа,
Ул бит сиңа яхшы күренә.

Бу һәйкәлең үзең салган һәйкәл,
Меңнәрчә күз аңа төбәлгән.
Кара әле, Тукай, Казаныңа:
Синең җырлар белән бизәлгән.

## Кисәтү

Халыкара сугыш чукмарларына нәфрәт белән.

Бу таш белән беркемгә дә сукмадым мин —
Әмма кулга алдым.
Крематорийларны күрмәдем мин —
Әмма яндым.

Тол хатынның тузган чәче сыман
Ап-ак төтен ургый.
Бу — мин янам шулай,
Янам тузгый-тузгый.

Эзләмәгез янганнарның гәүдәләрен,
Алар юк ич җирдә.
Янганнарга табут та юк,
Юк кабер дә.

Ә шулай да матәм маршы уйнамагыз!
Янучылар моңа каршы.
Уйнагыз,
Иҗат итегез
Җирдә нәфрәт маршы!

Тол хатынның чал чәчедәй
Тузгый-тузгый янам.
Һәм ашыгып җирдән
Кулга зур таш алам...

Крематорийларны күрмәдем мин —
Әмма яндым.

...Бу таш белән беркемгә дә сукмадым мин —
Әмма кулга алдым.

## Кырда учак

Кыр уртасы.
Мин зур учак ягам.
Ялгыз кунам бүген бу кырда.
Шулай телим, шулай рәхәт миңа...
Сандугачмы сайрый якында?..
Әллә шунда моңлы авыл карты
Курай сызып үтеп барамы?..
Әй, җәйге төн!
Нигә шул кадәрле
Яратасың икән караны?!

Ә мин менә сине мыскыл итеп
Учак ягып куйдым түреңә.
Учак җылысы ул — җир җылысы!
Шул җылыны тоям үземдә.

Төн куерган саен йолдызларның
Арта гына бара яктысы.
Көрәшләрдә шулай калкып чыга
Кешеләрнең иң-иң яхшысы.

Ә мин бүген зур бер учак белән
Эретәмен төннең карасын.
Бит минем дә килә үз җиремдә
Җир йолдызы булып янасым.

Кыр уртасы.
Яна минем учак.
Ялгыз кунам бүген бу кырда.
Шулай телим, шулай рәхәт миңа...
Сандугачмы сайрый якында?..
Әллә шунда моңлы авыл карты
Курай сызып үтеп барамы?..
Әй, җәйге төн, тагын учак яктым
Эретергә синең караңны.

## Кечке шигырь

Көмештәй ак йокы килә миңа,
Көмеш кебек тынлык.
Тик алтындай кояш китә миннән,
Алтын кебек чынлык.

Иртәгәмә кереп җитмәгәнмен,
Бүгенемнән китәм.
Кичләр саен чаңын катырак сугып
Гомер үтә икән.

Әй, бүгенем минем, һаваң сулап
Яшәдем ич синдә.
Болай эзсез генә китмә әле,
Болай эзсез сүнмә.

Көмеш кебек йокы, кит әле син,
Кит, көмештәй тынлык.
Кил, алтындай чиста шигырем минем,
Кил, алтындай чынлык.

●

*Таныш түгел абзый белән сөйләшкәч.*

Нинди дөрес сүзләр сөйләде ул:
«Намус...
Иҗат...
Ипи...
Дәрәҗә...»
Олы сүзләр белән уйнады ул,
Кылды нинди олы хәрәмҗә!

Тарайтты ул Намус мәгънәсен дә,
Ипи мәгънәсен дә тарайтты.
Каралтты ул Иҗат дигән сүзне,
Дәрәҗәнең аслын каралтты.
Янәсе лә: Иҗат — Ипи өчен,
Намус — Дәрәҗәгә кирәкле...
Ләкин онытты ул Иҗат итеп
Намус белән тапкан Икмәкне.
Онытты ул бөек Дәрәҗәнең
Бары Намус белән килүен.
Шигърияттән сынык Икмәк капкач,
Җанның Дәрәҗәгә менүен.

## Кар ява

Карлар белән уйный җил генә.
Кар бөртеге оча, җилпенә.

Нәни бала кебек наян ул,
Төшеп килә әнә каян ул —
Бер тузансыз чиста һавадан,
Яңа туган кебек анадан.

Кар бөртеге көлә, талпына,
Кар бөртеге көләч, шат була.
Кар бөртеге бигрәк ак инде,
Кар бөртеге бигрәк пакь инде.

Җиргә төшеп җиткәч сак кына,
Тузан куна аңа чак кына.

## Мәхәббәтем турында җыр

Нинди җыр ул ишетелә таулардан,
Ишетелә җиргә әллә кайлардан.
Күңелләрне айкалдыра, кузгата,
Татлы уйлар, матур уйлар уйлата.
Бу җыр минем мәхәббәтем турында,
Минем керсез мәхәббәтем турында,
Минем назлы мәхәббәтем турында,
Минем бетмәс мәхәббәтем турында.

Нинди көй ул ишетелә күкләрдән,
Кошлар кебек очып чыга чикләрдән.
Күңелләрне ашкындыра, күтәрә,
Аны тыңлап таулар җырлар җибәрә.
Бу җыр минем мәхәббәтем турында,
Минем керсез мәхәббәтем турында,
Минем назлы мәхәббәтем турында,
Минем бетмәс мәхәббәтем турында.

Нинди жыр ул давыллардан көчлерәк,
Язгы дәрья суларыннан ишлерәк,
Ул көй бөек табигатькә дан жырлый,
Мәңгелеккә бара-бара ул чыңлый.
Бу жыр минем мәхәббәтем турында,
Минем керсез мәхәббәтем турында,
Минем назлы мәхәббәтем турында,
Минем бетмәс мәхәббәтем турында.

## Тагын

Үпкәләшүләрне онытып кайттым сиңа.
Ә син тагын
Үткәндәге ялгышуларымны
Искә алдың.
Мин бит инде сине ничә тапкыр
Гафу иткән идем.
Син дә мине кичерерсең диеп
Көткән идем...
...Бәхәсләрне онытып кайттым сиңа.
Ә син тагын, тагын
Узгандагы үкенүләремне
Искә алдың.

## Карама син көзгеләргә

Нигә инде чәчләреңне тарыйсың син
Басып шушы жансыз көзге каршысына?!
Нигә шулай моңлы итеп карыйсың син
Үз гәүдәңнең көзгедәге яртысына?!

Мәхәббәтең, зур сөюең бар шул синең.
Ә көзгедә уйсыз, хиссез шәүләң генә.
Әнә шуңа хәсрәтләнә синең йөзең,
Көзгедә бит бары яссы гәүдәң генә.

Ташла, иркәм, карама шул көзгеләргә,
Нигә кирәк бер ләззәтсез ул моңлану?!
Бас каршыма!
Карап минем күзләремә
Үз гәүдәңне күрерсең син шат һәм сылу!

Синдәге хис, ә миндәге бөек өмет
Жыела да шулай минем күзләремә,
Мәхәббәтем жылысында өретелеп
Синең жанлы гәүдәң булып әверелә.

## Кыр казы сыман

Узып киткән кыр казы сыман
Үтеп кенә киттең каршымнан...
Нишләдем соң мин карашыңнан?!

«Кайтам... Кайтам...— диеп,— яңадан...»
Кычкырмадың да бит, ичмасам,
Узып киткән кыр казы сыман.

## Кайгы

Бу кайгыны язарга җитми талантым,
Акмый кан, бөгелми уй — турыга каттым.
«Әнкәң үлә... булмый... терелми», — диделәр,
Әй, баттым ла, бигрәк зур кайгыга баттым.

Үзбәк мамыгыдай йомшак иде күңлем —
Имән кайрысына охшап кытыршыландым.
Кигән киемемдә бер коры җеп тә юк,
Ага күз суларым — тәмам чыландым.

Өннәрем төшкә әйләнде, төшләрем өнгә,
Исәбем тайпылды, суынды назларым.
Күзләрем эсседә көйделәр, боз сукты җәемне,
Су булып эреде кышым, туңды язларым.

«Әнкәең үлә... булмый... терелми», — диделәр...
Нинди зур хисемә ак кәфен яптым.
Әй, дуслар, әй, илем, әй, минем Ватаным,
Баттым шул, бигрәк тә зур кайгыга баттым.

## Рашат Низамиев

### Идел

Бабайларның моңын, рухын эзләп
Ослан тауларына менгән идем, —
Акчарлагы, ак җырлары белән
Килеп керде җанга кичке Идел.

Табигатьнең изрәп төшкән мәле.
Йоклый кошлар, сеңеп оясына...
Тып-тын гына шаулый бөек Идел!
Кайтавазы кагыла намусыма.

Җирдә әле дөрес яшәдекме,
Ни кылдык та илгә, ни майтардык?
Еллар күкрәгенә яңа бизәк
Өсти алдымы соң безнең барлык?

Шаулый Идел...
Дулкын арты дулкын
Нәкъ йөрәккә килә тәгәрәшеп.
Бик тирәннән, тарих төпкеленнән
Оран сала кемдер күккә дәшеп.

Ят байраклар җилфердәтеп илгә
Яулар килгән, килгән явыз каган.
Су белән кан бергә кушылса да,
Ике иман бергә кушылмаган!

Су өстендә тибри акчарлаклар —
Җавап бирче, әйтче, и мәңгелек:
Фида җаннар калкып чыккан мәллә
Шушы якты кошка әверелеп?

Үткәннәрнең телсез шаһитыдай
Карт манара ярга чыгып баскан.
Шаулый Идел —
Кара елларда да
Ак җырларын югалтмаган дастан...

## Бирче, дөнья!..

Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә...

Г. Тукай.

Әй, дөнья,
бирче миңа Тукай күзләрен!

Тукайдан соң
күпме йолдызлар атылган,
күпме тәхетләр ватылган —
егерменче гасыр һаман хәрәкәттә.

Җир һаман да
үз күчәре тирәсендә әйләнә:
көннәр — төнне,
төннәр көнне куып тора.
Иске проблемалар үлә,
яңалары чәчрәп туып тора.

Илләр бәхәсләшә,
тәгълиматлар, хисләр бәхәсләшә.
Хакыйкатьне,
гаделлекле яклап
планетада Намус дәшә!

Съездлар, парламентлар, конгресслар,
үз күчәрендә әйләнгән Җир кебек,
ике сүз тирәли әйләнә:
— Сугыш?
— Тынычлык!

Сабыйлар — Кояшка,
өлкәннәр бомбага сузылган заманда
миңа — күпне күрү,
күпне ишетү кирәк!
Кояш белән бомба арасына
метеордай
сүзем атылып керер
һәм аннары... йөрәк.

Әй, дөнья,
бирче миңа Тукай күзләрен!
Кыйтгалар өстендә
үткен хәнҗәр булып
ялтырасын кайнар сүзләрем!

## Кичке аваз

Кошлар яба сары томшыкларын,
Яфрак асты ышык һәм тыныч.
Ботакларда — алма авырлыгы...
Юктыр төсле хәвеф, куркыныч.

Авылымның аулак почмакларын
Әрем исе баса, моң баса.
Кычытканлы яшел тыкрыкларда
Иләһи бер тынлык урнаша.

Әллә каян шул чак тынлык аша
Ишетелә миңа бер аваз.
Актара да сала йөрәгемне
Күктән иңгән серле кайтаваз.

Кичке аваз чыңлый колагымда —
Өнди,
дәшә,
каулый,
чакыра!
Көрәшергә һәм яшәргә куша
Туар таңнар, бәхет хакына.

Җанга якын тавышыннан таныйм:
Ярсуы бар аның, бар назы...
Матурлыкка дәшә мине шулай
Туган җирем, күгем авазы!

●

Җир — автографлар китабы.
Галиҗәнаб Вакыт
Төрле төсләр белән уйган үз имзасын:
Зәңгәр кара белән —
диңгезләрен, елгасын...
Яшел кара белән — болын-урманнарны.
Кызыл кара белән — янар тауларны...

Табигать тудырган кешене.
Галиҗәнаб Кеше
Җир-китапка төшергән тәүге автографын —
ялангач тәпи эзләрен...
Беренче куркыныч янау белән
Баш мие күзәнәкләре
дәррәү хәрәкәткә килгән:
Кеше тау актарган,
бүрәнәне кискән, ярган, өйгән...
Йорт-куыш ясаган бер дигән!

Тора-бара Кеше
Зурдан кубып сырлаган үз имзасын:
ташлаган да мескен ызбасын —
Иҗат иткән якты шәһәрләр,
гөлбакчалар, тимер юллар,
Хәтта... атом бомбасын!

Яшәп булмый
Кемдә диеп, кемнең ни эше?
Җир-китапта соңгы автографың
нинди булыр, Кеше?!.

•

Бәрелде йөрәгем тауларга,
Сеңдерде ташларның ныклыгын.
Чыкларда чыланган яфрактан
Соң тамчы су эчтем йотлыгып.

Текәлде күзләрем кояшка,
Рухыма, тәнемә нур тулды.
Җандагы болытлар пәрдәсе
Әйтерсең мәңгегә ертылды.

Орынды күңелем сагышка,
Моң белән тулды һәр күзәнәк.
Җыр белән бизәрмен дөньяны —
Түгел мин бер көнлек күбәләк!

•

Мин авылда авырып ятам.
Мендәрем, башым кайнар...
Күзге төн. Тәрәз каршымда
Чайкала моңсу таллар.

Салкын, юеш пыялага
Сары яфрак ябышкан, —
Күзен мөлдерәтеп гүя
Күз карый миңа тыштан.

Юылган җәйге авазлар:
Кошлар җыры, чыр-чулар.
Гарешкә киткән һәммәсе —
Гамь-шатлыклар, борчулар.

Караңгылык үзенә йоткан
Авылның бар халәтен.
Әтәчләрне «телсез» иткән,
Юашлаткан кара төн.

Айны дерелдәтеп этләр
Ник бер өрсен ичмасам!
Җанымны, сырхау тәнемне
Әллә ниткән үч баса.

... Мин авылда авырып ятам.
Өнме бу, әллә төшме? —
Төн карасын яңгыратып
Кырда ак байтал кешни!..

•

Яз турында хыяллансам —
Карлыгачтай канат кагына башлый
Якты, җитез уйларым.

Көз турында хыяллансам —
Болытлардай тып-тын агыла башлый
Талгын, моңсу уйларым.

## Гомер

Дөньяга килгәч тә кешене
(Ул әле җикмәгән пар атын)
Мендәргә салалар, — баш белән
Көнчыгыш ягына каратып.

Дөньясын куйгач та кешене
(Ул инде тугарган пар атын)
Ләхеткә салалар, — баш белән
Көнбатыш ягына каратып.

...Көнчыгыш, көнбатыш арасы —
Кояшка бер көндә барасы.

•

Син миңа күзләр бирдең:
Чыктагы салават күперен,
Таш өстендәге гөлләрне,
Күлгә төшкән айны күрергә өйрәндем.

Син миңа тел бирдең:
Дөньядагы иң көчле,
Иң татлы һәм
Иң назлы сүзләрне әйтергә өйрәндем.

Син миңа көч бирдең:
Өстеңә ташланган дулкынны,
Юлыңа ишелгән ташларны
Тыярга, читкә алып атарга өйрәндем.

...Син пышылдап нибарысы:
— Яратам, — дидең.

## Ярулла юкәсе

Әй, алма бит, алма бит,
Алма битләр кала бит.
Алма битләр калмас иде —
Патша солдат ала бит.

**Халык җыры.**

Тутырып егерме биш елын,
Кайткан да төшкән ул авылга.
Шул кичтә бер хатын ялгызы
Такмаклап елаган: «Ярулла-а...»

Винтовка дускаен, үчегеп,
Ыргыткан тузанлы чардакка.
Аракы-шайтанга кушып ул
«Сөймәскә» ант эчкән аулакта.

Ни кала кып-кыска гомердән?
Югыйсә яшь бара, яшь үтә...
Бәрәңге бакчасы янына
Утырткан Ярулла яшь юкә.

Бервакыт шау килгән тын авыл:
Тоташ ут эчендә — утарлар!
Атларны коткарган Ярулла,
Тик менә... гәүдәсен ут алган.

...Кәүсәдә — меңләгән җыерчык,
Карт инде Ярулла юкәсе.
Бөҗралап түшәлгән елларны
Эх, димен, кирегә сүтәсе!

Җилләрдә чайкала карт юкә,
Ачкан да йөрәген давылга.
Тамырдан күкләргә кадәрле
Моң ага: «Ярулла... Ярулла-а...»

*Равил Мирхәйдәров 1941 елны Көнбатыш Казагыстанның Мартук исемле район үзәгендә татар гаиләсендә туа. Шул ук 1941 елны Мәскәү тирәсендәге сугышларда аның әтисе һәлак була. Малай ятим кала. Үскәч ул тимер юлчылар техникумын тәмамлап, бер ел тимер юлда эшли. Аннан җиде ел дәвамында Урта Азия һәм Казагыстан төзелешләрендә хезмәт итә. Хәзерге көндә Равил Мирхәйдәров Ташкентта яши — төзелеш идарәләренең берсендә инженер. 1978 елдан СССР Язучылар союзы члены. Аның киләчәк планнары әдәбият белән нык бәйле. Авторның повесть һәм хикәяләре аерым җыентык булып Ташкентта, Мәскәүдә басылып чыкты. Соңгы елларда аның хикәяләре үзәк матбугатта даими күренеп киләләр. («Литературная Россия» атналыгы, «Мы — молодые» җыентыгының 6 саны һ. б.)*



*Еллар үтү белән язучы үзенең бала чагына, авыр сугыш елларына әйләнеп кайта, үткәнен бүгенге көннәр белән бәйләп уйлана, укучыларны да уйландыра.*

## Равил Мирхәйдәров

# КӨТЕП АЛЫНГАН СӘФӘР

КЕЧКЕНӘ ПОВЕСТЬ



Ул көзне Әскәров бер үк төшләр күрә башлады... Төнге урам... Мәктәп, раймаг, авыл советы һәм поселок кырыендагы автобаза утлары керә иде аның төшләренә. Оренбург ягыннан поселокка якынлашкан чакны караңгылык эченнән кинәт килеп чыккан бу утлар, җемелдәшеп, аны үзләренә чакыра башлыйлар иде. Кайтып килешли шуларны күреп, Далада яшәүчеләрдән кемнең генә йөрәге җилкенеп, күңеле нечкәрмәде икән...

Бозлы баганалар төбенә төшкән зәгыйфь утта кар бөртекләреннән башка берни күренмәсә дә, поселокның үзәк урамы «Украинская» аның төшенә һәр вакыт якты, бәйрәмчә бизәлгәндәй керә иде. Күз алдына ап-ачык булып күршеләрнең йорт-җире, каралты-курасы килеп баса, авыша төшкән коймалар, көзге кырлар төсен саклаган, аяк астына чәчелгән салам

кисәкләре, кар басып чүгә төшкән печән чүмәләләре һәм казакълар кварталында яшәгән Җумагуловларның дөяләре — хәтеренә сеңеп калган әнә шундый әйберләрне күрә иде ул төшләрендә.

Барыннан да бигрәк җәйнең чыклы иртәсен ярата иде Әскәров. Тузанлы юл, мөселман зиратын әйләнеп узып, далага алып чыга. Зират артындагы тирән чокырдан башланып елгага кадәр сузылган бу юлны Әскәров бала чактагы кебек җәяүләп уза.

Тар көпчәкле арба кискәләгән дала юлы, боргалана-сыргалана, еракта күгелҗемләнеп утырган агачлар арасына кереп югала. Нинди озын иде ул чакларны өч чакрымлык бу юл!

Поселокка ул ашыкмыйча, ял иткәләп, чикерткәләр, матур канатлы күбәләкләр тота-тота кайта иде. Кайвакыт күрше малае Бәхет янында озак сөйләшеп утыра, тегенең онытылган көтүе тимер юлга керә башлагач кына аерылып, кайтырга кузгала. Бәхет белән аерылышуның сәбәбе дә әлеге көтү хуҗасы — Әскәровларның усал, тәкәббер кәҗә тәкәсе Монгол була, чөнки аңа паровозның калын итеп кычкыртуы бик тә ошый, шуңа ул көтүне һаман тимер юлга ияртеп алып бара иде.

Елгага илтә торган бу юл сизелер-сизелмәс кенә күтәрелә барып, Илеккә бер чакрым каларак кинәт биек ярдан аска, хәтфә кебек җәелеп яткан болынга төшә. Җәйнең кызуында кылганга кадәр саргаеп корыган дала өчен үзәндә җәелеп яткан бу болын бигрәк тә күркәм иде. Язларын Илек ташый, үзәнне су баса, ә сулар китеп күпмедер вакыт үткәч, әйләнә-тирә ямь-яшел юрганга төренә. Елгада су кереп, өйләренә яки, киресенчә, поселоктан елгага ашыккан бала-чага күпереп үскән үлән өстендә аунамый булдыра алмый иде.

Юлның ике ягыннан да үрләр күтәрелә, анда ныгытмалар кебек саман кирпечтән салынган озын сарайлар күренә, ә җәйләрен алар тирәсендә ап-ак тирмәләр төзелгән була. Иртәләрен тирә-юньне сарык тавышларына күмеп, үрдән алалы-колалы көтүләр төшә. Поселокның хуҗалык көтүе дә елга буена, хуш исле үләннәр үскән болынга чыга иде.

Көтелмәгән бу төшләрендә Әскәров үзе әллә кайчан онытып бетергән бик күп танышларын да күрде. Бер төшендә аңа кәздән дүрт читле кирпечләр ясап ятучы рус мужиклары керделәр. Нидер сөйләшәләр, көлешәләр иде, йөзләре дә таныш — аларны Әскәров поселокның чиркәүле очында күргәне бар. Шунда ул берсенең бакчасында таба хәтле көнбагыш үскәнне хәтеренә төшерде.

Аның төшләренә елга да керә иде, әлбәттә. Аннары бергә уйнап үскән сабакташлары: Илгиз, Генка, Бисәмбай. Ә кайвакыт аңа аркасы белән утырган ниндидер бәхетле балыкчы төшкә килеп керә, ләкин аның йөзе күренми, шуңа Әскәровның кәефе кырыла иде.

Илектә аны нәрсәдер аргы якка тарта. Юк, комлы ярдан салып, дөнья бәясе торырлык кармакны харап итмичә балык тотып булганга да, ак комда шыр ялангач килеш кызынганга да түгел... Каршы якта комлык чигеннән калын урман башланып, текә үргә менеп китә иде. Нәкъ менә шул урман тарта иде Әскәровны.

Соңрак, бераз олыгая төшкәч, аңа Белоруссиядәге гаҗәеп урманнарны күрергә, Балтик буеның наратларына сокланып карап торырга туры килгәләде, ләкин Илек аръягының ул урманы нигәдер кадерлерәк, күңелгә якынрак иде...

Җәй көннәрендә Әскәров әлек урманның эреле-ваклы күлләрендә табаннар тоткалый, һәм бу ганлә табынына ярап куя торган иде. Тагын куе тал арасында кычытканга өтәләнә-өтәләнә кара бөрлегән җыя, иптәшләре белән аны Ташкент поездына илтә. Калай чиләкләргә тутырылган ул бөрлегәннәр Әскәровның үзеннән бигрәк, сату-

лашмый-нитми алучы карт пассажирларның исләренә ешрак төшә торгандыр, мөгаен.

Төшләрендә ни генә күрсә дә — балык тотамы, тирестә суалчан-нар казыймы, чокыр-чакырдан колмак җыямы — һәр вакыт янына чал чәчле урман каравылчысы Бәләй карт килеп чыга иде. Ул элек-ке кебек үк көтмәгәндә, мыштым гына килеп чыга, — чыбык та сын-дырмас, үлән-яфрак та кыштырдатмас...

Карт башта малайга күренми генә читтән карап торыр, аннан акрын гына тамак кыргалап, яшеренгән урыннан пәйда булыр, кы-рысрак күренергә тырышып, куе кашларын җыерыр һәм:

— Ә, Дамир! — диеп гаҗәпләнгәндәй итәр. — Урманда шаярма, кара аны!

Үзе тавышсыз-тынсыз гына юлына китәр, ә агачлар арасына ке-реп югалгач:

— Түгәрәк күлдә Петька-Тарзан кичә бер чиләк табан балык тотты, — дип кычкырыр.

Яки:

— Дамир, быел Җенле күлдә колмак бик уңган, — дияр.

Картның өе күрше кварталда иде. Бәйрәмнәрдә ул үзенең кара козырегында алтын имән яфраклары чагылган яшел фуражкасын киеп купшыланып йөрергә ярата. Бәләй карт ел әйләнә урманда бул-са да, поселок малайларының исемнәрен яхшы белә; аның бу гадәте-нә күпләр гаҗәпләнә, ә Дамирның исе дә китми, чөнки малай карт-ның урмандагы һәр агачны, һәр куакны белүенә нык ышана иде...

Бала чакның хуш исләрен, җылы яңгырларын, чатнама суык кышларын ул инде онытып та өлгергән кебек, гүя аның тормышын-да шушы аммиак исе аңкып торган бакыр эшкәртү комбинатыннан һәм гомумән шәһәрнең һавасын бозучы шуның ише комбинатлардан бүтән берни дә булмаган диярсең. Монда бит аның яуган кары да ике-өч сәгать үтүгә карала башлый, чөнки шәһәр читендә җил юнә-лешен искә алмыйча төзелгән цемент заводы эшләп ята.

...Көзнең явымсыз, җилле бер көне. Әскәров сырмасын җилбәгәй җибәреп кепкасын кигән дә, бәрәңге тутырылган капчыклар янында басып тора. Берничә җир арырак янган учактан борынга төтен исе килеп керә — бәрәңге сабагы ягалар. Капчыклар күрше-күләннән җыйган иске оеклар белән бәйләнгән. Дамир нигәдер шул оеклардан ояла, читкәрәк китеп баса. Каян гына табып бетергәндер әнисе?!

Бакчада алар әнисе белән генә. Сталинградтан яраланып кайткан үги әтисе язын бәрәңге утыртырга гына килә ала. Утырту — үзе бер бәйрәм! Ә алуын алар икәүләп алалар...

Промкомбинат полуторкасын көткән арада малай кипкән сабак-ларны бер кучкә җыеп, астына коры үлән кыстыра да, учак ягып җибәрә. Алар бакчасыннан да күренер-күренмәс тасма булып елга ягына төтен агыла башлый.

Ниһаять, алар үзләренә таба килүче ябык гәүдәле, үпкәсе белән изаланган Мирзагалине күреп алалар. Тегенең йөрешеннән «төшер-гәнлеге» сизелә.

— Мәрзия апа, — дип кычкыра ул килеп җитмәс борын, — кер-сәм, чыгып булмас дип куркам, минем арба бит, хуҗасы шикелле, көчкә эләгеп йөри, — ди күп балалы шофер шаяртып. — Әйдә, үзем дә булышырмын, — дип, зур капчыкка килеп ябыша.

— Куй, азапланма, тамагыңнан кан китсә, алла сакласын, — ди Дамирның әнкәсе.

Мәзәкче Мирзагалинең йөзенә күләгә йөгерә.

Шунда Дамир капчыклар янына килеп:

— Мирзагали абый, мин үзем... әни белән сез күтәрергә генә бу-лышыгыз, мин үзем... — ди ашыга-ашыга.

Шофер белән авыр капчыкны арттан тотмакчы булсалар да — кая ул!.. Дамир кузовы ачык машинага табан элдерә генә. Бу кадәр көч каян килгән малайга!.. Төшендә ул капчык авырлыгын сизми дә, шатлыгы эченә сыймый.

Оренбург далаларына кыш иртә килсә дә, соңарып китә. Мондый кышларда малга ашатырга да, астына җәяргә дә, ай-һай, күпме печән кирәк.

Ул заманда йорт саен сыер, ә казакълар белән татарларда кәҗәсе-сарыгы, кайберәүләрнең хәтта дөяләре дә була торган иде.

Елганың уйсу болыннарын чапмыйлар, анда колхозның сарыклары белән хуҗалык көтүе йөри. Печәнне тирә-юньдәге казакъ, рус авылларына барып хәзерлиләр. Исәп монда гади: тугыз машина колхозга булса, унынчысы — үзеңә. Авылдан киткәннәр дә җәйге яллары шушы вакытка туры китереп алалар, ә бала-чаганың каникулы. Улы-кызы шәһәрдә урнашканнар балаларын печән өстенә көтәләр, картларга печән әзерләшмәү иң хурлыклы гадәт санала.

Атна-ун көн эчендә әйләнә-тирәдән бөтен яшьләр Далага кайтып бетә, ә кайвакыт Ташкенттан онытылып беткән Әсхәт, яки Караганда шахталарыннан Николай кайтып төшә...

Кайберәүләр елның-елында әртилгә берләшәләр, ләкин күп вакыт компания яңабаштан оеша. Малай-шалайга иплерәк әртилгә эләгү өчен поселокны йөреп чыгарга туры килә, чөнки бу алай ук ансат эш түгел. Олылар янына эләгә калсаң, көт тә тор: өеңә печәнне берәр атна элек кайтарып аударасың. Аның каравы, яшьтәшләр белән эшләү күңеллерәк. Олылар, әлбәттә, колхоздан тегесен-монысын сорый беләләр, ләкин малайларның да печәнсез кайтканнары юк бит. Нервылары какшаган председательләр һәрбер малайның сугыш сөреме кагылган гаиләне тартып барганын яхшы беләләр, үзләре дә фронтка шушы малайларның әтиләре белән китеп, кайсы кулсыз, кайсы аяксыз кайтты лабаса. Иң күңелле әртил шәһәрнекеләрдә — монысы бәхәссез. Аларның эш тә уен-көлке белән бара, авыллар кебек «кемгә күпме?» дип бәхәскә кермиләр. Арылган булса да, ял көннәрне җыелышып клубка киләләр. Бригадаларында һәр вакыт баян яки аккордеон була. Ә Герасим картның Оренбургтагы Сергее гитара уйнап җибәрсә — үзе бер бәйрәм! Шәһәрнекеләр белән эшләү гомер онытылмаслык истәлек булса да, уңайсыз ягы бар. Безнекеләр якын-тирәдәге колхозларда эшли, шуңа печәнен дә күбрәк алалар. Ә печәнсез нишләмәк кирәк?

Беренче елны Дамир кая тукталырга белми озак йөрде. Шунда әртилдән әртилгә йөргән малайдан күршеләрнең күрә карау күзле Фатихы:

— Әллә Сергейның гитарасын көтәсеңме? — дип, беркатлы итеп сорап куйды. — Без Полтавкага барабыз, теләсәң, әйдә син дә... — Дамирны бәләкәй булганга әртилгә алырга бик ашкынып тормаганнарын абайламый иде булса кирәк. — Анда чулак Шубин председатель. Әнигә үзе: «Килсеннәр, печәнсез итмәбез!» — дигән. — Гитарага исең китмәсен, безнең үз җаебыз бар, — дип ярым пышылдауга күчте: — Селиван абый, малайларны колхозның пионер лагеренда ашатам, дигән... Туйганчы бүсәсең, аннан компот...

Онытыла барган тагын бер күренеш: тузанлы басу юлы... Тынлык... Төнге далада ике зәгыйфь ут уйный. Бу — эскерт кадәр итеп печән төялгән, өстән бастырыкланган, як-ягыннан аркан белән тарттырып бәйләнгән машина уты. Алда утыз чакрым юл, җәйнең кыска төне шунда үтәчәк. Әртил йөк өстендә бара, йолдызлар да якынайган кебек тоела. Берәү дә йокламый. Кая инде мондый чакта йоклау! Кайтып җиткәнче печәннең кемгә буласы билгесез. Фатих шобаганы авылга җиткәч кенә салдыра...

Кайвакыт Әскәров төн уртасында уянып китә дә, яктырганчы тынычлана алмый ята. Өйдәгеләрне уятмаска тырышып, шыпырт кына кысан кухняга чыга, халатына төренеп, караңгыда озаклап тәмәке тартып утыра. Ялгызы үткәргән бу сәгатьләрдә төшенә кергәннәрне уйлый, үткәннәргә әйләнеп кайта, гомумән, үткән тормышын күздән кичерә. Ләкин вакыты-вакыты белән үсмер чакның матур хатирәләре арасына хәзерге көне килеп кереп, хыялы бозыла. Әле генә күңеленә ямь биргән күренешләр югала, кәефе кырыла.

Бер иртәне ваннаның тимгел-тимгелле көзгесе каршында пөхтәләп кырынган җиреннән үзе үк әйтеп куйды:

— Ни булды соң әле миңа? Әллә ностальгия инде, чорт? Алай дисәң, миңа утыз биш кенә бит әле...

Ала-кола көзгедә тыелгысыз көч ташып торган яшь ир-ат йөзе. Чал чәчнең бөртеге дә юк, коела башлап юкармаган да, ә җыерчыклар — анысы инде хатын-кыз кайгысы. Киң маңгай астына кереп утырган җитди күзләре аның нык, сабыр холыклы кеше икәнен күрсәтә.

Ләкин көзгә кергәннән бирле Әскәровның тынычлыгы качты. Иртән торып шыгрым тулы автобуста эшкә барганда, үзе дә сизмәстән, һаман шул туган ягы, Дала турында уйлана торган булып китте.

«...Ул тормышны мин үзем ташлап киттем түгелме соң? Дуслардан, күрше-күләннән, туган-тумачадан, ата-баба нигезеннән... ачык кырда сызгырган җилдән, айлы кичтә уйнаган балыктан һәм әлләниләрдән үзем качып киттем түгелме?..»

Кысан автобуста этелә-кысыла барганда ул менә шуларны уйлый иде. Ярый әле, кемнеңдер билетка дигән тиенен кассага бирәсе яки чыгучылар белән урын алмашасы була һәм шуның аркасында берәзга булса да онытылып торасың...

Дамир шәһәрнең төзелеш идарәләре янына урнашкан бакыр эшкәртү комбинатында төшеп, үзе эшләгән юллар төзү идарәсенә килеп керә.

Сугыш елларыннан калган озын, бер катлы бу барак тышкы яктан күзне бик иркәләп тормый иде... Ләкин бусагасыннан атлап кергәч бу бинада яхшы хуҗа барлыгын һәм инженер фантазиясе хөкем сөргән сизәсең. Баракның эче бөтенләй үзгә: уртак стеналар сүтелгән, бүлмәләр кушылган яки бүленгән, түшәм яңабаштан такта белән тышланган, идәндә келәм сурәте төшкән линолеум ялтырый. Түшәмнән һәм ян-як стеналардан чиратлашып көнозын яктылык сирпелә. Шунсыз тәрәзәсе булмаган коридорда дөм караңгылык хөкем сөрер иде.

Һәр бүлекнең бәләкәй генә булса да якты кабинеты бар. Бүлмәсаен өйдәге кебек табигый газга көйләнгән голландка мич. Коридор түрендә дүрт конфоркалы ике плитә тора. Ишегалдына карый торган тәрәзәләрне ачып җибәрсәң, бүлмәләргә түтәлләрдән чәчәк исе саркып керә. Ишегалдын әле Дамир килгәнче үк гөлбакча иткәннәр. Төзелеш идарәсенең һәр өмәсе шунда үтә иде.

Әскәров эшкә бар кешедән элек килә иде. Коридорның буеннан-буена ут кабызып чыга. Баш инженерның кабул итү бүлмәсендә торган трюмо каршына туктап, үзенә бер күз сала. Аннан планнар бүлегенең ике катлы ишеген ачып, үзенең урынбасары, ягъни бүлекнең өлкән инженеры Кира Михайловна бүлмәсе аркылы зур өстәлле, өч телефонлы иркен кабинетына уза. Монда килгәч, Әскәров кабинетын үзгәртеп маташмады, бары тик кабинеттан кабул итү бүлмәсенә трюмо күчте дә, аны аерып торган ак пәрдәле пыяла ишек юкка чыкты.

Бәлки әлеге йокысыз төннәре, еш керә башлаган төшләренә аның эше гаепледер? Алай дисәң, Дамир Әхәтовичның эше үз җае белән

бара тора, югарыда да мөнәсәбәт начар түгел, хәтта аны трест үзенә ала икән дигән имеш-мимешләр дә ишетелгәләде. Бәлки ул артык күп эшләп талчыга, арый торгандыр? Әллә инде эш шартлары начармы?

Куйсана... Элегрәк тапшырасы объектларда көнен-төнен ятып, ару түгел, аяктан егылырлык хәлгә җиткән чаклары бар иде, ә хәзер... эш шартлары, имеш.

Төзелеш идарәсенә Әскәров халык хуҗалыгы институтын тәмамлагач күчте, ә шәһәргә комсомол путевкасы белән әлакте.

Өч елга дип стройбатка алынган Дамирга тагын ярты ел хезмәт итәргә туры килде. Ул чакны алар тиз тапшырасы объектта эшлиләр иде. Ә ул — бригадир. Эшне бетергәч, бөтен бригадалары белән диярлек Амурдан Ташкент тирәсенә килеп төштеләр. Кайда гына эшләргә туры килмәде: промышленность объектлары да төзеделәр, торак йортлар да салдылар, Металлурглар сараена да өлешләре тиде. Шәп эшләделәр егетләр, шуңа күрә дә беренче айларны ук төзелештә аларны гвардиячеләр дип йөртә башладылар. Трестта беренче булып коммунистик хезмәт бригадасы исемен алдылар. Ә ул заманда, бу хәрәкәт колачын җәя генә башлаган алтмышынчы елларда, мәсьәләгә бик таләпчән килenә һәм ул исемне алу җиңел түгел иде. Удар хезмәттән тыш коллектив үзенең белемен дә күтәрергә тиеш дип санала иде.

Язның бер көнендә бригаданы трест парткомына чакырып алдылар. Парторг, отставкага чыккан майор, гвардиячеләрне елмаеп каршы алды. Ул чакны егетләрнең күбесе армиядән кайткан гимнастерка белән итекләрен дә туздырырга өлгермәгәннәр иде әле. Алар ишектән керүгә парторг:

— Бу ниткән эш, егетләр, хезмәт күрсәткечләрегез ике бригадага җитәрлек, ә коммунистик дигән исем биреп булмый, — дип шакаттырды.

— Белем мәсьәләсендә калышасыз, — диде парторг, ниһаять, серне ачып. — Берегез дә укымый икән ләбаса. Үсәргә теләмисез...

Кыскасы, отставкадагы бу майор бөтенесенә урын тапты — өчесен кичке мәктәпкә, җиде кешене техникумга, ә бригадирны (аңа мәсьәләне катырак куйды) институтка керергә мәҗбүр итте. Армиядә үк андый планы бар иде дип, егетләр «сатты» Дамирны. Парторгның да гаебенә керерлек түгел: һәр вакыт кызыксынып, тикшереп торды, укучы егетләрне яшь белгечләр өчен махсус төзелгән тулай торакка күчерде, шеф итеп инженерлар билгеләде һәм квартира биргәндә дә онытмады...

Буяучы-агартучылар бригадасында эшләгән Машенька белән Дамир нәкъ менә институтка керергә йөргәндә очраша башлады. Эш һәм имтиханнарга хәзерләнү егеттән бик күп вакыт таләп итте. Мин дәресләкләр белән утырганда, Маша ычкынмагае дип, шүрләп тә куйгалый иде Дамир. Шәһәр зур, кая карама тулай торак, ә егетләре, бигрәк тә монтажчылар, менә дигән. Әгәр берәрсе шушында төпләнәм, гаилә корам дип ычкындырса, бер атна дигәндә, җир бетереп, квартира табып бирәчәкләр. Верхолазлар монда — алтын бәрабәре...

Ләкин аның шик-шөбһәләре юкка гына булып чыкты: бер көнне Машенька, аның дәресләкләр белән утырганын күреп, шатлык катыш тартыну белән колагына пышылдады:

— Дамир, әгәр институтка керсәң, сиңа кияүгә чыгам...

Дамир, әлбәттә, керде һәм тиздән алар өйләнешеп тә куйдылар. Беренче балалары Зарик туар алдыннан ике бүлмәле квартира алдылар.

Бу шәһәрдә һәрбер төзелеш диярлек тиз тапшырылырга тиешле дип саналганга, бригадир булып эшләү җиңел түгел иде, ә Дамир

инде алты ел гвардиячеләр белән җитәкчелек итә, шуның өстәвенә укый. Ярый әле, факультеты якын, урам аркылы гына.

Дөресен генә әйткәндә, бәлки әле ул Машенькасыннан башка институтны тәмамлый да алмаган булыр иде. Өченче курста аңа күкерт кислотасы цехын тапшырырга туры килде. Эш муеннан, күп вакыт икенче сменага калына. Дамир атналар буе институтка аяк та басмады. Нәкъ менә шул чакны өч ел рәттән ял күрмәгән, тәмам йөдәгән Әскәровның күңелендә институтны ташлыйм микән әллә дигән уй туды. Укуда да, эштә дә, миннән үткәнче, иясенә җиткәнче, дип көн үткәрүчеләрдән түгел иде Әскәров. Мәсәлән, кайбер зачетларны ул: «Вакыт юк, көне-төне күкерт кислотасы цехында...», — дип, бераз җиңелрәк тә тапшыра алган булыр иде. Һәм аны, әлбәттә, аңламый калмаслар иде, чөнки институтта шул ук трест һәм завод идарәсе инженерлары укыта, алар белән көн саен диярлек төзелеш мәйданнарында, планеркаларда очрашып торырга туры килә. Кайберәүләрнең нәкъ шушы метод белән укып барганнарын Дамир сизә иде, әлбәттә, ләкин...

Дамир, өйгә кайтып, Машага укуын ташлау турында әйткәч, нинди сафура бураны купканын сөйләп тә торасы юк.

Иртән эшкә килгәч, Дамир хатынының сүзләрен тагын бер күңеленнән кичерде һәм аның, чыннан да, хаклы икәненә ышанды. Әллә Машага җиңелме? Хатынына шундый биектә эшләргә туры килә, аска карарга да куркыныч. Җәен эссе, утыздан түбән булганы юк, кышын суык, өстәвенә ел әйләнә үтәли җил теңкәгә тия...

Ә уллары Зарик? Маша таң тишегеннән аны яслегә илтә, кичен вакытында килеп ала. Ә эшләгән объектлары бүген шәһәрнең бу читендә, иртәгә — тегендә. Дамирны иртән кайнар ашсыз җибәргәне, кичен яңасын пешермичә каршылаганы юк. Ничек кенә арымасын, ире институттан кайтмыйча, урынга ятмый. Дүшәмбе саен егетләр Дамирның чиста спецовкасын күреп башларын гына чайкыйлар. Беренче курсны тәмамлау шатлыгыннан Маша аңа премия акчасыннан язу өстәле белән китап шкафы бүләк итте. Кыскасы, мәсьәлә болай булып бетте: башлыклар киреләнсәләр дә, эш парторгка барып җитте. Маша ирен ике ел өчен ял алырга мәҗбүр итте, шуның аркасында Дамир язгы сессиядә бөтен «койрыкларыннан» да арынды.

Дүртенче курста баш инженер аңа әйткәләгән иде:

— Син, Әскәров, үзеңне аппаратка алмаганга рәнҗемә инде, брат, юньле мастерлар, бригадирлар җитенкерәмиапе, эш менә нәрсәдә... — Һәм шунда шаярыпмы, чынлапмы зарлана да куйды: — Трест парторгына очраган саен әйтә киләм, син безнең тамырга балта белән чаптың, дим... Укыткан иң шәп егетләребез, институт бетереп, я аппаратка күчәләр, я бөтенләй икенче оешмага урнашалар.

Шулай итеп, нәкъ утыз яшь тулганда Дамир Әхәтович дипломлы булды. Үзе эшләгән идарәдә каласы килмәде; элек бергә эшләгән егетләр белән мөнәсәбәтләрне башкача кору аның өчен сәер иде. Баш инженер аны юллар идарәсендәге танышына тәкъдим итте. Һәм ул ялтырап торган голландка мичле кабинетта Кира Михайловна кул астында эшкә керешге.

Баш инженер Әскәровны идарә башлыгына алып кереп, аның турында сөйләп торганда, тегесе, тыңлап та бетермичә, каршында тартыныбрак басып торган Дамир Әхәтовичка елмаеп:

— Шәп егет, чыннан да, гвардеецка охшаган. Алам! — диде һәм нигә икәнен аңлатып та бирде: — Хәтерең калмасын, гвардеец булмасаң да алган булыр идем, чөнки идарәдә ирләрдән без икәү генә — ул да мин, — башлык баш инженерына ымлады. — Син — өченче. Инженерлык хәзер, үзең беләсең, хатын-кыз кулына күчте. Бөтен

бүлекләр хатын-кыз белән тулган, хәтта вахтерыбыз да хатын-кыз... Яшь вакытта безнең агай-энегә тырышлык, чыдамлык җитми, күрәсең, шуның аркасында институтка керердәй бердәнбер баллны кулдан ычкындырабыз. Бер танышым: шул Анна Каренина аркасында институтка керә алмадым, дип зарланды. Әдәбияттан өчле алган да, керә алмый калган. Ә Каренина турында яхшырак белүче кызга — ишекләр ачык, понимаешь... — Ул бераз уйланып торды, аннан: — Четерекле ул хатын-кыз белән эшләве, четерекле, Дамир Әхәтович. Сезгә монда берүзегезгә калырга туры киләчәк... Безнең көн тегендәмонда чабып уза, мин — планеркаларда, киңәшмәләрдә, ә ул — объектларда...

Башта яңа инженерга карата хатын-кызларда зур кызыксыну уянды: беренче көннәрне алар Кира Михайловна белән сөйләшү, ачыклау, хәл итү сылтавын табып, бер-бер артлы планнар бүлегенә кереп чыккаладылар, ләкин инженерның баш та күтәрмичә ихлас күңел белән кәгазьләр актарып утыруын күреп, тиз суындылар.

Кира Михайловна хатын-кызга хас сизгерлек белән бүлеккә төпле кеше килгәнен абайлап алды булса кирәк, чөнки әкренләп Дамир Әхәтовичка эшнең серләрен чишә, белгәннәрен яшермичә сөйли барды. Көн үткән саен аны эшкә ныграк тартты, ярдәмчесенә яңаданяңа вазифалар өстәде. Я балалары, я үзе авыру сәбәпле Кира Михайловна бюллетеньдә йөргән арада, тапшырасы отчетлар тапшырылган, кирәкле хатлар язылып озатылган — кыскасы, бүлектә менә дигән тәртип сакланган була; моны күреп бүлек мөдире эчтән генә куана торган иде.

Әскәров та әкренләп ияләшә барды. Көннәрдән бер көнне өстәлендә башкаларныкы кебек чәйнек һәм ике касә пәйда булды. Әссе көнне ачык тәрәзә каршына утырып ашыкмыйча гына бер-ике чәйнекне бушату рәхәт иде аңа.

Ярты ел дәверендә аны өч тапкыр туган көнгә дәштеләр. Андый көнне төшкә кадәр кухняның сигез конфоркасы да бертуктаусыз янып тора, ә коридордагы аяк тавышлары акча алган көндә генә була торган ыгы-зыгыны хәтерләтә. Билгеләнгән сәгатькә башлыклар килеп төшә һәм ирләрнең барысы да техника бүлегенә чакырып алына. Монда бүлмә иркен, урын җитәрлек. «Т» хәрефе сыман итеп тезелгән өстәлләрдә дефицит ватман ялтырый, мәҗлес хуҗасы каршына: «Туган көнең белән котлыйбыз, Генриетта!» дип языла. (Әскәровның хәтерендә нигәдер шул Генриетта гына калган иде). Төсле фломастер белән бормалап язылган тексттан бүлекнең иң яхшы сызымчысы Лида кулын таныйсың.

Күптәнге гадәт буенча төп азыкны хуҗа үзе хәзерли. Әгәр соңыннан ай буе аны рецептлар сорап интектерсәләр, мәҗлес матур үткәнгә санала.

Мондый көннәрдә хатын-кызларда бик нык үзгәреш сизелә: аларга каяндыр сокландыргыч нәфислек иңә, үзара итәгатьле генә чүкердәшә башлыйлар. Ә мәҗлес хуҗасына нинди генә тостлар әйтелми дә, ел фасылы нинди булуга карамастан, ни төсле генә чәчәкләр бүләк ителми! Ләкин Дамир Әхәтович бер нәрсәгә тәки күнегә алмады: башта аракысы-шәрабы, аннан бүлекләрдә чәй эчеп әрәмгә үткән бу көнне ничек берәү дә кызганмый икән?

Көннәр, айлар шулай уза торды. Менә Кира Михайловна белән беренче тапкыр еллык отчетны да тапшырдылар, инде икенче яртыеллык якынлашып килә. Дамир Әхәтович инде калын тавышлы, эре гәүдәле, мыеклы диспетчер Генриеттаны хезмәт хакы бүлегендәге чибәр Валя Розенталь белән һич бутамый. Ул хәзер бер караганда бик дус та, бердәм дә күренгән хатын-кызлар коллективының чынында исә андый ук түгеллеген яхшы белә иде. Мәсәлән, бер лагерь-

да бухгалтерия, кадрлар һәм тәэминат бүлекләре, икенче лагерьда планнар, техника һәм производство бүлекләре тупланып, алар арасында еш кына бәрелешләр булгалап тора. Мөнәсәбәтләр, әлбәттә, бер килеш кенә тормый, монда җил-давыл да, тыныч, чалт аяз көннәр дә күренгәли. Һава торышын галимнәр карлыгачларга, кырмыскага карап, ә җир тетрәүне ташбака һәм еланнарны күзәтеп алдан белеп була диләр. Ләкин берәү дә иртәгә идарәдә нинди ситуация буласын алдан әйтергә батырчылык итмәс иде. Биредә, зур дипломатиядәге кебек үк, ташка басылмаган кагыйдәләр хөкем сөрә; мәсәлән, бәйрәм-фәлән вакытында берәү дә тынычлыкны бозмый, туган көннәрдә, юбилейларда да бөтен эш күмәкләшеп башкарыла — бертуганнар диярсең. Шулай да иң кызыгы — конфликт шторм дәрәҗәсенә күтәрелгәч була иде.

Генриетта рация ватык дигән сылтау белән теләсә кайсы вакыт базарга чыгып китә ала һәм аннан сумкасына дыңгычлап тутырып дуңгыз аяклары алып кайта. Әй, тәмле дә була торган иде соң койкасы! Эше юклыктан ул аларны плитәдә өтәли башлый. Ишекләр ябык булса да, ун минуттан көйгән йон исе бөтен бүлекләргә кереп тула.

Кинәт ишекләр ачылып, җәнҗал башлана. Ләкин Генриетта бирешүчеләрдән түгел, аның үз сүзе сүз. Эшеннән аерылмый гына, исе дә китмичә:

— Харап булгансыз икән, югары белемле аксөякләр... тәрәзәне киңрәк ачыгыз, җилли ул, — дип кенә җибәрә.

Мондый көннәрне каршы лагерь Кира Михайловна кабинетына кереп тула да, кофе тирәсенә җыелып, телевизорда күргән спектакль турында гәпләшә, үч итеп эш вакытында базарга йөрүне беразга туктатып тора.

Күп тә үтми, ике якның да делегациясе башлык янына килеп керә. Озын гомер кичереп, гаилә тормышында да зур тәҗрибәсе булган идарә башлыгы низагның үзеннән-үзе бетәчәген белсә дә, ике лагерьның аһ-зарын игътибар белән тыңлый һәм, аз гына түзегез, чаралар күрелер дип, делегацияне кабинетыннан озата иде.

Ә кайчак көтмәгәндә идарәгә «кырык тартмачылар», ягъни сумкаларына дефицит товар тутырган хатын-кызлар килеп керә; аяк киеме, эчке кием-салым, парфюмерия, трикотаж, ә соңгы вакытта промтовар әйберләреннән: түбе калмый торган кофе, паштет һәм треска бавыры консервлары, сәйлән чәе кебек нәрсәләр дә алып килә башладылар.

Кием-салымны иң әлек идарәнең ыспай кызы Валя Розентальгә китерәләр, ә азык-төлекне Генриеттага, әлбәттә.

Шул минуттан идарәдә үзара тынычлык урнаша. Киеп, үлчәп караулар, киңәшүләр, алмашулар, бурычка акча сорап торулар китә...

*

* *

Ике ел үтүгә, көтмәгәндә, Дамир Әхәтович югарырак эшкә күчте. Беренче Май алдыннан Кира Михайловна аны үзенә, алсу пәрдәле кабинетына чакырып алды да, трюмо каршына утыртып, болай диде:

— Дамир Әхәтович, мин сезнең белән урыннарны алмаштырырга булдым, башлыклар да каршы килмәс дип уйлыйм. Сез моңа ничек карыйсыз?

Әскәров ничектер югалып калды.

— Үземдә андый теләк барлыгын сиздергәнем юктыр ич...

— Гаеп сездә түгел, Дамир, соңгы вакытта сәбәпләре чыгып тора әле... Сезне билгесезлектә калдырмас өчен барысын да сөйлим инде, алайса... Көзен олы кызым мәктәпкә йөри башлый, аны илтеп куясы, барып аласы булачак, ә безнең шәһәрдә, үзегез беләсез, әбиләр башка җирдәге кебек үк дефицит... Хатын-кызга эшкә караганда балалар әһәмиятлерәк, кадерле Әскәров. Аннары тагын бер сәбәп бар. — Кира Михайловна бер генә секундка оялган кебек тоелды. — Безнең планда бала бар иде, бәлки монысы малай булыр... Ә балалы хатыннан ике-өч ел юньле эш көтмә инде. Бүлек өчен борчылмыйм, көчегез җитәренә ышанам. Ну, ничек соң?

Бүлек башлыгы буларак Дамир Әхәтович еш кына прораблар, мастерлар белән атнага ике тапкыр үткәрелә торган планеркага калгалый иде. Бу аның өчен мәҗбүри түгел иде, әлбәттә, ләкин соңгы вакытта аны түбәннән планлаштыру мәсьәләсе бик кызыксындыра, шул турыда үз фикерләре дә бар иде. Андый көннәрне Әскәров идарә башлыгы машинасында кайта. Бер көнне планерка вакытында техника һәм производство бүлекләре прораблар белән бәрелештеләр. Шул планеркадан кайтышлый янәшәсендә утырган Әскәровка баш инженер сөйләп китте:

— Сез, Дамир Әхәтович, шефның да, минем дә бүлекләрне яклавыбызга бәлки гаҗәпләнә дә торгансыздыр? Без дә, соңгы ике елда инде сез дә аларның ничек эшләүләрен яхшы беләсез. План һәр вакыт үтәлеп бара. Байрак та квартал саен гына түгел, елның-елында бездә. Ярый, эштә система булмасын ди, перспективаны да алдагы кварталдан артык күрмәсеннәр ди, әмма кирәк булганы срогына төгәл башкарыла... Аннан соң кая гына карама (трестта да, главкада да) хатын-кыз утыра. Шактый авырга туры килә, туган... Кайвакыт шундый китереп териләр, эшне өч көнгә дә кичектерергә бирмиләр. Шунда Кира Михайловнаны җибәрәсең дә, алар үзара бала-чага турында гәпләшеп, ирләреннән зарланышып, пасталар алмашып утыралар һәм эш тә җайланып өлгерә. Хатын-кыз ул, кадерле Әскәров, зур көчкә ия!

Башлык белән бәхәскә кермәсә дә, Әскәров бу турыда күп уйлана иде.

«Ниһаять, исебезгә төшкән икән... Мәктәпләрдә хатын-кыз күбәюе, шуның нәтиҗәсе турында сүз куертабыз. Болай барса, төзелешнең дә хатын-кыз кулына күчүе ихтимал. Ә техника прогрессы, монда хатын-кыз эшли, җайлабрак кыланыйм әле дип тормый, үзенекен итә. Бәлки менә нәкъ шундый «объектив» сәбәпләр аркасында төзелә башлаган объектларга техник документация кичегеп килә дә тоткандыр? Ә проекттагы хаталар? Шуларны төзәтә-төзәтә йөз меңнәрчә сум акча җилгә оча. Болары да шуның нәтиҗәсе түгел микән? Хәзер проект институтының туксан процентын хатын-кыз тәшкил итә. Дөресен генә әйткәндә, техника прогрессының руленә хатын-кыз ябышкан булуы Әскәровны бер дә куандырмый иде. Юллар идарәсендә эшләвенең өченче елында Дамир Әхәтович менә шундый фикергә килде.

Кира Михайловнаны декретка озаткач, Әскәров берничә ай дәвамында матур прическалар остасы — табельщица Юлия белән объектларга йөрде. Нияте — идарә күләмендәге иң реаль айлык һәм еллык хезмәт хакы фондын билгеләү иде. Бу идеяне баш инженер да күтәреп алды һәм боларның икесенә аерым хокуклар да бирде. Бүлекләрдә кинәт эш артты. Дамир аларга яңадан-яңа йөкләмәләр яудырып кына торды, һәм өченче кварталда эш, ниһаять, тәмамланды.

Документны тантаналы рәвештә трестка алып киттеләр, аңа күпме көч куелганын барысы да аңлый иде.

Трестта исә бу хезмәт макталды, яхшы дип табылды, ләкин җилкәсенә канатлар үскән Әскәров ишектән чыгып машинасына утырырга да өлгермәде, трест плановигы мондый нәтиҗә ясады:

— Көчле мужик, ләкин ничек диләр әле, бер бөртек бодайдан күмәч пешереп булмый, диләрме? Так что мондый эшкә безнең егерме идарә дә барыбер алынмаячак... Төзелешнең киләсе елгы реаль күләмен билгеләү шактый авыр. Хезмәткә, чыннан да, ифрат зур көч куелган һәм мин аңа ара-тирә күз салгалармын... Шуннан артыгын, кызганычка каршы, вәгъдә итә алмыйм...

*
* *

Суык кыш килде. Юлларны кар басты. Идарәнең кабинетларында көнозын голландка мичләре дөрли, эссе иде. Бозлана башлаган тәрәзә каршында бакчаның матурлыгына, карның чисталыгына сокланып торган Әскәров күршедәге цемент комбинатының көздән бирле реконструкциядә икәнлеген уйлап алды. Бала чактагы шикелле, аның салкын урамга йөгереп чыгасы, йомарлап кар атышасы, иреннәренә тидереп карның салкынлыгын, тәмен татып карыйсы килде, ләкин берничә минуттан инде бу теләге онытылды, юкка чыкты.

Кызу мич каршында тукташтыргалап, ул әкрен генә кабинетның буеннан-буена йөренә иде.

Кира Михайловна озак көтелгән малай тудырып, ниһаять, ялга китте, бер елсыз да эшкә чыкмас әле.

Дамир Әхәтович гомере буе эшнең сыйфаты да, күләме дә бары тик аның үзеннән генә торуына күнеккән иде. Ә менә хәзер, идарә күләмендәге планлаштыруның серләренә төшенгәч, үзенең генә монда берни дә хәл итә алмавын аңлады. Ул әле кайчан гына ун ел буе төзелештә эшләп, күпме нәрсәгә ирешүе, астан күтәрелүе белән горурлана иде бит. Баксаң, боларның бөтенләй кирәге юк икән ләбаса. Бердәнбер аерма шунда: «планны үтәү», «хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү» дигән шома сүзләрне ул икенче төрлерәк күз алдына китерә, чөнки вакытында планны да үтәде, хезмәт җитештерүне дә күтәрде егет.

— Чиновник, коеп куйган чиновник мин хәзер, — диде ул үзенә беркөн, шаяргандай итеп.

Ләкин аның бу уе бик еш кабатлана торгач, инде алай ук көлке дә тоелмый башлады.

Атналык план үтәлеше сводкасын хәзерләү, югарыдан төшкән планны участокларга бүлү, төрле формалар буенча отчетлар төзү кебек эшләрне, берәр еллык курс бетерсә, табельщица Юлия дә рәхәтләнеп башкарган булыр иде. Ә моннан артыгы барыбер Әскәровтан тормый. Еллык план беренче квартал азагында гына килеп төшә, һәм аның ел дәвамында берничә тапкыр үзгәрми калганы юк. Ел уртасында планлаштырылган объектларның техник документациясе юк икәне ачыклана, ә документациясе булган объектлар көтмәгәндә финанслаудан туктатыла. Әскәров эшләгән шушы дүрт ел дәвамында гына да төзелешне бәяләү критерийлары өч тапкыр үзгәрде, таләпләр дә капма-каршы куела килде. Үзенең ни булса да үзгәртә алмаячагын тоеп, зур машинаның винтигына әвереләчәген күреп, Дамир Әхәтовичның көннән-көн күңеле суынды, ул эштән бизә башлады.

Әгәр Әскәров бу уйларын элекке бригада егетләренең берәрсенә сөйләсә, тегесе, мөгаен, болай гына дияр иде:

— Куертма, Дамир Әхәтович, урының җылы, чиста, тир дә түк-

мисең, премиясе дә аллага шөкер... Ни кирәк сиңа тагын? Урының, туган, көнләшеп туймаслык...

Тикмәгә генә күздән бирле төшләренә Дала керми иде шул аның. Дамирны тагын бер нәрсә борчый иде. Соңгы вакытларда ул үзенең бөтенләй шәһәр кешесе түгеллегенә ышанды. Утыз биш яшьтә бик тә сәер ачыш иде бу аның өчен.

Армиядә сайлап тору юк, шәһәрнекеме, авылданмы — кая эләксәң, шунда хезмәтен дә итәсең. Соңрак, бригада белән дигәч, ул аерылырга, комсомол путевкасыннан баш тартырга кыенсынды. Ул чакны да Далага кайтып урнашу турында хыяллана иде бит, соңгы елны туган җире төшләренә дә кергәләде.

Аннан вакыт тәгәрмәче кызурак әйләнә башлады, йокысы да тәүлеккә биш сәгатьтән ары тими иде. Эш белән, уку белән башың тулган, тирә-ягыңда нләр барганын күрмисең дә.

Шулай йөгерүдән соң кинәт туктап, як-ягына каранса, ят җиргә килеп чыкканын абайлады. Юк, бу еллар, әлбәттә, заяга үтмәде, ул аларны кызганмый. Бөтен җанын-тәнен биреп эшләде. Укуын тәмамлады, бу да ни җитте эш түгел. Ә Маша? Аны да ул биредә тапты бит.

Гомерендә беренче буларак ул үзенең җирдән аерылганын, бишенче катта яшәгәнен тойды, аста күгәрешеп беткән гаражлар кысанлыгында кечкенә генә ишегалды күренә. Нәкъ менә шул минутта кечкенә улы Зарикны кызганып куйды Дамир — нәрсә күреп үсә бу ишегалдында бала?

Шәһәр кешесе булуга карамастан, ул үзе театрал да, футболга табынучы да булмады. Битарафлыктан түгел иде бу, әлбәттә, ничектер тормышы шулай корылды. Һәм ул моны уйлап җанын талкымый иде. Ә менә шәһәргә ул гашыйк та, сөймәс дәрәҗәдә дошман да түгел. Моны аңлау авыр — алар бер-берсенә битараф иделәр. Хәтта кайчандыр үзе төзегән йортлар да аңа шатлык китерми, үзләренчә мөстәкыйль тормыш белән яши бирәләр. Әгәр бер көнне исенә төшеп, үзе тырышып төзегән стенаның яки утырткан рамның ни хәлдә икәнен күрәсе килсә, һәм шул ният белән берәр квартирага килеп керсә, бу сәер тоелмас идемени? Бәлки, диванага санап, аны бөтенләй кертмәсләр дә иде әле.

Ә менә Далада сиңа өй салган кеше гомергә онытылмый. Кыш уртасында, яз көне өеңдә мич чыгарган кеше килеп кереп, ничек тартуын сорашса, моңа берәү дә сәерсенмәс, киресенчә, миччене кадерле кунак итеп каршы алырлар, хөрмәтләп түргә утыртырлар.

Институтта укыганда бәйрәмнәрне, ял көннәрен Дамир я китаплары белән, я гаилә мәшәкатьләре белән уздыра иде; башка көннәрне соңарып, улы йоклагач кына кайта, шуңа малай тансык иде. Шулай итеп, үзе дә сизмәстән, ул бригада егетләреннән ераклаша башлады. Кичләрен бергәләшеп телевизор карарга да, бәйрәмнәрдә бер өстәл янына җыелырга да вакыт тими. Ә яңа эшкә күчү аны дусларыннан тагын да аера төште.

Кайбер аралашучан кешеләр бәлки утыз яшьтә дә яңа дуслар табадыр. Ләкин аның кичә телевизордан күрсәтелгән концерт турында сәгатьләр буе сүз көрәштереп утырасы килми иде. Бу — әйтер сүзе юклыктан да түгел (хәзер һәркемнең әйтер сүзе бар), ә фәкать үзенең һәм кешенең вакытын әрәм итәсе килмәүдән иде булса кирәк. Аннан соң компания белән салат оливье ашау өчен шәһәр бетереп яшел борчак эзләүне, ә инде табып кайткач, күкрәк киереп, җәмәгать интересларын кайгыртучы герой сыйфатында йөрүләрне аңламый да, теләми дә иде ул.

Идарәнең хатын-кызлары затлы күлмәкләрен буяудан, прическаларын бозудан куркып, бердәнбер ир заты буларак, аннан еш кына

югары шүрлектә яткан папкаларны алып бирүне сорыйлар иде. Күлмәгегез популяр җырчыныкыннан бер дә ким түгел икән, тик җырчы аны эстрадага чыкканда кия, дип әйтәсе бик килсә дә, Әскәров дәшми, түзә иде. Ләкин кайбер зирәгрәкләре аның күзеннән: «Эшкә эшчәрәк киенергә кирәк», — дигәнне аңлыйлар иде, ахрысы. Мондый шартларда яңа эштә каян килеп аның дуслары булсын да, ничек итеп беренче елны ук хатын-кызлар аны үзара «Сытык чырай» дип йөртмәсеннәр икән?

Шулай итеп, Әскәров гомеренең уртасына җиткәч кинәт үзенең кадерле почмагы — туган җире Дала бар икәнен исенә төшерде. Анда Дамирны аңларлар, көтеп торалардыр кебек тоела иде аңа.

Барыр кешесе, чакырыр кунагы юк, имеш. Поселокның үзендә генә дә уннан артык туганы, балаларын да исәпкә алсаң, санап бетергесез якыннары бар түгелме соң? Гомерең туйга йөреп кенә үтәчәк. Их, бер кайтып, онытылган «Бишле бию»не сиптерәсе, я булмаса кыңгыраулы тальян гармун көенә шаян такмаклар әйтәсе иде! Ә янында, малай-шалайлар белән шаярып, кулына бер кантар чәкчәк тоткан Заригы йөрер иде.

Авылның урамы саен Зарикның абыйлары, апалары булыр иде, алар, әле мыек та чыгып өлгермәгән абыйлары, малайны йөзәргә дә, чаңгы шуарга да, явымлы көнне учак ягып, шыртлака белән итләч жумбадан менә дигән уха пешерергә дә өйрәтерләр иде, әлбәттә. Ул малайларга ияреп Илеккәме, күлгәме куна барыр иде, су кереп, зур әрекмән яфрагы белән чебен-черки кугалап, шыр ялангач комда тәгәрәр иде.

Язга кергәндә инде Дамир Әхәтович үз күңеленең шәһәргә берегә алмавына, көннән-көн эшеннән бизүенә тәмам ышанган иде. Шуңа аның йөрәге бик тә борчулы иде.

Туган якларга кайтып күренү теләге анда көннән-көн үсә барды, һәм ул, хатынын җәйге ялны Далада үткәрергә күндереп, һаман шул киләчәк җәй, тирә-якның матурлыгы турында сөйләнде.

Дөрес, аның инде сигез еллап Далада булганы юк, соңгы тапкыр үги әтисенең хәле начарлангач телеграмма белән чакыртып алдылар. Ул чакны оятлы булуы әле дә булса онытылмый, искә төшеп йөрәген телгәли.

Ул көнне арзанлы яулык бәйләгән, пөхтә итеп киенгән, сабыр холыклы әнисе белән Дамир больницадан кайтып керделәр. Әлеге басынкы, тыйнак бу карчыкның кайчандыр бакчасын да үзе утыртып, ялланып саман кирпеч тә сугып, рус хатыннары белән көнлекләп хәллерәк кешеләрнең саман өйләрен дә агартып йөргән үткен Мәрзия апа булуына хәзер беркем дә ышанмас иде кебек. Үги әтисен җирләү хәстәреннән машина табасы бар иде. Дамир, кесәсеннән акча чыгарып, әнисенә сузды:

— Әни, мин машина табып кайтам, син кабер казырлык бирәр кеше тап инде.

Акчага дип сузылган әнисе кулын, ут тоткандай, кинәт тартып алды да әкрен генә сәкегә ава башлады.

Дамир аңа ташланды, каушап сорады:

— Әни, ни булды?

Мәрзия апаның көтмәгәндә күзенә яшь килде, карчыкларча тавышсыз-тынсыз гына елый башлады. Шунда Дамир нindидер әчке сизенү белән бу күз яшьләренең мәрхүмне жәлләп түгел, ә аны, Дамирны, уйлап акканын абайлады.

— Туган нигездән китеп күпме еллар читтә йөрүең хәерлегә түгел икән, улым, — диде әнисе. — Син бит бөтенләй икенче кеше идең... Бездә ничек күмгәннәрен оныттың дамыни инде шулай...

Авылларында элек-электән кабер казучы юк иде. Бу минутта Дамирның исенә нәкъ менә шул килеп төште. Берәрсенең үлеме турындагы хәбәр таралганның иртәсендә егетләр, малайлар, ир уртасы агайлар һәм аксакаллы картлар — барысы да зиратка агыла башлыйлар. Картлардан берәрсе кабер урынын күрсәтә, мәрхүмнең фәлән җиргә, фәлән кеше белән янәшә җирләгез, дип әйтеп калдырган сүзе булса, васыятен үтәмичә калмыйлар.

Һәркем үз ломы, көрәге белән килә. Халык күп була, кайчагында бер-ике көрәк кенә алырга өлгерәсең. Каты суыкларда бигрәк тә шулай. Мондый эш берәүгә дә авыр тоелмаска, адәмнең актык сыеныр урыны булган кабер җиңел һәм тиз казылырга тиеш. Ничек кенә онытты соң Дамир моны? Күрше малае Бәхет белән ничә тапкыр зиратка барганы бар бит инде, югыйсә. Кыш көннәрендә: «Дамир кая, аның ломы яхшие?» — дип сораштыралар иде картлар. Ә Дамирларның ломнары, чыннан да, менә дигән, патша заманыннан калган, җир казучы булып йөргән бабасының бердәнбер мирасы.

Ялга китәр көн якынлашкан саен Дамирның күңелендә бу хатирәләр күбрәк урын алды, ул Даладагы тормыш турында ешрак уйлана, кабат-кабат үткәннәргә әйләнеп кайта, теге вакыттагы кебек аңгармастан берәрсен рәнҗетүдән курка иде.

Китәргә бер-ике генә көн калып барганда көтмәгәндә Машаның апасы Катерина Алексеевнадан телеграмма килеп төште. Ул Воркутада япа-ялгызы Зарик белән яшьтәш бер малай үстереп ята иде. Сезгә киләм, кояшта кызынасым килә, дип язган. Ул һәр вакыт шулай: еллар буе язмый-язмый да, көтмәгәндә килә дә төшә.

«Тиз күрешеп булмас, ул географик картаның бер читендә, мин — икенчесендә», — дип, Маша Зарик белән өйдә калырга булды.

Поезд кузгалып киткәч, Дамир: «Далага кайтасы ул кадәр озак та түгел инде»,— дип уйлап куйды. Ташкентка хәтле бер сәгатьлек юл, аннан бер тәүлек скорый белән, төшеп бер-ике сәгать машинада барсаң — кичкә өйдә буласың! Бер уйласаң, ерак ара түгел инде, ә менә еллар буе, вакыт юк дигән булып, кузгала алмый ятасың.

Далага ул үзе уйлаганча кичен килеп төште. Европа белән Азия кушылган бу җирдә Әскәровлар борын-борыннан яшәгәнлектән, өйләре дә поселокның нәкъ уртасында, автостанция тирәсендә иде. Үги әтисе, аксак булуына карамастан, поселокның яхшы балта осталарыннан санала иде, шуңа өйләре хуҗасын югалтса да, Украинская урамында әле дә күзгә бәрелеп тора. Соңгы елларны картлач балта эшен ташлады, үзе әйтмешли, сау аягы да тузып эштән чыккан иде. Ул өендә «Заготконтора» өчен тире кабул итеп ятты. Түбә кыегына кадакланган ике тәкә мөгезен күреп, Дамирның йөрәге кысылып куйды.

Борынгыча итеп ишегалды түренә үк кертеп салынган өйнең бикләнмәгән ян капкасын төртеп ачуга, Дамирның күзенә үги әтисе утыртып калдырган сиреньнәрнең зураеп үсеп китүләре чалынды. Ләкин ул бу турыда шундук онытты да. Пардан киенгән ике карчык җәйге веранда ышыгында чәй эчеп утыралар иде. Иске җиз самавар конфоркасында таныш кытай чәйнеге. Бермәлне Дамирга самавар чыжылдавына хәтле ишетелә сыман тоелды. Ул әйберләрен шыпырт кына җиргә куйды да, карчыкларга сиздермәскә тырышып, чемоданына утырды.

Карчыкларның берсе башын күтәрде һәм аны күреп алды:

— Дамирым, улым... — диде ул өздереп.

Тирән галошларына сөртенә-сөртенә, озын итәген җыярга тырышып Мәрзия апа улына ташланды.

— Дамирым, улым кайткан...

Дамир юл тузанын кагып, кием алыштырган арада әнисе белән ахирәте самавар яңарттылар, табага салып тиз генә коймак пешерделәр, күкәй куырдылар.

Аннары өчәүләп верандада һәм ишегалдында ут кабыздылар, тузанны басар өчен комганнан су сиптеләр. Аннан йолдызлар күренгәнче өстәл янында утырдылар. Дамир инде улының үсеп зур малай булуын сөйләде, хатынының нигә кайта алмавын әйтте, ә карчыклар тиз күрешергә насыйп булмас инде дип, башларын чайкап кайгырышып утырдылар.

Алдагы төнне Дамир тамбурда үткәргән иде. Чөнки йокысы килмәде... Поезд өйгә якынлашкан саен ул үзен әнисе, үги әтисе, туган нигезе, дуслары, күршеләре каршында һәм гомумән Дала алдында нindидер гаебе бар сыман тойды... Нидән гыйбарәт ул гаеп, нигә аның җаны тыныч түгел — ул моны әйтеп бирә алмас иде, ләкин бардыр аның гаебе, бардыр... тикмәгә болай борчылмый торгандыр. Уйлый торгач, ул үзен ничектер әсирлектән кайтып килүче солдат кебек итеп күз алдына китерде. Нинди батырлыклар күрсәтеп әсир төшсәң дә, барыбер һәр кешегә нигә әсир булуыңны сөйләргә туры киләчәк...

Шушы тәгәрмәчләр шакы-шокысында үткәргән төндә гаебенең нидә икәнен төгәл белмәсә дә, ул туганнары алдында нindидер аклану сүзләре эзләде... Әнисе ничек кабул итәр? Кайтып күренмәгәненә ничә ел бит инде... Ә менә кайтып кергәч, бернинди үпкә сүзе ишетмәде. Улының исән-сау килеш үзе белән бер өстәл янында утыруына әнисе хәтсез шат, бәхетле иде. Моны күреп Дамирның күзләренә яшь килде, тамагына төер утырды.

Аннары карчыклар, берьюлы исләренә төшеп, юлдан кайткан кунакны ялыктырабыз дип, каблана-кабалана табын җыя, урын җәя башладылар. Ә Дамир бөтенләй арымаган иде, аның таңга чаклы сөйләшеп утырасы килде.

Каз йоны тутырылган зур мендәргә чиста тышлык киертеп маташкан Мәрзия апа:

— Улым, кайсы якка җәйик, — дип сорады.

— Печәнлектә булса, шәп булыр иде, — диде Дамир.

Әнисе белән ахирәте бер-берсенә карашып алдылар.

— Әй, улым, ун ел инде печәнлеккә печән кайтканы юк, исе дә таралып бетте, — диде әнисе һәм шунда улының кәефе кырылганны сизеп өстәп куйды: — Борчылма, борчылма, базар көнне авыл казакъларына әйтермен, берәр йөк кертми калмаслар. Соңгы вакытта атаң авылларда эшләп йөрде, хәзер, аллага шөкер, анда да матур яшиләр, шундый өйләр салдырдылар, бер дә поселоктагыннан ким түгел.

Мондагы чама белән ул шактый соң уянды. Әллә, чыннан да, арылган иде, әллә туган туфрак галәмәте булды — ул торганда ишегалдында морҗасыз самавар аны гөрләп көтә иде инде.

Карчыклар чүгәләгәннәр дә тирән табакта яткан зур кара тавыкны йолкыйлар. Саргылт тиресенә караганда, тавык симез булырга охшый.

Дамирны күреп, табакны читкәрәк этәреп такта кисәге белән капладылар, — төшкә хәтле өлгерербез әле, янәсе...

Таныш юынгыч янда гына булса да, карчыкларның кулга салып юындырасылары килде. Кай арада комган белән эмаль йөгертелгән таз алып чыктылар. Дамир рәхәтләнеп, ашыкмыйча юынды. Сандыкта ятудан саргая да башлаган сөлге белән сөртенгәндә Дамир

станция ягында күккә күтәрелгән кап-кара төтенне күреп алды. «Монда да шул икән...» — дигән уй төтен күләгәсе сыман йөзендә чагылып узды.

Улының төтенгә карап торуын күреп Мәрзия апа:

— Аллага шөкер, биш ел инде үзебезнең әсфәлт заводыбыз бар, — диде. — Юллар хәзер күзгә шикелле, ә элек көн итексез чыкмалы түгел иде. Поселок урамнарына җәеп, инде авылныкына тотындылар. Халык куанып бетә алмый. Безнең урамны бетергәч, шатлыгымнан ике тавык суеп сыйладым үзләрен. Ә алар, ай-ваема карамыйча, ишек төбенә хәтле сукмак суздылар.

Шунда гына Дамир ишегалдына юеш тасма булып сузылган асфальтка игътибар итте.

Көндез ул келәттән бер банка буяу, керосинда җебеп яткан пумалалар табып алды, көрәкнең сабын рәтләде һәм, карчыкларга әйтеп, зиратка китте. Тегеләр аның артыннан озак итеп карап калдылар.

Үги әтисенең каберен ул тиз тапты. Зиратта артык тәрбияләп тотылган яки ташландык хәлгә җиткән каберләр юк иде. Һәрберсенең нәзек арматурадан ясалган чардуганы, баш очында үзенә күрә исем-фамилиясе язылган бетон плитәсе бар. Тик кайберләрендә генә чардуган читенә утыртылган ае яки биш почмаклы йолдызы күренә. Ә үги әтисенең менә (Дамир гаҗәпләнеп карап торды) ае да, йолдызы да бар иде. Ул як-ягына каранды, ләкин берәүдә дә берьюлы ай белән йолдыз күрмәде. Каберне төзәтеп, ашыкмый гына папирос көйрәтте, аннан чардуган буярга керешә. Эшен бетергәч, зиратның кирпеч коймасыннан чыгып, үзән аръягыннан башланган бормалы-сырмалы дала юлына карап торды. Иртәнге таңнан торып Илеккә китәсе бик килсә дә, олы кеше буларак, йорттагы эшләрне онытып, туган-тумача белән күрешмичә елгага чыгып чабуның килешмәсен яхшы аңлый иде Дамир.

Зираттан кайткач ул түбәдә эшләде, кителгән шиферларны алыштырды, телевизорга яңа антенна куйды. Базга төшеп баз стенасының дымнан кубып коела башлаган җирләрен сылады, ныгытты. Баз инде бәрәңге-фәлән саклап булмас дәрәҗәгә җиткән иде.

Иртән торгач рәхәтләнеп бакчада эшләде. Хәзер инде Дамир белгән күршеләр дә, Мәрзия апаның улын белгән танышлар да әллә кая китеп беткән булып чыктылар. Бары да яңалар, авыллардан Далага күчеп килгәннәр. Ә элеккеләре тирә-юньдәге Оренбург, Уральск кебек шәһәрләргә китеп урнашканнар. Күршеләр әлегә Әскәровка сүз катмыйча ишегалларыннан гына күзәтәләр иде.

Кич җитүгә әнисе белән Дамир икәүләшеп кунакка чыгып киттеләр. Артыгы белән дип уйлап алынган бүләкләренең туганнарына җитмәсен абайлап, шактый ук борчыла башлаган Дамирны әнисе тиз тынычландырды.

Сандыклар ачылды, карчыклар аннан ниндидер яулык, косынка, сөлге, ситсы, штапель, мәрҗән, тарак, сабынише әйберләр алып, Дамирның бүләкләре белән аралаштырып үзләренә генә билгеле бер тәртиптә аерым-аерым тезә башладылар. Бу ыгы-зыгыга Дамирның күңеле йомшарып утырды.

Бер көнне кунактан кайтып килгәндә Мәрзия апа улына болай диде:

— Мин, улым, кайтуыңа өмет өзгән идем инде. Кайтып күренүеңә рәхмәт. Менә килен белән баланы гына алып кайтмагансың. Шунысы кызганыч, әтиеңнең дә бик күрәсе килгән иде үзен, үпкәләп йөри күк сизә идем. Үги булса да ул сине бик ярата иде бит, хәле авырайгач, поселок советына барып, өйне дә сиңа яздырып кайтты. Җибәргән акчаңа да кул тидертмәде. Безгә, картларга, болай да җитә, диде... Китеп барганчы кулы эштән өзелмәде мәрхүмнең, тик уты-

ра белми иде шул, урыны изге булсын... Ә акчаң кенәгәдә ята, кирәксә, барып ал...

Ул төнне Дамирның күзенә йокы кермәде...

Алар көн дә самавар янынннан тиз генә купмыйча сөйләшеп утырырга яраталар. Дамир күршеләрне сораша, кичен кунакка барасы туган-тумача белән кызыксына, бергә үскән дус-ишләрен искә төшерә...

— Аларны бик сирәк күрәм, — ди Мәрзия апа. — Күбесе синең кук төрле якка таралышты, кайчак көтмәгәндә Сочига-фәләнгә барышлый бер-ике көнгә күренеп киткәлиләр... Кайбере шушында Актүбәдә яисә Ырынбурда тора, аларны күргәлим... Зур түрә булып, ялтыравыклы машинага утырып йөриләр. Элегрәк сине сорашалар ие, хәзер инде әллә мин аларны танымыйм, әллә алар мине танымый... Бик бирештем соңгы вакытта. Өйдән чыгып йөрүем дә исәпле. Менә Бәхет кенә күргән саен сәлам әйтә.

— Бәхет?! Әй, аның безнең Монголдан күргәннәре! Әни, Монголны хәтерлисеңме?

— Хәтерләми соң, хәтерлим... Син шәһәргә киткән елны ул поезд астына керде, сиңа язмадык кына...

— Бичара... Ә Бәхет кайда эшли?

— Элеваторда, механик.

— Ул укыдымыни?

— Юк, улым, укымады, аңа укырга туры килмәде, ул бит ундүрт яшеннән элеваторда, шунда үсте. Ә яңа элеватор аның белән үсте дисәң дә була. Солдат киемен дә салмыйча, армиядән кайтканның икенче көнендә үк иске эшенә урнашты. Ул бит слесарь. Үзем дә биш ел анда эшләп чыктым, пенсиягә стаж җитмәгән иде... Күп тә үтмәде, Бәхетне бригадир иттеләр. Җыелыш саен мактамый калмыйлар үзен. Чыннан да, яхшы егет. Төнме, ялмы — бер дә карышуны белми. Карт механик Глухов үлгәч аның урынына кемне генә куеп карамадылар монда. Дипломлы берәрсе килә дә ярты ел, күп булса бер елдан эшнең бөтен рәтен җибәрә. Андый чакта инде егетне тиешле срогын эшләттерү кайгысы түгел, ничек котылу җаен карыйлар... Икенчесен көтәләр, бусы иплерәк булыр дип өмет итәләр. Ә бәлки бушаган урынга шәһәр үзе җибәрә торгандыр. Законы шундый, күрәсең, һәр дипломга урын тиешледер... Шулай... — Мәрзия апа бераз уйга чумып утырды. Аннан сүзен дәвам иттерде: — Инженерның яңасы килгәнче эшне Бәхет алып бара иде. Безнең поселок яшьләреннән дә механикка укыганнар булгандыр, югыйсә, әмма берсенең дә әйләнеп кайтканы юк әле.

Шулай итеп, бер-бер артлы биш механикны озаттылар. Бер вакыт райкомда кемдер өстәл сугып: «Җитте! Безгә диплом кирәкми, лаеклы кеше кирәк», — дигән. Шул көннән Бәхет механик булып китте. Узган елны өлкәнең ярты ашлыгын безнең район тапшырды. Бәхеткә дә орден бирделәр...

Төннәрен Дамир еш кына уянып киткәли, караңгыда озак уйланып ята; аннан мендәр астындагы фонарен алып, какшаган баскычны шыгырдатып печәнлектән аска төшә. Тавыш-фәлән ишетеп уянса, әнисе күрмәсен дип, кое бурасы артына чүгәләп сигаретын тарта да урамга чыгып китә.

Уйларына чумып көзге төшләрендәге кебек Украинская урамының буеннан-буена, баганадан-баганага, кирпеч заводыннан автобазага кадәр юлны йөреп кайта. Бу урам әйләнүләре нәрсәсе беләндер элек кухняда үткәргән йокысыз төннәренә охшаган иде булса кирәк.

Аерма тик шунда: ул чакны Дамир гел Даланы, әнисен уйласа, хәзер исә үзенең өйдә калган якыннары — хатыны һәм Зарикы турында уйлый иде. Уйлары, тигез генә агылмыйча, әледән-әле алмашынып тордылар. Күтмәгәндә күз алдына зиратта үткәргән көн. Үги әтисенең чардуганына беркетелгән ай белән йолдыз килеп баса. Сурик белән буялган бу йолдыз үз әтисе турындагы уйларын кузгата. Дөресен генә әйткәндә, Дамир аны сирәк уйлый иде. Ул кырык беренченең көзендә туды, ә бер айдан Мәскәү янындагы сугышларда әтисе хәбәрсез югалды. Улы туганны белмичә китте әтисе...

Соңрак, Дамир мәктәптә укып йөргән чакны, ул әнисенең ничектер ачуы килеп: «Кеше шикелле үлә дә белмәде, ичмасам, печтеки генә пенсиясен дә әле бирәләр, әле тыялар», — дип әйткәнен ишетеп калган иде.

Әнисенең ачынып әйтелгән бу сүзләре аның күңеленә үк кереп утырдылар, куркуга төште малай. Мәктәптә берәр анкета кебек нәрсә тутырырга туры килгәндә, кызара иде. «Һәлак булды» дип язарга кыюлыгы җитмәде.

«Хәбәрсез югалды» дигән сүзләрдә ниндидер начар мәгънә бар кебек тоела иде аңа; мәсәлән, качып киткән яисә качып калган шикелле... Бу турыда уйлап ул күп изаланды һәм бер көнне елга аръягында Бәләй картны күреп сорамыйча булдыра алмады. Малай әнисе авызыннан әтисенең урманчы карт белән бер эшелонда китүен ишетеп калган иде.

— И җүләр, җүләр, — дип сүгәргә кереште аны Бәләй карт. Малайның нәрсәдән шикләнүен ул шунда ук сизеп алды. — Мәскәү янында, улым, ниләр генә булмады, алла язмасын... Ә без, төркестанлылар, иң кызу чакны килеп төштек, Мәскәүнең иң җаваплы көннәрендә. Ул тәмугтан бик аз кеше исән чыкты. Хәбәрсез югалган, имеш. Сугышта нәрсә генә булмас: документлары югалып, танымаулары да ихтимал, бәлки, иптәшләре һәлак булып, танырлык кеше калмагандыр... Ул дәһшәттә тимер булып тимер дә эреде... Куй ул җүләр уйларыңны, Дамир, атаң синең кеше артына яшеренә торганнардан түгел иде.

Дамир төнге сәгатьләрдә җан әрнүе белән үз әтисенең кабере турында уйлана иде. Кайда ята икән ул? Исемсез микән? Фанер йолдыз кадакланган кабер...

Күпме еллар үтүгә карамастан, әтисенең каберен эзләтү түгел, архивка хат кисәге дә язып җибәргәне юк. Бәлки күптән инде рядовой Әхәт Әскәровның кайда һәм нинди шартларда һәлак булуы ачыклангандыр.

Караңгы урамда ялгызы гына шушындый уйларга бирелеп йөргән Дамир бите ут кебек янганын сизде. Аңа оят иде.

...Бер атна вакыт бик тиз, сизелми диярлек үтеп тә китте.

— Дамир улым, — диде әнисе бер көнне иртәнге аш вакытында, — атна буе әле түбәдән төшмисең, әле идән астыннан чыгарып булмый, бар, елгага да барып кайт. Шәһәрдән кайтучылар көннәрен шунда уздыра. Бездәге ком Кырымныкыннан да, Балтик буеныкыннан да ким түгел, диләр. Үземнең инде егерме еллап Илектә булганым юк, әмма матурлыгын, алтын ком түшәлгән ярларын әле дә оныта алмыйм. Бар, бар, калган көннәреңдә ял итәрсең, кызынырсың, бәлки таныш-белешләрең дә очрап куяр... Бар дигәч бар!..

Әнисе күкәйләр пешереп, бакчадан тегесен-монысын җыеп, ике литрлы термоска самавардан чәй агызып, шуларны төйнәп яткан арада Дамир улы Зарик белән алдан хәстәрен күреп алып кайткан кармакларын рәткә китерде.

— Дамир, елга бик якынайды, — диде Мәрзия апа азык-төлек тутырган сумканы улына сузып. — Җәяүләп анда хәзер бала-чага да йөрми, велосипедта барырга да иренәләр. Күбрәк мотоциклетта, машинада...

* * *

Һәр иртәне кояш күренү белән Дамир сикереп торып зарядка ясый, су тутырылган мичкәдән билгә кадәр юына һәм, әнисен уятмаска тырышып, шыпырт кына кухняда капкалап ала.

Ян капкадан чыгып барганда үзләренең сыеры булмавы исенә төшеп үкенә, менә хәзер рәхәтләнеп көтүгә илтер иде бит, югыйсә. Күрше-күләндә дә сыер тотучы күренми. Поселокта хәзер, элеккеге шикелле, кәҗә белән сарык көтүе дә юк икән.

Йөрер болыны, туйдырыр азыгы булмагач, каян килеп көтү булсын ди инде! Зират артыннан башланып киткән, элек көтүләр йөргән, ә хәзер исә юллары гына калдырылып елгага кадәр тоташ сөрелгән даланы Дамир үз күзләре белән күрде түгелме соң? Хәтта язын су астында калып, җәйләрен малай-шалай тәгәрәп уйнаган болыннар да актарылып, кара җиргә әйләндерелгән. Анда-санда тишелеп, уйдык-уйдык булып утырган солы басуы язын чәчкән кадәр орлык бирмәсә дә, үҗәтләнеп, чәчү мәйданнарын үстерү планын үтәү йөзеннән ел саен сукалыйлар да, чәчәләр дә икән бу җирләргә.

Ә печәне? Колхозда эшләгән кешенең әле ничектә печән юнәтү өмете киселми, ә поселок бит район үзәге, монда, саный китсәң, үз хуҗалыклары белән көн күрүче эшче һәм хезмәткәрләр колхозчыга караганда ун тапкыр күбрәк. Печәнгә дә хәзер элеккеге шикелле җыйнаулашып йөрмиләр икән, ун ел инде печән сату катгый рәвештә тыелган.

Кайчагында ерак авыллардан берәр машина табып була булуын, әмма аның хәзерге бәясе теләсә кем алырлык түгел икән, бигрәк тә пенсионер ише халыкка. Шулай итеп, Дала тирәсендә дә терлек саны елдан-ел кими бара икән.

Ниһаять, Дамир елганың машина тавышларыннан ераграк җирендә бер урын сайлап алды. Урынны ул көне буе диярлек эзләде — елга бик тә саеккан, текә ярлары утырган, комлы сөзәк яры да шактый киңәйгән иде. Кызынып ятканда кешеләрдән ишетеп калды: Актүбә һәм Алга кебек шәһәрләрнең металлургия һәм химия комбинатлары елга суын чамадан тыш чөмерәләр икән. Җитмәсә ул шәһәрләр күпме чүп-чарын, пычрагын да шушы елгага агыза ди. Инде елга, барысына да ярарга тырышып, тәмам хәлдән тайган, кеше ярдәменнән башка аякка баса алмас хәлгә килгән иде.

Элекке кебек кышлары явым-төшемле булсын иде, ичмасам, соңгы елларда анысы да бу тирәләрдән качты бит дигән сүзләр дә ишетелгәләде.

Иртәләрен Дамир кармак салып утыра, чабак, кызылканатлар токталый, ләкин шушы тыныч сәгатьләрдә дә балык уйнамавын күреп көенә иде. Ә элегрәк нинди чуртаннар, сазаннар бар иде бу суда, шуларның уйнавын рәхәтләнеп күзәтә идең...

Төш җитәрәк Дамир су кереп елга буенча өскәрәк менеп китә иде. Бара торгач, урман эченә килеп керә дә зур агачлар күләгәсенә сузылып ята. Беркөнне шулай ял итүчеләр компаниясенә барып юлыкты. Бу урында Илек төбенә җитмәслек тирән була иде. Малай чакта алар нәкъ менә шушында коеналар, кайбер тәвәккәлрәкләре йөгереп килеп биек ярдан сикерергә дә ярата иде.

Ун-унике кешедән торган компания Әскәровны шатланып кабул итте — футбол уйнарга кеше җитми иде. Каршы якның биек ярында сөт төсле ике «Жигули» һәм берничә мотоцикл күреп, Дамир болар бергә килеп, бергә китә, ахры, дип уйлап алды. Компаниядә барысы да диярлек Дамирдан бераз яшьрәкләр иде, тик берсе генә (бирелә аның сүзе сүз икәне сизелеп торды) аннан өлкәнрәк булыр; анысына Станислав Михайлович дип дәшәләр иде. Сөйләшә торгач, барысының да Дала егетләре икәнлеге ачыкланды, хәзер менә төрле яклардан кайтып ял итәләр икән.

Бер поселокта туып үссәләр дә, Әскәров аларны, алар Әскәровны танымадылар. Ял итү мәсьәләсендә алар бер дә артта калганнан түгелләр булып чыкты: сайлыкта сөрәкәләре җеби, комда ялтырап яткан спиннингларыннан бала-чага күзен ала алмый. Ике өчаяк, котелоклар, примус, термос, хәтта шашлык кыздыра торган җайланмаларына кадәр үзләре белән алып килгәннәр.

Станислав Михайлович беренче көнне үк яшь дуслары исеменнән Дамирны көн дә пешерелә торган ухага чакырды. Компания белән утырасы килгән чакларында ул гел алар янына килеп чыга торган булып китте.

Ухага дип махсус тотылган бер чиләк алабуга белән шыртлака егетләрне бик тә сөендерә, чөнки үзләренең кармак белән утырырга түземлекләре җитми. Уха пешереп, шашлык кыздырып, кыйммәтле коньягын да берәр рюмка җибәргәч, сүз чыгып кына тора: спортмы, театрмы, галәмме — барысы турында да кызып сөйләшә башлыйлар, әмма сүз ахырда барыбер Далага кайтып кала.

Арадан берсе (аны авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты диделәр) күзлеген борын өстенә шудыргалап, әгәр шушы темплар белән барса һәм берәр чара күрелмәсә, бу тирәләрдә әрем дә сирәк үсемлеккә әйләнәчәк, диде. Ә бераздан артык кызып китеп:

— Ә быел берәрегезнең кукчәчәк яки шайтан таягы күргәне бармы? — дип ачынып сорау да биреп куйды.

Икенче берәү (монысы теплотехник булып чыкты) тагын өч-дүрт елдан асфальт заводы поселокның горурлыгы саналган фарсы канәферен бөтенләй харап итәчәк дип, кандидатның сүзен җөпләп утырды. Чөнки завод җиңелдән уйлап, исәпләми-нитми генә торак йортларга якын салынган, җитмәсә, тузан тоткыч та куймаганнар.

Станислав Михайлович (ул атаклы режиссер икән) поселокның Культура сараенда сәхнәне бик начар итеп ясаганнар, дип сөйли башлагач, чал чәчле, зур белемле, яхшы мөгамәләле, бөтен компанияне үзенә каратырлык итеп сөйли белә торган бу сәләтле кеше турында Дамир ничектер ошатмыйча, ачуы килебрәк уйлап куйды: «Сез, Станислав Михайлович, шәһәргә чыгып киткәндә, заманасы бөтенләй икенче иде аның. Сезгә паспорт алыр өчен язу сорап председатель бусагасын әнигезгә шактый таптарга туры килгәндер... Ул чакны төп аргумент итеп сезнең сәләтле булуыгыз түгел, ә бөтенләй башка нәрсә — укып бетергәч туп-туры поселокка кайтып культура һәм сәнгать казанышларын халыкка җиткерәчәгегез куелгандыр, әлбәттә. Бәлки үзегез дә шуны әйтеп ант иткәнсездер әле?!.» дип уйлады. Аннан: «Карале, нигә мин бу интеллигент кешегә бәйләнәм соң әле, ә? — дип Дамир үз-үзен эчтән генә сүгеп алды. — Әллә үзем әүлияме? Минем янда утырган бу тәти егетләр дә дусларына, туганнарына, күрше-күләнгә, мәктәпкә, авыл советына һәм, ниһаять, сөйгән кызына: укып бетергәч кайтам! дип ышандырмаган дисеңме әллә?..»

Менә бит кайттык... Әрмән коньягы белән кәеф-сафа кылып, әллә кайлардан килгән, шушында тир түгеп йөргән колхоз председателен сүгеп утырабыз... Әгәр дә менә шушы акыллы кандидатыбыз

колхозга кайтып хуҗалыкны үз кулына алса, кадерле болыннарны сөрдермичә ике гектар җирне бәлки башка урыннан да тапкан булыр иде. Ул чакта хуҗалык көтүе дә бетмәс, печәне дә табылыр иде. Өйдә сыер асрауның нәрсә икәнен онытмаган да бит үзе, югыйсә.

Шулай итеп, теплотехнигыбыз фарсы канәферен саклап калса, Станислав Михайловичыбыз Даладагы халык театрының данын таратыр, ә менә бу аз сүзле хирургка өлкәдән консультациягә йөрерләр иде. Ә мин үзем, Әскәров... кыскасы, һәркемгә эш табылыр иде, күңел салып тотын гына...

Дамир елга буенда балык тота торган тыныч урыныннан бүтән чыгып йөрмәде. Өч чакрым юлны ул иртә-кич бала чактагы кебек җәяүләп кенә үтә иде.

Һәр иртәне тузаны кутәрелергә өлгермәгән юлга чыга да җиргә сыенган томанга һәм солы кырларына карангалап елга ягына атлый. Кайчак шулай солы уртасына ук кереп китә, начар эшкәртелеп чүп басарга өлгергән кыр буенча бара-бара да ферма янына килеп чыга. Елга турында онытып, озаклап хәрабәләр арасында йөри, тукталып карап тора; еллар үтүгә дә карамастан, әле һаман таралып бетәргә өлгермәгән ферма исе элек монда зур көтүләр йөргәнен, сарык кычкыруыннан, тояк тавышларыннан тирә-юньнең яңгырап торганын хәтерләтә.

Ул шушы тирәдә кайчандыр ап-ак тирмә торганын, бер көнне шул тирмәдән көмеш беләзекләр таккан ягымлы карчык чыгып, аңа әйрән салып биргәнен исенә төшерде. Ләкин ничә килеп тә, тирмәнең кайда торуын хәтерли алмады. Бала чакның озын чакрымнарын үткәндә ул әледән-әле узган тормышына әйләнеп кайта иде.

Әнисе... Кинәт авырып китсә, кем кулына калыр ул? Ялгызы ятмас, әлбәттә, әйбәт кешеләр юк түгел, ләкин аның үз улы, онытгы, килене бар лабаса...

Кайбер көнне юлда Дамир янында берәр машина туктап, шоферы кабина ишеген ача иде дә:

— Әйдә, агайне, утыр, ату Далага хәтле тузан кунар үзеңә, — дип машинасына чакыра иде. Дамир аңа рәхмәт әйтеп җибәрә, ә кайчак игътибар да итмичә, үз уйларына чумган килеш кырыйдан атлый бирә...

Вакыты-вакыты белән ул үзенең каршына малай чактагы Бәләй карт арбасы килеп чыгар дип өмет итә, аны күреп алган карт: «Дамир, сикер арбага, алып кайтам», — дияр төсле тоела иде.

Яңа чабылып, хуш ис аңкып торган печәнгә сузылып яткан килеш, җәйге күкнең эңгер-меңгерендә күренә башлаган сирәк йолдызларга карап, ул бәлки хәзерге көнендә нишләргә кирәген аңлаган да булыр иде.

Хатыны... Иремне укыттым, укуын ташлаттырмадым дип ул шул кадәр шатлана, горурлана ки, ничек итеп инде аңа ак күлмәкне салып рәхәтләнеп спецовка кияр идем дисең...

Өйләре... Ул да Украинская урамында иң матурлардан санала бит. Әскәровлар өе... Әскәровлар... Аның теләсә кайсы шәһәрдә квартирасы булуы мөмкин, әмма әнисеннән соң инде җир йөзендә Әскәровлар өе булмаячак, чөнки өй ул хуҗа исемен йөртә. Бу — элек-электән шулай килгән һәм киләчәк тә...

Көн саен Дамир шушы юлдан өч чакрым араны уза, көннән-көн адымнары «нишләргә? Нишләргә?» дигән катгый сорау булып һаман саен көчлерәк яңгырый.

Русчадан **СОЛТАН ШӘМСЕТДИНОВ** тәрҗемәсе.

## Гамил Афзал

### Канәгатьсезлек хисе

Күз алдымда көзләр, язлар төсе,
Тирә-ягым болын, гөлләр исе;
Ә күңелдә таш гасырдан калган
Иске
Канәгатьсезлек хисе.

Ташлар кисеп, текә тауга мендем,
Учларыма таштай сөял үсте,
Бу тормышның бар серләрен белдем,
Ә күңелдә канәгатьсезлек хисе.

Бит-маңгайны бозлы яңгыр кисте,
Бу йөзгә дә җылы җилләр исте,
Ил алдында кадер-хөрмәт күрдем;
Ә күңелдә канәгатьсезлек хисе.

Бер адымлап һәр көн алга бардым,
Гомер буе җигелгән ат төсле...
Дәрәҗәдән, мактаулардан арыдым;
Ә күңелдә канәгатьсезлек хисе.

...Мин ат булып тусам, булмас иде
Канәгатьсезлек хисе.

### Пасха утравы

Океан уртасында, тозлы суларда,
Йөзек кашы кебек яшел утрау бар,
Пасха утравы ул — телсез моң иле,
Язмышлар төелгән, таш һәм ком иле.

Таш гасыр хакиме чуер таш белән
Башлар сугып ярып тәхеткә менгән,
Баш булып сөенгән, хакимлек иткән,
Кан эчеп күбенгән. Тереклек беткән.

Өстенлек өмете, дан һәм мал исе...
Тәкәббер горурлык, сыешмау хисе —
Ике тәкә башы сөзешкән почмак,
Кеше вакчыллыгы дөрләгән учак.

Кыргый көнчел ачу, мин-минлек янган,
Урман,
кеше,
бәхет — иминлек янган.
Әҗәл бәйрәм иткән упкыннар калган,
Телсез шаһит булып таш сыннар калган.

Бер кәрлә күңелгә байлык күп кирәк,
Урман, сулар, таулар, зәңгәр күк кирәк,
Бар кешеләр иелеп, «Шаһ!» дисен аңар,
Чал дулкыннар килеп баш исен аңар!

Курку белән ачу җинаять кылып,
Баш өстендә йөри агулы болыт...
Җир шары да шулай калмасын иде
Кешесез һәм өнсез каберлек булып!

Океан уртасында, зәңгәр суларда
Йөзек кашы кебек яшел утрау бар,
Пасха утравы ул — телсез моң иле,
Кыяларда елый Тын океан җиле...

## Сфинкс елмаюы

Сүз сөйләү хәвефле, сөялле аяк-кул,
Бил-бөер япмасы киндердән,
Сфинкс йөзенә хәйләкәр, даһи кол
Сихерле елмаю иңдергән.

Агачсыз, үләнсез, үле ком илендә
Тере җан янадыр, көядер,
Кырык гасыр буе Африка чүлендә
Сфинкс елмая нигәдер.

Сфинкс елмая, таш йөздә кинaя,
Карашы мыскыллы, янаулы:
Күрегез, мин монда дүрт мең ел елмаям,
Ә сезнең сәгатьләр санаулы...

Карчыга карашлы баскыннар шомланган
Зәһәрле елмаю алдында.
Чалмалы гарәпләр, греклар уйланган:
«Илаһи кисәтү бар монда».

Сфинкс елмая: — Күзегез кылычта,
Таларга планнар корасыз,
Белегез: хаким дә, закон да, сугыш та
Елмаю алдында коралсыз!

●

Болытлы, яңгырлы кара көз,
Кояшсыз, чәчәксез кич-иртә.
Нигә бу төн кебек кара күз
Талчыккан йөрәкне җилкетә?

Болытлы, яңгырлы кара көз
Саргайган каенны елаткан.
Нигә бу ягымлы кара күз
Елмаяерактан-ерактан?

Болытлы, яңгырлы кара көз,
Җылысыз, кояшсыз бик читен;
Кайда син, тылсымлы кара күз,
Яфраклар үбешкән айлы төн?

## Иҗат

Ат булып йөрдем буранда,
Бүрәнә, кирпеч ташып.
Эт булып өрдем урамда,
Нык басып, горур басып.

Капитан идем, давылда
Корабта торганым бар.
Утын урладым авылда,
Карак та булганым бар.

Генераль планнар корам,
Иң биек үрләр юрап.
Ишек төпләрендә торам,
Мәрхәмәт-шәфкать сорап.

Үлемгә бардым һөҗүмгә,
Җиңелде, үлде Үлем.
Иске окоплар төбендә
Сөякләр ята минем.

Дөньядан киттем, котылдым,
Соңгы кат һава сулап.
Алдадым, оттым, отылдым,
Һәм кабат тудым елап.

Чапайны күрәм төшемдә,
Без менә исән әле.
Солы басуы өстендә
Җил булып исәм әле.

Сандугач килгән чагында
Сайрадым гөлгә кунып,
Мин хәзер Идел ярында
Тирбәләм таллар булып.

## Ностальгия

Кәккүкләр кычкырган чагында,
Иделдән дымлы җил искәндә,
Кайта да, йөри ул авылда,
Яшьләре җитмештә-сиксәндә.

Киң күлмәк, ап-ак йөз, ап-ак чәч,
Камзулы укалы, таңкәле.
— Илле ел чит җирдә интеккәч,
Ни эзләп кайтасың, әйт әле?!

— И улым, гөжләгән уҗымнар,
Учмалар, көлтәләр күңелдә.
Әбиләр, бабайлар моңы бар
Кайгылы каеннар төбендә.

Кырыс як, туң җиргә ятмый кар,
Җир соры, күк соры, көн ятим.
Җилпенә сап-сары яфраклар,
Яфрактай йөрәкне нишләтим?!

Таш кала салдык без далада,
Заводка котлован казыдык.
Тормышлар күңелле анда да,
Тик менә йөрәктә ялгызлык.

Тартадыр туган як моңы да,
Ярлары чирәмле чишмәләр,
Какылы, юалы болында
Җиләкләр исләргә төшәләр.

Таллыкта чалгылар чыңлаган,
Сыерлар мөгрәгән авылның,
Кыз чагым җилкенеп җырлаган
Тургайлы таңнарын сагындым.

Бу илдән бер киткән кеше мин
Уйларым болгавыр елларда.
Кайтам мин, иң изге төшебез —
Зиратка бер ятып еларга.

Калада, оныклар туенда,
Ефәккә төренеп йөрсәк тә,
Кендегең киселгән урында
Сандугач сайравы җирсетә...

## Ачык калган китап

Ачык калган китап ята,
Бәхетләр, кайгылар тулы,
Шаулап үткән гомер юлы —
Ачык калган китап ята.

Ачык калган китап ята,
Изге теләк, кайнар йөрәк
Өметен, сафлыгын сөйләп,
Ачык калган китап ята.

Ачык калган китап ята —
Якты күңел шатлыклары,
Хөсет, күңел баклыклары —
Ачык калган китап ята.

Ачык калган китап ята,
Үксеп елап, яшен сөртеп,
Заманның җанына төртеп,
Ачык калган китап ята.

Ачык калган китап ята,
Кыю яшьлек сүзе булып,
Акыллы карт күзе булып
Ачык калган китап ята.

Ачык калган китап ята,
Кемнеңдер язмышы кебек,
Кемнеңдер ялгышы кебек,
Ачык калган китап ята.

Эдуард Касыймов

# «АХИРИ» ДУСЛАР

әкият



Бүренең ачка интегеп йөргән көне сирәк булмыйдыр.

Шулай, бер бүре, карыны ачыгып, байтак җирләрне айкап йөргәннән соң, сарык көтүенә юлыга. Билгеле инде, аптырап калмый, көтү читендәрәк йөргән бер бәрәнне эләктереп кача да, бик әйбәтләп кенә ялмап куя. Ашап туйгач, куак төбенә ятып йоклый.

Алай да моның йокы симертүе әллә ни озакка сузылмый, бервакыт уяна. Уянгач, бәрәннең калган хәтлесен капкалап бетерә дә үз җаен белеп кенә коры елга буйлата китә. Шунда ипле генә барган чагында, моның каршысына, ләң-ләң өреп, бер көчек килеп чыга. Бүре башын калкытып караса, якындагы басуда ирле-хатынлы икәү урак урып ята. Көчек шуларныкы икән.

Бүре ике уйлап тормый, ун атлам җирне өч итеп, көчек өстенә атыла да аны сыртыннан эләктереп тә ала. Чината-чиелдата алып төшә коры елга ярына. Ләкин кәеф әйбәт булгач, ерткалап ташламый, ычкындыра көчекне. Җибәргәч, ухылдап куя да әйтә:

— Карап-карап торам да, сиңа, көчек, шаккатам: хәлләрең хәрти, ахрысы, тире белән сөяккә генә калгансың. Хуҗаларың әллә юньләп ашатмыймы? — ди.

— Ашатмыйлар шул, — ди көчек, үзе дер-дер калтырана.

— Тunың да ябагаланып беткән, бигрәк мескен күренәсең, — ди бүре.

— Тамагыңа бер туйганчы ашамасаң, синең тunың да шулай булыр, — ди көчек. Инде хәзер бераз хәлгә килә.

— Карале, көчек, мин сиңа әйбәт тун кигезә алам бит, — ди бүре, башын кыңгыр салып кына. — Тик безгә аның өчен ахири дуслар булырга кирәк, — ди.

— Анысы ни тагы? — дип сорый көчек.

— Менә без синең белән, көчек туган, үлеп кабергә кергәнче дус булырга тиешле, — ди бүре. — Безнең нәсел-ыруыбыз бер диярлек, бик борынгыда ата-бабаларыбыз дошманлыкны белмәгән, шулай булгач, синең белән ахири дуслар булып китсәк, беркем дә гаеп итә алмас, — ди.

— Ярар, алайса, — дип килешә көчек. — Ахири икән ахири... Тик син минем тунымны ничек итеп яңартмакчы буласың, ахири дус? — ди.

Шул чагында бүре кыр ягына күз ташлап ала да әйтә:

— Әнә анда синең хуҗаларың урак ура. Аларның суслон төбендә бәбәйләре йоклап ята. Мин шул бәбәйне искәрмәстән генә эләктереп алып китәрмен дә син минем арттан өрә-өрә чабарсың. Син мине куып җиттем дигәндә генә мин бәбәйне ташлап качармын. Менә шуннан соң инде синең хуҗаларың, «Һай, шәп көчек икән бу» дип, үзеңне туйганчы ашатырлар, әйбәт тәрбия кылырлар. Тамагың тук булгач, өстең дә бөтен булыр — тунның өр-яңасын киярсең, — ди.

— Бәбәйне бугазламассыңмы соң син? — дип сорый көчек куркып кына.

— Нишләп бугазлыйм? Аңа тамчы да зыян килмәс, менә күрерсең, — ди бүре. — Тик бер генә шартым бар: соңыннан син үзең дә миңа берәр яхшылык эшләрсең.

— Яхшыга яхшы булу — минем шөгыль инде ул, — ди көчек. — Әйдә, сынап карыйк, алайса, минем карыным бик ач, — ди.

— Бик әйбәт, киттек, ахири дус, — ди бүре.

Көчек хуҗалары янына кайта да, алар тирәсендә бераз буталгач, читкәрәк китеп ята. Ә бүре кача-поса гына икенче яктан суслон төбенә килеп җитә дә, хуҗалар үлле-мәлле урак урып маташканда, көлтә өстендә йоклап яткан бәбәйне эләктереп тә ала. Зыян килмәслек иттереп, чүпрәгеннән эләктерә. Аннары җәһәт кенә коры елгага таба элдертә. Шул чагында көчек посып яткан җиреннән атылып килеп чыга да бик яман өрә-өрә бүре артыннан чаба. Бу хәлне күреп, уракчы ир белән аның хатыны ах итәләр. Аннары:

— Оланыбызны бүре алган, оланыбыз харап була! Һәй-һәй! — дип, ураклырын болгый-болгый болар артыннан йөгерәләр.

Менә бервакыт көчек бүрене куып та җитә. Куып җитеп, тегенең койрыгыннан эләктерим дигәндә генә, бүре бәбәйне ташлап кача. Ул арада хуҗалар да ахылдый-ухылдый килеп җитә. Бәбәйне шундук җирдән күтәреп алалар. Әйбәтләп карасалар, бәбәйгә берни булмаган. Берәр җире канау түгел, сыдырылган төше дә юк. Рәхәтләнеп йоклавын белә. Хуҗаларның исләре китә бу хәлгә.

— Һай, әйбәт көчек тә икәнсең. Бүре хәтле бүрене өркетеп, бәбәебезне исән калдырдың, рәхмәт яугыры! — дип, көчекне дә сөя-сөя күтәреп алалар.

Моның соңында суслон төбенә кире кайталар да, көчекне ашатырга тотыналар. Булган кадәр ипиләрен дә кызганмыйлар, сөт тә эчерәләр. Көчек койрык болгап, чинавын гына белә, үзенчә мең рәхмәтләр укый. Бу эшләр беткәч, хуҗалары янә урак урырга тотына, ә көчек көлтә янында бәбәйне саклап кала. Тамак тук моның, корсагын сыпыргалый: «Ахири дус булып йөрүләре шәп икән. Сынатмады, сүзендә торды, егетләрнең дә егете икән бүре дус», — дип уйлый.

Авылга кайткач, хуҗалар кырда булган хәлне очраган бер кешегә сөйләп бирәләр. Барчасы хәйран кала. Ә көчеккә, билгеле инде, кадер-хөрмәтнең зурысы эләгә хәзер: алдына ипи белән аш та чыгаралар, сөякнең корысын гына түгел, итлесен дә ыргыткалыйлар. Мондый хәлләрдә көчек тазарганнан-тазара бара, атна-ун көн үтүгә, ябагалары коелып, чибәрләнеп китә.

Шулай тук тамак белән матур гына көн күреп ятканда, бер дә бер кичне боларның ихатасына, койма аша сикереп, бүре килеп керә. Көчек шундук һау-һаулап өрергә тотына. Бүре моңа тешләрен шыгырдатып, ухылдап эндәшә:

— Чәбә, тының чыгарма! Ахири дусны шушылай каршылыйлармыни, ахмак! — ди.

Көчек өрүеннән туктап, койрыгын болгарга тотына:

— Танымыйча торам, синмени әле, ахири дус? Ни хәлләрдә йөрисең, сау-сәламәтме? — ди.

— Хәлләр хәл әле монда, — ди бүре. — Бер атна теш арасына берни кергәне юк, үләр чиккә җиттем инде, ахири дус.

— Шулаймыни? Тукта, минем яшереп куйган бер сөягем бар. Хәзер мин сиңа шуны чыгарып бирәм, рәхәтләнеп кимер,— ди көчек.

— Юк-юк, анысы үзеңә калып торсын, рәхмәт, — дип, башын чайкаштыра бүре. — Син теге чакта «яхшыга яхшымын» дигән идең, хәзер син миңа яхшылык кыл.

— Ничек итеп? — ди көчек.

— Менә синең хуҗаңның абзарында әллә нихәтле сарык бар, мин шуларның берсен буып алып китәрмен, син миңа мишәйтләмәссең, ямә.

Бүре шулай дигәч, көчек ни дип җавап бирергә дә белми. Чылбырында тартылып куя да артына утыра.

— Аның өчен хуҗам минем үземне бәреп үтерер ич, — ди.

— Курыкма, дускай! — ди бүре. — Ул сине бернәрсә эшләтмәс. Син бәйдә бит. Бәйдә булгач, ни кыла аласың? Мин сарык бәрәнен эләктереп шылуга, син бик яман иттереп өрергә ябышырсың — шул бик җиткән синнән.

Көчек хәзер колак артын кашып куя да, шыңшынып кына:

— Ярар, алайса, тик син анда бар булган сарыкны буып бетермәссеңме соң? — ди.

— Бетермәм, кайгырма, дус! — ди бүре. — Анда да әле сарыкның зуррагына тимәм. Җегәрем бик чамалы, җиңелрәген сайлармын.

Көчек риза булгач, бүре иплап кенә абзарга керә дә үзенә ярардай сарыкны сайларга тотына. Абзарда сарыклар дөбер-шатыр килә. Бүре берсен, җиңелрәген тотып алып, бугазлый да ихатага чыга. Чыккач, көчеккә әйтә:

— Булды бу, рәхмәт, ахири дус! — ди.

— Элдерт җәһәтрәк! — ди көчек.

Бүре сарык бәрәнен койма аша ыргытып, артбакчада юкка чыгуга, и тотына көчек өрергә, и ябыша чинарга! Атына-бәрелә чак кына чылбырын өзми кала.

Ул арада тавышка хуҗалар да чыгып җитә. Башта берни аңламыйлар. Аннары фонарь яндырып чыгалар. Абзарда сарыклар әле һаман тынычланып бетмәгән, шуларны кереп санап карасалар, бер бәрән юк, җитми. Кире ишегалдына чыгып, койма янына килсәләр, койма тактасында кан эзләре. Шул чагында гына бот чабалар инде болар.

— Һай, бүре кергән икән ләбаса! — ди хатыны.

— Шул нәгъләт эше, тамагына утыргыры, — ди ире дә. — Юк, моннан болай этне бәйдә тотарга ярамас, бәйдә тормаса, бүрегә алай ирек бирмәгән булыр иде, — ди.

Шушы хәлдән соң көчекне бәйдә асрамыйлар инде. Ректә тегендә чабып, монда килеп гел кинәнүдә була бу. Тамак та тук, тун да шәп!

Шулай кинәнеп яшәп яткан чагында бер дә бер кичне янә бүре килеп чыга. Аягын көчкә өстерәп килә. Көчек аптырап кала.

— Бөтенләй бетешкәнсең, ни булды сиңа, бүре дус? — ди.

— Хәлем хәл әле, — ди теге. — Инде атнадан артык тамагыма ризык капканым юк, теге чактагы кебек хуҗаңның берәр бәрәнен алып сыпыртсам гына иңгә-юньгә килермен. Зинһар, юлыма аркылы басма, дускай, — ди.

Көчек бу юлы усал гына иттереп ырлап куя:

— Юк, хуҗама хыянәт итә алмыйм. Бер булды — җитте. Хәзер мин бәйдә түгел инде, сиңа ирек бирә алмыйм, — ди.

— Их, мин иткән яхшылыкны син бик тиз оныткансың икән, — дип чиелдый бүре. — Югыйсә без ахирләр дә бит әле. Шушында тәгәрәп үлим микәнни инде? — ди.

— Юк, — ди көчек, — онытмадым. Тәгәрәп тә үлмәссең, ахири дус. Мин синең тамагыңны туйдыра белермен, сарыкның да кирәге калмас, — ди.

— Ничек алай? — дип сорый бүре.

— Әнә безнең күршедә бик әйбәтләп туй итеп яталар. Шунда кереп тукланырбыз. Мин инде бер сыйланып чыктым, — ди көчек.

Бүре сөенеченнән иреннәрен ялап куя:

— Бик шәп, алайса, минем әле туй ризыгын моңарчы авыз иткәнем дә юк, — ди.

Күршедәге өйгә кереп китәләр болар. Шыпырт кына, мыштым гына. Туйлы өйнең чоланында итнең пешкәне дә, чие дә бар икән, суытырга чыгарылган катырмасы, каклаган казлары, бүтәне. Ике ахири тегесеннән дә, бусыннан да авыз итәләр. Шартлардай булып ашагач, бүре кикереп җибәрә дә:

— Их, эчәселәр бик килә! — ди.

— Эчәбез аны, — ди көчек. — Менә монда нидер бар, әйдә, дус!

Чоланда чиләге белән ачы бал да бар икән. Суытырга чыгарганнар, күрәсең. Чиратлашып шуны чөмерәләр болар. Бераздан бүре:

— Ай-һай, рәхәт булып китте. Туйның сые әкәмәт икән шул! Кая, тагын аз гына чөмерим әле, ахири! — ди.

Тагын чөмерә. Аннары әйтә:

— Их, җырласылар килеп китте әле! — ди.

— Ә нигә, җырлыйбыз аны, — ди көчек.

Шуннан өйалдының бер почмагына кочаклашып яталар да, тотыналар. Тегендә өй эчендә туйчылар җырлый, өйалдында бу ике ахири дус җырлый:

> Сары сандугач микән, кара карлыгач микән,
> Аны үстергән әнкәсе...

Менә бервакыт өй эчендә гармун тавышы тына, җыр да өзелә. Ике дус аңа карамый, үздерепме үздерә: берсе чиный, икенчесе улый. Өйдәгеләр, бу ни хикмәт дип, чыгып карасалар, хәйран калалар.

— Тукта, бу икенең берсе бүре ләбаса! — дип кычкырып җибәрә кияү егет. — Җәһәт ябыгыз капканы! Тот, бәр, үтер! — ди.

Бүре шул чакны гына айнып киткәндәй була. И тотыналар куышырга! Бүре тегендә барып орына, монда килеп төртелә, юк, ычкына алмый. Минут эчендә моны дөмбәсләп үтерәләр. Үтергәч, билгеле инде, тиресен тунап алалар. Аңардан яшь киленгә бик матур яка, кияүгә бик әйбәт бүрек чыга.

Көчеккә ни? Аңа тимиләр. Тию түгел, үтереп мактыйлар: «Бүре хәтле бүрене кочагыннан ычкындырмаган, маладис!» — диләр.

Инде хәзер үзен ике өйләп туендыралар. Дөньяның түмен, рәхәтен белеп кенә яши.

Алай да күршедәге яшь киленнең якасын, кияүнең бүреген күргән саен:

— Әрәм булды ла ахири дус. Шул хәмер дигән нәмәрсә генә башына җитте. Шәп егет иде югыйсә, — дип, дусын кызганып, шыңшып-чиелдап алгалый, имеш.

Әнә шуннан бирле көчек су белән сөтне дә өч мәртәбә иснәмичә торып, эчмәс булган, ди.

Марсель Зарипов

# УТ БРИГАДИРЫ

*Бөтен гомере буе сварщик булып эшләгән дипломлы штурман Андрей Акимович Тригубның документаль фактлар нигезендә язылган тормыш сәхифәләре.*

Минем иң зур кимчелегемне беләсеңме?

— Беләм: яшең олы, башың ап-ак. Бөтенләй бабай булгансың.

— Анысы шулай. Җиденче дистәне тотырып киләм, берни эшләр хәл юк. Ләкин хикмәт анда түгел. Хикмәт башкада — мактанырга яратам. Тел бистәләрен җенем сөйми, буш халык, зарарлы халык, ә минә эшләнгән эш белән мактанып алырга яратам...

Без кечерәк заводны хәтерләткән мастерской буйлап зур-зур станоклар, гөжләп торган аппаратлар яныннан узабыз, күз камаштыргыч сварка утлары белән ияләнмәгән кешенең котын алырлык цехларны карап йөрибез.

— Күрдеңме? — дип кычкыра минем колакка Тригуб, сварка эшенең, иске детальләрне ремонтлауның нindидер хикмәтләрен аңлатырга тырышкандай. — Биредә углекислый газ белән эретеп ябыштырабыз. Менә монда флюс кулланып эшлибез. Арырак — плазма белән кисәбез. Искиткеч! Уникe мең градус! Эх дигәнче кисә дә ташлый! Компрессорлар заводында мондый җайланма аргон белән эшли. Аргон — кыйммәтле газ. Аны, машина җибәреп, Одессадан кайтарырга кирәк, бер смена эшләрлек баллон уникe сумга төшә. Ә мин плазманы гади һава белән эшләтәм. Күптән түгел авиация заводыннан бер иптәш бездә булып китте. Фырт киенгән, галстуктан. «Плазмагызны безгә бирегез. Безнең самолетлар ясыйсы бар, сез аны сабан төрәннәре кисәргә тотасыз», — ди. «Мин ул төрәннәр белән җир сөрәм, икмәк үстерәм, — дим. — Ашарга ипи булмаса, синең самолетың кемгә кирәк», — дим.

Тригуб үз стихиясендә, сварка һәм ялкын тирәсендә гүзәл! Ул туры, төз бәдәнле, хәрәкәтчән; каты, нык басып йөри; тик яңа яуган кар кебек ап-ак чәче һәм тырышып берәр җитди кәгазь язганда калтырый торган бармаклары гына аның күп гомер кичергән өлкән кеше булуы хакында сөйлиләр.

Тригуб бик яшьли үз тамагын үзе туйдыра башлый. Шуңа күрә эшсез яшәүне күз алдына да китерә алмый. Хезмәт сөючәнлеге аңарда тормышка кырыс, таләпчән мөнәсәбәт тәрбияли, аның фикер һәм гамәлләрен, яшәү принципларын һәм гадәтләрен билгели. Ул әтиәнисен бөтенләй хәтерләми, күп еллар элек, гражданнар сугышы чорында ук, алар бер-берләрен югалталар һәм шуннан соң беркайчан да очрашмыйлар. Шул авыр һәм кырыс елларда ятим калган барлык балалар кебек үк, ул вагон һәм вокзал идәннәрендә ауный, бик үк гадел булмаган юллар белән ризык таба, йөри торгач, чекистлар кулына килеп юлыга, балалар йортына эләгә. Биредә ул, колга буе малай, хәреф танырга өйрәнә, биш елда җидееллык мәктәпне тәмамлый. Аннан елга техникумының пароход йөртүчеләр бүлегендә укый, аны бетергәч, Иделдә йөзә торган «А. С. Пушкин» пароходына өченче штурман итеп эшкә билгеләнә. Беренче җәйдә үк Тригуб Астраханьга эләгә — «А. С. Пушкин» пароходы вак-төяк ремонтка туктый, пассажирларын төшереп, иске, әле Нобельләр үк төзеткән причалларга килеп якорь сала — һәм шунда яшь штурман беренче тапкыр зәңгәр сварка утларын күрә... Адәм баласының утлы дуга ярдәмендә ике кисәк металлны ялгавын, ялгаган урында тимернең тоташ урынга караганда да ныграк булып чыгуын күреп сихерләнгән Тригуб пароходтан китә. Карл Маркс исемендәге пароход ремонтлау заводында аны автоген участогы белән бер түбә астында урнашкан ярдәмче цехка нормировщик итеп алалар. Буш минут чыгуга, ул зәңгәр яшеннәр патшалыгына чабарга гадәтләнә.

Яңа нормировщикның, үз эше белән шөгыльләнмичә, гел читтә йөрүен сизеп алган завод директоры Николай Гаврилович Кострико көннәрнең берендә сорарга була:

— Син нигә монда чуаласың? Эшең юкмы әллә?
— Кызык ич.
— Эшләп карарга телисеңме?
— Булырмы икән?
— Тырышсаң, булырга тиеш!

Ике көннән ярдәмче цехның нормировщигы Тригуб махсус приказ белән автоген участогына күчерелә, дипломлы штурман өйрәнчек сварщикка әйләнә. Аңа тимер койма белән әйләндереп алынган мәйданчык — эш урыны, аппарат, электродлар, зәңгәр пыялалы маска бирәләр, өйрән диләр. Бәхете бар икән егетнең, өч айдан аны Днепропетровск, Ростов, Харьков, Мариуполь (хәзерге Жданов шәһәре), Саратов кебек шәһәрләрдәге чуен, корыч коя торган заводларга тәҗрибә алырга җибәрәләр. Аннан ул яңа белем туплап кайта, кайтуга үзен мастер итеп куялар!

Сварка эшенең остасы булып танылган Тригубны утыз алтынчы елда Печорага, ерак тайгадагы Шелья-Юр пароходлар ремонтлау затонына эшкә җибәрәләр. Ике ел күп вакыт түгел, әмма яшь мастер вакытны бушка уздырмый, төрле металларны эретеп ябыштырырга өйрәнә. Тыңлап карауга, үсемлекләрнең күзгә күренмәс тукымалары буйлап җирдәге дымның ничек күтәрелгәнен, яфрагын, сабагын күреп, җимеш һәм игеннәрнең ничек сулавын, җаена карап ни эшләргә кирәген белгән яхшы бакчачы, игенче кебек, Тригуб үз һөнәренең бетмәс-төкәнмәс нечкәлекләрен үзләштерә.

Тригуб төньякта эшли башлаган беренче җәй. Нарьян-Мардан Печораның югары агымына хәтле йөри торган «Совет» пассажир пароходының ишкеч валы сынып чыга. Архангельскидагы төп базага хәтле — 900 километр ара. Аннан яңа вал китертү өчен ким дигәндә бер ай вакыт кирәк, шуның белән бу яклардагы кыска навигация тәгәлләнә дә диган сүз.

Авария булгач, Тригубны да йокыдан уяталар. Төнге ике булуга карамастан, урамда яп-якты. Затонда беркемгә йокы юк. Начальник бүлмәсенә халык тулган: пароход командасы, ремонтчылар... Әрләшәләр, бәхәсләшәләр. Югыйсә, ике генә юл бар: я базадан яңа вал китерергә, я сынган валны ялгап карарга. Тригубтан, сынган валны ялгый аласыңмы, дип сорыйлар. Ә ул, тәвәккәл җан, тота да алам, дип ычкындыра.

— Булырмы икән? Гарантияң бармы?

— Бар — алтмыш процент.

Әлеге алтмыш процент гарантияне Тригуб каян алып әйткәндер, алла белсен. Аның беркайчан да валлар эретеп ябыштырганы булмый. Чөнки пароходның куәтле машиналарындагы көчне ишкеч көпчәкләргә тоташтыра, авыр судноны агым уңаена гына түгел, агымга каршы да йөртә ала торган бу төп детальне һәрчак тоташ металлдан ясыйлар. Нәрсәгә ышанган ул — сукыр бәхеткәме, әллә үз сәләтенәме — әйтүе кыен.

Башта Тригуб электродлар белән кайнаша. Пыяла төя, акбур урынына теш порошогы, су урынына агач җилеме алып, измә ясый, тимер чыбыкларга шул измәне сылый... Өч көн буе зәңгәр башлыгын салмый, баш күтәрми эшли Тригуб. Башта электродын бер яктан «төртә», эсселек үзгәреп торудан вал бөгелмәсен өчен, затон эшчеләре арасыннан сайлап алган ярдәмчеләренә «әйләндерегез!» дип кычкырып тора һәм, бер генә мизгел дә тукталып тормастан, каршы яктан ябыштыра башлый.

Ә вал барыбер туры чыкмый, бер очы икенчесенә караганда җиде миллиметрга читкәрәк авыша. Болай караганда тигез дә кебек, төбәп карасаң, шунда ук сизелә. Пароходта, үз урынына куйгач нишләр? Машинаны алдый алмыйсың, ул төгәллек ярата!..

Тригубның шуннан соңгы язмышы нинди юлдан китәр иде, әйтүе кыен. Мондый уңышсызлыктан соң, теләсә кайсы остаңың да күңеле сүрелүе мөмкин. Очраклы хәл ярдәм итә — затонда бик шәп тимерче табыла.

Петр Игнатьевич дигән кеше була ул, заманында ерак төньякка урман кисәргә килеп, ахырдан шунда төпләнеп калган. Аның кушуы буенча, валны алачыкка алып килäләр. Ярты тонна чамасындагы авыр тимерне күтәреп учак өстенә куялар, каен күмере белән күмеп, утны дөрләтеп җибәрәләр.

Хәзер тимерче эшенең нечкәлекләрен онытып баралар шикелле. Алачыкларда мичкә ни әләкте шуны, күбрәк ташкүмер вагы салалар. Элекке осталар чын күмернең кадерен әйбәт белгәннәр, каен күмерен — үзенә, нарат күмерен үзенә аерым яндырганнар. Уралдагы чуен коючылар, зур басымга түзәрлек сыгылучан металл кирәк булганда, мичләргә күмер вагы сипкәннәр, һава өрдерүне соң чиккәчә көчәйтеп, ялкын өстенә тузы алынмаган чи каен күсәк тыкканнар. Хикмәт шунда, наратта металлның уалучанлыгын арттыра торган углерод бар, корымсыз янган каен исә аны чиста һәм бөгелүчән итә.

Ниһаять, валның ялгаган җире пешкән чия төсенә кергәч, Петр Игнатьевич аның бөгелгән төшен яны белән сандал өстенә алып куярга куша — һәм педальга баса. Шалт! Үлчәп карыйлар, тагын сугалар. Аннан тагын, тагын бер сугалар. Булды! Ура! Җиңү!.. Тригубның, шулай дип, бик кычкырасы килә, ләкин хәзер инде ул кушканны үтәп, ярдәм итеп торучы гына.

Ике тәүлектән валны механика цехына илтергә алып киләләр. Тригуб токарьның ничек итеп детальне станокка беркеткәнен, штангенциркуль белән үлчәгәнен, кискеч җайлаганын күзәтеп тора. Йо-

мычка хасил булырмы, әллә беренче әйләнештә үк сынып төшәрме— шуны карап тора. Гадәттә, уалучан корычтан — сына торган, сузылучанлыннан әйләнмәле йомычка хасил була. Станокны ходка җибәрәләр, йомычка сынмый, кискеч астындагы вал да чиста, тапсыз була. Димәк, металлның структурасы тигез дигән сүз... Әмма Тригубны котларга ашыкмыйлар әле. Иң мөһиме алда була, ике кисәктән ялганган вал урынына куйгач нишләр — шуны тикшерәсе кала. Валны куялар. Беренче көнне үк агым уңаена биш, агымга каршы биш километр юл узалар, ахырдан подшипникны ачып карыйлар — һәммәсе тәртиптә була. Күрәсең, артык төпченүчән, бәйләнчек кеше булгандыр инде, механик тагын бер сынау уйлап таба:

— «Үле йөрештә» сынап карарга кирәк, — ди.

Тәгәрмәч калаклары суны күбрәк ишә алсын өчен, барлык мичкәләрне, кап һәм капчыкларны бер якка өеп, пароходны янтайталар, аннары, аны борыны белән ярга терәтеп, машиналарны бөтен көчкә эшләтә башлыйлар. Тулы көчкә гүләгән машиналар ике сәгать буена пароходны ярга, яр исә, көчле басымга бирешмичә, аны артка этәрә. Сварка түзә! Команданың ничек итеп Тригубны ярга күтәреп чыкканын сөйләп тормыйм, минем өчен сварщикның шул чактагы хис һәм фикерләрен, рухи халәтен аңлау мөһимрәк. Аустерлиц янындагы җиңүдән соң Наполеон Бонапарт үзен ничегрәк сизсә, Тригуб та шундыйрак халәттә була, горур һәм бәхетле була.

Шелья-Юрда бер атналап торганнан соң, «Совет» пароходы кабат Нарьян-Марга китә. Ә Тригуб, сварщик буларак, үз гомерендә беренче бүләген ала — кулына исеме язылган алтын сәгать тага.

*
* *

Сугыштан соң Тригуб Казанга килә, конвейерлар, асылма юллар эшләп чыгара торган иске, инде революциягә хәтле үк салынган «Урак һәм чүкеч» заводына урнаша. Үз эшен белә торган шәп оста бередә дә мактанып алырга ярата торган иске гадәтенә турылыклы кала, тиз арада иптәшләренең хөрмәтен һәм ихтирамын яулый. Ул беркайчан да әзергә хәзер булып утырмый, завод эчендәге субординация дигән нәрсә белән санашып тормый. Әйтик, гади эшче буларак, минем вазифам цех начальнигына, директорга хәбәр итү, ә калганы алар эше, дип яшәми. Үзе башкарган эшкә үтә таләпчән карый, алдына бары тик олы, хәтта көч җитмәслек максатлар куеп яшәгәндә генә кешенең тормыштагы абруе, дәрәҗәсе күтәрелә дип саный.

Алдарак мин, гомере буе сварщик булып эшләгән дипломлы штурманның гыйбрәтле тормышы турындагы бу язмалар документаль характерда булыр дип вәгъдә иткән идем. Әйе, бередәге фактларның һәркайсы документларга нигезләнә. Алар — авторның иң тулы, иң тәфсилле аңлатмаларына караганда да күбрәкне сөйләрлек, чөнки берсендә дә күп язмаларда очрый торган төп кимчелек — булмаганны бар дип раслау, уйлап чыгару юк. Шушы төштә, Тригубның яшәү принципларын аңлар өчен, аның архивыннан берничә мисал китерү урынлы дип уйлыйм.

«Казанның «Урак һәм чүкеч» заводы эшчесе ип. Тригуб, яңа сварка аппаратларын эшләтә башлау өчен кирәк булган ток чыганагы һәм кремнемарганец чыбыклар табу мәсьәләсендә ярдәм итүне сорап, «Советская Россия» газетасына үтенеч белән мөрәҗәгать иткән иде,— дип яза Бөтенроссия халык хуҗалыгы советының председатель урынбасары В. Ефремов.— Халык хуҗалыгына тагын да җитештерүчән сварка аппаратлары кирәклеген искә алып, Бөтенроссия

халык хуҗалыгы советы Росглавэлектроснабсбытка «Урак һәм чүкеч» заводы өчен ВС-200 маркалы биш турайткыч бирергә боерды.

5 июль, 1961 ел».

Газеталар, төрле хуҗалык оешмалары белән элемтәдә тору эшкә нык ярдәм итә, шул ук вакытта күп кенә мәшәкатьләр дә тудыра. Берәр кызыклы фикерен, ниятен тормышка ашыру артыннан йөргәндә, Тригубка беркемгә билгеле булмаган эчке серләрен ачарга — нәрсә эшләгәнен, ниләр башкарырга җыенганын сөйләп бирергә туры килә. Нәтиҗәдә аны тинтерәтүче кешеләр күбәя, һәркайсы өйрәт ди, киңәш сорый.

«Казандагы «Гаро» заводы углекислый газ белән эретеп ябыштыра торган шланглы ярымавтомат кайтарткан иде, әмма белгеч булмау аркасында, аны эшләтә алмый тора. «Гаро» заводына техник ярдәм күрсәтү өчен ип. А. А. Тригубны җибәрүне сорый.

Завод директоры С. Феденев».

Үтенеч кәгазенең бер почмагында «Урак һәм чүкеч» заводы директорының резолюциясе:

«Ип. Тригуб! Дүшәмбедән 3 көнгә рөхсәт. Иптәшләргә ярдәм итегез.

14 сентябрь, 1962 ел».

*
* *

Яхшылыктан яхшылык эзләмиләр, диләр, әмма яхшылыкның үзен ничек аңлыйсың бит — хикмәт әнә шунда. Тирә-юньдәге кешеләрнең сиңа карата булган кадер-хөрмәте дипме, әллә кешене беркайчан да ахыры булмый торган, аны ачышлар юлына этәрә торган яңа эзләнүләр бәхете дипме?!.

Озын сүзнең кыскасы шул, «Урак һәм чүкеч» заводыннан — тәмам иярләнгән, аңа дан һәм хөрмәт китергән, җитәкчеләрнең игътибарлы карашын, иптәшләренең хөрмәтен казанган җирдән — Тригубны, кызыктырып, авылга алып китәләр.

Тау чаклы вәгъдәләр, җиңел эш, рәхәт тормыш белән дә түгел, ә эшлекле һәм нык ихтыярлы барлык кешеләрне мавыктыра торган нәрсә — үз-үзеңне күрсәтү мөмкинлеге белән кызыктыралар.

Инде пенсия кенәгәсе хакында уйлар чак якынлашып килгәндә «Сельхозтехника»га эшкә күчәргә өнди башлагач, Тригуб аның җитәкчеләреннән: «Ә сезнең нәрсәгез бар соң?» — дип сорый. Берләшмә председателе Николай Григорьевич Энвальд мондый кешеләрнең — яшәлгән һәр көнне башкарган эше белән үлчәргә гадәтләнгән, эзләнүчән табигатьле тынгысыз җаннарның күңелен ничек кузгатып буласын яхшы белә.

— Бездә хәзергә берни дә юк,— ди ул, турысын ярып сала. — Аның караве, колач — бөтен республика. Бар эшең кеше күзе алдында. Иске тимер-томыр ямап утыру белән генә калмабыз, үзебезнең ремонт индустриясен булдырырбыз, тузган детальләргә икенче гомер бирербез. Барлык сварщиклар башлыгы — бригадир булырсың, алар 500 ләп кешегә җыела. Үзең белгәнне аларга өйрәтерсең, шунда сиңа игенчедән дан һәм хөрмәт булыр!

Менә шулай, нәкъ пенсиягә чыгар алдыннан Тригуб шәһәр пропискасын авылга алмаштыра, үз сүзләре белән әйткәндә, дан һәм хөрмәт эзләп, «Сельхозтехника»ның Биектау авылындагы төп базасына эшкә күчә.

Республика буйлап йөрү өчен, Тригубка шофер белән махсус машина — электродлар, трансформаторлар, төрле тимер-томыр белән

тулган тугыз урынлы фургон бирәләр. Шул машинасына утырып, бер көнне минем янга килеп чыкты бу. Бик ярсыган, күренеп тора, кемгәдер, нәрсәгәдер ачулы.

— Әйдә, гауга күтәрәбезме? — ди бу.

— Нәрсә өчен?

— Горелкалар өчен. Бөтен җирдә пропан-бутан тулып ятканда, сасы карбид белән эшләү — адәм көлкесе бит. Пропан-бутанга резин шланг булса, шул җитә. Мин монда бөтенесен яздым.

Папкасыннан алып, ул миңа зур мәкалә тоттырды. Металлны кыйммәтле ацетилен урынына сыек газ ярдәмендә кисү яки эретепябыштыруның өстенлекләре хакында язган. Шулай эшләү күп тапкыр гадирәк, арзанрак, уңайлырак икән.

Минем сварка буенча мәгълүматым әллә ни тирән түгел, шуңа күрә төпченергә булдым:

— Нәрсә бу, Америка ачуыңмы әллә? Синә хәтле пропан-бутанны белмәгәннәрмени?

— Белгәннәр. Мин бу турыда биш ел элек укыган идем. Горелкасын исә күргәзмәдә генә күреп калдым.

— Шулай булгач, акыл сатудан ни файда? Кем гаепле, эшне кем тоткарлый, шуларны камчылау кирәктер.

Ул чагында мин Тригубны рәтләп белми идем әле. Дөресен әйткәндә, бер-ике көннән Тригуб кабат килеп чыгар дип көтмәгән дә идем. Бик теләп бай тәҗрибәсен уртаклаша, төрле сәбәпләр аркасында халык хуҗалыгында үзләренә юл яра алмый торган яңалыклар хакында оста итеп сөйли белгән төпле белгечләр, акыллы инженерлар, зур-зур җитәкчеләр күп. Әмма төп мәсьәләгә килеп җиткәч — ни өчен, кем аркасында мөһим эш тоткарланып тора, аның эшләгән урынын, исем-фамилиясен атарга чират җиткәч — нишләптер дәрт кими, кешеләр куркып-өркеп калалар...

Мәкаләсенең икенче варианты өстендә Тригуб күпме утыргандыр, өзеп әйтә алмыйм. Бәлки, кызып китеп, бер утыруда язып аткандыр, әмма яңа вариант усал, ачулы тон белән язылган, берәүне дә тыныч, битараф калдырырлык түгел иде. Иң яхшысы, әйдәгез, «Советская Россия» газетасының беренче битендә «Мөһим темага хат» дигән рубрика астында басылган «Гаҗәеп горелка» исемле ул мәкаләне тагын бер кат укып карыйк:

> «Мин үзем сварщик, «Татсельхозтехника» берләшмәсенең инструкторы. Республика буйлап йөрим, халыкны тракторларның, машиналарның тузган частьләрен ремонтларга өйрәтәм. Безнең эштә иң кыены, ихтимал, ацетилен табудыр. Көтмәгәндә, ацетиленсыз эшләп була, аны сыек газ белән алмаштырырга мөмкин икән, дип ишетәбез. Җитмәсә, ацетиленны алмаштыра торган газ алты тапкыр арзанрак тора ди. Өченче ел СССР Госпланының председатель урынбасары А. Лалаянц урыннарга бер кәгазь җибәргән иде. Ул документта Бөтенсоюз автогенмаш фәнни-тикшеренү институты тарафыннан үткәрелгән тәҗрибәләр пропан-бутанның сварка эшенә тулысынча яраклы булуын күрсәтте... СССР Госпланы металларны газ ялкыны белән эшкәрткәндә табигый һәм сыек газларны мөмкин хәтле киңрәк файдалануга юнәлтелгән чаралар билгеләргә киңәш итә», диелгән иде.
>
> Киңәш итүе җиңел, эшләве кыенрак...
>
> Газ ярдәмендә эретеп ябыштыра торган гаҗәеп горелканы мин беренче тапкыр 1968 елда Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә күрдем. Куругә түзмәдем — әлеге институтка киттем:

— Горелкагыз белән ничек эшләргә кирәклеген аңлатмассызмы икән? — дим.

Дөресен әйтергә кирәк, институтта мине әйбәт каршыладылар. Анда җәмгысы дүрт мәртәбә булдым, сораулар белән галимнәрне туйдырып бетердем, яңа технологияне өйрәндем. Ләкин миңа горелкалар кирәк. Ни эшләргә? Мәскәүдәге әлеге гаҗәеп горелкаларны эшләп чыгара торган кислородлы машина төзелеше заводына чаптым. Ничек тә булса табылыр, Госпланның «тиешле чаралар билгеләргә» дигән кәгазе бар бит, дип юатам үз-үземне.

Мине заводның капкасыннан да уздырмадылар. Баш инженер телефоннан: «Нарядыгыз бармы? Фондларыгыз бармы?» — дип сорады да трубканы куйды.

Үзенең үк тәкъдимнәрен материаль һәм оештыру чаралары белән ныгыту юнәлешендә СССР Госпланы берни дә эшләмәсме икәнни?»

Мәкалә китте. Без Тригуб белән аны кайчан басарлар икән, баскач, «хат эзеннән» нинди чаралар күрерләр икән дип, көннәрне, сәгатьләрне саный башладык. Тригуб редакция белән дус яши. Күп еллар буена газета битендә эшлекле тәкъдимнәр белән чыгыш ясап килә, иптәшләре, тормышта очраган яхшы һәм әйбәт кешеләр турында яза, җитди мәсьәләләр күтәрә, чөнки белә, газета аша яңгыраган сүз— трамвайда барганда яки тәмәке тартканда сөйләнә торган гайбәт түгел, ә бәлки күп миллионлы зур аудитория алдында җаваплы чыгыш ясау. Шуңа күрә ул беркайчан да җавапсыз калмаска тиеш.

Шулай бервакыт заводка ниндидер материаллар, станоклар алып кайту, берочтан, ничек эретеп ябыштыруларын карау өчен, аңа Волгоград өлкәсенә барырга туры килә. Завод буйлап йөри, андагы эшләр белән таныша. Кайткач, «Толкачлар» янында бер көн» исемле зур мәкалә язарга утыра.

«Моңа кадәр «толкачларны» фольетоннар, мәкаләләр буенча гына белә идем. Һәм менә күптән түгел аларны тормышта, әгәр шулай әйтергә яраса, «эш өстендә» күрергә туры килде. Бу хәл Волгоград өлкәсенең Кызыл Армия районына сварка эшенең яңа алымнарын өйрәнергә баргач булды.

Гостиницада урын юк иде. Колхоз базарының гомуми торагына урнаштым. Блокнот алдым да, бүлмәдәшләремә ияреп, корыч арканнар эшли торган заводка киттем. Килдек, халык җыелган, иллеләп кеше бардыр. Утырганнар, көтәләр. Ни генә эшләнми монда! Берсе бугазын киереп акыра, башкала белән куркыта. Икенчесе, төчеләнеп, бөгелә-сыгыла, шыпырт кына пышылдый:

— Шурочка, җаным, мин цех белән килештем, бөтен эш синнән тора. Изгелегеңне онытмам...

«Толкачлык», әгәр шулай әйтергә яраса, тыелган эш. Шуңа күрә җитәкчеләр ачыктан-ачык алдашырга керешәләр. Командировка кәгазьләрендә: «номенклатураны хәл итү өчен җибәрелде», «бракның сәбәбен ачыкларга», хәтта «тәҗрибә уртаклашырга» дигән язмалар пәйдә була.

Мин берниндн дә «Америка ачмыйм», болар һәммәсе күптән билгеле нәрсәләр. Тик шуны аңлый алмыйм: «толкач» дигән зат ни өчен яши соң? Бездә кирәгеннән артык кайгыртучан җитәкчеләрне авызлыкларлык көч юкмы әллә?»

Мәкалә «Советская Россия» газетасының 1961 елгы 16 ноябрь санында басыла. Әллә ни күп вакыт узмый, КПСС Үзәк Комитетының РСФСР буенча бюросы әлеге мәкалә уңае белән тәпле карар кабул итә.

«Тикшерү күрсәткәнчә,— диелә карарда,— күп кенә предприятие директорлары, совнархозларның, оешма һәм ведомстволарның җитәкчеләре дәүләтнең «толкачларны» командировкага җибәрүне тыю турындагы карарын бозалар, материаль-техник тәэминат эшен оештыруны яхшырту өчен тиешле чаралар күрмиләр. Агымдагы хуҗалык елында Магнитогорск металлургия заводына төрле совнархоз, предприятие һәм ведомстволарның 3238 эшчесе командировкага җибәрелгән. Саратов подшипник заводына—1427 кеше, Тула совнархозының Яңа Мәскәү химия комбинатына — 1560 кеше, Свердловск совнархозының Беренче Урал труба заводына 1703 кеше килеп киткән. Иң күп «толкачларны» Свердловск, Чиләбе, Удмуртия, Ленинград, Новосибирск һәм күп кенә башка совнархозларның предприятиеләре җибәргән.

Әйбер һәм материалларны «толкачлар» ярдәмендә юнәтү кебек начар практика ямьсез формалар алып бара...»

Газетаның беренче битендә гади эшченең мәкаләсе басыла, шул мәкалә буенча дәүләт, югары партия органы махсус карар кабул итә— кайда, башка кайсы илдә хезмәт кешесенең сүзенә шулай колак салалар икән?! Билгеле, һәр мәкалә мондый бәхетле язмышка юлыкмый. Әмма ни генә булмасын, үз юлында нинди генә киртәләргә очрамасын, ахыр чиктә гаделлек барыбер җиңеп чыга.

...«Гаҗәеп горелка» исемле мәкалә басылганга айлап гомер узды, ә нәтиҗәсе һаман да күренми. Дөньяда көтеп ятудан да кыен эш юктыр. Ниһаять, Тригубның түземлеге бетә, ул, җыенып, редакциягә китә. Аның ничек итеп кабинетлар буйлап тузынып йөргәнен, ничек итеп формалистларны теткәнен күз алдына китерү кыен түгел. Хәер, иң ныгы журналистларга эләгә, аларга карата ул бигрәк тә таләпчән. Эш Тригубка усал, принципиаль хәбәрче Гриша Орловскийны беркетү белән тәмамлана. Алар икәүләп бәхетсез язмышлы горелкалар турындагы мәкалә эзе буйлап чыгып китәләр. Завод, институт, министрлык... әлеге сәяхәттән соң тагын бер мәкалә языла...

*

* *

Бу мәкалә басылып чыкканнан соң Тригуб югалды. Ихтимал, горелкалар мәсьәләсе, ниһаять, хәл ителгәндер, эшләр ул уйлаган дәрәҗәдә үк катлаулы булмагандыр, аларны күбрәк чыгара башлагannардыр, һәм картлач тынычлангандыр, дип уйладым.

Ә ул, баксаң, сварка эше буенча күчмә күргәзмә оештырып йөргән, үзе белән әлеге горелкаларын, пропан-бутан баллоннары алган да республика буйлап халыкка газ ярдәме белән эретеп ябыштыру ысулларын өйрәтергә чыгып киткән икән. Идел, Кама аръягында, Вяткада, Зөядә булган, «юл уңаеннан» башкортларга, мариларга кереп чыккан. Сәяхәттән кочагы белән рәхмәт кәгазьләре алып кайткан.

Бер елдан Тригуб минем янга, шатлыгын яшерә алмаган сабыйдай, елмаеп-балкып килеп керде:

— Булды! Бүген карбидтан бушаган соңгы мичкәне металл ватыгына озаттык, минем егетләр бары пропан белән генә эшли. Елга 60 мең сум табыш дигән сүз. Хәер, хикмәт акчадамыни?! Эш шәп бара!..

*
* *

Мондый ашкыну һәм түземсезлек үзенең ярты гасырдан артык гомерен багышлап та аны һич тә туйдырмаган хезмәте белән горурлана алу сыйфаты Тригубка каян килгәнен күпләр белмидер дип уйлыйм. Туймау гына түгел, киресенчә, ул көн саен сварка эшенең билгесез яңа якларын ача бара. Моның хикмәте, минемчә, шунда, сварка аның өчен гадәти эш кенә түгел, ул аның өчен, кешеләрдә табигатькә, сирәк очрый торган сәнгать әсәрләренә карата туа торган мәхәббәт кебек, зур хискә әйләнгән. Матур булганы өчен түгел, ә кеше эшчәнлегенең бер төре буларак, халыкка байлык, бәхет китергәне өчен. Нәкъ әнә шуңа күрә зәңгәр дуга очкыннарыннан ул чиксез ләззәт ала!

Аек акыллы кеше буларак, Тригуб бер нәрсәне төптән аңлый: ил, гомум кешелек мәдәниятенең алга барышы ахыр чиктә һәр шәхеснең тырышлыгына бәйләнгән. Хәер, эшнең зуры яки кечкенәсе булмый, хикмәт — эшен башкарганда кешенең үзен ничек хис итүендә. Иң зур хокук һәм көчкә ия булып та, бәләкәй генә киртәне атлап чыгарга куркып калырга мөмкин, беренче карашка вак кына булып күренгән эшләрне үтәгәндә дә рух һәм характерың белән күкләрдә йөзәргә мөмкин.

*
* *

«Сельхозтехника»ның Тригуб эшли торган Биектау заводында машиналар, тракторлар белән бергә сабан төрәннәре кебек нәрсәләрне дә ремонтлыйлар. Гадәти төрәннәрне төзәтү кыен булмый, тузган өлешен кисеп ташлыйлар да яңаны ябыштыралар. Әмма завод кешеләре, сука төрәне озаграк хезмәт итсен дигән ният белән, төрән йөзенә үтә каты катнашма — сормайт ялгый башлыйлар. Сормайт — игенчегә җәннәт, ремонтчыга — тамуг газабы. Өч мең төрән кискәннән соң аппарат сафтан чыга. Үз һөнәрен яраткан кеше кыен хәлдән ничек котылырга белми иза чиккән оста буларак, Тригуб ачуыннан шартларга җитешеп йөри. Ниһаять, Мәскәүгә, автоген машина төзелеше институты директоры, күптәнге танышы Игорь Александрович Антоновка шалтырата.

— Игорь Александрович, тыңлагыз әле, — дип ялвара ул автогенмаш директорына.— Шул юньсез сормайт җәфалый. Булыша алмассызмы?

— Сәер кеше син, Андрей Акимыч, — ди Антонов. — Мең километрдан торып мин сиңа ничек булышыйм ди? Белмисеңмени: врачлар телефон аша рецепт та, консультация дә бирми. Килеп чык, бергәләп уйлашырбыз.

Тригуб — юл йөрергә күнеккән кеше. Портфеленә электр бритвасы, сабын, сөлге, порошок белән щетка төреп сала, һәркайсы унар килограммлы ике төрәнне кәгазьгә төрә, бау белән бәйли — һәм юлга чыга. Йөк ипсезрәк икән. Вагонга кереп, төеннәрен дөбердәтеп идәнгә ташлауга юлчылардан берсе шаяртып куя:

— Нәрсә, башкалада тимер-томыр беткәнме әллә?

— Анда башка төрләләре, мондыйлары дефицит.

Кыскасы, Мәскәүгә Тригуб хәвеф-хәтәрсез килеп җитә. Институт директоры кабинетына тимерләре-ниләре белән барып керә, шуның белән охшап та куя. Төеннәрен сүтеп, тимерләрен тартып чыгара, үзенең нинди бәлагә тарганын сөйләп бирә...

— Ярар, бу бәла бәла түгел,— ди Антонов.— Килгәнсең икән, бик шәп! Хәзер үк Барнаулга чыгып кит. Анда безнең заказлар бу-

енча плазмалы өч аппарат ясыйлар, аргон да, гелий дә түгел, ә гади һава белән кистерә торганны. Берсен ал, тик эш өчен, тикшереп эшләтеп карау өчен. Галимнәргә дә ярдәм ит. Килештекме?

— Мә бишне!

Шәхсән, мине Тригубның табигатендә һәм язмышында барыннан да ныграк уйландырган, гаҗәпләндергән нәрсә — аның гади бригадир кулыннан килмәстәй хыялларны тормышка ашырырлык фикердәшләр таба, үз уйларын галимнәргә, хуҗалыкчыларга, тәэминатчыларга, завод җитәкчеләренә, партия хезмәткәрләренә йоктыра белүе. Холык-гадәтләре, хезмәт урыннары белән төрле-төрле булган ул кешеләр, аның теләк-хыялларын якын итәләр, чөнки үз максатына, үз дигәненә ирешә торган эшлекле булуын сизәләр.

Е. О. Патон исемендәге электросварка институтыннан техник фәннәр кандидаты Д. М. Кушнеров, үзенең коллегасы белән киңәшкәндәй, Тригубка хат яза:

«Безнең лабораториядә валларны һәм 40—50 миллиметрлы, аннан да юанрак кучәрләрне үзгәреп торучы электрод ярдәмендә киң катлы итеп эретү буенча уңай тәҗрибә тупланды. Бәлки сез бу алым белән кызыксынырсыз һәм аны терсәкле валларны ремонтлаганда кулланып карарсыз?!»

«Мәскәүдәге кичке металлургия институтында пайкалау эретмәсе һәм аны алюминий детальләрдәге кимчелекләрне төзәткәндә куллану технологиясе эшләнде, —диләр металлургия галимнәре, ачышлары белән уртаклашып һәм шунда ук фән мәнфәгатьләрен кайгыртуларын да сиздерәләр. — Ремонт эшен яхшырту белән чын-чыннан кызыксынган кеше буларак, без сезгә авыл хуҗалыгы машиналары һәм җиһазларындагы алюминий детальләрне ремонтлаганда флюссыз пайкалау алымын куллану эшендә бергәләп эшләргә тәкъдим итәбез.

Пайка эшләре буенча фәнни җитәкче, техник фәннәр кандидаты, доцент Г. Смирнов.
17 февраль, 1977 ел.»

Хәер, хезмәт кешесенең даны шулай зур булганга нигә гаҗәпләнергә?! Популярлык спортчыларга, артистларга, космонавтларга гына хас нәрсә түгелдер бит! Тригуб популяр һәм бәхетле кеше икән, бу аның характеры, табигате белән генә түгел, ә заманның үзе белән аңлатыла, ялкау һәм авыр кузгалучан кешеләргә караганда булдыклы һәм энергияле кешеләргә фикердәшләр һәм көрәштәшләр табуы күп тапкыр җиңелрәк булуын гына күрсәтә.

*
* *

Тригуб көчле оптимист булуы белән бәхетле, уңышсызлыкларга юлыкса да, иң изге теләкләре ерак киләчәктә генә тормышка ашачагын яхшы белсә дә, өметсезлеккә бирелми. Киртәләр һәм каршылыклар никадәр кыенрак булса, үзенең теләк һәм омтылышларына, язмышына ныклык ышанып, ул һәртөрле объектив һәм субъектив хәлләрнең чытырманнарын тагын да үҗәтләнебрәк ера башлый.

«Сельхозтехника»да бишенче елын эшли башлагач, Тригуб исәпләп-санап карый: төрле курслар ачып, күчмә күргәзмәләр оештырып, ул авыл мастерскойлары өчен күп булса ярты меңләп кеше хәзерләгән икән.

Дөрестерме, юктырмы, шундый бер вакыйга турында сөйлиләр. Белемнәрен күтәрү өчен, районнардан сварщикларны җыеп алалар,

курсның программасы белән таныштыралар. Тригуб бу вакыт ялда икән.

— Тригуб буламы? — дип сорый курсантларның берсе.

— Юк, әле генә ялга китте, бер айдан кайтачак, — диләр.

— Алайса, без дә бер айдан килербез, — диләр сварщиклар һәм өйләренә кайтып китәләр.

Тригуб хакында сөйләгәндә, аның характерына хас тагын бер сыйфатны билгеләп үтәсе килә: сүз аның башлаган эшне тәмамлап куярга яратуы хакында бара. Бу очракта инде ул безнең алга гади бригадир гына түгел, олы фикер, бөек хыяллар белән яши торган зур дәүләт кешесе булып килеп баса.

Бер уйлаганда, бөтен эше рәтләнеп бара кебек: китап языла, эшнең рәтен белгән сварщиклар саны арткан нан-арта бара, шул чак электродлар җитми башлый. Сварка күбрәк кулланыла, ихтыяҗ арта.

— Нәрсә, сварщикларың шулай тик ятармыни? — дип бәйләнә аңа Энвальд.— Әллә ни кыен эш түгел, электродларны үзебез ясап карыйк.

— Ә майлагыч пресслар, шарлы тегермәннәр, эретү мичләре, ташваткыч агрегатлар һәм механик иләкләрне каян алабыз?

— Без ни өчен куелган, әзергә хәзер булып утырыргамы? Н. Хикмәтне укыганың бармы?..

— Әгәр син янмасаң, әгәр мин янмасам, бу дөньяны кем яктыртыр...

— Әйдә, яктырт дөньяны!

Электродлар ясау турындагы фикерне ул башта «Сельхозтехника»ның Бөтенроссия берләшмәсендә күтәреп чыга. «Нинди шәп идея! Молодцы! Әйдәгез-әйдәгез!» дип хуплыйлар аны, тырышлыгы өчен мактыйлар, әмма ярдәм итмиләр. Ярдәм итә алмыйлар — мөмкинлек юк. Мондый очракларда, командировка кәгазен кесәгә тыгып, кире кайтып китәргә дә мөмкин, тырышып йөргәнеңне аклар өчен, билетларыңны, командировка кәгазендәге мөһерләрне күрсәтәсең. Бу кадәресе әллә ни кыен түгел.

Бүгенге уңышсызлыкка караганда, киләчәк хыялларына күбрәк ышанучы, оптимист табигатьле Тригуб, тагын бер «юк» дигән сүз ишетү өчен, башкаладан Одессага чыгып китә.

«Бездә планлы хуҗалык. Нарядлардан тыш, коры рәхмәт сүзенә ышанып, кем читкә завод хәтле завод биреп җибәрсен, —диләр аңа. — Сез сораган комплектны без елга бишне генә җитештерәбез. Һәркайсы Госплан югарылыгында бүленгән».

Кайтканда Тригуб Одесса—Мәскәү экспрессына утыра. Вагон дерелди, көпчәкләр дөпелди, тәрәзә артында табигать үзгәреп тора — очсыз-кырыйсыз Украина далаларын Россия урманнары алмаштыра. Юлны, гадәттәгечә, сүз белән кыскарталар. Билгеле, Тригуб түзми, зарланып ала, ни эзләп йөргәнен сөйли. Шундый бәхетле очрак туры килүен әйт син. Юлчыларның берсе үзе яшәгән Куйбышев шәһәрендә «Электрощит» дигән завод булуын, ни өчендер шундагы электрод цехын сүтәргә җыенуларын әйтеп ташлый. Тригуб өчен көзге яңгырлы сүрән көн яңадан ал шәфәкъле җәйге таңга әйләнә. Беренче станциядә үк төшеп, тел ачкычына дип, ул бер ярты алып менә, иплэп кенә юлчыдан сораша-белешә башлый...

Казанга да кереп тормыйча, Мәскәүдән туп-туры Куйбышевка китә. Эх, бу хыялларның өрфиядәй юка пәрдәсе! Татлы хыялларга бирелеп, ул шатлыктан җиде кат күккә менеп җитә, һәм реаль дөнья аны, лып итеп, каты җиргә төшереп утырта.

— Теләсә кемгә биреп җибәрергә ул сиңа атаң малы түгел,— ди кырыс чырайлы завод директоры.

Тригуб та нык торырга була:

— Мин дә бит кардәшем өчен йөрмим,— ди.

— Йөрмәсәң соң. Тәртип дигән нәрсә бар. Миңа өстән кәгазь китер, аннан агрегатларны теләсә нишләт. Сүтеп ташлагач, бәласе генә артачак. Тегендә-монда ташып, таратып бетерәчәкләр.

Бу юлы Тригуб акыллырак эшли, үз файдасы артыннан түгел, ә бәлки «Сельхозтехника» мәнфәгатьләрен кайгыртып йөрүен раслый торган рәсми кәгазьләр алырга башы җитә. Шуларны тотып, ул Энергетика һәм электрофикация министрлыгына китә, чират җиткәнне көтеп, ике көн кирәкле Главканың ишек төбендә утыра. Аның каравы, яңа гына станоктан төшкән көмеш акча кебек, шатлыктан балкып кайтыр юлга чыга! Могҗиза белән кулга төшкән җиһазларны ничек итеп тагылма арбалы унсигез машинага төяп алып кайтулары, яңа урында аларны ничек корулары, ничек эшләтә башлаулары хакында, ихтимал, сөйләп тору кирәкмидер. Башка кыенлыклар нинди авырлык белән җиңелсә, бу юлы да шулай була. Хәзер конвейер эшли, елына трактор детальләренә, авыл хуҗалыгындагы башка техникага ныклы, ышанычлы җөй булып ята торган ике йөз тонна металл чыбык бирә.

*

* *

Мәскәүдәге кечке металлургия институты галимнәре белән бергәләп эретеп ябыштыруның яңа ысулларын үзләштергәч, бәхет һәм уңышлар теләп, галимнәр өйләренә кайтып киткәләр — яңалыкларны тормышка ашыру Тригубка кала. Припайлар ясау өчен цинк, алюминий, галлий кирәк булганда, аны ничек тормышка ашырасың? Алюминий белән цинк күп, ә галлий юк. Ихтимал, алтыннан да кыйммәтрәк торадыр.

Нишләсен Тригуб — Мәскәүгә, Төсле металлургия министрлыгына, аның сирәк металлар бүлегенә юл ала, кирәкле Главканы, кирәкле кешене таба, гозерен әйтә.

— Исәнмесез. Безгә 10 килограмм галлий кирәк иде.

— Сез кайдан?

— Татарстаннан, «Сельхозтехника» сварщигы.

— Ерактан икән...

— Республиканың атказанган механизаторы. — Тригуб өстәлгә кызыл тышлы кенәгәсен чыгарып сала.

— 10 килограмм дисезме? Кичә без космос ихтыяҗлары өчен 120 грамм язып бирдек.

— Бирсәгез соң. Сез шулай хәерче яшәгәнгә кем гаепле? Яхшырак эшләргә, ихтыяҗларны белеп торырга кирәк. Сүз уңаеннан әйткәндә, мин СССР Журналистлар союзы члены да әле. Кичә «Правда»да минем фельетонымны бастылар. Рәхим итегез!..

Тригуб куен кесәсеннән кызыл кенәгәсен, папкасыннан «Правда» газетасының «Флюс астындагы күбек» дигән баш белән чыккан мәкаләсе басылган соңгы санын чыгарып сала. «Правда» газетасын Тригуб Главка башлыгына истәлеккә калдыра, ә кесәсенә 5 килограмм сирәк металл — галлийга наряд салып кайтып китә.

*

* *

Соңгы тапкыр Тригуб минем янга үзенең республика берләшмәсенә барышлый керде. Кабаланган, дулкынланган.

— Телисеңме, бер нәрсә күрсәтәм?— ди.

— Тагын берәр могҗиза уйлап таптыңмы? — дим төрттереп.

— Күрерсең,— минем төрттерүгә аның исе китмәде, бик мәгънәле итеп, серле генә елмаеп куйды. Гүя ул, чыннан да, берәр могҗиза уйлап тапкан.

Без район үзәге Арчага, Киров өлкәсе белән чиктәш булган, нәкъ Вятка ярында утырган Балтач якларына чыгып киттек.

Юл буе Тригубның хәйләкәр һәм серле елмаюын күзәтеп бардым, тизрәк ни булганын беләсем килә. Ә ул дәшми! Барабыз төрле юк-барны сөйләшеп. Эш турында ләм-мим. Әйтерсең балыкка, гөмбәгә, я булмаса ауга юл тотабыз! Ниһаять, мин түзмәдем, ул көтмәгән яктан һөҗүмгә күчтем.

— Кара әле, Андрей Акимыч, син бит хәтта тозны да чиратсыз алырга гадәтләнгән адәм. Син әрсез кеше, кемнедер күкрәк белән этәсең, кемнедер җилкә белән төртәсең, баксаң, син инде иң алга чыккан, башкалар калып тора.

— Ишетмәсәң ишет! — Тригуб урындыгыннан сикереп торыр хәлгә җитте.— Чиратка мин тоз алырга тыкшынаммы әллә? Мин эш артыннан йөрим. Торбалар ялгый торган трассаларда гына ул шакмаклы автоматлар. Бүтән урыннарда эш күбрәк һәвәскәрлеккә, энтузиазмга корылган. Мин эшемне башкаларга күрсәтергә оят булмасын дип, аны шәп итеп башкарырга тырышам, син миңа нәрсә тәкъдим итәсең? Зәңгәр пыялага карап, галимнәр патент алганны, аннан һәртөрле тәҗрибә, сынаулар уздырганны, ниһаять, эшнең Госпланга, министрлыкка, завод конвейерына барып җиткәнен көтеп утырыргамы? Әйт менә: «Тригуб, яле, синең сварщикларыңа нәрсә кирәк? Нигә дәшмисең?» — дип миннән кайчан сорарлар...

Балтачта Тригуб мине трактор мастерскоена алып китте. Тузган тормоз барабаннары, цапфылар, терсәкле валлар, юнәлткеч тәгәрмәчләр, тормоз шкифлары, тоташтыргыч муфталар, тагын дистәләрчә башка детальләр ремонтлый торган төштәге ике аппарат янына алып килде. Берсендә зур түгәрәк каток ремонтлыйлар — флюс ярдәмендә зәңгәр утлы чыбык урыйлар, шуның өстенә металл эретеп салалар. Аннары станокта артык катламнарны кырдырып алалар, шомарталар, детальне утта чыныктыралар, шуннан ул кабат хезмәт итәчәк.

Икенче аппаратта махсус курслар бетергән дүртенче разрядлы яшь сварщик Вакыйф Шакиров һәм читтән торып белем бирүче Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы институтының авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау кафедрасы доценты А. И. Смирнов (күренеп тора, Тригуб аны Мәскәүдән ниндидер исәп-хисапларын тикшерү һәм берочтан киңәш сорау өчен чакырып китергән) нәрсәдер эшләп яталар. Парикмахерларда кешеләргә одеколон сиптерә, малярлар йорт агарта торган пульверизаторга охшатып ясалган плазма аппараты, гадәти горелка түгел. 15 мең градус эсселектә металл порошок газга, гади күз белән күреп булмастай атом һәм молекулаларга әйләнә, шуның белән тигез итеп тузган өслекне каплап чыгалар. Тиз дә, төгәл дә! Плазмалы аппарат башка төрле сварка машиналарына караганда дүрт тапкыр күбрәк җитештерүчән, металл бер ярым мәртәбә азрак китә, ә деталь ике мәртәбә ныграк булып чыга.

— Хәтерем ялгышмаса, бу Россиядәге бөтен авыл мастерскойларындагы бишенче аппарат,— дип мактана Тригуб, кабат үзенә якын ут һәм сварка стихиясенә бирелеп.— Сирәк очрый торган нәрсә, ә могҗиза дип уйлыйсыңмы? Юк. Металлны газга әйләндерә торган приборларны утыз тугызынчы елда ук эшлиләр. Плазмалы горелкаларны илле алтынчы елда ясарга өйрәнәләр. Безнеке кебек гади мастерскойларда мондый машиналар кайчан була әле? Кеше

гомеренең яртысы юк дигән сүз. Плазма өчен аппаратларны берәмләп чыгаралар, сиптергеч порошокларны аптекадагы дарудан да азрак бирәләр. Үткән юлы төрле порошоклар табу өчен үзем белән әллә нихәтле запчасть алырга туры килде.

Мин түзмәдем, кулга блокнот белән ручка алдым.

— Яз, яз. Тик эшкә ярдәм итәрлек булсын. Мохтаҗлыктан төрлечә алдарга, хәйләләргә мәҗбүр булган бер бригадирны җавапка тарту кыен булмас. Мохтаҗлык бетсен, мин закон, кагыйдә нигезендә эш итәрлек булсын, хикмәт әнә шунда. Яңа техника артыннан йөреп бер инфаркт, аны төяп озату артыннан йөреп икенче инфаркт аласың. Шулай Владимир өлкәсендәге Кольчугино дигән җиргә, төсле металлар эшкәртүче бер заводка хәер сорашырга киттем. Зур завод, Октябрь Революциясе һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы. Оялып тормадым, плазма белән кисү өчен кирәк булган 8 килограмм цирконий теләнеп алдым. Бер электродка 2 грамм цирконий китә, килосы 107 сум тора, алмашка тагын әллә нихәтле запчасть төрттем. Алар да хәерче яшиләр, нишләргә белмиләр. Мин — сиңа, син — миңа, шунсыз берни эшләп булмый. Шуның өчен син мине гаепле саныйсың, кызартасыңмы?!.

— Илебез зур. Һәммәсен дә ничек җиткермәк кирәк?

— Җитмәс шул, байлыкны шулай әрәм-шәрәм иткәч. Руданы казып чыгарырга, металл итеп эретергә, аннан машиналар, станоклар, приборлар, агрегатлар ясарга кирәк, ә без уйлап тормый гына һәммәсен кабат мартен мичләренә озатабыз. Алга таба киттек. Хәзер күрерсең...

Арчадагы мастерскойда Тригуб мине трактор дизеле эшләп чыгара торган тагын бер сынау стенды янына алып килде.

— Кара, әйләнә бит, күгәрченкәем! — дип кычкырды ул минем колакка, шатлыктан нишләргә белмәгән сабый кебек.

— Мотор, әйләнергә тиеш, — дидем мин, аның болай шатлануын аңлап җитмичә.

Башта ул югалып калды, ахырдан эшнең асылын белмәгән кешедән башка сүз көтеп булмасын төшенде шикелле.

— Моторның терсәкле валы икенче срокын әйләнә.

— Терсәкле вал шул ук деталь түгелмени? — дип сорадым мин. — Һәр деталь, һәр машина ике-өч срок хезмәт итәргә тиеш, дип үзең әйттең ич.

— Эшләргә тиеш белән эшли арасында шактый аерма бар. Автомашиналарның терсәкле валларын күптән ремонтлыйлар, тракторларныкына тотынып караганнары булмаган. Ремонт ясаган саен, моторның төп детален алып эретергә озаталар, урынына яңаны куялар. Терсәкле валда алты потлап металл бар, ул 100 сумнан артыграк тора. Мотор сигез елга хәтле түзә, шул вакыт эчендә ике-өч тапкыр ремонтта була, димәк, һәр моторга 3 терсәкле вал кирәк. Бу бишьеллыкта авыл хуҗалыгына 1 900 000 трактор сатылачак, алар нормаль эшләсен өчен 5 700 000 терсәкле вал чыгарырга кирәк, — дип тезеп китте Тригуб. Күрәсең, бу хакта ул күп уйланган.

— Син, Андрей Акимыч, үзеңнең кечкенә генә уңышыңны да ил күләмендә зурайтып күрсәтәсең.

— Нигә зурайтмаска? Һәр кеше үзенең күпме файда, күпме зыян китергәнен ачык белергә тиеш, моңардан отачакбыз. 1977 елда безнең «Сельхозтехника» 30 000 000 сумлык запас частьләр һәм детальләр алдырды, ә ремонтлаганнарны 4 000 000 сумнан артмый. Без, игенчеләр, нужадан нидер эшлибез әле. Ә нихәтле завод, фабри-

ка, төзелеш оешмалары, промыселларда детальләрне икенче кат файдалану турында уйлап та бирмиләр. Кирәкле аппаратлар аз, порошоклар җитми. Бер безнең «Сельхозтехника» буенча гына да беренче ремонттан соң елына уртача 25 000 тонна металл мартен мичләренә озатыла — кул кушырып көтеп утырыргамы? Мин башкача уйлыйм: кулдан, көчтән килгәнчә тырышып карыйм, җир шарын ярты градус, ярты минут, һич югы ярты секундка гына булса да селкетеп булмасмы, дим. 109 тракторның терсәкле валын ремонтладык — махсус флюс сайлап алдык, сварка дугасын кислородтан саклый торган гадәти флюска феррохром, көмешсыман графит өстибез. Шуларның һәммәсен сыек пыялага кушып болгатабыз, хасил булган катнашманы 500 градус эсселектә чыныктырабыз, яңадан порошокка әйләндерәбез — һәм сылыйбыз. Бер валны ремонтлауга — сафтан чыккан детальләрнең яртысын яңадан эшләтергә була, хәзергә 500 данә генә ремонтлыйбыз — 3 килограмм материал китә, акчага күчереп исәпләгәндә 40 сумга төшә. Илле процент — чик түгел, кемнәрдер безне узар, зурракка ирешер дип ышаныйк. Мактанырга да мөмкиндер, ләкин булдыра алмыйм. Киресенчә үземне тиргим, аз дим. Ниндидер вак-төяк белән санашабыз, зурын югалтабыз. Ә син «күпертәсең» дисең?..

Чыннан да, 1970 ел белән чагыштырганда республикада ремонтланган детальләр саны 3,3 мәртәбәгә арткан. Тригуб әйтмешли, бу саннар белән мактанырга да була. Инде оешмаганлык, хуҗа булалмау, уртак хәзинәгә салкын карау аркасында әрәм булганын санап карасаң, хәтта оят булып китә. Мәсәлән, Госплан һәр елны, запас частьлар эшләү өчен, илнең автомобиль промышленностена миллион тоннадан артык төрле сорт прокат, йөзләрчә мең тонна корыч һәм чуен, бик күп затлы һәм сирәк металлар бүлеп бирә, бу чама белән бөтен фондның биштән бере дигән сүз. Бернең бишкә чагыштырмасы үзгәрми торган даими сан, ләкин запас частьлар өчен металл тоту елдан-ел арта бара. Әйтик, соңгы елларда Ярославль шәһәрендәге «Автодизель» берләшмәсендә эксплуатация ихтыяҗлары өчен детальләр җитештерү 2,2 мәртәбәгә арткан, продукция реализацияләүнең гомуми күләмендә запас частьләрнең чагыштырмасы 30 процентка җиткән.

Зур чыгымнар тотып, көч куеп эшләнгән запас частьларне ничек саклыйбыз соң? Деталь эшләп, әйләнеп торганда саклыйбыз, сафтан чыгуга «Вторчермет» базасына озатабыз. Ярославль «Автодизель» белгечләре, эшлибез-эшлибез, һаман запчасть җитми, хикмәт нәрсәдә икән дип кызыксынып карыйлар һәм шул нәрсәне ачыклыйлар: илдәге автомобильләр һәм моторлар ремонтлау белән шөгыльләнә һәм кырыклап тармакка буйсына торган 850 предприятиенең биштән дүрт өлеше тузган детальләрне ремонтлап тормый, аларны турыдан-туры мартен мичләренә озата икән. Ә галимнәр исәпләп караганнар һәм исбат иткәннәр: бер кулланылган калдыкларны кабат файдалану яңаны эшләүгә караганда күп тапкыр арзанракка төшә икән!

Тригуб кызганнан-кыза барды. Мин дәшми генә тыңлыйм. Дөресен әйткәндә, аның үз планнарын тормышка ашыру юлында кулланган принципларын мин өнәп бетермим, шул ук вакытта дәүләт файдасын кайгыртып йөрүе белән килешми мөмкин түгел. Чыннан да, промышленностьның икмәге булган металл кебек байлыкны, аерым бер илнең генә түгел, ә бөтен кешелекнең индустриаль үсеш нигезе булган, җир астындагы рудниклардан табылган, машина, станок, детальләр итеп коелган байлыкны беренче сроктан соң ук, аларга икенче, өченче,— кыскасы, озын гомер бирү турында уйлап та карамастан кабат мартен мичләренә озату акыллы эшмени?!.

*
* *

Өченче ел җәй көне Тригуб Киевка барып чыга. Гомер хезмәттә узган. Бер Татарстанда гына утыз елдан артык яшәлгән. Телләре, холыклары, гореф-гадәтләре белән төрле-төрле, әмма рухлары белән үзара якын булган сварщиклар арасыннан беренче, дипломлы штурманнар арасыннан бердәнбер кеше булып ул Татарстан АССРның атказанган механизаторы дигән мактаулы исем ала. Туган-үскән, укыган, кеше иткән җирләрен күрергә күпме җыенды, һаман вакыт җитмәде.

Ниһаять, ял алып «кыргый турист» сыйфатында ул Феодосиягә китә, Грин йортын, Айвазовский музеен карый, борынгы крепость хәрабәләре арасында йөри, Кара диңгезнең чайкалуын тыңлап, эше, тормышы турында уйлана. Көтмәгәндә уянган эчке тавыш аны күптән узган яшьлегенә дәшә, тиз генә җыена да, үзенең детдомын эзләп китә.

Владимирск урамы... Гражданнар сугышыннан соң балалар йорты урнашкан бинада хәзер балалар бакчасы икән. Ярсып типкән йөрәген тыярга тырышып, Тригуб бала-чага яныннан уза, мөдир бүлмәсен шакый.

— Мөмкинме?

— Мөмкин, тик бездә урыннар юк,— ди мөдир, кар кебек ак чәчле кешене күреп.— Рәхим итегез, утырыгыз!

— Миңа урын кирәкми,— ди Тригуб.— Минем узган гомеремне искә төшерәсем килә. Бу миңа мәңгелек су кебек шифа.

Берсе ак халат кигән яшь кенә мөдир, икенчесе олы яшьтәге чал чәчле кеше, узган елларны искә төшереп, бүгенге тормышны телгә алып, киләчәк белән хыялланып бик озак сөйләшеп утыралар.

## Бикә Рәхимова



*Җир тормышының һәр сулышы миңа шигырь булып тоела.*

*Шигырьдә тормыш матурлыгы, көрәш матурлыгы җырлана. Поэзия шундый кодрәте белән сокландыра мине. Гомумән, поэзия тылсымлы — кеше күңелен мәңгегә үзенә тарта. Шигырьсез яшәү мөмкин түгел кебек.*

●

Идел өсте күк томан,
яннарыңда күп тормам.

Идел өсте күк томан.
Әллә китмәскә кунган?

Булса булыр,
ул Иделгә иш туган.

Яннарыңда бар да, юк та,
мин бит рәшә сыман.

Идел өсте күк томан...

### Әни үлеменә

Үкенүләрнең, диләр,
файдасы юк.
Шулайдыр, дөрестер бу.

Үкенүләрнең, диләр,
чикләре юк.
Шулайдыр, дөрестер бу.

Үкенүләрнең, диләр,
чамасы юк.
Шулайдыр, дөрестер бу.

Үкенүләрнең, диләр,
чарасы юк.
Бусы да дөрестер шул.

## Шаяру

Исле гөлләр сибәр идем
алма бакчаларына.
Нинди бүләк бирим икән
йөрәк сакчыларыңа?

Бүләгемне алсыннар,
карап шаклар катсыннар,
уяулыкларын җуеп,
йөрәк бигең ачсыннар.

Йозаклары ачылды,
ачкычлары кулымда.
Бер киртә юк юлымда.
Ә мин бераз шаярыйм,
ачкычны алып качыйм —
хәлеңне читтән карыйм.

●

Каберенә ал гөл салып,
мин мәхәббәтне күмдем.

Тоташ аккан яшьне сибеп,
мин мәхәббәтне күмдем.

Зифа буйны сыгылдырып,
мин мәхәббәтне күмдем.

Каберенә тезләндем дә,
мин мәхәббәтне күмдем.

Ташына башымны орып,
мин мәхәббәтне күмдем.

Йөрәгемне ташка куеп,
мин мәхәббәтне күмдем.

Мин мәхәббәтне күмдем...

Башкаларныкы яшәсен!

## Фирдәвес Бәширова



*Мин сугыш беткән елның көзендә туганмын. Агыйдел суын эчеп, җырын тыңлап үстем. Бала чактан ук күңел әйтерсең шуңа кушылып, тавыш-тынсыз гына җырлый торган иде.*

*Үсә төшкәч, ул җырлар хәреф-энҗеләр ярдәмендә ак кәгазь битләренә төшә барды...*

*Мәктәпне тәмамлагач, Чиләбедә белем алдым. Хәзерге көндә КамАЗда инженер булып эшлим.*

### Кояшым

Иртәләрдә кулым сузып
Каршы алам, Кояшым.
Син яраткач, мин дә сине
Бик яратам, Кояшым.

Алтын нурың тигез бүлеп
Таратасың, Кояшым.
Тиң күреп син бар халыкны
Яратасың, Кояшым.

Кайсы чакта күк болытлар
Сине каплый, Кояшым.
Тик барыбер тукталмыйсың
Безне тапмый, Кояшым.

Алсу таңлы бер иртәдә
Мине ал син, Кояшым.
Бик биеккә, күк читенә
Алып бар син, Кояшым.

Тик бераздан Җиргә кире
Кайтарып куй, Кояшым.
Туган җирсез, кешесез мин
Яши алмам, Кояшым.

### Күрсенүең борчылдырды әле...

Тирән итеп бер көрсенеп куйдың.
Нигә шулай тирән көрсендең?
Мин белмәгән берәр уең бармы?
Ачык кебек иде һәр көнең.

Ерак карап бер көрсенеп куйдың.
Кайгы-хәсрәт сине бастымы?
Әллә саф чишмәдәй күңелеңә
Явыз шик тап булып яттымы?

Төйнәп бөтен моңын, хәсрәтләрен,
Тирән итеп йөрәк түреннән,
Урал тавы үзе көрсенгәндәй
Тик сабырлар гына көрсенгән.

...Син сабырсың. Уйлар, кичерешләр,
Сөенечләр бар да эчеңдә, —
Сине аңлаганнар өчен генә
Шәүләләре уйный битеңдә.

Көрсенүең борчылдырды әле...

●

Кеше күңеле — серле сандык.
Ачу аны җиңел түгел.
Әмма ачсаң, күп бүлмәле
Лабиринттай тоела күңел.

Бүлмәләрдә яшеренгән
Зөбәрҗәтне табу — теләк.
Серле сандык ачылыр да...
Зөбәрҗәтне тану кирәк!

**Мансур Хәсәнов,**
филология фәннәре докторы, профессор

# СОЦИАЛИСТИК РЕАЛИЗМ ҺӘМ ТАТАР СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Иҗат методы мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнү, совет әдәбиятының бүгенге тәҗрибәләрен аның үзәк принциплары яктылыгында анализлау һәм тикшерү гаять зур фәнни-практик әһәмияткә ия. Бу исә, үз чиратында, нык үскән социализм чорын яңадан-яңа әдәби җәүһәрләр белән баеткан, казанышлары бөтен дөнья күләмендә танылган социалистик реализм әдәбиятының новаторлыгын тагы да тулырак ачу һәм күрсәтү мөмкинлекләре тудыра.

Социалистик реализм теориясе һәм эстетикасын иҗади үстерүгә йөз тоту, нык үскән социализм һәм фән-техника революциясе шартларында социалистик реализм проблемаларын фәнни нигездә эшләүнең кирәклеге һәм актуальлеге ике юнәлештә аеруча әһәмият ала. Беренчедән, конкрет милли әдәбиятларны өйрәнми торып, аларның җанлы тәҗрибәсен гомумиләштерми торып, күп милләтле социалистик культураның бөтен байлыгын тирәнтен аңлау мөмкин түгел. Чөнки социалистик культура милли башлангычлардан читтә һәм алардан бәйсез рәвештә яши алмый. Икенчедән, совет әдәбиятының иҗади методы проблемаларын алга таба фәнни эшләү, социалистик реализмның бай резервларын һәм мөмкинлекләрен тагын да киңрәк файдалану фән-техника революциясенең кызу темплар белән үсүе шартларында халыкара әһәмияткә дә ия.

Тормыш һәм халык массалары ихтыяҗларын үзенә чит санаган буржуаз әдәбият һәм сәнгать тирән кризис кичергән бер чорда, совет әдәбияты социализм һәм коммунизм, тынычлык һәм социаль прогресс идеяләре белән рухланып ныклы адымнар белән алга атлый, яңа кеше һәм объектив чынбарлыкны үзләштерү юлында сокландыргыч уңышларга ирешүендә дәвам итә. Без көндәлек һәм рухи тормышыбызда әдәбият һәм сәнгать моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә зур урын яулый барган матур бер чорда яшибез. КПССның тарихи XXV съезды документларында билгеләп үтелгәнчә, совет кешеләренә идея-политик, әхлакый һәм эстетик тәрбия бирү, аларның рухи ихтыяҗларын формалаштыру һәм канәгатьләндерү юлында социалистик культура һәм сәнгатьнең роле өзлексез үсә һәм арта бара.

Бүгенге әдәби процесс тиңдәшсез идеологик көрәш шартларында дәвам итә. Күп милләтле совет әдәбиятының күзгә ташланып торган казанышларын да буржуаз пропаганда һәм модернизм тарафдарлары, төрле уйдырмаларга нигезләнеп, күрмәмешкә салыналар, яисә киметеп күрсәтергә тырышалар. Ул гына да түгел, идея

дошманнарыбызның төп ярсуы әдәбиятыбызның асылы һәм үзәге булган социалистик реализм методына юнәлтелгән. Социалистик реализмны алар художникны тар рамкалар белән чикләп торган ниндидер бер директив һәм норматив метод буларак күз алдына китерәләр, күрсәтергә тырышалар. Шуңа күрә дә совет әдәбиятының бүгенге торышын, аның иҗат методының новаторлыгын фәнни нигездә өйрәнү һәм гомумиләштерү гаять зур әһәмияткә ия. КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында бүгенге әдәби процессның төп закончалыклары һәм үсеш тенденцияләрен тирәнтен өйрәнү һәм анализлау, әдәбият һәм сәнгатьтә партиялелек, халыкчанлык кебек ленинчыл принципларны ныгыту, совет сәнгатенең идея-эстетик югарылыгын өзлексез күтәрә бару һәм буржуаз идеологиягә каршы көрәшнең эзлеклелегенә ирешү зарурлыгы ассызыклап күрсәтелде.

Совет халкының тарихи гомумилеге нигезендә аның эстетик гомумилеге һәм дөньяга караш гомумилеге барлыкка килде. Бу гомумилек әдәбиятта һәм сәнгатьтә дә һәр даим ачык чагыла килә, үсә, тирәнәя бара. Социалистик реализм методының какшамас принциплары — чынбарлыкны революцион үсештә сурәтләү, партиялелек һәм халыкчанлык — язучыларга тормышны дөрес сурәтләргә, тарихи үзгәрешләрне күрергә, тормыш конфликтларын дөрес чагылдырырга, кешеләр характерындагы яңалыкны ачарга зур мөмкинлекләр бирә.

Социалистик реализмның бүгенге казанышлары күп милләтле совет әдәбиятының уртак иҗади уңышы булып тора. Академик А. Егоров билгеләп үткәнчә, «конкрет халыкларның художество культурасын өйрәнми торып, уртак социалистик культураны тулаем бер бөтен итеп күз алдына китерү һәм аңлау мөмкин түгел, чөнки ул милли сәнгатьләрдән читтә яисә аерым яши алмый»[1].

Совет Көнчыгышы әдәбиятлары туплаган күп кырлы һәм бай рухи мирас тө туган илебез әдәбиятлары йолдызлыгында махсус игътибарга лаек үзенчәлекле урын алып тора. Һәм монда социалистик реализм методын үстерүгә совет Көнчыгышы әдәбиятлары керткән өлешне махсус өйрәнү «күп милләтле совет әдәбиятын тагы да тулырак, күп бизәклерәк һәм гыйбрәтлерәк итеп күз алдына китерүгә»[2] ышанычлы нигез булачак, дип санаган Г. И. Ломидзе белән килешмәү мөмкин түгел.

Совет Көнчыгышы язучылары Ч. Айтматов һәм Б. Кербабаев, Ш. Рашидов һәм К. Яшен, М. Әүэзов һәм С. Муканов, М. Турсунзадә һәм М. Миршакар, М. Ибраһимов һәм А. Кешоков, М. Кәрим һәм Д. Кугельтиновның художество эзләнүләре социалистик реализмның нык базасына нигезләнгән эстетик системаны яңарта, кешенең акылы һәм рухына йогынты ясауның яңа мөмкинлекләрен һәм чараларын ача.

Көнчыгыш поэзиясе, фәлсәфи һәм эстетик фикеренең классик үрнәкләрендә гәүдәләнгән гуманизм һәм гаделлек идеяләре татар халкына инде күптәннән якын һәм аңлаешлы. Прогрессив татар җәмәгатьчелеге, фикер ияләре һәм күренекле язучылар Г. Курсави, И. Хәлфин, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, З. Бигиев, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Х. Ямашев, М. Вахитов, Г. Ибраһимов һәм башкалар һәркайсы теге яки бу дәрәҗәдә Әбугалисина, Хәйям, Низами, Фирдәүси, Фозули, Сәгъди, Хафизларның әдәби-эстетик мирасларына бурычлы.

Казанның географик урыны һәм фәнни-культура потенциалы аны Көнбатыш һәм Көнчыгыш культурасы арасында арадашчы итеп, рус, татар һәм Россиянең башка халыклары арасында традицияләрне, әдәби һәм фәнни элемтәләрне якынайту пункты итеп билгели сыман.

Идел буе, Кама буе, Урал халыкларының милли үзаңын уяту, аларның культурасын һәм сәнгатен үстерүдә алдынгы рус әдәбиятының роле аеруча зур булды. Казан — борынгы әдәби традицияләр шәһәре, Державин, Аксаков, Л. Н. Толстой, А. М. Горький шәһәре. Биредә Радищев, Пушкин, А. Н. Толстой һәм күп кенә башка күренекле язучылар, шагыйрьләр булган.

Алдынгы рус культурасы белән нәтиҗәле аралашу милли культураларда критик реализмны үстерүгә булышлык итте, әдәбиятта эпик жанрлар туып, театр һәм сәнгатьнең башка төрләре барлыкка килүен тизләтте.

---

[1] А. Егоров. Строительство коммунизма и развитие национальных художественных культур. Журнал «Коммунист», 1969, I сан, 37 бит.
[2] Бүгенге шартларда социалистик реализм. Мәкаләләр җыентыгы. М., 1977, 65 бит.

Социалистик революция һәм яңа җәмгыять төзү чорындагы совет Көнчыгышы әдәбиятлары өчен характерлы булган төп үзенчәлекләр һәм үсеш тенденцияләре әдәбиятыбызда да ачык чагылыш тапты. Шуңа күрә дә тарихи үсеш юлы шактый катлаулы, форма һәм эчтәлеге белән бай һәм күп кырлы булган татар әдәбияты теоретик уйлану һәм фәнни гомумиләштерүләр ясау өчен киң мәйдан, ышанычлы җирлек булып тора.

Көнбатыш һәм Көнчыгышның, барыннан да элек бөек рус әдәбиятының бай традицияләрен синтезлаштыра һәм өйрәнә барып, кызу темплар белән үсеп киткән татар әдәбияты Россия составындагы төрки телле әдәбиятларның беренчеләреннән булып XX йөз башында ук алдынгы эстетик процесска килеп кушылды.

Гаять зур әһәмияткә ия булган бу тарихи акт бигрәк тә халык шагыйре Габдулла Тукай иҗатында ачык чагылыш тапты. Аның поэзиясендә халкыбызның гасырлар буе тупланып килгән рухи мирасы рус һәм Көнбатыш сәнгатьләренең бай традицияләре белән очрашып, сыйфат ягыннан бөтенләй үзгә булган яңаны тудырды. Тукай иҗаты XX йөз башы шартларындагы иң югары әдәби-эстетик критерийларга җавап бирерлек биеклеккә күтәрелде. Һәм бу биеклек милли әдәбиятның алга таба үсеп китүе өчен ныклы нигез булды. Тукай татар халкының әдәби-эстетик фикерен сыйфат ягыннан бөтенләй үзгә булган яңа мәйданга алып чыкты, аның рухи дөньясын революцион эпоханың яңа тарихи эчтәлеге белән бизәде һәм, гомумән, Көнчыгыш поэзиясе офыкларын алсу нурга күмеп, сизелерлек дәрәҗәдә киңәйтеп җибәрде. Шигърияттә ул тугандаш халыкларның килер буын шагыйрьләре дәвам иткән, чын мәгънәсендә яңа бер мәктәпне нигезләүче иде. Башкорт шагыйрьләре Д. Юлтый һәм С. Кудаш, күренекле үзбәк шагыйре Г. Голәм, казакъ совет әдәбиятын нигезләүчеләр С. Сейфуллин һәм Б. Майлин, таҗик совет әдәбияты классигы С. Айни, төрекмән халкының танылган язучысы Б. Кербабаев һәм совет Көнчыгышы әдәбиятларының күп кенә башка күренекле әдипләре үзләрен Тукай мәктәбе шәкертләре дип санадылар, кайтып-кайтып күренекле татар шагыйрен хөрмәт белән искә алдылар.

Россия составына кергән төрки телле халыкларны бөек рус әдәбияты һәм культурасына якынайтуда да Тукай иҗаты әйтеп бетергесез әһәмиятле роль уйнады. Мәсәлән, С. Айнидан, Октябрь революциясенә кадәрге чорда Пушкин поэзиясе белән таныш булу-булмавын сорап кызыксынгач, ул: «Әйе, ишеткәнем дә, укыганым да бар иде, Тукайдан укыдым», — дип җавап бирә.

Рус әдәбиятындагы кебек үк татар әдәбиятында да социалистик реализмның формалашуы һәм нигезләнүе өчен уңайлы шартлар язучылар арасында хезмәт халкы, аның тормышы һәм яшәеш шартлары, иҗтимагый һәм рухи омтылышларына игътибар өзлексез үсә бару нәтиҗәсендә туды. Әлеге җитди борылыш әдәбиятта Октябрь революциясенә кадәрге чорда ук башланган иде инде. Пролетар язучысы Гафур Коләхметов иҗаты шуның аеруча якты һәм характерлы мисалы булды.

Совет властеның беренче елларында ук татар әдәбияты ил күләм әдәби процесска кушылып, яңа иҗат методының үзәк принципларын үзләштерә барды һәм, нәтиҗәдә, сокландыргыч әдәби-эстетик ачышлар ясады. Милли әдәбиятның яңа шартларда тиз арада һәм кызу темплар белән үсеп китүе, әлбәттә, аның чишмә башында революцион көрәш мәктәбен узган, зур тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе булган өлкән әдипләр торуы белән аңлатыла. Аларның иң күренеклесе Галимҗан Ибраһимов иде.

Г. Ибраһимов иҗаты һәм эшчәнлегенең әһәмияте милли рамкалар белән генә чикләнеп калмады, ул күп кенә башка тугандаш әдәбиятларга да шифалы йогынты ясады. Бу хакта төрекмән әдәбияты классигы Берды Кербабаев «Правда» газетасы сәхифәләрендә: «Совет властеның беренче елларында татар әдәбияты, Урта Азия халыклары әдәбиятлары белән чагыштырганда, нык үскән, алга киткән әдәбиятлардан санала иде. Ә аның алгы сафында Галимҗан Ибраһимов барды. Бу әдипнең әсәрләрендә социалистик милли культураларның барысы өчен дә уртак булган принципиаль яңалык бар иде», — дип язып чыкты.

Талантлы художникның күзәтүчәнлеге, аерым очракларда, махсус тикшеренүләр биргән нәтиҗәгә тиң була. Б. Кербабаевның совет Көнчыгышы әдәбиятларында социалистик реализм методы формалашуга Г. Ибраһимов керткән өлешне бәяләве

шул хакта сөйли. Гомумән, татар әдибенең күп кырлы һәм бай иҗаты илебез халыкларының уртак рухи-эстетик казанышына әйләнде.

Г. Ибраһимовның социалистик реализмны нигезләүгә керткән өлеше аның әдәби әсәрләре белән генә чикләнми. Ул яңа иҗат методын практик язучы буларак кына түгел, фикер иясе, теоретик буларак та үстерү өчен янып яшәгән тынгысыз әдипләр плеядасыннан иде. 1924 елда Мәскәүдә аның «Пролетар әдәбияты турында» дип исемләнгән китабы дөнья күрә. Яңа әдәбиятның теоретик мәсьәләләрен яктырткан хезмәтләрнең ил күләмендә беренчеләреннән була ул. Аңарда Г. Ибраһимов, революциядән соңгы беренче еллар әдәби хәрәкәте җирлегендә, марксистик-ленинчыл методологиягә нигезләнеп, материалистик эстетиканың үзәк мәсьәләләрен, әйтик, әдәбият-сәнгатьнең иҗтимагый асылы һәм функциясе, партиялелек һәм халыкчанлык, әдәби мираска мөнәсәбәт кебек җитди проблемаларны яктыртып чыкты.

Төрки телле әдәбиятлар үсешендә әдипнең, татар, үзбәк һәм әзербәйҗан телләрендә басылган ак эмигрант әдәбиятны анализлау нигезендә язылып, буржуаз милләтчелек идеологиясен кискен тәнкыйть иткән «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» хезмәте дә әһәмиятле роль уйнады. Бу китап күп милләтле совет әдәбиятының какшамас нигезе — халыклар дуслыгы һәм интернационализм идеяләрен пропагандалау һәм ныгытуга аеруча җитди өлеш кертте.

Социалистик реализмның теоретик һәм методологик мәсьәләләрен өйрәнүгә бу чорда Г. Сәгъди һәм Г. Нигъмәти кебек әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләр дә зур өлеш кертә. Г. Сәгъди исә бер үк вакытта үзбәк совет әдәбияты белемен нигезләүче галимнәрнең иң күренеклеләреннән санала.

Яңа иҗат методының новаторлыгы һәм бетмәс-төкәнмәс эстетик мөмкинлекләре Г. Ибраһимовның әдәби иҗат практикасында аеруча киң чагылыш тапты, сокландыргыч гүзәл нәтиҗәләр бирде. Аның «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», «Татар хатыны нилэр күрми», «Кызыл чәчәкләр» кебек роман һәм повестьлары, «Яңа кешеләр» драмасы һәм башка әсәрләре иң элек халыкның социаль һәм рухи тормышын чагылдырудагы новаторлыклары һәм заманның социаль актив героен тасвирлауда ирешелгән тирәнлекләре белән игътибарны җәлеп итсә, икенчедән, алар форма өлкәсендәге эзләнү-табышларының төрлелеге, социалистик реализм поэтикасын үстерүдәге яңалыклары белән дә әдәбиятыбыз тарихында лаеклы урын яуладылар. Бу әсәрләр, хаклы рәвештә, төрки телле совет әдәбиятларының 20—30 нчы еллардагы уртак казанышы буларак кабул ителде.

Билгеле булганча, социалистик реализмның тәүге уңышлары әдәбият һәм сәнгатьтә Бөек Октябрь тудырган яңа геройны иҗат итүгә юнәлтелгән өзлексез эзләнүләр процессында яуланды. Яңа герой концепциясен көн тәртибенә кую бер хәл, әле аның үз эченә нинди мәгънә, нинди илаһи көч туплавын ачыкларга кирәк иде, шуннан соң гына чын сәнгать чаралары белән аның кабатланмас эре фигурасын тасвирлау мөмкин булачак. Юк, бер селтәнүдә генә хәл ителә торган проблема түгел иде бу. Яңа дәвернең кабатланмас үз геройларын эзләү һәм иҗат итү күп милләтле совет әдәбиятында дистә елларга сузылган тарихи бер процесска әверелде. Татар әдәбиятының бу өлкәдәге эзләнүләре һәм табышлары бигрәк тә революция һәм яңа тормыш җырчысы Һади Такташ иҗатында ачык чагылыш тапты. Яңа тормыш төзү процессында туган яңа тойгылар шагыйрь өчен яңа матурлык чыганагы, бетмәс-төкәнмәс илһам чишмәсе булып әверелә. Такташның үз сүзләре белән әйтсәк, «шагыйрьнең яңалыгы яңа форма уйлап чыгарырга маташуында түгел, шагыйрьнең яңалыгы — аның яңа хисләрендә, яңа уйларында»[1].

1924 елның февралендә шагыйрь «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын тәмамлый. Мәгълүм булганча, әсәрнең үзәгендә революция юлбашчысы даһи Ленинның якты һәм масштаблы образы гәүдәләнә. Поэма шагыйрь иҗатында гына түгел, бөтен татар совет поэзиясендә социалистик реализмның киң мөмкинлекләрен күрсәткән, олы казанышын раслаган әсәр булды. Ул гына да түгел, «Күп милләтле совет әдәбияты тарихында билгеләп үтелгәнчә, Такташ, гомумән, ил күләмендә беренчеләрдән булып, җир кешесенең иң күркәм һәм гүзәл сыйфатларын үзенә туплаган Владимир Ильич Ленин образында яңа дәвер герое идеалын гәүдәләндерде[2].

[1] Һ. Такташ. Пьесалар. Хикәяләр. Мәкаләләр. Казан, 1953, 257 бит.
[2] История многонациональной советской литературы (в 6-ти томах). Т. I, М., «Наука», 1970, 423 бит.

Ләкин, кызганычка каршы, эчтәлеге һәм формасы белән дә поэзиядә чын новаторлык үрнәге булган һ. Такташ әсәрләре рус теленә тәрҗемәдә лаеклы яңгыраш тапмады әле. Бу хәл күңелне борчымый кала алмый, әлбәттә. Шулай да публицистик көче, кабатланмас музыкальлеге һәм милли колориты белән шигърияте безгә нур сирпеп торган Такташ поэзиясе үзенең масштаблылыгы, җорлыгы һәм бар нечкәлеге белән рус телендә дә һичшиксез яңгырар дигән өмет безне ташламый.

Г. Ибраһимов һәм һ. Такташ иҗатларында татар әдәбиятының социалистик реализм методын үзләштерү юлындагы тәүге адымнары һәм сокландыргыч уңышлары чагылыш тапты. Нәтиҗә буларак, әдәбиятыбыз лаеклы рәвештә союзкүләм әдәби процесска килеп кушылды, анда урын яулады. Совет язучыларының Беренче бөтенсоюз съезды программасына татар әдәбияты буенча махсус доклад кертелүе дә, аерым алганда, әдәбиятыбызның 20—30 нчы еллардагы уңышларының ил күләмендә танылуы һәм югары бәя алуы турында сөйли торган факт.

Билгеле, бу казанышларда Г. Ибраһимов һәм һ. Такташ белән бер сафта, татар совет әдәбиятының авангардында барган тәҗрибәле өлкән язучылар Ш. Камал һәм М. Гафури, Г. Камал һәм М. Фәйзи, әдәбиятка яшьлек ялкыны белән килеп кергән Ш. Усманов һәм К. Нәҗми, К. Тинчурин һәм Ф. Бурнашларның да өлеше зур һәм аерым игътибарга лаек булуын онытырга ярамас. Алар һәркайсы татар совет әдәбияты алдында торган бурычларның масштаблылыгын һәм җаваплылыгын ихлас тоеп бөтен таланты һәм иҗат энергиясен социализм төзү эшенә, туган халкына хезмәткә багышлаган зур әдипләр булды.

Тугандаш әдәбиятларның, аерым алганда, татар әдәбиятының 20—30 нчы елларда туплаган бай тәҗрибәсе социалистик реализм методының өстенлекләрен һәм яшәүчәнлеген раслаучы хакыйкать иде. Аның киңлекләре, иҗади мөмкинлекләре нигезендә милли әдәбиятлар арасында моңарчы күрелмәгән дуслык һәм үзара якынлык атмосферасы барлыкка килде, киләчәккә үсеш перспективалары ачык төсмерләнде.

Бөек Ватан сугышы җәмгыятебез һәм халкыбыз өчен генә түгел, социалистик реализм әдәбияты өчен дә җитди сынау, зур сынау булды. һәм ул бу сынауны да намуслы рәвештә узды дип раслларга тулы нигез бар.

Муса Җәлил... Бөек Ватан сугышы чоры татар әдәбиятының иң югары биеклеге аның исеме белән бәйле. Муса Җәлил — күп милләтле совет әдәбиятының горурлыгы һәм даны. Патриот-шагыйрь милли поэзиябезнең фәлсәфи тирәнлеген, идея эчтәлеген үстерде, иҗади офыкларын киңәйтте. Аның ялкынлы иҗатында бөтен совет поэзиясенә характерлы партиялелек һәм гражданлык, патриотизм һәм интернациональлек сыйфатлары ачык чагылыш тапты. «Традицияләр бергә үрелә. Шагыйрь җаны бик күп нәрсәне сыйдыра ала. Оренбург, Үзбәкстан, Украина далаларының гражданнар сугышыннан соң чистарып калган саф һавасын да, Александр Фадеев, Эдуард Багрицкий, Павло Тычиналарның революцион романтикасын да...»[1] — дип язды шагыйрь Сибгат Хәким, Җәлилнең иҗат һәм тормыш батырлыгы хакында уйланып. Җир йөзендә иң кара көч — фашизм белән бугазга-бугаз килгәндә дә үзенең рухи һәм физик гүзәллеген, гармониясен җуймаган социалистик җәмгыять кешесен тасвирлауда М. Җәлил бай поэтик арсеналын чын талантларга гына хас осталык белән эшкә җигә. Шуңа да татар халкының һәм тугандаш халыкларның революцион традицияләрен үзендә туплаган лирик герой бүген, лаеклы төстә, «дөнья әдәбиятының иң олы масштаблы күркәм образларыннан санала»[2], Җәлил иҗаты поэзиябезне дөнья аренасына чыгарып, аны сыйфат ягыннан яңа биеклеккә күтәрде.

Әлеге сыйфат үзгәрешләрендә, Җәлилнең каләмдәшләре һәм көрәштәшләре, Бөек Ватан сугышы кырларында туган ил өчен башларын салган Ф. Кәрим, А. Алиш, Г. Кутуй, Нур Баян кебек күп кенә башка шагыйрь һәм язучыларның да роле зур, әлбәттә. Бу әдипләр иҗаты шулай ук татар совет әдәбиятының иң күркәм сәхифәләрен тәшкил итәләр.

Сугыштан соңгы чор татар әдәбияты Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал традицияләрен дәвам иткән, масштаблы проза әсәрләре — роман һәм повестьлар язылу белән ха-

[1] Муса Җәлил. Герой-шагыйрьнең тууына 70 ел тулуга багышланган Бөтенсоюз фәнни конференциясе материаллары. Казан, 1978, 27 бит.
[2] Шунда ук, 43 бит.

рактерлана. Шушы елларда дөнья күргән ике әсәр — Гомәр Бәшировның «Намус», Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романнары СССР дәүләт премияләренә лаек булды. Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар», Мирсәй Әмирнең «Саф күңел», Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» һәм Әмирхан Еники повестьлары да киң җәмәгатьчелек тарафыннан 50 нче еллар татар совет прозасының җитди казанышы буларак кабул ителде. Бу еллар поэзиясендә аеруча Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, Г. Хуҗиев, С. Хәким, З. Нури, Х. Камалов кебек шагыйрьләр актив иҗат итте.

Хаклы рәвештә, нык үскән социализм чоры һәм фәнни-техник революция заманы дип саналган 60—70 нче елларда социалистик реализмның бай эстетик потенциалын тагы да киңрәк масштабларда тормышка ашыру өчен яңа мөмкинлекләр туды. Туган илебездә һәм тормышыбызда барган глобаль үзгәрешләр әдәбият һәм сәнгатьтә дә өзлексез чагылыш табып килә. Совет язучыларының нәтиҗәле идея-эстетик эзләнүләре социалистик реализм теориясе һәм поэтикасын яңа ачышлар, сокландыргыч уңышлар белән баетты. Бер үк вакытта әдәбият теориясе, әдәби-эстетик фикер һәм әдәби тәнкыйть үсеше өчен дә моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә уңайлы шартлар тудырылды. Бу уңайдан, КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мәгълүм карары (1972 ел, январь) партия һәм дәүләтебезнең әдәби-эстетик фикер һәм тәнкыйтебез торышы турында даими кайгыртучанлык күрсәтүен раслаган аеруча әһәмиятле вакыйга булды. Әлеге документ әдәбият теориясе һәм тәнкыйди-эстетик фикернең киң җәмәгатьчелек алдындагы авторитетын күтәрүдә дә хәлиткеч роль уйнады.

Үзебезнең татар әдәбиятын өйрәнү фәненә килсәк, ул да соңгы елларда башка республикалар һәм барыннан да элек рус совет әдәби-эстетик фикере казанышлары белән үзара тыгыз бәйләнештә үсеп, җитди уңышларга иреште. М. Гайнуллин, Х. Госман, Г. Халит, К. Фасеев, И. Нуруллин, Й. Нигъмәтуллина, Н. Юзиев, Л. Ачкасова, Л. Юдкевич, Х. Хәйри, Б. Гыйззәт, Р. Мостафин, К. Гыйззәтов, А. Әхмәдуллин, Ф. Әгъзәмов, Ф. Мусин, Т. Галиуллин, А. Яхин, Ф. Хатипов, Ф. Миңнуллин һәм башкалар әдәбият һәм сәнгатьнең актуаль проблемалары өстендә актив эшлиләр. Соңгы елларда гына да татар әдәбияты тарихын, анда социалистик реализмның формалашуы һәм үсеше, милли әдәбиятның рус һәм илебезнең башка әдәбиятлары белән үзара бәйләнешен җентекләп өйрәнү һәм гомумиләштерүләр нәтиҗәсендә байтак хезмәтләр язылды. Дөрес, әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйтебездә әле җитешсезлекләр дә шактый. Әмма аларны киметә бару һәм бөтенләй юкка чыгару өчен дә әлегәчә файдаланылмаган мөмкинлекләр, резервлар байтак.

Галимнәр хәзер социалистик реализмны бигрәк тә хәрәкәттәге һәм үсештәге процесс буларак өйрәнүгә зур әһәмият бирәләр. Әдәбият теориясендәге бу тенденция, үз чиратында, күп милләтле совет әдәбиятларының заман тормышына тагын да тирәнрәк һәм нечкәрәк үтеп керүе, аларның форма һәм стиль үзенчәлекләре арта бару, талантлы әдипләрнең иҗат палитраларында яңа төсләр гаммасы һәм сурәтләү чаралары берөзлексез ишәя килү белән аңлатыла.

Хәзерге татар әдәбияты, барлык совет республикалары әдәбиятлары кебек үк, хәрәкәттәге социалистик реализм ул. Күп кенә әсәрләрнең новаторлык асылы социалистик үзгәртеп коруларның революцион асылы белән билгеләнә. Яңа экономик һәм социаль процесслар язучылар һәм әдәбият белгечләренең дә даими игътибар үзәгендә. Республикабыз төбәкләрендә барган гигант үзгәрешләр, хезмәт батырлыгы һәм энтузиазм әларга иҗатларында колачлы гомумиләштерүләр һәм гүзәл ачышлар ясау мөмкинлекләрен тудырды. Тормышта яңа традицияләр, хезмәт кешесе характерында моңарчы күрелмәгән күркәм сыйфатлар формалашуы да язучы талантының тулырак ачылуы өчен кирәкле шартларны бермә-бер арттыра төшә. Хезмәт кешесенә игътибар үсү әдәбиятта коммунистик җәмгыять төзүчеләрнең яңа тарихи гомумилеген һәм советча яшәү үрнәкләрен тагы да тирәнрәк һәм киңрәк өйрәнү дигән сүз. Әйтик, соңгы елларда эшче сыйныфы тормышы белән якыннан кызыксыну һәм аларның бай рухи тормышын җентекләп өйрәнү татар әдипләрен яңа иҗади уңышларга китерде. Мисал өчен Г. Ахуновның «Хәзинә», Ш. Бикчуринның «Каты токым», Ә. Баяновның «Ут һәм Су», Э. Касыймовның «Чулман — оныклар елгасы» романнары, С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы» поэмасы һәм Д. Вәлиевнең «Сиңа тормыш бүләк итәм» пьесасын искә алу да җитә. Кара алтыны һәм бөек

төзелешләре белән данлы Татарстан эшчеләре турында язылган әсәрләр күп милләтле совет әдәбиятында нык урын алдылар. Иҗатында Г. Ибраһимов һәм Ш. Камаллар традициясен дәвам иткән өлкән язучы Габдрахман Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романындагы Уразмәтовлар династиясе, Журбиннар (В. Кочетовның «Журбиннар» әсәре) яки Рудаевлар династиясе (В. Поповның «Бу да гадәти эш көне» әсәре) белән янәшә тора. Татар язучылары иҗат иткән геройлар бүген, әдәбият белгечләре тарафыннан, хаклы рәвештә, Г. Николаева, В. Кожевников, В. Липатов, Г. Пенджикидзе, Ә. Мохтар, В. Бубнис, П. Загребельный әсәрләрендә сурәтләнгән замандашларыбызның эре образлары белән бергә искә алына, билгеләп үтелә. Фәнни-техник революция чорында әдәбиятыбызда фән эшлеклеләре һәм галимнәр тормышы белән кызыксыну да бермә-бер арта төште. А. Расихның «Ике буйдак» һәм Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романнары татар прозасы өчен чагыштырмача яңа булган бу өлкәдә беренче һәм җитди уңышлар санала.

Татар совет прозасы беркайчан да фәкать фән һәм техника прогрессын күрсәтү белән генә мавыкмады. Һәм бу, барыннан да элек, аның социаль-аналитик яктан җитлеккәнлеге турында сөйли булса кирәк. Үзәгендә эшче класс вәкиле яисә фән эшлеклеләре торган әсәрләрдә дә әдипләр социалистик гуманизм идеяләре яктылыгында формалашкан совет кешесенең рухи һәм физик матурлыгын, аның күңеле һәм хисләре сафлыгын, гүзәллеген, икенче планга калдырмый күз уңында тоталар. Бу исә, үз чиратында, совет эшчеләр сыйныфының үзаңы формалашу процессын бөтенләй яңа иҗтимагый-идеологик яссылыкта өйрәнү һәм сәнгатьле чаралар белән тасвирлауда иксез-чиксез мөмкинлекләргә юл ача.

Фәнни-техник революция һәм советча яшәү рәвеше мәсьәләләре белән тирәнтен кызыксыну язучыларны, телиме-теләмиме, турыдан-туры үзара мөнәсәбәтләр һәм заман кешесенең әхлак нормалары турында уйлануларга юлыктыра. Шуңа да әхлак темасы, әсәрдә производство яисә авыл тормышы яктыртылуга да карамастан, гадәт буларак югарыга калкып чыга. Безнең татар әдәбиятында бу әһәмиятле теманың тирәнлекләренә төшүдә соңгы елларда шагыйрьләр һәм бигрәк тә драматурглар аеруча нәтиҗәле эшлиләр. Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр», Ш. Хөсәеновның «Әни килде», А. Гыйләҗевнең «Югалган бер көн» пьесалары шуның характерлы мисаллары булып тора.

Тарихи-революцион темага багышланган әдәбият та замандаш язучыларыбызның социалистик реализм принципларын үзләштерүдә яңадан-яңа үрләр яулый баруы хакында сөйли. Бу күп кырлы һәм җитди темага тотынган әдипләрнең игътибар үзәгендә, кагыйдә буларак, кеше, үзенең бай рухи дөньясы булган тарихи шәхес тора. Һәм ул күп яклы, тирән психологик анализга дучар ителә. Нәтиҗәдә, тарихи шәхес максатлы, үз җаны һәм үз кичерешләре, борчу, омтылышлары булган әдәби герой булып яши башлый, безнең күңелләргә юл таба. Дөрес, әле тарихи-революцион үткәнне торгызу һәм аның геройларына җан өрү кебек җаваплы иҗат эшенә беркатлы һәм шаблон юллар аша гына килергә азапланучылар һәм, ул гына да түгел, шуны хуплаучылар да юк түгел. Күренекле казакъ язучысы А. Нурпеисов мәкаләләренең берсендә, үзенең «Кан һәм тир» трилогиясе герое Еламанның «массаларны җитәкләп, аларны революцион көрәшкә күтәрә алмавын» кимчелек итеп күрсәткән тәнкыйтьчеләр булуын юкка гына искә алмыйдыр. Оппонентларына җавабында язучы, авыр елларда дөньяның бар кыенлыкларын үз җилкәсеннән уздырган кичәге гади балыкчының ялгызу һәм адашулар аркылы яңа тормыш өчен көрәшкән халык массаларына килеп кушылу юлын күрсәтүне төп максат итеп куйганлыгын искәртә.

Тарихи-революцион темага язылган әсәрләрдә заман әдәбиятына хас сыйфатлардан аналитиклыкка омтылу тенденциясе аеруча ачык чагылыш таба. Бу исә әдипләрнең тормыш чынбарлыгына, фактларга һәм документаль башлангычларга игътибары күзгә күренеп үсүе хакында сөйли. Аналитик башлангыч бигрәк тә 60 нчы елларда бөтен совет әдәбиятының характерлы үзенчәлеге булып торды.

Ә инде 70 нче еллар башында тормышны сәнгать чаралары белән үзләштерүдә яңа сыйфат үзгәрешләре котелү һәм башлануы турында фикерләр ишетелде. Бу исә бер төркем талантлы прозаикларның чынбарлыкның фәлсәфи тирәнлекләрен өйрәнүгә омтылышы, иҗатларында синтезга зур әһәмият бирүләре белән аңлатыла

иде. Нәкъ менә шул чорда Ч. Айтматов, В. Астафьев, В. Распутин кебек язучылар инде ил күләмендә танылып өлгергән яңа әсәрләрен тәмамладылар. Татар әдәбиятында исә бу тенденция прозаиклардан Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, поэзиядә Х. Туфан, С. Хәким, Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Харис һәм драматургиядә Х. Вахит, Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, Д. Вәлиев әсәрләрендә матур чагылыш тапты, игътибарны җәлеп итте.

Шул рәвешле, соңгы еллар татар әдәбиятында, бөтен совет әдәбиятына да хас булган ике төрле үсеш тенденциясе төсмерләнә. Аларның берсе аналитик фикерләү җимеше булса, икенчесе — синтетик фикерләүнең өстенлек итүеннән. Әлбәттә, алар үзара берниндн дә кытай стенасы белән дә чикләнмәгән, бу бүленешнең билгеле бер дәрәҗәдә шартлы булуын да истән чыгарырга ярамас. Шулай да, безгә калса, социалистик реализм методына нигезләнгән бай традицияле олы әдәбиятыбызның киләчәге чынбарлыкны сәнгать чаралары белән үзләштерүдәге әлеге ике башлангычның үзара тыгыз бәйләнешендә һәм органик бөтенлегендә.

Совет власте елларында татар әдәбияты тугандаш әдәбиятларның җан җылысын тоеп данлыклы үсеш юлы узды. Ул үткән юл социалистик реализм иҗат методының яшәүчәнлеген, аның бетмәс-төкәнмәс иҗади мөмкинлекләрен раслап торган дәлилләрнең берсе. Күп милләтле совет әдәбияты бакчасында үзенә бер төрле чәчәк булып аткан татар әдәбиятының алтмыш еллык үткәне, тәҗрибәсе бер үк вакытта җитди гомум теоретик һәм эстетик мәсьәләләр куярга, аларны уңышлы хәл итәргә дә бай материал чыганагы, ышанычлы җирлек булып тора.

Илебездә яңа тарихи гомумилек — совет халкы формалашу яңа эстетик гомумилекне барлыкка китерде. Ләкин әдәбият белгечләре әле еш кына бу әһәмиятле фактны искә алу, гади констатацияләү белән генә чикләнеп калалар. Бу яңа эстетик категориянең асылы нидә, социалистик реализм теориясе һәм практикасы, күп милләтле совет әдәбиятының алга таба үсеше өчен ул нәрсә бирә? Әдәбият белемендә бу сорауларга җитди һәм тулы җавап бирелгәне юк әле.

Яңа эстетик гомумилекнең төп үзенчәлекләреннән берсе, әлбәттә, ул — совет әдәбиятының интернациональлеге. Бу үзенчәлек бигрәк тә нык үскән социализм чоры әдәби процессына хас. Шуңа күрә дә интернациональлек мәсьәләләре әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләрнең үзенә даими рәвештә игътибарлы булуларын сорый.

Милли әдәбиятларның үзара мөнәсәбәтләре, шул мөнәсәбәтләр йогынтысында чәчәк атуы һәм үзара якынаюы мәсьәләләрен алга таба өйрәнү дә бүгенге әдәбият белеме фәне алдында иң актуаль проблема булырак кала бирә. Бу уңайдан тәрҗемәләрнең роле көннән-көн үсә һәм арта баруын да махсус билгеләп үтәргә кирәк. 1917—1976 нчы елларда татар язучыларының 603 китабы 23 миллион гомуми тираж белән рус телендә, 217 китабы 2,5 миллион тираж белән СССР халыклары телендә бастырып чыгарыла.

Нык үскән социализм чоры әдәбияты форма һәм стиль төрлелекләренең өзлексез камилләшә баруы белән дә характерлы. Ләкин язучыларның бай иҗат практикасы әле бу өлкәдә дә җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгән һәм гомумиләштерелгән дип әйтеп булмый.

Әдәбиятларның жанр һәм стиль үзенчәлекләрен өйрәнү процессында традиция һәм новаторлык мәсьәләләренә аерым игътибар итү зарур. Чөнки әдәбиятыбызның барышы аларны алга таба өйрәнү өчен күп кырлы һәм бай материал бирә.

Тәнкыйть һәм әдәбият белеменең җитди игътибарын үзләренә җәлеп итәргә тиешле әлегедәй актуаль проблемалар байтак. Аларны фәнни нигездә җентекләп өйрәнү социалистик реализм юлыннан үсүләрендә дәвам иткән тугандаш әдәбиятларның төп үсеш тенденцияләрен билгеләү һәм нык үскән социализм чорында совет җәмгыятенең уртак рухи казанышына аерым әдәбиятлар керткән өлешне ачыклау буенча кызыклы һәм гыйбрәтле нәтиҗәләр бирәчәк.

Халыклар дуслыгы, кешеләрнең яңа тарихи гомумилеге — коммунистик җәмгыять төзүче күп милләтле Ватаныбызның төп казанышы. Күп милләтле совет халкының бердәмлеге алмаз кебек нык,—диде КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Л. И. Брежнев.—Халкыбыз бердәмлеге аны тәшкил иткән һәркайсы бай, тулы канлы һәм бәхетле тормышта яшәүче милләтләрнең күп төрлелеге белән алмазның күп төсмерле кырлары балкуына тиң.

## Шәмси Хамматов

# «МИЛЛИОННАРНЫҢ БӘЙЛӘ ЙӨРӘГЕН...»

*Журналист, галим, җәмәгать эшлеклесе Шәмси Хәбибулла улы Хамматовның «Газета һәм әдәбият дуслыгы» дигән хезмәте быел Татарстан китап нәшриятында басылып чыгачак. Журналистларга, әдипләргә, эшче-авыл хәбәрчеләренә, әдәбият сөючеләргә юллана торган әлеге китап матбугатның әдәбият белән күпьяклы элемтәләрен, аңа партия җитәкчелеген тәэмин итешүен, әдипләр белән тормыш арасындагы бәйләнешләрне ныгытуга булышуын күрсәтә.*

*Ул, авторның татар матбугатының 60 еллык эшчәнлеген өйрәнү җимеше булу белән бергә, озак вакытлар җитәкче вазифалар башкару вакытында журналистика һәм әдәбиятның үсеш процессында актив катнашу җирлегендә тупланган бай тәҗрибәне гомумиләштерү нәтиҗәсе дә.*

*Китапның авторы инде 1930 нчы елларда ук вакытлы матбугатта күп санлы мәкаләләр, шигырьләр белән катнаша башлаган авыл хәбәрчесеннән республикабызның җаваплы матбугат органының редакторы дәрәҗәсенә үскән тәҗрибәле журналист, оештыручы, партия хезмәткәре.*

*Ул читтән торып Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Сугыш елларында КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлап, 1945 елдан журналистика өлкәсендә хезмәт итә башлый. Башта «Кызыл Татарстан» газетасының редактор урынбасары була. Берничә ел КПСС өлкә комитетында бүлек мөдире булып, һәм тагын фәнни учреждениеләрдә эшли. 1960 елдан хәзергәчә — «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы.*

*Ул 1939 елдан КПСС члены (апрель аеннан), җәмәгать эшендә актив катнашып килә, күп еллар партиянең Татарстан өлкә комитеты члены, КПССның XXIII съезды делегаты, Республика Верховный Советы депутаты, 1959 елдан ТАССР Журналистлар союзы идарәсе председателе, СССР Журналистлар союзы идарәсе члены.*

*КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Иҗтимагый Фәннәр академиясендә 1950 елны диссертация яклап тарих фәннәре кандидаты дигән гыйльми исем алгач,*

*доцент буларак, фәнни-тикшеренү эшләре алып бара. Ул берничә фәнни китап, күп санлы публицистик мәкаләләр, юлъязмалар авторы. «Почет билгесе», «Халыклар дуслыгы», Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән, РСФСРның атказанган культура работнигы.*

*Кырык елдан артык гомерен партия эшенә һәм матбугатка багышлаган коммунист-журналист үзенең быел апрель аенда туласы 60 еллыгын да яңа актив иҗади эшләр белән каршылый.*

*«Совет әдәбияты» журналында, мәсәлән, беренче публицистик чыгышларын 1948—1949 елларда бастырган булса, «Казан утлары»нда соңгы елларда гына да әдәбият һәм матбугат темасына унга якын публицистик мәкаләләре басылды.*

*Хәзер исә журналыбыз укучыларына аның телгә алынган яңа китабыннан Һ. Такташ һәм М. Җәлилнең 20—30 нчы елларда «Кызыл Татарстан» газетасы эшендә катнашуын күрсәтүче бер бүлеге кыскартып тәкъдим ителә.*

...«Кызыл Татарстан» газетасы публицист-шагыйрьләр Һ. Такташ һәм М. Җәлил белән тыгыз иҗади элемтәдә яши. Бу һәр ике як өчен дә нәтиҗәле була. Алар матбугатны көрәш, хезмәткә, батырлыкка өндәү мәйданы итеп карыйлар. Һ. Такташ әдип-публицистларга газета аша «миллионнарның бәйлә йөрәген» дигән чакыру ташлый һәм: «Каләм безнең кулларда тормышны социализмча яңартып коруның һәм кешелекне үзгәртүнең гаять куәтле коралы» [1],— дип яза ул.

Казанга килгәч, ул төрле вакытларда «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, соңрак «Чаян», «Октябрь яшьләре», «Авыл яшьләре», «Азат хатын» журналлары редакцияләрендә җаваплы секретарь, бер үк вакытта «Яңалиф» журналы редколлегиясенең члены була. Вакытлы матбугатта эшләү тәҗрибәсе Һ. Такташны политик мөхитны, социаль көрәш кыйбласын бик яхшы сизә торган шагыйрь итә, политик зирәклеген үткенли, иҗади үсеше өчен йогынтылы этәргеч була, чорның актуаль мәсьәләләрен тирәнтен аңларга, тормыш күренешләренең асылын, типик үзенчәлекләрен дөрес тотып алырга булыша.

Укучылар Һ. Такташның политик рухлы шигырьләре, поэмалары һәм иҗат командировкаларында язган публицистик мәкаләләре белән иң әүвәл «Кызыл Татарстан» газетасы аша танышалар.

Шагыйрь газетаның даими игътибар үзәгендә. Ул бер кичәдә Һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын укуын хәбәр итә. «Һади Такташ иптәшнең «Гасырлар һәм минутлар»ыннан Ленин үлгән атнадагы картиналарны ачык күрсәткән шигырьләре белән чыгуы кичәгә аерым рух, тәэсир бирде» [2], дип яза газета.

Һ. Такташның матбугатка, аерым алганда, «Кызыл Татарстан»га олы ихтирамы 1927 елның октябрь аенда газетаның 2000 нче саны чыгу уңае белән язылган «Онытылган тәбрик» шигырендә калку чагыла. Шагыйрьнең бу әсәре газетаның 16 октябрь санында басыла.

«Никахсызлар», «Син дә үл инде», «Бүгенге матурлык», «Москва — Лондон сөйләшә», «Җырым сиңа булсын», «Лорд Чемберленга...», «Үтеп барышлый», «Син дошманым минем», «Гайбәт теле», «Тун трагедиясе», «Мин дизертир бугай, командир» кебек бик күп шигырьләрен Һ. Такташ башлап «Кызыл Татарстан»га тәкъдим итә. Алар газета битләрендә басыла да. Ул социализм өчен көрәшчеләрне, яңа тормыш төзүчеләрне данлый, яшәү, тормыш матурлыгын хезмәттә күрә, иҗади хезмәт батырларына мәдхия җырлый, халык дошманнарының, империалистларның мәкерле уйларын фаш итә.

---

[1] Һ. Такташ. «О себе», «Красная Татария», 1931, 24 мая.
[2] «Кызыл Татарстан», 1924, 24 апрель.

Йөрәк ялкыны белән сугарылган публицистик рухлы бу әсәрләр газетаның политик үткенлеген, актуальлеген көчәйтә. Мәсәлән, аның буржуаз милләтчеләргә, солтангалиевчеләргә каршы юнәлдерелгән шигырьләре шундыйлардан. «Кызыл Татарстан»да 1929 елның 20 сентябрендә «Солтангалиевчелек турында» ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бюросы карары басылып чыга. Газетаның 29 октябрь санында шушы карарга мөнәсәбәттә Һ. Такташның «Син дошманым минем» («Партияле» һәм партиясез солтангалиевчеләргә) исемле шигыре басыла. Шагыйрь социалистик төзелеш дошманнарын — солтангалиевчеләрне нәфрәт белән тамгалый.

Һ. Такташ «иҗатының мәгънәсен, көчен партия белән, халык белән өзлексез бәйләнештә, партиянең бөек идеалларына, совет халкына хезмәт итүдә күрде... Ул: «Минем үлеп бара торган сыйныфлар белән бер бәйләнешем дә юк. Мине бер подлец та партиядән аера алмый. Партиядән читтә — мин шагыйрь түгел»,— диде һәм үзенең матур әсәрләрен партияле рух белән сугарып язды»[1].

Газетада, матбугатта Һ. Такташ үзенең очерклары, мәкаләләре, фельетоннары, юлъязмалары белән дә актив чыгыш ясый. Ул Татарстан районнарында, авылларында, хәрби частьләрдә, Идел буе шәһәрләрендә, Донбасста була, язучыларның 1929 елны милли республикаларга оештырылган экскурсия-сәяхәтендә йөри, Мәскәүдә М. Горький белән очрашуда катнаша.

1928 елны Астраханьга барып кайткач, Һ. Такташ газетада «Сагынган җырләрдә» дигән очеркын язып чыга. «Эшче районының,— ди ул,— безне кызыксынып каршылавы күңелне күтәрә. Эшчеләр алар инде бөтен мәдәни байлыкны, шигырьне дә, әдәбиятны да, үзенеке итеп хис итү дәрәҗәсенә үсте. Бу безнең өчен зур җиңү»[2].

Газетаның 1929 ел, 6 октябрь санында әдипләрнең экскурсиядә алган тәэсирләре турында да Һ. Такташ горурланып яза. «Без,— ди ул,— безнең әсәрләребез белән кызыккан унлап милләтнең меңнәрчә эшчеләрен күрдек. Алар безгә милләт, тел аерымлыгына карамый, сыйнфый күзлектән карап, интернациональ әдәбият тудырырга социаль заказ бирделәр... пролетариат язучыларына үзләренең эшләрендә никадәр җаваплы булуларын аңлаттылар. Без кемлегебезне, кем булырга тиешлегебезне аңладык. Без нәрсә турында җырларга, нәрсә турында язарга кирәклегебезне белдек».

Экскурсиядә катнашучыларның Мәскәүдә Максим Горький белән очрашулары Һади Такташ күңелендә онытылмаслык эз калдыра... Шуны әйтү кызыклы: М. Горький белән «мәҗлестә,— дип яза галим Хатип Госман,— Такташ Горькийга үзенең «Мокамаен» укып күрсәткән. Горький шагыйрьнең әсәренә дә, аның үз шигырьләрен уку осталыгына да шунда бик югары бәя биргән, аны дөнья әдәбиятында үз әсәрләрен иң оста укучы зур шагыйрьләр белән чагыштырган»[3].

Һади Такташның матбугатта басылган публицистик чыгышлары партиябезгә совет кешесен социализм рухында тәрбияләргә булышлык итте, газета-журналларның оештыру көчен, тәрбияви куәтен арттырды. Ул журналистларны, әдипләрне бүген генә туып килгән яңа күренешләрдән киләчәккә карап олы нәтиҗә ясау осталыгына өйрәтте. «Кызыл Татарстан» газетасында чыккан бер мәкаләсендә, әдәбиятның, театрның ролен тукталып, ул болай дип язды: «...шаулап үткән вакыйгаларны әдәби калыпка салып күрсәтү, үзе шул вакыйганы күреп үткән укучыны язган нәрсәгә ышандыру, аны әйтергә теләгән уйлары белән чолгау — язучыдан күп көч, күп эшләүне сорый... Ә бит әдәбият, театр бүгенге теләкләрне җанландыру, укучының, тыңлаучының фикерен шул теләкләр тирәсенә оештыру нигезендә үсәргә, көндәлек проблемалар белән караучының йөрәген дулкынландырып, бүгенгенең туып килгән вакыйгаларына реагировать итәргә тиешләр»[4].

Һ. Такташ газета аша укучыларына үзенең иҗат планнарын сөйли, «Киләчәккә хатлар»ының төп идеясен аңлата. «Хәзерге вакытта мин «Киләчәккә хатлар» әсәре

[1] Хатип Госман. Такташ поэзиясе. Казан, Татгосиздат, 1953, 141 бит.
[2] «Кызыл Татарстан», 1928, 29 июль.
[3] Хатип Госман. Такташ поэзиясе, 118 бит.
[4] «Кызыл Татарстан», 1929, 8 декабрь.

өстендә эшлим. Аларда мин киләчәк буыннарга безнең яңа тормыш-көнкүреш, яңа кеше өчен алып барган көрәшебезне тасвирларга тырышам.

Беренче хатта (1930 елда «Кызыл Татарстан»да басылып чыкты[1]), мин сыйнфый көрәшнең гомуми фонын бирдем. Икенче хатта (басылып ята) колхозчы һәм гомумән безнең күчү чоры кешесенең психологиясендәге каршылыклар берлегән күрсәтәм.

Өченче хатта мин социалистик хезмәт кешенең психологиясен ничек үзгәртүен сурәтлим»[2].

1930 ел. Газетада әдәби сәхифәләр «Матур әдәбият фронты» дигән исем белән бирелә. Һ. Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасыннан өзек шушындый битләрнең берсендә иң элек «Кызыл Татарстан»да басыла. Әдәбиятыбыз тормышында зур вакыйга була бу. Социализм төзүчеләргә шигъри гимн булган бу әсәр күп меңләгән укучылар күңеленә шунда ук юл таба.

1931 елның февраль аенда Бөтен Татарстан Советларының IX съезды эшли башлый. 17 февральдә Һ. Такташ «Съезд ачылды» дигән публицистик шигырен яза. Ул газетаның беренче битендә 19 февральдә басылып чыга.

Съезд берничә көн дәвам итә. Газетаның 22 февраль санында «Шагыйрь Һ. Такташның Бөтен Татарстан Советларының IX съездында сөйләгән шигыре» дигән рубрика астында «Безнең чор» дигән әсәре басыла. Газетаның шул ук санында «Съезд көндәлеге» дигән информациядә делегатлар алдында Һ. Такташның чыгыш ясавы әйтелә. Бу факт утыз яшьлек шагыйрьнең революция, халык трибуны, «үз әсәрләрен иң оста укучы шагыйрь» булуы турында сөйли.

Шагыйрьнең Татарстан Советлары съезды трибунасыннан укыган «Безнең чор» исемле әсәре соңыннан «Киләчәккә хатлар» поэмасына икенче хатның бер өлеше булып керә.

Һади Такташ, әйткәнебезчә, төрле жанрда иҗат итә. Менә аның «Кызыл Татарстан» газетасында басылган «Тун трагедиясе»[3] дигән әсәре. Ул газетаның беренче битендә ярыш темасына багышланган материаллар белән янәшә урын ала. Шагыйрь бу фельетонында брак ясаучыларны үткен сатира теле белән фаш итә, эшнең сыйфаты өчен көрәшергә чакыра.

Ялкынлы публицист гомер буена журналистикадан аерылмый. Ул, Татарстан районнарында булып, колхозчылар, совхоз эшчеләре белән очраша. Аларның тырыш хезмәте, колхоз авылының үсеше турында үткен мәкаләләр, очерклар яза. Шуларның берсе — «Таң»[4] дигән очерк. Анда Актаныш районы, «Таң» колхозы эшчәннәренең тормышы сурәтләнә... «Җиңүләр өчен көрәшкәндә бөек җиңүләргә алып баручы Коммунистлар партиясенең тоткан сәясәтен, алга куйган теләкләрен бик нык өйрәнү кирәк,— ди автор.— Шуның өчен «Таң»да сәяси аң-белем кружоклары төзегез, шул кружокларга колхоз активын тартыгыз... Хезмәтне җиңелләштерә торган яңадан-яңа юллар эзләгез. Үз эшен белгән сәяси кадрлар әзерләгез». Болардан тыш, Һ. Такташ сыйнфый дошманнарга карата уяу булырга чакыра. Кыскасы, очерк 1930 еллардагы колхоз авылы тормышын төрле яклап ачык күз алдына китереп бастыра.

Кызганычка каршы, талантлы шагыйрь һәм ялкынлы публицист Һ. Такташның гомере бик иртә өзелде. Газета, аның вакытсыз үлеме турында хәбәр итеп, әдипләрнең, интеллигенция вәкилләренең, хезмәт ияләренең сөекле әдип турындагы мәкаләләрен, истәлекләрен урнаштыра. Кави Нәҗми «Кызыл Татарстан»дагы чыгышын «Үлем түгел бу!» дип исемли. «Һадиның,— дип яза К. Нәҗми,— пролетариат революциясен җырлаган шигырьләрендә, аның әле матбугатта чыгарга өлгермәгән

[1] «Кызыл Татарстан», 1930, 12 апрель.
[2] «Советская Татария», 1931, 24 май.
[3] «Кызыл Татарстан», 1930, 30 декабрь.
[4] Шунда ук, 1931, 5 август.

соңгы әсәрләрендә яшәү утлары бүген тагын да яктырак яналар. Бүген аның шигырьләре меңнәрчә йөрәкләргә электр тогы кебек тоташып, иҗат дәртен дөрләтәләр. Бүген Такташ кулыннан вакытсыз төшкән каләм — аның замандашлары тарафыннан күтәрелеп, тагын да очлана төшәр!» [1].

Муса Җәлилнең вакытлы матбугат белән бәйләнеше һ. Такташныкына бик охшаш. Шагыйрь 1922 елның көзендә Казанга килә, «Татарстан» газетасы редакциясенә күчереп язучы булып эшкә урнаша.

Муса Җәлилнең якын дусты, публицист Мәхмүт Максуд аның журналистлык эшчәнлеге турында болай язды: «Муса гомере буе газета-журналларда актив катнашып килде. Бөек Ватан сугышында ул кызылармеецлар газетасы «Отвага»ның сотрудникы иде.

Унҗиде яшьлек яшүсмер вакытында, 1923 елның җәендә, Муса Казанда «Кызыл Татарстан» газетасының редакциясендә эшләде.

Муса, әйтергә мөмкин, тумыштан ук шагыйрь булуы белән бергә, журналист та иде, журналистлык хезмәтен ул чын күңеленнән яратып башкара иде» [2].

«Татарстан» газетасында М. Җәлил имзасы 1923 елдан күренә башлый. Ул елларда газетаның җаваплы секретаре булып эшләгән Шәриф Байчура истәлекләренә караганда, газетаның 23 март һәм 8 июль саннарында һава флоты төзелү уңае белән Мусаның ике шигыре, 15 апрель санында Тукайга багышлап «Тукай каберендә», 24 июль санында «Корбан» дигән атеистик шигыре басылып чыга.

Г. Тукайның үлүенә ун ел тулу уңае белән язылып, «Тукай каберендә» шигырендә шундый юллар бар:

**Син җырлаган бәхет, дус-туганлык,**
**Син теләгән батыр эш көне,**
**Синдә булган хаклык, миһербанлык**
**Илгә килде хәзер бөтене...**
**Әйе, монда синең өстеңдә дә**
**Ал чәчәкләр үскән һәммәсе —**
**Алар нинди матур!**
**Киң илдә дә —**
**Хәзер шундый ирек, ямь яши** [3].

Күргәнебезчә, М. Җәлил бөек шагыйрь исеме белән горурлана, «син җырлаган бәхет, дус-туганлык... илгә килде» дип шатлана. Аның иҗатына Габдулла Тукай тәэсире бик зур була. Мәхмүт Максуд егерменче еллар башында бездә (рус поэзиясендәге шикелле үк) төрле «изм»нар калкып чыкканлыгын, әмма 17—18 яшьлек Мусаның «изм»нарның берсенә дә иярмәвен яза. Моны ул Тукай йогынтысы белән аңлата [4].

Гази Кашшаф әйткәнчә, футуризмны алга сөргән, барлык «иске» кануннарны — элекке әдәби традицияләрне җимергән сул фронт оешмасына — «сулф»ка Муса Җәлил «кушылмый, ул әдәбиятның киң массага аңлаешлы булуын яклый» [5].

Шагыйрь шул елның көзендә ачылган рабфакның икенче курсына укырга кергәч тә редакциягә еш килеп йөри. Ул һәр вакыт диярлек берәр хәбәр яки шигырь

---

[1] «Кызыл Татарстан», 1931, 10 декабрь.
[2] Мәхмүт Максуд. Сагынган минутларда (Муса Җәлил турында истәлекләр һәм уйланулар). Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1963, 26—27 битләр.
[3] «Татарстан», 1923, 15 апрель. Карагыз: шулай ук М. Җәлил. Әсәрләр. Дүрт томда. I том. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1975, 74 бит.
[4] Мәхмүт Максуд. Сагынган минутларда, 122 бит.
[5] Гази Кашшаф. Муса Җәлил. Тормышы һәм иҗаты турында очерк. Казан, Татгосиздат, 1957, 125 бит.

алып килә. Аның бу чорда «Татарстан» газетасында хәбәрче һәм шагыйрь буларак катнашуы 1925 елның җәенә, рабфакны тәмамлап китүенә кадәр дәвам итте. Ул рабфак тормышыннан язган мәкалә һәм хәбәрләренә тулы имзасын куймый иде. Мәсәлән, газетаның 1924 ел, 1 январь санында басылган «Татар эшче факультетында» дигән мәкаләсенә ул «М» дип кенә кул куя. Аннары шул ук елның 11 февраль санында «Балалар әдәбиятына ярдәмгә» исемле мәкаләсе урнаштырыла. Анда сүз комсомол Үзәк Комитеты янындагы татар-башкорт бюросы тарафыннан чыгарыла торган «Кечкенә иптәшләр» исемендәге журнал турында бара. Бу мәкаләгә инде ул «Муса» дип кул куя, 20 февральдә чыккан «Татарстан» газетасындагы «Татар эшче мәктәпләрендә татар теле дәресенең урыны» дигән мәкаләсенә инде ул М. Җәлил дип тулы имзасын куя. Кыскасы, ул шигырьләренә һәр вакыт тулы имзасын, ә хәбәрләренә «М» яисә «Муса» дип кул куя иде [1].

«Татарстан» газетасы редакторы булып эшләгән Фәтхи Бурнаш аның әдәби яктан үсүенә нык ярдәм итә. Библиограф, пенсионер М. Бурнашева, бу иҗади ярдәм турында искә алып, мондый юллар яза: «Муса Тукайга багышлап язган яңа шигырен Фәтхи абыйга китергән икән, ул аны үзе бик әсәрләнеп, меңа кат-кат укып күрсәтте.

— Тукайның юбилее уңае белән Фәтхи абый бер җыентык чыгарырга әзерләнә, шул җыентыкка китердем,— диде Муса.— Гомумән, Казанга килгәч, Бурнаш ага миңа күп ярдәм итте,— диде ул.

Бөек Тукайның юбилеена карата тулы җыентыгы һәм шагыйрь турында әдәби парчалар җыелмасы... 1926 елны дөнья күрде.

1923 елны Ф. Бурнаш «Көрәш җырлары» исемендә беренче тапкыр совет поэзиясе җыентыгын чыгарды һәм бу җыентыкта Муса Җәлил иҗатына аерым бер бүлек бирде. 1925 елны Ф. Бурнаш МОПРның өлкә комитеты председателе булып эшли башлады. «МОПР көтепханәсе» сериясендә китаплар бастыруны оештырды. Беренче китапны ул үзе төзеде һәм шул сериядән өченче китап итеп Муса Җәлилнең «Иптәшкә» исемле беренче шигырьләр җыентыгын чыгарды. Ул җыентыкны Ф. Бурнашның үзе редакцияләгәне хәтеремдә калган» [2].

Муса Җәлил яшьтән үк ленинчыл комсомол рухында тәрбияләнә, әдәби әсәрләренең идея эчтәлегенә бик нык игътибар итә. «Кызыл Татарстан» газетасында 1925 елның 13 январь санында «Театрларда» дигән рубрика астында Муса Җәлилнең «Бибкәй кыз» исемле драмасы Татар дәүләт театры сәхнәсендә куелуы уңаеннан, «Алтынчы урындык» псевдонимы белән әсәрне идеологик яктан тәнкыйтьләгән рецензия басылып чыга.

Матбугатта чыккан бу рецензиягә җавап итеп, М. Җәлил «Редакциягә хат» яза. Ул газетаның 1925 ел, 15 январь санында басыла.

«Редакциягә хат.

Дәүләт татар театры сәхнәсендә дәүләт труппасы тарафыннан уйналган «Бибкәй кыз» музыкалы драма 1922—1923 елларда язылган иде. Ул һәм аның кебек күп әсәрләрем надан хәлемдә, эшләнмәгән талантка таянып язылдылар да, шунда ук югалдылар да. Алар үзләренең мөндәриҗә һәм идеологик яклары белән минем хәзерге карашымда бөтенләй дөрес түгелләр. Алар минем иҗадиятем сафыннан күптән алынып ташланганар.

Шулардан берсе «Бибкәй кыз» каян табылып килеп эләккән дә татар театрында минем аерым рөхсәтемнән һәм аның өстенә мәсьүлиятемнән башка уйналган. Шулай ук ул һәм башкалары да, ишетүемә караганда, Уфа, Бәләбәй кебек төрле шәһәрләрдә шулай уйналып йөриләр икән.

Шушы язуым белән мин мондагы мәгънәсез эшнең моңысы иң соңгысы булуын белдереп әйтәм:

---

[1] «Социалистик Татарстан», 1967, 18 февраль. Ш. Байчура истәлекләре.
[2] Шунда ук, 1968, 11 февраль.

Минем каләмем белән элек язылган 1) «Бибкәй кыз» (музыкалы, дүрт пәрдәдә), 2) «Чиган егете» (җиде картина), 3) «Кабил-Һабил» (музыкалы, өч пәрдәдә), 4) «Каз канаты» (музыкалы, өч пәрдәдә) исемле әсәрләр бүгеннән игътибарән һичбер җирдә, һичбер сәхнәдә уйналырга, укылырга, төзәтелергә, йөртелергә тиеш түгелләр.

Тыңламаучыларны каты мәсьүлияткә тарттыруны үземнең комсомол бурычым дип беләм. Бу белдерүне башка газитләр дә күчереп бассалар икән.

**Муса ҖӘЛИЛ»** [1].

Бу документ егерме яшьлек Муса Җәлилнең үз иҗатына җаваплы, партиячел каравы турында сөйли. Ул эчтәлеге белән укучыга, тамашачыга дөрес тәрбия бирмәгән әсәрләр «һичбер җирдә, һичбер сәхнәдә уйналырга, төзәтелергә, йөртелергә тиеш түгелләр» дип белдерә.

Мәскәүгә күчеп эшли башлагач та М. Җәлил республика матбугаты, бигрәк тә «Кызыл Татарстан» белән элемтәсен өзми. Һ. Такташ үлгәч, «Пролетариатның әдәби фронттагы көчле бер союздашын югалтканда» дигән мәкалә язып шагыйрьгә үз мөнәсәбәтен белдерә. «Һади Такташны югалту,— ди ул,— әдәби фронтта ударник — әдәби көчләрне тагын да киңрәк, тирәнрәк оештыру, сафыбызны ныгыту һәм бөек большевизм сәнгате өчен көрәшебезне көчәйтү белән каршыланырга тиеш...» [2]»

Бөек Ватан сугышы алдыннан, 1939 елны, Казанга кайтып эшли башлагач, М. Җәлил «Кызыл Татарстан» газетасында әдәби-тәнкыйть, публицистик мәкаләләре, рецензияләре белән актив катнаша. Партиянең Казан шәһәр комитеты кушуы буенча бу газетаның еллык эшенә күзәтү дә ясый. Н. Җиһановның «Качкын» операсы (Ә. Фәйзи либреттосы), Таҗи Гыйззәтнең Татар дәүләт академия театры куйган «Кыю кызлар» пьесасы (Гадел Кутуй белән бергәләп), Н. Исәнбәтнең «Болак арты республикасы» пьесасына, шул ук авторның «Хуҗа Насретдин» пьесасына, «Үги кыз» [3] спектакленә рецензияләр язып, театрыбыз, драматургиябез — гомумән, сәнгатебез үсешенә зур өлеш кертә.

Шәриф Камалның әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенә утыз ел тулу көненә багышлап, шагыйрь газетага «Данлы утыз ел» дигән мәкалә яза [4]. Шәриф Камал иҗатының көче, М. Җәлил фикеренчә, аның татар әдәбиятында чын реализм мәктәбен тудыруында. Аннары автор Шәриф Камалның татар әдәбиятына эшчеләр тематикасын алып килүен, шуны өзлексез дәвам иттерүен күрсәтә. «Ш. Камал...— ди Муса Җәлил,— үз иҗатын бөтен кешелек көрәше мотивлары белән сугарып, аны күп телдәге совет әдәбиятының бер кисәге итә алды» [5].

М. Җәлилнең газетада басылган «Драматургиябез алдындагы бурычлар» дигән мәкаләсе бүген дә актуальлеген югалтмаган. Татар драматургиясенең иң зур җитешсезлеге, автор фикеренчә, бүгенге тематикадан, бүгенге политик актуаль проблемалардан артта калуында. Драматургиядә югары художество сыйфаты өчен көрәш төп бурычлардан булырга тиеш. Психологик тулы эшләнгән образлар, тирән эчтәлек, ышандырырлык вакыйгалар, җанлы әдәби тел — драматургның төп максаты булсын [6].

1941 елны «Алтынчәч» операсының нәкъ Бөек Ватан сугышы башлану алдыннан сәхнәгә куелуы уңае белән М. Җәлилнең «Иҗат дуслыгы» дигән мәкаләсе басыла. Ул анда үзенең Н. Җиһанов белән дуслыгын чагылдыра. Анда шундый юллар бар: «Алтынчәч» либреттосы буенча опера иҗат иткән композитор Нәҗип Җиһанов әсә-

---

1 «Кызыл Татарстан», 1925, 15 январь.
2 «Кызыл Татарстан», 1931, 14 декабрь.
3 Шунда ук, 1939, 12 июль; 1940, 25 январь; 22 февраль, 29 апрель; 1941, 4 январь.
4 «Кызыл Татарстан», 1940, 20 февраль.
5 Муса Җәлил. Әсәрләр. Дүрт томда. 4 том, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976, 207 бит.
6 «Кызыл Татарстан», 1940, 23 март.

рендә төп тема — халык патриотизмы темасы, ул әсәрнең характерын, идеясен һәм төп мотивларын тирән аңлап, аны музыкада тулысынча чагылдырды. Ул әсәрдәге гомумиләштерелгән романтик образларны сыйфатлау өчен халык музыкасының эпик алымнарын һәм лирик мотивларын файдаланды. Композитор халыкчанлыкны халык көен шул килеш механик куллану дип аңламый, киресенчә, чын халык рухында, халыкның бай хыялын чагылдырган оригиналь музыка иҗат итү дип аңлый. «Алтынчәч» операсы шул нигездән чыгып эшләнгән... Композитор Җиһанов белән без бу эшне һәр вакыт тыгыз бәйләнештә, бер-беребезнең иҗат табигатен аңларга тырышып эшләдек һәм бергә эшләү безгә күп нәрсәдә ярдәм итте»[1].

Газетаның иң актив авторы санап, М. Җәлил дусты Г. Кашшафка 1942 елның 3 апрелендә, аңа язучы «Фадеев тәкъдим иткәнчә», үзен «Кызыл Татарстан» газетасының «спец. хәрби корреспонденты итеп билгеләүләре турында газета редакциясе белән» сөйләшүен үтенеп яза, «милли татар частена тизрәк эләгер идем һәм «Кызыл Татарстан», «Красная Татария» газеталары өчен бик кирәкле күп нәрсәләр эшләр идем»,— дип белдерә. «Юкса, ачу килерлек,— дип дәвам итә ул аннары,— янында гына якташларың фашист хәшәрәтләрен кырып, әллә нинди могҗизалар эшләсеннәр, ә мин, аларның үз шагыйрьләре, шуның өстенә журналист, алар белән бәйләнеш тотмыйча, аларның батыр эшләре турында бер сүз дә язмыйм... Газета бу нәрсә белән бик кызыксынырга тиеш»[2].

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Гали Динмөхәммәтовка 1942 елның 2 июнендә язган хатында Муса Җәлил үзенең «Кызыл Татарстан» газетасының «махсус военкоры булып, милли частьларда йөрергә, татар геройлары турында язарга теләр идем»[3],— ди. М. Җәлил, хәрби корреспондент буларак, фронтның алгы позицияләрендә «боевой походта йөреп үткәрергә туры» килүен әйтә, чөнки «шунсыз газетаны оператив һәм боевой итеп чыгарып булмый. Фронтның чын геройларын, шулай ук командир һәм сугышчыларны газетада яктырту, анализ ясау өчен, боевой эпизод һәм боевая операцияне бары фронтның алгы сызыгында гына күреп була. Мин, үз фронтыбызның бөтен почмагында булып, шактый нәрсә күрергә, шактый хәлләр баштан кичерергә өлгердем инде. Зур батырлыклар күрсәтеп, орден-медаль алган байтак татар егетләрен дә күрдем. Алар турында «Кызыл Татарстан»га язам, шулай ук әдәби әсәр язарга җыенам. Шулай итеп, монда чын-чынлап, шигырьдә әйткәнчә, бер үк вакытта каләм һәм автомат белән сугышырга туры килә. Мин үз эшемнән бик разый»[4].

*

*   *

Матбугат белән шундый дуслык татар совет әдәбиятының корифейлары Һ. Такташ һәм М. Җәлил поэзиясенә политик үткенлек, актуальлелек бирде, гражданин буларак аларның шәхесен югары күтәрде.

---

[1] «Кызыл Татарстан», 1941, 20 июнь.
[2] Муса Җәлил. Әсәрләр. Дүрт томда. 3 нче том, 581—582 битләр.
[3] «Казан утлары», 1976, 5 сан, 146 бит.
[4] «Казан утлары», 1976, 5 сан, 146 бит.

Сибгат Хәким

# ҖӘЛИЛЛӘР АЧКАН ЮЛДАН

Шигърият һәм шагыйрь исеме. Поэзиядә Тукай, Такташ, Җәлил рухы. Шагыйрь һәм гражданин, гражданлык, традицияләр... Күпме сорау. Кабатлаудан куркам. Моңа хәтле язылган мәкаләләрдә, матбугатта бу турыда сүзнең тукталганы юк. Бөтен әдәбиятлар өчен дә уртак сораулар.

Башта әле шигырь турында. Нәрсә ул шигырь? Бу сорауны Туфанга бирсәң, ике дә уйлап тормастан, шигырь ул ритм дияр һәм бармакларын бөгә-бөгә шигырьне ритмик буыннарга аера башлар. Теориясенә керешер, шигырь төзелешенә керешер. Туфан шигырьнең теоретигы, теориясен яхшы белә, ярата, хезмәтләре бар.

Минем караштаʔ Моннан кырык ел элек шигырь миңа моңсулык иде. Билгесез моңсулык. Авылым кырлары күк үзем дә, шигырем дә сентименталь. Хәзер? Хәзер мин үзем турыдан-туры катнашкан вакыйгалардан алган хисләр хисабына язам. Вакыйгалардан кысып алынган, активлык бәрабәренә бирелгән хисләр хисабына яшим. Онытгысыз яшьлек малайны магнит тавына алып менгән еллар, синең хәрәкәтең шушыннан башланып китә дип, стартка куйган еллар мине гигантларның бер түбәсеннән икенче түбәсенә ташладылар, вакыйгаларның берсеннән икенчесенә ыргыттылар шикелле. Вакыйгаларны мин бусы колхоз хәрәкәте, бусы бөек төзелешләр дип бүлгәләмим, кешеләр язмышы минем күңелдә бер тоташ өермә булып калган, сугыш алды, сугыш еллары, сугыштан соң кичергәннәрнең һәр көне шушы өермәдә бөтерелгән. Моннан ничек исән чыктым әле дип, дөньяга гаҗәпләнеп карап торган чаклар да булган. Бик күп каләмдәш-көрәштәшләрне югалтканмын — кайгырганмын, моңа чаклы бөтенләй күрмәгән яңа буын вәкилләре белән очрашканмын — сөенгәнмен. Һәр яңага сөенгәнмен, яшәүгә сөенгәнмен. Европаның үзәгендә, Җәлилләр, Алишлар узган юлларның читләренә басып, үз халкымның язмышы, культурасының язмышы турында уйланганмын. Хәзер миңа шигырь — Тукайлар язмышы, Җәлилләр язмышы. Бөтен каршылыклары белән кайнап торган тормыш, ә хисләр шуннан көрәшеп алынганы гына икән. Шигырьгә бары шулары гына көчә икән. Александр Блокның «Над строкой обольюсь слезами» дигән сүзләре мәгънәсен хәзер тирәнрәк аңлыйм. Күп сыйдырышлы икән бу дүрт юлдан торган шигырь. Моңсулык, кеше күңеле, интим дөнья, хисләр дөньясы — барысын да элеккечә саклаган хәлдә, шигырьнең бөтен формаль якларына турылыклы булып калган хәлдә, хәзер инде ачык итеп әйтә алам, шигырь минем карашымда ике генә сүздән тора: шигырь — заман рухы, заман сулышы.

Шагыйрь исемеʔ Кайда гына булсам да, татар шагыйренең исеме чыкканда миңа кимсенергә туры килмәде. Төрле төштә, төрле шартларда сынадым мин бу

исемне. Бу исемгә үз халкымның хөрмәте зурлыгын күптән беләм, укыган китапларыннан аңына борынгыдан ук әкренләп сеңгәндер ул хөрмәт. Башка халыкларда да шулай булгандырмы, ләкин татар халкы китапка, аның язучысына, шагыйренә ниндидер бер табыну белән карый. Башка халыкларда да шулайдыр, шагыйрьләр кайда гына тусалар да, нинди генә телдә язсалар да, аларны бер сыйфат берләштерә: намуслылык, тугрылык. Халык аларга ышанган. Халыкның ихтирамын тиз генә яулап алып була дип уйлаучылар бик нык ялгышканнар.

Миңа кимсенергә туры килмәде. Һәр халыкның үз талантлары бар. Үзенә генә түгел, башка халыкларга да билгеле, бик күп бүтән телләргә дә күчерелгән талантлары бар. Менә шулар арасында урта куллар югалып кала, тоныклана, төсе китә, сүнә, йолдызлар арасында сүнә. Менә шунда, шунда күренә чын талант. Хөрмәт ителә торган таланттан тыш тагын нинди талантның булуы мөмкин? Бар икән. Пушкин, Лермонтов алдына барып баш иясең, табынасың, хөрмәтең чиксез. Язмышлары сине тирәнгә-тирәнгә, әллә кайларга алып керә. Син ачыклап бетерүне киләчәк буыннарга калдырасың. Мохтар Әүэзов, Сабит Муканов, Бирды Кербабаев, Чыңгыз Айтматовларны мин Тукай турында сөйләгәндә, официаль хөрмәттән чыгып түгел, үз язмышларын татар шагыйре йөрәгеннән укыган кешеләр итеп күз алдыма китердем. Шундый ук хәл Җәлилдә кабатланды. Кайсын Кулиев һәм Давид Кугультиновлар үзләре дә кечкенә шагыйрьләрдән түгел. Муса Җәлил язмышы аларда әле кузгатылмаган, ләкин бер кузгалырга тиешле, үстерелергә тиешле икенче хисләрне уятты күк. Аларда мин Муса Җәлилгә гаҗәп бер эчке якынаю тойдым.

Язучыларның бөтен союз күләмендәге пленум һәм съездларында, поэзиянең урыны турында сүз барганда күп кенә чыгышларның Җәлилдән башлануы миндә әйтеп бетергесез горурлык хисе уятты. Идеологик көрәшнең иң кискен моментларында Муса Җәлил иҗатының эталонга әйләнүе мине, татар шагыйрен, канатландырды. Күп язучыларын югалтып, шуның фаҗигасен кичергән, тетрәнеп калган, яңадан күтәрелү өчен рухын җыйган татар поэзиясенә Муса Җәлил исеме уттан исән чыккан байрак булып, батырлык, гражданлык байрагы булып килеп керде. Поэзиядә Тукай кебек, Җәлил кебек юлында мәңге янып торган исемнәр кирәк. Үз халкың тудырган исемнәр кирәк. Ничек кенә димә, башта син үз җиреңнән атлап китәсең. Иҗатта аларның җитәкләгән җылы кулларын тоясың. Бөек исемнәр. Бөек үрнәкләр. Горурлык хисе бик конкрет нәрсә, аңа кабыну өчен үз җиреңнең чаткысы кирәк.

Шагыйрь исеме. Тормышның калын катлауларыннан бәреп чыккан исемнәр халыкта калды. Тормышның үзеннән калыккан исемнәр. Тукайны әйткән дә юк. Халык улы булып туган, халык улы булып калган. Такташ исеме, миңа калса, Төркестан сахралары түреннән, кайнар ком далалары эченнән янып килә кебек, шуннан революциягә тоташып, ул исем зурая, ут шарына әйләнә шикелле. Такташ революция биргән энергияне татар шигыренә күчерде, шигырьнең революция биргән трибунадан яңгырарлык пафосын тапты, шушы чорга гына хас романтик рухын җырлап узды.

Үз чорын, үзе яшәгән заманны җырлый шагыйрь. Бөтен рухын шул чорга туплый. Маяковский җырлаган чорны башка берәү дә бүтән төрле яңгырата алмас кебек. Такташның да үзенә беркетелгән шундый чоры бар. Туфан исеме дә Уралны үзенә беркетте. Ярты гасыр узуга карамастан, яшь, озын буйлы, калын чәчле Туфанны әле һаман мин Урал, Арча якларыннан иртәнге сәгатьләрдә ашкынып, шаулап Казанга килүче поездларда күрәм. Артында Урал, Урал байлыклары, запас хисләр, уйлар запасы. Казанга буш кул белән түгел, күңелдә тулышкан хисләрне кемнәргәдер әйтми калсаң ярамас диган фикер белән килә.

Үзең яшәгән чор, кабатланмас чор. Татар совет поэзиясенең үсешендә зур баскычлар күрәм. Тормышның бер чорыннан икенче чорына сузылган баскычлар, тормыш баскычлары. Шул яңа чорның үзенә генә хас яңа талантлары туа.

Татар совет поэзиясенең Бөек Ватан сугышы чорына туры килгән кайнар дүрт елын тарих иң элек Муса Җәлил һәм Фатих Кәримгә беркетмәдемени? Ялкынлы гражданлык лирикасының дүрт еллык фронты тулысы белән алар кулында иде. Солдатлары Шәрәф Мөдәррисләр, Гали Хуҗилар, Мансур Гаязлар. Дүрт ел аз диярләр. Бу шагыйрь җанының бәхетле кабынган моменты гына. Фаҗигале кыска бер мо-

ментта җанның ташуы гына. Дөньяга шагыйрь булып килүенең зур исемен раславы гына. Шагыйрьләр үлемсезлекне шулай гына яулыйлар кебек, шагыйрьләр тормышта шулай гына яшиләр кебек. Бөек исемнәр. Бөек үрнәкләр. Аллага табынган кебек табынган шагыйрьләр. Кайчандыр Александр Блок белән бергә укыган карт профессор безгә, студентларга, дәрестә Гете, Шиллер, Гейнеләр турында сөйли иде. Шул хәтле еракта ул шагыйрьләр, баш җитми. Кайчан да булса татар шагыйрен дә шулар арасында очратырмын дип башыма да китермәгәнмендер. Кайда ул! Әмма менә очраттым, күп еллар узгач нәкъ шулар арасында, янәшә, бер залда, Европаның уртасында, Берлинда, «Дуслык йорты»нда очраттым. Мин һәр вакыт горурлык хисеннән акланауына шатланып яшим. Минем рухымны гел горур тоту өчен бәлки язмыш миңа шулай мәрхәмәтле булгандыр. Татар шагыйре титаннар арасында. Күрелмәгән хәл. Берсенә дә таныш түгел. Ә карашы нык, ышанычлы, «Фауст», «Буря и натиск», «Германия» әсәрләре турында бәхәскә керергә әзер тора. Үзен иркен тота. Ирекка, азатлыкка юллар мең төрле. Җәлил шуның иң авыры аша узган, көрәшеп, сугышып. Ә үзең көрәшеп тапкан юллар үтемлерәк, салмаграк, аларның тормышны раслый торган көче зуррак, аларның яшәү гомере дә озынрак. Гражданлыкның бөтен өстенлеге дә шундадыр дип беләм.

Гражданлыкка шагыйрьләрнең килү юлы төрле. Такташның Зөбәйдәләре Гейне Матильдасының рухы белән рухланган. Фатих Кәрим Лермонтовны үзенең пәйгамбәре дип атый. Фронтта Такташ исеменнән дошманнарына залп бирә. Гомумән, татар шагыйрьләре арасында Байронның ирек сөючән олы рухы яши. Алар арасында ниндидер билгесез җепләр сузылган. Шәһәрләр, илләр, океаннар аша сузылган. Шагыйрьләр дәверләр аша ирек, азатлыкның каршына йөгерәләр шикелле. Байроннар — Грециягә, Җәлилләр — Германиягә. Пабло Нерудалар үз илләре — Чилига таба.

Гражданлыкны минем аерым шәхесләрнең иҗатларына гына кайтарып калдырасым килми. Җәлилләр язмышы сирәк язмыш. Җәлил иҗаты гражданлыкның бөтен дәверләр өчен дә үрнәк булырлык югары формасы. Ләкин гражданлык поэзиядә нинди генә формаларда чагылмасын, аның нигезендә тормышка актив мөнәсәбәт ята. Минем үземә килгәндә, шушы тип шагыйрьләрне иҗатта үрнәк иттем.

Көтү, каршылау, каршы алу. Кем син? Шушы кызыксыну миндә беркайчан да бетмәде. Яңа исемне күрәсе килү, танырга теләү, яңа талантка сусау. Әдәбиятның өзлексез яңаруы. Иҗатның чикләнмәгән мөмкинлекләре. Яшермим, хафаланган чаклар да булды. Ләкин көттем, эчке бер ууҗәтлек белән көттем. Безнең халыкның бетмәс-төкәнмәс рухи байлыгына яшәгән саен ныграк ышандым, халык сабан туй мәйданына батырларын кертән кебек, талантларын әдәбият мәйданына да үз эченнән көрәшкә чыгара тора. Сугыштан соң сафлар сирәгәеп калган чакта шигърият ишеген беренче булып Шәүкәт Галиев какты шикелле. Кем син? Кем урынына? Кайсысы урынына? Әйтерсең ишек артында чират кына көтеп торганнар, Әхсән Баянов, Илдар Юзеев, Марс Шабаев, Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов, Гамил Афзал, Хисам Камаловлар, Рәшит Гәрәйләр түргә узды. Алар сугыштан яңа гына кайтып төшкән Зәки Нури, Әнвәр Давыдов, Зыя Мансурларга килеп кушылдылар. Без сугышта чакта үсеп җиткән буын. Безнең белән ул-бу була калса, алмашка әзерләнеп торган буын. Мусаларга, Кәрим, Алишларга алмашка әзер торган буын. Резерв, рухи резерв. Тыл ачык калмаган. Сугыш еллары аларның җанын гариплəндерә алмаган. Йөрәкләре сау калган. Күңелләре киң, табигатьләре бай калган. Поэзиягә Шәүкәтләр буыны керде, иманнары нык, иманнары Тукайча.

Әдәбият — тормыш. Әдәбият — биография. Шәүкәт Галиевнең иң яхшы әсәрләреннән берсе «Әткәйгә хат». Марс Шабаевның иң уңышлы әсәрләренең берсе «Җирән Конрад». Әхсән Баяновның иң көчле поэмаларының берсе, бөтен иҗатының эчке юнәлешен билгеләгән, язмышында тирән эз калдырган әсәрләренең берсе — «Сез аңларсыз мине». Саҗидә Сөләймpraнованың бөтен язганнарын үз тирәсендә тоткан әсәре «Җир-су». Гамил Афзалның тылы Урал, Магнитогорск. Урал заводлары чыныктыра яшь Гамилне. Иң көчле шигырьләре «Үзем үлеп ятам» дип башлана аның. «Дүрт алмагач», «Коммунист йөрәге турында баллада»лар Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндәге шигырьләре белән авыздаш. Коммунист йөрәге Мусаның үз батырлыгын хәтерләтә. Темада, хисләр, гражданлыкта нинди охшашлык!

Кышкы шыксыз бураннар, шомлы төннәр, ятимлек сагышы. Хисам Камаловның әнисенең үлеменә багышланган шигырьләре дә шушы авыр елларны тасвирлыйлар. Илдар Юзеев иҗаты сугыштан соңгы оптимистик настроение белән бергә күтәрелә. Яшьлек белән, институт, мәхәббәт белән бергә каядыр ашкына, өметле, якты, бераз романтик, бераз Такташча. Бу шагыйрьләр тормыштан, халыктан.

Мәкаләмне Трусковецта дәваланудан калган буш араларда язам. Янымда шигырь китаплары да юк, язмалар да юк. Үзебезнең поэзиягә ерактан карыйм, кайдадыр еракта үсеп утырган агачка караган кебек карыйм. Яфраклымы, юкмы? Бай безнең поэзия. Талантларга бай. Рухландыра, фикер әйтергә өнди. Һәркайсының үз төсе. Традициягә нык ябышканнар. Бу буын Җәлилләр, Әхмәт Фәйзиләрдән әйтерсең аерылып бетмәгән. Якынлык характерларында, тыйнаклыкта. Традиция мәсьәләсендә гүя бер сүздә, безгә бер Тукае да бик җиткән диган шикеллерәк караштә торалар. Бер Тукае да. Тукай үзе зур бер традиция. Күп нәрсәне үзенә җыйган. Үзәге — Тукай. Исәнбәт, Туфан, Җәлилләрдә Тукай барыннан да күбрәк. Шәукәтләр буынында да нык сизелә, алардан соңгыларда азая, арага Дәрдмәнд керә. Тукай традициясе. Нигезе шулай. Әмма кемнең күңеле кайда уйнаганын әйтүе читен. Яңа чор яңа хисләр өсти. Яңа чор үзара бәйләнешләргә бай. Яңа талант, яңа шәхесләр йөзләгән әдәбият, культура, традицияләрнең берлеген эзлиләр. Эзлиләр, яңарыш чоры бара. Традициядә берсе тарихка чума, Сәйф Сараилар янына тикле төшеп җитә, поэзия катлауларын шуннан кубарып менә. Берсенең рухы Назыйм Хикмәт, Пабло Нерудалар эзе буйлап чикләр аша алар рухына тоташа. Фәнни-техник революция үзе генә дә инде яңача уйлаучы шагыйрьләрен тудырды.

Шәукәт Галиевләр буыны шагыйрьләрен бер традиция берләштерсә дә, алар һәркайсы аерым талант. Бу чирек гасыр вакытны җырлаган поэзиянең эченә керергә тырыштым. Чирек гасыр, шулай дим, ә бит шагыйрь күңеленә ул чирек гасыр чик түгел. Шагыйрь күңеле конкрет чордан читкә чыгып, шактый еракка китеп эзләнә. Минем үземнең дә сугыш алды елларына кайтып, поэзияне күзәтеп, кайбер чагыштырулар ясыйсым килә. Кайбер кешеләр гел бертөсле генә итеп күрәләр шикелле поэзияне. Бертөсле түгел. Шактый зур үзгәрешләр кичерде поэзия. Кеше хисләренең бик ярлыланып калган чакларын беләм. Хистән бигрәк, кичерештән бигрәк тышкы күренешләрне сөйләү белән мавыккан чоры да булды аның. Булды, мин үзем дә иҗат гомеремнән 6—7 елымны сызып ыргыттым. Фатих Кәримнең дә баштагы иҗатына хас ул. Хисләр эрозиясе. Барьы өч шагыйрь генә аңа бирешмәде: Такташ, Туфан, Әхмәт Фәйзи. Муса Җәлилнең 30 нчы еллардагы шигырьләренең кайбер кимчелеге турында әйткәч, Гази Кашшаф үпкәли иде. «Моабит дәфтәре»н иҗат иткән Муса, әйе, бөтенләй икенче Муса. Шул кимчелекләрдән арынып, Фатих Кәримнең яки Муса Җәлилнең гражданлык поэзиясенең иң яхшы үрнәкләрен бирү дәрәҗәсенә күтәрелә алуы — менә мине нәрсә сокландыра. Шагыйрьнең көче дә шунда бит! Нури Арслановның соңгы ун-унбиш ел эчендә язганнарын элекке иҗаты белән чагыштырып карагыз. Элек тә ул шигырь техникасының остасы иде. Язганнары бар да үз урынында иде, дөрес иде. Шагыйрьгә дөрес язу гына җитми, күрәсең. Ул шагыйрьлеккә кире кайтып, стартка яңадан басты кебек, хисләр давылы кузгалды, татар, казакъ, Көнчыгыш әдәбиятлары традицияләренең шигырьдәге байлыгы кабат хәрәкәткә килде, шагыйрь үзен тапты, шагыйрьнең үзенә дә рәхәт, безгә дә рәхәт булып китте.

Фикер, уй, хис, кичереш поэзиясе. Һәркайсының үз төсе. Берсендә хакыйкать һәм халыкчанлык, традицион форма ярылып ята. Берсе лирикада җебеп китми, кырыс. Берсе традицион формаларда язып та йөзләгән традиционнар арасында һаман да яңа. Берсендә мәхәббәт хисләре ачыну дәрәҗәсенә күтәрелә. Минемчә, ачына белү дә әйбәт сыйфат. Чын шагыйрьләр кабатланмый. Һаман нәрсәдер өстәлә бара поэзиягә. Моңсулыктан барыгыз да качасыз, моңсулык кайсыгызга ят ди кебек берсе. Шигырьнең башы бәлки шул сентиментальлектәдер? Шул хакта үзенең лиро-эпик, публицистик поэмалары белән Әнвәр Давыдов чыга мәйданга һәм аның «Ташу»ы һәртөрле сентиментальлекне үз юлында шәфкатьсез рәвештә юып китә төсле.

Төрлечә иҗат итә шагыйрьләр. Әмма эзлекле рәвештә күзәтсәң, буыннар арасындагы чылбырны өзмәсәң, поэзиянең кинәт төшеп киткән җирләре дә, үрләре дә

ачык күренә. Башта ук традиция дигән нәрсәнең ныклыгына ышанасың. Фикер һәм формаларда бик нык эзләнгән, башкача булырга тырышканнар да бөтенләй үк ычкына алмыйлар ул традициядән. Өстәлә, үзгәрә. Хәзер Равил Фәйзуллиннар, Гәрәй Рәхимнәр буыны дип сөйлибез поэзиядә. Бер буын, үзенә аерым буын. Бу буынга кергәннәрнең хәзер бөтенесе төсмерләнде. Ренат Харис, Зәлфәт һәм Мөдәррис Әгъләмов, Радиф Гатауллин һәм Рөстәм Мингалимовларның берсен дә сызып булмый. Бергә килделәр, бер вакытта, бер теләкләр белән, бәхәсләшеп, үткәннәрне анализлап, бәяләп, кабул итеп һәм нәрсәнедер кире кагып. Дәгъва белән килделәр. Күбрәк мәктәптән. Равилләрнең поэзиягә керүе кайбер яклары белән Такташ, Туфаннарның шаулы чорын бераз искә төшерә, бераз гына ләкин. Шуның ерактан килә-килә элекке куәтен югалткан бер күренеше сыман.

Бер төркем. Төркем-төркем. Шәүкәт Галиевләр төркеме, Равил Фәйзуллиннар төркеме. Шул төркемнәргә кергән шагыйрьләрдә нәрсәдәдер уртаклык яши. Бер чорда бергә поэзиягә кергәнгәме, карашларда, омтылышларда уртаклык яши. Роберт Әхмәтҗановны гына бер төркемгә дә кертеп булмый. Тормышта да, әдәбиятта да буыннар арасында йөри... Ялгыз йөри, шуңа күзгә күбрәк ташлана. Үз талантының берсенеке белән дә кушылмавын эчтән яхшы белеп йөри. Буыннарны ялгый.

Гәрәйләр, Радифләр буыны шагыйрьләре. Поэзиядә ун-унбиш ел. Кайберләре хәзер Җәлил, Тукай премияләре алу дәрәҗәсенә иреште. Һәркайсы берничә җыентык авторы. Алар турында тәнкыйть күптән үз фикерен әйтеп килә. Аларның талантлы бәхәссез. Аларның иҗат үзенчәлекләрен күрергә тырышканмын, кайчандыр аларга хәерле юл теләгәнмен. Берьюлы күреп бетерү читен. Талант бер урында тормый.

Мин инде Илдарлар буыны иҗатына күнеккән идем. Күнеккәнмен, ияләшкәнмен. Шуннан яңа кешеләр, яңа исемнәр, Зәлфәтләр, Мөдәррисләр, Гриша-Гәрәйләр. Тыйнакларга күнеккәнмен, болар кыюрак, усалрак, дәгъвалырак, үзенекен сугышып алырга әзерләр. Поэзиягә сугышчанлык хас. Бу шагыйрьләр минем күнеккән нормаларымны җимерделәр. Аларның килүе үз иҗатым өчен дә кирәк булган, шуны тойдым.

Бәйләнеш хәтта төрле чор шагыйрьләре арасында да яши. Мөдәррис Әгъләмовның шигырьләрен тыңлаганда нигә Сәгыйть Рәмиевнең «Таң вакыты» искә төшә? Тонындамы, рухындамы, каян уртак хисләр? Нинди җепләр бәйли шагыйрьләрне? Ә Виктор Хара язмышы, Чили язмышы турындагы шигырь? Мөдәррիснең мондый шигырьләре булмаса, аны мин берьяклылыкта гаепләр идем. Виктор Хара... Талантлы шагыйрьләр үзеннән бөтенләй ерак темаларда да яна алалар. Зөлфәтнең трибунлыгында Такташлык шактый. Беренче чиратта, гражданлыкта, хисләр белән шигырьдәге иркенлекнең оста кушылып яңгырашында. Шагыйрьләрнең бәгырьләре үзенә якын бәгырьләрне эзли. Йөрәк тә түгел, җан да, күңел дә түгел, бәгырь. «Есенин бәгыре өстендә». Маяковскийның Есенин үлеменә багышланган шигыреннән соң татар шагыйренең җанны тетрәтерлек яңа шигырен уку минем өчен шатлыклы күренеш. Бер яклы түгел безнең шагыйрьләр. Төрле вакыйгаларга, төрле континентларга тоташа алалар. Радиф Гатауллинның «Европада татар шагыйрьләре» циклы да башка шигырьләреннән үзенең гражданлык горурлыгы белән аерылып тора, шагыйрь үзен дөнья уртасында иркен тотып яза. Шагыйрьләрнең иҗат характерлары төрле, гражданлык төрле. Кайчандыр гражданлыкны ниндидер бер зуррак теманы сөйләп чыгу дип аңлаучылар да бар иде. Хәзер ул чор узды шикелле.

Бу буын шигырьнең үз көченә күбрәк ышана. «Көрәшчеләр», «Мулланур», «Рәссам», «Күз карасы», «Юл өстендә тургай» кебек поэмалар да иҗат итте Ренат Харислар буыны. Теләсәк без дә поэмалар яза алабыз дигән сыман... Шулай да бу шагыйрьләрнең көчен күбрәк шигырьдә күрәм.

Шигырьдә беренче чор. Шагыйрьләр беренче чорга йомгак ясыйлар. Сизенептерме, сизенмичәме, иҗат йомгагы кабатлана. Җиде-сигез елдан үзенә күрә бер йомгак. Равил Фәйзуллин, Радиф Гатауллин, Гәрәй Рәхимнәрнең сайланып чыккан җыентыклары шундый тәэсир калдырды. Ренат Харис, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәтләрнең соңгы китаплары да шул ук хакта сөйли. Гәрәй Рәхим «Моңнарым»да үзенең баштагы реалистик принципларына турылыгын тагын бер тапкыр раслады. Аның шигырьләрендәге реализм, кайбер натуралистик алым һәм детальләрне, кай-

бер беркатлылыкны берләштерә. Миңа шул формасында ошый алар. Тормыш үзе дә бит гел хәсрәттән генә тормый. Хәсрәте, кайгысы бар, шуклыгы, шаянлыгы, яшәү шатлыгы. Көннең уртасы кебек якты шигырьләр алар. Соңгы вакытта Гәрәй Рәхим берничә повесть та язып ташлады. Прозасы күңелендә шигырь куплектән. Әхмәт Фәйзи шагыйрь булып калган шикелле, Гәрәйне дә шагыйрьлек җиңәр. Нигәдер бу кешенең якты стиле шигырьдә бүгенге көннең зуррак әсәренә өметләндерә мине. Әгәр Такташ «Киләчәккә хатлар»ын язмаган булса, үткәндәгерәк кеше булып тоелыр иде миңа. Шагыйрьне күп кырлырак итеп күрәсе килүдәндер бу.

Шагыйрьләр киң дөньяга чыгалар. Шул ук Гәрәй Рәхимнең «Молодая гвардия» нәшриятында «Чәчәкле капкалар» исемле китабы басылган иде. Аның артыннан Ренат Харис үз шигырьләрен рус телендә бөтен союз укучысы хөкеме алдына куйды. Сынауны әйбәт үтте. РСФСР Язучылары союзындагы тикшерүдә ул 1978 елның яхшы китапларының берсе диган югары бәягә ирешә. Шигырьне хәзер бәяләү инстанцияләре үзгәрде. Төрле катлау укучылары бәя бирә, үзенең туган телендә, рус телендә. Шигырь рус теле аша башка телләргә дә күчә. Шигырьнең юлы киң.

Ренат Харисның миңа беренче чоры якын. Хисләр сафрак, хисләр кабатланмаган, образлар таушалмаган, шигырь табигый, кыскарак та, бөтенрәк тә, фикерләр формага ятып тора. Ренат Харис иҗатын миннән башка да күзәтеп торучылар бардыр. Берсенең ике кулын җилет кесәләренә тыгып, артта күзәтеп, горур басып торган сынын мин дә төсмерлим.

Беренче чор. Равил Фәйзуллинның моннан берничә ел элек Казанда чыккан, сайланма дәрәҗәсендәге татарча китабын мин аның яшьлек белән саубуллашу китабы дип атаган идем. Хәзер дә шул фикердә. Үксеп, сыктап саубуллашмый шагыйрь. Үксү, сыктау, гомумән, Фәйзуллин шигырьләренең характерына ят. Бик күп татар шагыйрьләре чирләгән сентиментализмның анда эзе дә юк. Икешәр-өчәр юллык нюансларда сыктап торырга нинди урын булсын. Фикер һәм образ. Шигырьнең башланып китүе генә. Дәвам иттерәсе, гадәт буенча сузасы килә. Юк, нокта куелган. Укучыга да уйланырга калсын. Аннан лирик парчалар китә. Шигырьнең формасында иркенлек. Бер яктан фикердә тыгызлык, икенче яктан шигырь калыпка кысылмаган. Моның уңышлы ягы да бар, кимчелеге дә үзендә. Җыр кебек аккан шигырьләр белән бергә агышы авырайганнары да очрый. Бу китап бер бөтен. Шигырьләренең фәлсәфәсе: кеше буларак җиргә килү, җирдә яшәү үзе генә дә зур бәхет. Иҗатка рухландырган төп көч — тормыш, яшәеш. Шагыйрьнең максаты — иҗат итеп калу. Шагыйрьнең омтылышы ачык. Шигырьләрнең күбесе бик интим да шикелләр, аның яшьлеге, аның мәхәббәте генә, аның тормыш турындагы уйлары гына. Ә шул шигырьләрдә күпме гомумкешелек хисләре. Сәнгать индивидуаль нәрсә. Бу беренче чор Равил Фәйзуллинны киләчәктәге иҗатына зур таләпләр куярга мәҗбүр итәчәк әле. Бу шагыйрь дә минем өчен башлангыч чоры белән кызык. Шагыйрьнең «Советская Россия» нәшрияты чыгарган китабына өч йөзгә якын шигырьләре кертелгән. Зур сайланма. Җентекләп сайланып алынган тәрҗемәләр. Татар поэзиясенең зур кимчелеге — Такташ, Туфан, Фатих Кәрим кебек шагыйрьләрен үз вакытында тәрҗемә иттереп, ил күләмендә күрсәтә алмады. Дөнья әдәбиятына юл — яхшы тәрҗемәләр аша. Хәзерге шагыйрьләрдән Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәтләрнең бикләнгәнлеге эчне пошыра минем. Шигырьләре ил күләмәндә алдынгы чордашлары белән ярыша алырлык шигырьләр. Тәрҗемәләре юк.

Татар совет шагыйрьләренә Муса Җәлилләр ачкан юлны тарайту хәзер оят. Иҗатта Җәлилләргә хас гражданлык, фидакарьлек өчен көрәшергә тиеш татар поэзиясе.

Талантлы төрле буын шагыйрьләрен үстерде безнең поэзия. Буын артлы буыннар. Күрергә, танырга теләү хисе көчәйгәннән-көчәя генә бара миндә. Кем син? Татар поэзиясен нинди яңа биеклекләргә алып менәрсең?

**Октябрь, 1978. Трусковец.**

Роберт Әхмәтҗанов



# ТӨП ЮНӘЛЕШ — КЕШЕНЕ САКЛАУ

*Шигъри проблемага бер караш*

Конкрет әсәрләргә тукталуны максат итеп куймыйча, бүгенге поэтик иҗат дөньябыздагы иң характерлы сыйфатлар, күңелне борчыган кайбер мәсьәләләргә генә тукталып үтмәкче булам.

Шундый гадәт инде, рәссам үзенең полотносына читтәнрәк карый. Болай карaганда, бөтен детальләр бер фокуска туплана, әсәр гомумиләштерелеп карала. Бер бөтен итеп кабул ителә. Бусы — ара ераклыгы буенча читтән карау. Әсәрләргә вакыт буенча да «читтән» карарга мөмкин. Бу очракта әсәрнең тотрыклылыгын, вакыт сынавын узу-узмау сәләтен күрәсең.

Вакыт-вакыт шигъри иҗат юлына да шулай борылып карау теләге туа. **Элегрәк ничек иде дә, хәзер ничек! Үсеш ниндирәк!**

Минем карашымча да бүгенге шигърият үзенең заманча яңгырашы, интеллектуальлеге белән шактый югары баскычка күтәрелде. Соңгы вакытта гына поэтик иҗатта үзенә бер вакыйга булырлык яңа шигъри бәйләмнәр дөньяга килде. Шулар арасыннан бигрәк тә Равил Фәйзуллинның «Шигырьләр һәм поэмалар», Радиф Гатауллинның «Ирләр булыйк», Зөлфәтнең «Утлы бозлар», Мөдәррис Әгъләмовның «Исәнме, йөрәк!» дигән китапларын атап үтәсе килә. Моннан берничә ел элек кенә исем-фамилияләре «һ. б.»лар рәтендә йөргән кайбер яшьләр, билгесезлек кордонын уңышлы кичеп, яңа мәйдан даулаучы иҗатчылар рәтенә бастылар. (Мин биредә шигырьләргә «күзәтү» ясамыйм. Шунлыктан, фамилияләрен китереп, үзем яратмаган «һ. б.»ны куеп тормыйм. Аннан соң исем санау язманың проблематик юнәлеше өчен артык натураль булыр иде.)

Инде, чыннан да, вакыт буенча да шактый читтә, бер артка әйләнеп карарга да була. **«Булмаганны эзләмибез икән, булганны үстерәбез икән пәса!..»** Аерым уңышларыбыз шул хакта сөйли. Тик мин биредә уңышларыбыз хакында түгел (аларга махсус тукталасы бар, алар моңа лаек), ә бәлки кайбер башка мәсьәләләр турында сөйләрмен дигән идем.

Соңгы вакытта шигырьдә лирик-фәлсәфи монолог янсә ниндидер күренешләргә, вакыйгаларга нигезләнеп язылган конструктив опуслар, верлибр тибындарак, әмма ул ук булып бетмәгән **«ак шигырьләр»** ишәеп китте. Газеталарда һәм журналларда басылган аерым шигырьләрне, подборкаларны күздән кичерик. Күпчелеге «ак шигырьләр». Әйдә, «аклар» икән «аклар» булсын! Мәсьәлә анда түгел. (Поэзиядә ак шигырь үзенең хаклы урынын яулады инде.) Мәсьәлә менә шунда: авторларының имзаларына карамасак, без аларның күбесен бер-берләреннән аера да алмас идек. Индивидуальлек, яхшы дигәндә дә, сизелер-сизелмәс кенә. (Биредә «шагыйрьнең үз тавышы» дигән билгеләмәнең кыйммәте ничек арта!)

Аннары. Миңа калса, соңгы вакытта безнең тыныч шигърият ызаннарында идиллия чәчәк ата кебек! Матур, әлбәттә, рәхәтлектән хәтта җанны оета! Гөлләр тирбәлә, ниндидер көйләр ишетелә... Әйтерсең дөньясында ут та, зилзиләләр дә, кырылыш та, көрәшләр дә юк. Кыскасы, рәхәт дөнья! (Үзем дә читтә түгел, үземне дә кертәм!). Мондый шигырь үрнәкләрен кемдер ирония белән: «Тук поэзия», дип

бәяләгән иде. Мондый шигырьләрдә табигыйлек, тормыш җылылыгы, көрәш рухы юк. Алар әйтерсең лә «балык каны» белән язылалар. Мондыйларны «торгынлык поэзиясе», «пассив поэзия» дип атарга да мөмкин. Бер тәнкыйтьче әйтмешли, шигырьдәге эчке киеренкелек шкаласы даими нуль өстендә тора икән, мондый шигырьне иң камил стилистика да, иң күркәм идеяләр дә коткара алмый.

Тагын. Бүгенге поэзиянең бер характерлы ягы, ул — аның әгәр шулай әйтергә яраса, **кешесезлеге.** Кешесез шигырь! Шигырьләрдә, авторның лирик «мин»еннән гайре, шәхес югалды шикелле. «Кешесез шигырьләр!» — сәер яңгырый түгелме? Әйе. Сәеррәк.

Әгәр дә игътибар итсәгез, поэмаларыбыз монолог юнәлешендә генә туа башлады. Алтмышынчы еллар башында фәнни-техник революция өлкәсендәге зур сикерешләр, борылышлар чорында заманга соклану характерындагы, лирик геройның чорга мәдхия җырлавы формасындагы беренче лирик-публицистик монологларда бу хәл әле аңлашыларак иде кебек. Үткән сугыш корбаннарын искә алган реквиемнарда да бу шулай иде. Ә аннан соң инде тоташ шул юлга кереп китү —айһай, заман таләбенең чагылышы гына микән? Кешесез поэмалар туунын сәбәбен заманга сылтау гына урынсыз, минемчә. Бүген геройлар азмы?

Хәзер һәр яшь һәм башлап язучы үзенең лирик «мин»еннән бер иҗади герой тудырырга, формалаштырырга омтыла кебек. Әлеге лирик «мин»не бер шәхес итеп күтәрү, гомумиләштерү өчен, әлбәттә инде, шагыйрьнең үзенең дә һәр яктан шактый ук калку шәхес булуы сораладыр. Юкса, үзеңдә булмаганны «бар» дип бәян итү гадәткә керә түгелме? Шулай булмаганда әлеге «мин» үз өстенә андый зур йөкләрне күтәрә, заман герое буларак чор каршында саллы сүз әйтә алмаячак бит. Әмма ничек кенә булмасын, шунысы бәхәссез: лирик «мин» исеменнән генә сөйләү кайбер иллюзияләргә дә ишек ача, трафаретлыкка, төссезлеккә китерә кебек.

Олы прозаның яшәүчән куәте — аның әдәби образлар тудыра алуында, чорның рухи сынланышын әдәби персонажлар аша чагылдыруда, аларга тормышта яңа гомер бирүендә. Поэзия тарихына күз салсак та без шундый хәлне күрмибезме? Бөек Гомердан алып Твардовскийга чаклы әдәби геройлар, тормышка «атлап кергән» тере әдәби персонажлар иҗат иткәннәр. Геройлар булгач, шуннан вакыйгасы туа, вакыйгасы бар икән, тарихилыгы һ. б. шартлары да килеп тора аның. Кыскасы, әсәр яши. Көрәштә, үсештә, хәрәкәттә яши! Юкса, хәзер «шигырь» дигән төшенчәгә нинди генә үрнәкләр керми! Көйлесе дә, көйсезе дә, регистратор язмасын хәтерләткән вакыйгалар күчермәсе дә... Бөек Шекспир тудырганны да без «шигырь» дибез. Әмма ул иң олы исәптән караган шигырь, вакыйга һәм конфликтлары муллыгыннан ташып, драматик әсәргә, хәтта чорның фаҗигасына үскән! Алайса безнең чал тарихтагы Кол Галидән алып, Тукай, Такташ, Фатих Кәрим һәм башка әдипләребезнең иҗат үрнәкләре ни хакта сөйли? Карәхмәтләр, Алсулар, Мокамайлар, Аникиннар, Гайҗан бабайлар, Хисамилар... Алар инде үз иҗатчыларыннан башка, мөстәкыйль рәвештә дөньяда яшәп йөриләр. Чыннан да бүген без шундый геройлар галереясенә кемне өсти алабыз? Әлеге дә баягы, шул лирик «мин»ебезнеме?

Әлбәттә, лирик «мин»нәр күп, тик менә аларның үз йөзләрен анык ачыклап булмавы гына борчый бераз. Әйтерсең лә томанда хәбәрләшә ул «мин»нәр. Бер өлкән әдибебез: «Кешеләре булмаган шигырьләрне мин ничектер кешесез йорт, ягылмаган, кеше тормаган буш йорт итеп күзаллыйм», дигән иде бер әңгәмә вакытында. Ул чагында мин: «һәр шигырьгә дә кеше исеме кертү кирәкме икән?» дип уйлаган идем. Чөнки исемнәрне атау гына «йорт»ны кешеле итә алмый әле. Сүз бирелә, билгеле, җитдирәк нәрсә: образ тудыру, аны әсәрдә җанландырып «тормышка җибәрү» турында бара. Әдип, чыннан да, үзеннән гайреләрне дә күрергә тиештер бит инде. Кем әйтмешли, «үз персонасыннан» гайрене дә?.. Әйтик, Лермонтов бер караганда үтә шәхси кичерешләр җырчысы кебек. Ул да Мцыриларны, Арбениннарны, Печориндай үз заманы геройларын күргән, образларын иҗат иткән. Масштабы, колачы — бүтән!

Әлбәттә, лирик «мин»гә беркем дә каршы түгел. Биредә без кулына каләм алган барлык шагыйрьнең дә **«мин»** исеменнән генә язуы хакында сүз алып барабыз, **шигырьдә кешесезлек һәм гомуми стереотип** турында сөйлибез. Бу, минемчә, бүген бик өлгереп җиткән проблемаларның берсе. Болар, үз чиратында, безнең гомум **инерция** белән баруыбыз хакында сөйләмиме? Башына өч йолдыз тәрткән, хәтта график сурәтләре дә бер-берсенә охшаган рифмалы һәм рифмасыз тезмәләрнең метражы шактый артып китте. Мондый шигырьләрне теләсә кайсы җирендә өзәргә һәм ялгарга мөмкин. Әмма моннан шигырьгә әлләни зыян килмәс иде. (Үзеннән-үзе конвейер системасы күз алдына килә).

Шигырьдә, билгеле, ниндидер әзер рецептлар юк. ЭВМны никадәр генә «хәтерле машина» дип «үтереп» мактасалар да, ул инде индивидуаль була алмый, ул да бөтен ЭВМнар шикелле үк бер калыпка язар иде. Программа гына бирелсен. Мәсьәлә менә шунда да шул. Шәхеснең индивидуальлеген саклап калу проблемасы? Юкса, шигырь иҗатына юл ярып кергәндә остазларның «үз тавышы бар» дигән беренче бәясе яшь иҗатчы өчен иң кыйммәтле бәяләрдән саналмас та иде! Азаккача үз тавышыңны саклап булырмы? Үз йөзеңне? Инде ирешелгән казанышларга нинди яңалык өсти алам? Чорның мең төрле сораулары, проблемалары, үсеш каршылыкларының «тегермән ташыннан» имин чыгып булырмы? Яшь әдип алдында шундый сорауларның тууы бер дә гаҗәп түгел. Ә тумаса — гаҗәп! Башкалар да бу сораулар хакында уйланалардыр, билгеле.

Юк, мин барысын да бер калыпка сыйдырып, бөтенесен дә тигезләргә җыенмыйм. Ә тагын бер мәсьәләгә тукталып үтмәкче булам. Ул — иҗатта (көйләрдә, моңнарда, үлчәмнәрдә, темаларда, терминнарда, алымнарда) бер-беребезне кабатлавыбыз. Моңа бик күп мисаллар китерергә мөмкин булыр иде. Бер-беребезгә күрә торып та, механик төстә дә иярәбез. Бу исә мәсьәләнең иң характерлысы, хәйлә-мәкерсезе, иң «өстә ятканы» гына әле.

Бер-береңнең иҗатына үзара игътибарлы булу мәсьәләсе һәрчак көн тәртибендә торган. Ул һәр көн актуаль. Бу нәрсә каләмдәш иптәшеңнең уңышларына куана белү, аның иҗатына эчкерсез сүзеңне әйтү юнәлешендә дә чагыла.

Шагыйрь-әдип ул губка (күзәнәкле полиэтилен) кебек, чорның бөтен рухи байлыгын, каршылыкларын, тетрәүләрен үзенә сеңдерә. Кабинеттан торып кына, чын дөньяның үзен күрмичә, үз-үзеңне «сыгып» кына бүгенге укучыга мәгънәле сүз, хикмәтле рух азыгы биреп булмый, билгеле. Күпне күрергә, күп аралашырга, чор җилләрендә дөрләргә, иң әһәмиятлесе — барысын да үз йөрәгең, үз иләгең аша үткәрү кирәк. Иҗат әше әнә шуны таләп итә.

Сүз сәнгатенең бер төре булган поэзия тормышыбыздагы туң йөрәклелек, кешелек кайгыларына битарафлык «үзеңнеке — үзәктә, кешенеке — киштәктә» принциплары белән килешеп яши алмый. Җентекләбрәк карасаң, шул икән ич безнең илкүләм иң актуаль проблемабыз! Кешенең рухи дөньясын баету, тәрбияләү иң олы социаль бурычларның берсе булып кала бирә. Тормыш шартларының яхшыра баруы, моннан күпмедер еллар элек кенә буй җитмәстәй күренгән комфортның инде көнкүрешебезнең иң гади бер атрибутына әверелеп китүе яшь буынга гел уңай яктан гына йогынты ясый дип уйлап булмый. Үз-үзләреннән гаҗәеп канәгать булган, күктән дию төшеп биесә дә гаҗәпләнмәс кешеләрнең артуы, һәрхәлдә, әдипләр файдасына түгел инде, дияр идем. Әйе, бу өлкәдә дә «ак таплар», буш урыннар шактый. Ничек кенә булмасын, идиллия безнең өлкә түгел...

Кыскасы, безгә әле бүгенге көннең характерын, рухи асылын, аның поэтик төсмерен киң итеп, рельефлы итеп кабул итүгә ирешәсе бар. Гел бертөрле конструктив тезмәләрдән китеп, характерлар поэзиясен тудыруга ирешәсе, шигъри иҗатның ниндидер хобби түгеллегенә, ә бәлки шәхеснең табигый рухи хаҗәте икәнлегенә ныклап төшенәсебез бар.

Бөтен проблемаларның асылы — бу катлаулы заманда кешене һәм аның күңел дөньясын саклау булып кала.

## Лэлэ Хэйдэрова

# КЕМ СОҢ СИН, ЗАМАНДАШ

Һәр заманның үз шагыйре була, һәр буын үз шагыйрен алып килә. Кол Гали, Г. Кандалый, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни... Шигъриятебез күгенә мәңге янар йолдыз булып Тукай калыккан. Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим иҗаты турында уйлансаң да, бүгенге көндә актив иҗат итүче Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов, Н. Дәүли, З. Нури кебек өлкән шагыйрьләрне укысаң да, шигъриятебезнең олылыгына, традицияләребезнең байлыгына горурлану хисләре кичерәсең.

«Шигырь җене кагылган» кеше булярак, бер нәрсә уйландыра мине — бүгенге яшьләрнең һәм алардан алдагы буыннарның шигъриятькә мөнәсәбәтләре. Безнең әти-әниләр (яшьләрнең әби-бабалары) Тукай шигырьләрен күңелдән белә, көйләп йөри иделәр. Без исә Тукайга гына түгел, Такташка да гашыйк идек. Студент елларыбызда айлы кичләрдә озата килгән егетләр безгә Пушкин, Лермонтов, Блок, Есенин шигырьләрен яттан укый иделәр. Ә бүгенге яшьләрдә шигърият белән кызыксыну сизелерлек дәрәҗәдә кими төште түгелме соң?.. Хикмәт нидә?

Кешеләрнең хис һәм тойгы нечкәлегенә фәнни-техник революция, цивилизация зарар китердеме әллә? Юктыр, булмаска тиеш. Материаль җитеш тормыш, тоташ грамоталылык замандашны интеллектуаль яктан камилләштерә. Димәк, белеме, культурасы, зәвыгы үскән бүгенге кеше әдәбият һәм сәнгатькә рухи ихтыяҗ тоярга, шигъри күңелле булырга тиеш.

Әллә чорыбызның эстетик таләпләренә җавап бирердәй талантлы яшьләребез — шигъри алмаш юкмы? Ә Зөлфәт, М. Әгъләмов, К. Сибгатуллин? Поэзиябезгә «аҗаганнар уйнатып», шау-шу белән килеп кергән шагыйрьләр: Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, Р. Мингалимов? Сугыш афәтен буыннары ныгымаган көйгә үз җилкәләрендә татыган урта буын вәкилләре Ш. Галиев, Г. Афзал, И. Юзеев, Х. Камалов, Ә. Баянов? Бар, үзләренең остазларына лаеклы алмаш — чын шагыйрьләр бездә бар! Алар заман тудырган җитди мәсьәләләрне яңа тарихи шартларда яңача хәл итәргә тырышалар, югары зәвыклы укучы кабул итәрлек поэзия җәүһәрләре тудыралар.

Менә Зөлфәт. Мин аның һәр шигырен, һәр китабын (8 ел эчендә аның кечкенә генә, җыйнак кына, тыйнак кына ике китабы дөнья күрде) көтеп алам. Бер мин генә түгел, бөтен гаиләбез белән көтәбез: аның һәр шигырен минем 78 яшьлек әнием дә, рок-музыка белән җенләнә торган 17 яшьлек улым да йотлыгып тыңлыйлар.

> **...Сүз яңгырар хәзер!**
> **...Урамнарга**
> **Аяк тавышлары түшәлә,**
> **Акыл гильзасына утыртылган**
> **Хыял снаряды —**
> **Көпшәдә.**
> **Ильич фикеренең ялкыннары**
> **Илнең йөрәгенә сарылыр.**
> **Шушы бомба**
> **баррикадаларның**
> **Арьягына төшеп ярылыр.**
> **...Ильич кулын алга сузган мизгел**
> **Юк, монумент түгел —**

**Җан гына!**
**Бу ишарә — кояш ягына гел,**
**Космодромлы көннәр ягына...**

Заманча, яңача һәм матур.

Зөлфәт пейзаж остасы, поэтик бизәкләр, образлар остасы. Аның каләме орын-са, «каеннарның чуклары арасыннан яңгыр тамчылары түгел, сагыну тама». «Гөл та-җына кунаклаган җил кузгалырга таңны көтә», «сүтелә дә айның толымнары, офык-ларга төшә таралып», «болан мөгезе» телгә килә, «төнге баржа» серен сөйли.

Шагыйрьнең гражданлык пафосы, тавышы көчәя, уй-фикерләре тирәнгәрәк китә, заман тудырган, бөтен кешелекне борчыган мәсьәләләр калкып чыга.

Табигатьне саклау темасына язылган берничә шигыре белән генә дә ул заман-даш укучы күңеленә юл ярырга тиеш. «39 нчы квартал» турындагы шигырь. Саз-лык турында, аны поэтик образ дәрәҗәсенә күтәреп, аның фаҗигасен шундый тет-рәткеч итеп бирергә кемнең күңеленә килер. Киресенчә, язарына материал эзләп интегеп йөргән берәү бу тирәгә килеп чыкса, элек сазлык булган урында яңа квар-таллар үсте дип, риторик шигырь язачак. Ә Зөлфәт таш пулатларның нигезенә күз төшерә, җир-ана һәм табигать күңеленә ачкыч таба — сазлыкны телгә китерә.

**...Тыңлады Төн. Биектәге йолдыз**
**Тетрәп-тетрәп серле төнгә дәшә:**
**— Әйтче, Төнем, әйтче: нәрсә булды!**
**Нәрсә булды! Ник җир бәхилләшә!**

Һәр тереклек иясенә тормыш бүләк иткән җир-анага, табигатькә карата мәрхәмәтле, кешелекле булырга чакырып инанган җан авазы бу! «Янабыз!» һәм «Кәк-күк» ши-гырьләре дә шундый үк тәэсир көченә ия.

Кеше күзенә юлыкмый, бары тик җәй башында гына аваз салучы кечкенә генә кошчык — күке дә шагыйрь ихтыяры белән шигъри образга әйләнгәч, могҗизалар ясый. «Кәк-күк!» дип бер аваз салуы була, «очып барган йолдыз туктала», «яңгыр тамчысы ярты юлда эленеп кала».

Куанычка каршы, Зөлфәт ялгыз түгел. Аның белән янәшә, әмма үз юлы, үз моңы, үз уйлары, үз җырлары белән Мөдәррис Әгъләмов килә. Яшь авторларның икесен дә бер үк мәсьәләләр борчый, әмма алар аңа төрлечә якын киләләр. Зөл-фәт «Янабыз!» шигырендә табигый матурлыкларны тагын да калку, аларның фаҗи-гасен тагын да тетрәндергечрәк итеп күрсәтеп, кешеләр күңеленә мәрхәмәтлелек са-лырга тырышса, «Урман яна» шигырендә М. Әгъләмов бөтенләй башкача:

**...Яна урман, әнә шулай**
**Янар сыман бу дөньялар...**
**Ә кешеләр аударылган**
**Агачларга ут ягалар,**
**Утка каршы ут ачалар,**
**Ут очраша, җиргә сеңә,**
**Сүнә-сүнә раслап тора:**
**Утка каршы ут якканда**
**Урманыңны саклап була,**
**Үз илеңне саклап була...**

Тынычлык турындагы уйлары Мөдәррисне сугыш хәрабәләренә алып чыга, авыр истәлекләрне яңарта... «Бердәнбер кыз турында баллада»да шагыйрьнең сугышка, агрессорларга булган үч һәм нәфрәте бар көчкә ташып чыга. Ул үз исеменнән ге-нә түгел, замандашлары исеменнән дә «Ышаныч» белдерә:

**...Никадәр үзгәрде дәверләр,**
**Һавалар, офыклар үзгә гел...**
**Куерса болытлар, барыбер**
**Әйтәчәк бу нәсел: — Без әзер!**
**Әгәр дә Ватанга кирәксә —**
**Халкымнан калкачак мең Җәлил.**

Бу мисалларны М. Әгъләмов шигырьләренә заман билгесе житешми, аларда гражданлык пафосы тонык яңгырый, кайчак ул артык сентименталь, тар булып китә диючеләргә җавап итеп китердем. Әйе, шагыйрь үз халкының тарихына, гореф-гадәтләренә, йолаларына, теленә зур мәхәббәт белән карый. Бу начармыни? Үз халкын яратмаган кеше башкаларны яратамы?

Минемчә, Мөдәррис талантлы, уйлы, оригиналь шагыйрь.

**...Моңы барның йөрәгеннән**
**һәрвакытта җылы чыгар —**
**Үзе туңар,**
**Үзе туңар...**

Туган ил, туган җир һәм халык гаме белән янып иҗат итүче Кадыйр Сибгатуллин да үзенчәлекле шагыйрь. Аның «Ирләр», «Иргә чыкмый калган апалар», «Атлар көтте авыл малайлары», «Без синеке инде», «Кибәнче карт» кебек шигырьләре шул хакта сөйли. К. Сибгатуллин шигырьләренә карагандa, ул туган җиренә кендеге белән береккән, «рәшәле кырларның» ямен, икмәкнең тәмен, сугышның илгә китергән афәтләрен чын шагыйрь йөрәге белән тоя.

**...Дулкынга ташланган кызлар күк,**
**Кырларым күмелгән рәшәгә.**
**Җырчы да,**
**Шагыйрь дә булма ди,**
**Монда ту,**
**Монда үс,**
**Яшә дә!**

Шигъри фикерне кыска, бөтен, җыйнак итеп бирүе, үз халкының тарихы, рухы, гореф-гадәтләре белән кызыксынып, лирика белән юморны куша алган Р. Миңнуллинның киләчәге дә өметле.

Мәңгелек тема — мәхәббәт фәлсәфәсен хатын-кызга гына хас нечкә бер тоем белән сурәтли белүче Н. Измайлованың да үз сукмагы бар. Дөньяга киң итеп ачылган саф күзләре белән сокланып караучы героиня үз җаны, үз йөрәгеннән чыккан хисләр белән уртаклаша.

...Шушы урында бераз гына артка чигеп, шигъри аренага өченче «дулкын» дигән матур кушамат белән ургылып килеп кергән Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, Р. Мингалимовлар буынына күз саласы килә. Алар шигърияткә эчтәлек һәм форма ягыннан да яңалык алып килделәр. Бәхәсләр дә булды. Зур эрудиция, белем һәм бай фантазия белән килүче бу буын интеллектуаль поэзиянең яңа үсешен тәэмин итте. Озын-озын, сюжетлы, тасвирлы шигырьләр урынына берничә юллык шигъри парчалар, этюдлар модага керде. Яшерен-батырын түгел, сокландык та, шатландык та, кайбер шигырьләрне аңлап бетерә алмый да азапландык...

Уйлап карасаң, диалектика законнарына нигезләнгән зарури күренеш булган — чор үзе, заман үзе, Вакыт үзе тудырган икән аларны! Тагын бераз вакыт үтте, шигърияткә «дүртенче», «бишенче дулкыннар» килде. Алар иҗаты аша карагач, «өченче дулкын»ның да «кардан ак, сөттән пакь» кына түгел икәнлеге ачылды. Шау-шусыз, әдәби традицияләрне хөрмәт иткән хәлдә дә заманча язарга була икән ләбаса! Мисаллар: Зөлфәт, М. Әгъләмов, К. Сибгатуллин. Алардагы гадилек, моң, мөлаемлык, хисләр муллыгы, шигырьләренең һәр юлыннан коелырга торган поэтик бизәкләр фикерне тагын да калкурак, үтемлерәк итеп бирергә ярдәм итә икән.

Димәк, бүгенге укучыга рухи азык тәкъдим итәрлек талантлы шагыйрьләребез — лаеклы шигъри алмаш бездә бар. Барысы да яхшы, үз урынында, әмма мәсьәлә һаман ачыкланмады бит әле. «Сүз башыбыз» яшьләрнең шигырь китапларын читләтеп үтүе турында иде...

Шигырь кануннарын яхшы белгән кешегә берничә строфа шигырь язу да, шул кадәр вакытлы матбугат чыккан илдә аның дөнья күрүе дә гаҗәп түгел. Яшь кешенең бер шигыре дөнья күрсә, аның күңеле үсә — тагын яза, тагын басыла. Кыскасы, шулай итеп, шагыйрьләр туа, шигырьчеләр дә ишәя. Шигырьләр дә арта, халтура да күбәя. Чын шигырьләрне менә шушы халтура басып китә, чөнки «шигырьче»-

нең — бөтен максаты басылып чыгу. Ул иң актуаль, көн кадагына суга торган темаларга тотына. Чөнки аларга ихтыяҗ бар, аларны бастыру җиңелрәк. Өстәвенә сәләте аз кешенең әрсезлеге күп була.

Шул рәвешчә, чын шигырьләрне халтура арасыннан эзләп табу укучы өчен кыенлаша. Бер шигырь укып карый ул бүгенге газетадан, иртәгесен журналдан икенчесен — икесендә дә халтураларга эләксә, өченче көнне шигырь юлларына күз дә салмый уза.

Актуаль темаларга беренче чиратта язарга кирәк, әлбәттә. Әмма укырдай, поэзия атлы затлы жанрның нәфис иңнәре күтәрә алырдай камил әсәр булсын ул. Булдыра алмый икән мәкалә язсын: шагыйрьлеккә дәгъва итүче кешенең мәкаләсе, һәрхәлдә, укырлык булачак.

Урта кул яисә предметсыз шигырьләр талантлы шагыйрьләр кулы астыннан чыксалар, бигрәк күңел рәнҗи. Бер вакыт соклана-соклана, куана-куана, Р. Гатауллин шигырьләрен укыганда берничә шигыренә сөрлегеп калган идем: беренчесе — тамаша грамоталысы — «Күңел бакчасына ташлар».

**...Балалык акылының рецидивисты булма,**
**Мәхәббәт моңының пессимисты булма,**
**Өметсез эшләрнең оптимисты булмасаң булма,**
**Максатыңның тик — оппортунисты**
**булма...**

Кыскасы, тешкә тия. Яки «Өстәлемдә торна тора» шигыре (бусын ул хәтта соңгы җыентыгына да керткән). Шагыйрьне илһамландырган материал нәрсә? Нәкъ шигырьнең исеменнән күренгәнчә — өстәлендәге пластмасс торна... Әгәр автор «пластмасс» сүзен өстәгән булса, шунда нокта куярга да булыр иде. Бу юлларны поэзиягә «җилкәннәрен киереп килеп кергән», игътибарга лаек шигырьләр иҗат иткән Р. Гатауллин язгандыр дип ышанасы да килми. Нигә шулай икән соң бу? Язар материал юклыктан түгелдер бит?..

Замандаш поэзиядә үзен, үзенә хас сыйфатлар, хисләр эзли, үзен дулкынландырган сорауларга җавап табарга омтыла. Кеше язмышы белән бәйләнмәгән, тышкы информациягә генә корылган сәнгать сәнгать була алмый. Ул вакытта хис шигырьнең тышкы кабыгында гына. Әлеге тип шигырьләр җиңелчә генә тәэсирләнү нәтиҗәсе — шуңа күрә дә аларда әле бер нәрсә, әле икенчесе, өченчесе тиз һәм ансат кына тасвирлап чыгыла. Шигырь — шәхси тормышның тудырган тәэсирләр генә дә түгел: тудым, укыдым, эшләдем, өйрәндем, шигырьләр яздым. Безнең поэзиябезнең иң авырткан җиредер бу, мөгаен.

70 нче еллар кешесенең тулы канлы образын, беренче чиратта, шул буынның үз иҗатчысы тудырырга тиештер. Чөнки ул син үзең — кичәге колхозчы, кичәге эшче, кичәге ташчы. Ул да синең белән бер үк вакытта телевизор карый, аның кызы да синең кызың белән музыка мәктәбенә йөри, улы этюдник тотып табигать кочагына юл ала. Материал байлык тудыручы хезмәт кешесе тарихта күрелмәгән лаеклы дәрәҗәгә иреште. Мондый кеше белән чын-чынлап аралашу, аның рухи дөньясына үтеп керү чын иҗатчы өчен зур мәртәбә. Хезмәт кешеләрен якыннан өйрәнү, тормышның үзәгенә үтү нәтиҗәсендә генә Замандаш укырлык әсәр иҗат итәргә мөмкин.

Хезмәтне үзенең ихтыяҗы, иҗат чыганагы санаган кешенең рухи дөньясын лирик шагыйрьдән дә тулырак итеп кем ача алыр... Шигъриятнең мөмкинлекләре чиксез.

Поэзиябез бай, шагыйрьләребезнең мөмкинлекләре һәм перспективалары зур. Иң сөенечлесе шул — елдан-ел шигъри аренага тагын да сәләтлерәк яшьләр килә. Алар гасырлар буе чарланып килгән халык поэтикасын үз иҗатларында файдаланулары, өлкәннәр иҗатына таянулары, сүз белән эш итә белү осталыклары, фикергә дә, хиска да тиешенчә игътибарлы булулары белән сөендерәләр. Шундый талантлары булган шигърият Замандаш күңелен яуламый калмас!

Ленар Җамалетдинов

# ТУКАЙ ҺӘМ ӘДӘБИ ӘКИЯТ

Г. Тукайның иҗаты һәм әдәби эшчәнлеге халык иҗаты белән тыгыз бәйләнгән. Бу — күптән мәгълүм һәм танылган хакыйкать.

Г. Тукай һәм халык иҗаты мәсьәләсен төрле аспектта карарга мөмкин: шагыйрьнең иҗатына фольклорның йогынтысы; Г. Тукайның халык иҗатына теоретик карашлары, шулай ук халык иҗаты әсәрләрен җыюы һәм бастырып чыгаруы; ниһаять, фольклор жанрлары үрнәгендә һәм шул жанрларга карый торган әдәби әсәрләр (җыр, бәет, әкият һ. б.) иҗат итүе. Без шушы аспектларның соңгысына туктапып, Г. Тукайның әкиятләре турында сөйләргә җыенабыз.

Язучылар иҗат иткән әкиятләрне шартлы рәвештә әдәби әкиятләр дип йөртәләр. Шуннан да уңышлы атаманың әлегә табылганы юк. Г. Тукай заманында исә язучы иҗатының бу төрен билгеле торган атама бөтенләй дә булмый. Чөнки ул чорда әле татар әдәбиятында әкиятләр иҗат ителмәгән. Бу эшне беренче булып үзенең мәшһүр «Шүрәле» поэмасы белән Г. Тукай башлап җибәрә. Шулай итеп, татар әдәби әкиятенең тарихы 1907 елда иҗат ителгән «Шүрәле»дән башлана, һәм бу тарихның юл башында олуг Тукаебыз басып тора.

Г. Тукай һәм халык иҗаты өлкәсенә караган махсус хезмәтләрдә[1] генә түгел, бәлки, гомумән, Г. Тукай иҗаты турындагы тикшеренүләрдә, шулай ук фольклор мәсьәләләренә багышланган кайбер хезмәтләрдә[2] дә шагыйрьнең әкиятләренә кагылышлы шактый күп мәгълүмат табарга мөмкин. Ләкин әлеге хезмәтләрнең берсендә дә әдәби әкият халык иҗаты һәм профессиональ иҗат чигендә туган һәм матур әдәбиятның мөстәкыйль бер жанрын тәшкил иткән аерым күренеш буларак каралмый.

Әдәби әкиятнең асылын Г. Тукай яхшы аңлаган. Ул үзенең «Халык әдәбияты» дигән лекциясендә болай ди: «...әгәр дә шушындый ук хикәя (сүз халык иҗаты әсәрләре турында бара — Л. Җ.) бер-бер мөхәррир вә шагыйрь тарафыннан бизәкләп вә матурлап язылса, инде ул «халык әдәбияты»лыктан чыга. Бу җөмләдән Пушкинның «Алтын балык» вә «Алтын әтәч» кеби хикәяләрен санарга мөмкин. Мондый

---

[1] Г. Толымбай. Тукай һәм әдәби фольклорыбыз. «Безнең юл», 1928 ел, 6—7 саннар, 21—27 битләр; Ф. Габдрахманов. Тукай һәм фольклор әсәрләре. «Совет әдәбияты», 1938 ел, 4 сан, 39—47 битләр; Г. Халит. Тукай һәм халык иҗаты. «Совет әдәбияты», 1938 ел, 5 сан, 74—84 битләр; М. Гайнуллин. Тукай һәм халык иҗаты. «Совет әдәбияты», 1945 ел, 12 сан, 57—63 битләр; Х. Ярми. Тукай һәм халык иҗаты. Габдулла Тукай. Шагыйрьнең тууына алтмыш ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан, 1948 ел. 93—112 битләр; И. Вәлитова. Г. Тукай һәм халык әкиятләре. «Совет мәктәбе», 1970 ел, 10 сан, 37—39 битләр.

[2] Ф. Әмирхан. Габдулла Тукаев шигырьләре. Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. Ике томда. II том. Казан, 1958 ел, 183—186 битләр; Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Төзүче, текстны хәзерләүче һәм искәрмәләр бирүче Мансур Хәсәнов. Казан, 1960 ел, 40—42 битләр; Г. Нигъмәти. Тукай иҗаты. Г. Нигъмәти. Сайланма әсәрләр. Казан, 1958 ел, 228 бит; Ә. Фәйзи. Халык шагыйре. Ә. Фәйзи. Әдипнең эрудициясе. Казан, 1973 ел, 66—71 битләр; Г. Халит. Тукай үткән юл. Казан, 1962 ел, 115—150 битләр; И. Нуруллин. Тукай иҗаты (Беренче рус революциясе чоры). КДУ нәшрияты. Казан, 1964 ел, 104—112 битләр.

хикәяләрнең башта халык авызында сөйләнүе дә вә халык рухынча язылуы да аның «халык әдәбияты»лыктан чыгуына манигъ (киртә — Л. Ж.) була алмый»[1].

Бу өземтәдән күренгәнчә, шагыйрь мисалны рус әдәбиятыннан китерә. Чөнки Г. Тукай өчен прогрессив рус әдәбияты әкиятләр иҗат итүдә дә абруйлы үрнәк булып торган. «Шүрәле» поэмасы басылган беренче җыентыгында шагыйрь бу турыда ачыктан-ачык: «Мин бу «Шүрәле» хикәясен Пушкин вә Лермонтовларның шундый авыл җирендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуына истинадән (таянып — Л. Ж.) яздым»[2],— ди.

Г. Тукай рус әдәбиятыннан үрнәк алып кына калмый, бәлки андагы иң яхшы әкиятләрне татар теленә дә тәрҗемә итә. «Алтын әтәч» (Пушкиннан, 1908 ел), «Япон хикәясе» (Буренинтан, 1909 ел), «Өч хакыйкать» (Майковтан, 1912 ел) — әнә шундый әсәрләр.

Әдәби әкиятләр язуда ике төрле ысул бар. Беренчесе — халык иҗаты арсеналындагы сюжетларны эшкәртү; икенчесе — халык иҗатының төп закончалыкларын саклаган хәлдә, яңа сюжетлар иҗат итү. Г. Тукай, бу өлкәгә тәүге сукмакны салучы буларак, беренче ысул белән эш иткән, ягъни аның әкиятләрендәге сюжетлар турыдан-туры халык иҗаты әсәрләреннән алынган.

Г. Тукай иҗат иткән дистәгә якын әкият арасында «Шүрәле» (1907 ел) , «Су анасы» (1908 ел) һәм «Кәҗә белән Сарык хикәясе» (1909 ел) аеруча популярлык казана. Шуларның баштагы икесе турында сөйләгәндә, тикшеренүчеләрнең кайберләре шагыйрь аларны халык әкиятләреннән файдаланып язган, дигән караштә торалар. Ләкин бу карашка тәгәллек җитми. Чөнки халыкта киң таралган шүрәле һәм су анасы турындагы кечкенә хикәяләр — чын мәгънәсендәге әкиятләр түгел. Аларда, тасвирлаудан бигрәк, хәбәр итү, белдерү өстенлек ала, һәм кешеләрнең борынгы ышануларын чагылдырган ул нәни хикәя-легендалар әкият белән тиңләрлек эстетик вазифа үтәмиләр. Менә шушы хәл, әлеге легендаларны әкият иҗат итүдә нигез итеп файдаланганда, язучы фантазиясенә зур мәйдан ача.

Г. Тукай легендаларның халык тормышына иң якын булганнарын сайлаган һәм аларның да үзенең идея-эстетик позициясенә туры килә торган вариантларын гына алган[3]. Бу очракта әлеге вариантның иң популяр булуы мөһим түгел.

Шушы уңайдан Г. Тукайның «Кәҗә белән Сарык хикәясе»нә тукталып үтик. Бу сюжетка корылган халык әкияте ул заманда ни дәрәҗәдә популяр булгандыр — әйтүе кыен. Чөнки безнең кулда бу хакта әлегә бернинди мәгълүмат юк. Ләкин шулай да бер факт игътибарга лаек. 1877 елда Казанда үткәрелгән IV Археология съездында В. Н. Витевский «Оренбург губернасы Верхнеуральск өязе нугайбәкләренең әкиятләре, табышмаклары һәм җырлары» дигән темага белдерү ясый. Белдерүдә нугайбәкләрнең XVI йөздә чукындырылып, бирегә күчереп утыртылган Казан татарлары булуы әйтелә һәм бу фикерне раслау өчен фольклорның төрле жанрларына караган әсәрләр белән бергә ике әкият тә китерелә. Шуларның берсе — кәҗә белән сарык турындагы әкият[4]. Ләкин аның сюжеты Г. Тукай әкияте сюжетыннан аерыла, ягъни аерым бер вариант тәшкил итә.

Әлбәттә, бу сюжет үзе борынгы, ләкин шунысы игътибарга лаек: әлеге әкият IV Археология съездына хәтле һәм аннан соң басылып чыккан әкият җыентыкларының берсендә дә очрамый. Бу фактка өлкән фольклорчы Х. Ярми дә игътибар иткән[5].

XX йөз башында халык арасында популяр булган әкият, әйтик, Таип Яхин төзегән җыентыкларга, аерым алганда, йөзгә якын әкиятне берләштергән «Дәфгыль-кәсәл...» (Казан, 1900 ел) җыентыгына керми калыр идеме икән? Бу бер. Икенчедән, Татарстан районнарына оештырылган бер генә экспедициянең дә В. Н. Витевский вариантын алып кайтканы юк. Ә бу әкиятнең Г. Тукай вариантын исә һәр авылда табарга мөмкин.

---

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. II том, Казан, 1955 ел, 260 бит. (Алга таба бу басманың том һәм битләре генә күрсәтеләчәк.)
[2] Г. Тукай. I том, 259 бит.
[3] Ф. Габдрахманов, М. Гайнуллин һәм И. Нуруллинның алда күрсәтелгән хезмәтләрендә бу мәсьәлә тәфсилләп бәян ителә.
[4] Труды четвертого Археологического съезда в России. II том, Казан, 1891 ел, 277—278 битләр.
[5] Х. Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан, 1967 ел, 21 бит.

Моннан түбәндәгечә фараз итәргә мөмкинлек туа: бәлки кәҗә белән сарык турында-гы борынгы әкият Г. Тукай заманында инде Казан татарларында популяр булмагандыр (бөтенләй онытылган булган дип әйтергә җыенмыйбыз), һәм шагыйрь үзенең әсәрен В. Н. Витевский тарафыннан теркәлгән әкият нигезендә иҗат иткәндер? Әгәр инде бу әкият ул чакта халыкта сөйләнеп, җыентыкларга очраклы рәвештә генә керми калган булса да, барыбер хәлнең асылы үзгәрми: 1909 елдан соң Г. Тукай әсәре популярлашып, аңа кадәрге вариант соңыннан бөтенләй онытылган булып чыга.

Кыскасы, әлеге әкиятнең бүгенге көндә популяр булган бердәнбер варианты Г. Тукай иҗаты белән бәйле, ягъни шагыйрьнең фольклор нигезендә язылган әсәре, гаять дәрәҗәдә халыклашып китеп, ахыр чиктә үзе фольклор әсәренә әверелгән.

Г. Тукайның әкиятләр язуы, беренче чиратта, балалар әдәбиятына хезмәт итүе белән бәйле. Мәгълүм булганча, Г. Тукай балаларны эстетик тәрбияләүгә ифрат зур игътибар биргән, алар өчен дәреслек һәм уку китаплары төзеп бастырган. Үзенең әкиятләрен дә ул балаларга атап нәшер ителгән «Җуаныч» (1908 ел), «Балалар күңеле» (1910 ел), «Җан азыклары» (1912 ел) дигән җыентыкларында чыгара, янсә аларны аерым китап итеп бастыра. Әнә шундый аерым китап булып чыккан «Алтын әтәч» әкияте турында драматург Г. Камал «Йолдыз» газетасында (1909 ел, 406 сан) болай дип яза: „Габдулла әфәнде бу әсәрне яшь балалар өчен язмыш вә китабының мәфһүменә (эчтәлегенә — Л. Җ.) Пушкинның «Золотой петушок» нам әсәреннән алынмыштыр. Назымы гаять җиңел булу өстенә, тасвирлары да гаять шагыйранәдер».

Әкият баланың рухи дөньясын баета, фантазиясен үстерә, холкын төзәтергә һәм тормышка карашын ачыкларга ярдәм итә. Чөнки әкияттә өстенлек итүче эстетик вазифага төрле дәрәҗәдә идея вазифасы да (әхлакый, социаль, политик һ. б.) юлдашлык итә. Әкиятнең тәрбияви көче әнә шул вазифалар тәэсиренең суммасыннан гыйбарәт. Г. Тукай моны яхшы аңлаган һәм фольклор әсәрләрен, беренче чиратта, әнә шул сыйфатларына карап сайлап алган.

Әдәби әкиятнең исә зур өстенлеге шунда: автор үзенең идея-эстетик карашларына ярашлы рәвештә әлеге вазифаларның теләсә кайсын игътибар үзәгенә куя, көчәйтә, тагын да тәэсирлерәк итә ала. Әйтик, «Шүрәле» поэмасында эстетик вазифаны тагын да калкурак итү максатында халык әкиятенә бик үк хас булмаган алымнардан файдалану (мәсәлән, пейзаж һәм портретны тәфсилләп сурәтләү) күзгә ташлана. Бу исә әдәби иҗатның асылы белән бәйле: халык иҗатына гомумиләштерү сыйфаты хас булса, «әдәбият конкретлыкка омтыла, гомумиләштерү белән бергә, индивидуальләштерүне таләп итә»[1]. Поэмада вакыйганың билгеле бер урынга — Кырлай авылы тирәсенә беркетелүе дә шуның белән аңлатыла.

Эстетик вазифаны көчәйтү белән бер үк вакытта, Г. Тукай үзенең әсәрендә, бик оста итеп, халыкның җәбер-золым эчендә хокуксыз яшәвен, кешелек дөньясы туплаган сәнгать һәм культура хәзинәләреннән мәхрүм булуын да күрсәткән.

Поэманың урманны сурәтләгән өлешендә шундый юллар бар:

**Монда бульварлар, клуб һәм тансавальня, цирк та шул;**
**Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.**

Ягъни цивилизацияле халыкларның һәммәсендә дә булган культура чараларының һәммәсен монда бары тик бер урман күренешләре генә алыштыра.

**Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:**
**Аһ! — дисең,— без ник болай соң! Без дә хакның бәндәсе.**

Бу юллар әлеге нәтиҗәгә өстәмә ачыклык кертә: әйе, «шагыйрь татар милләтенең шул вакыттагы хәле, хокуксызлыгы һәм артталыгына ачына»[2].

Шулай итеп, Г. Тукай лирик пролог ярдәмендә әсәрнең эстетик вазифасын көчәйтеп кенә калмый, бәлки аңа социаль-политик вазифа да йөкли.

«Кәҗә белән Сарык хикәясе»ндә социаль мотивлар тагын да ачыграк чагыла. Мәсәлән, В. Н. Витевский вариантында карт белән карчык кәҗә тәкәсе белән сарык

---

[1] И. Нуруллин. Күрсәтелгән хезмәт, 107 бит.
[2] И. Нуруллин. Күрсәтелгән хезмәт, 110 бит.

тәрәсен «бу малларны языклы булып асрамыйк» дип чыгарып җибәрсәләр. Г. Тукай бу хәлне турыдан-туры реаль чынбарлыкка бәйләп сурәтли: ир белән хатынның «тормышлары шактый гына фәкыйрь булган», маллар «берсеннән дә берсе арык», чөнки печән хакы кыйммәт.

Әлбәттә, халык мәнфәгатен яклаган, халык кайгысын кайгыртып яшәгән шагыйрьнең социаль хәлен үзенең әкиятләрендә дә чагылдырмый калмый. Г. Тукайга кадәр фольклор әсәрләренең сыйнфыйлыгы мәсьәләсе бөтенләй диярлек кузгатылмаган булуны искә алсак, шагыйрьнең новаторлыгы тагын да калкурак күренер.

Ә менә «Су анасы» әкиятендә Г. Тукай эстетик вазифа белән беррәттән әхлакый вазифаны күз уңында тота.

> **Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым.**
> **«Йә иясе юк!» — дип, әйберләргә тими башладым.**

Шулай итеп, әдәби әкияттә кайбер поэтик чаралар активрак кулланыла, әсәрнең идея юнәлеше автор ихтыяры белән үзгәртелә. Г. Тукай халык иҗатындагы сюжет һәм мотивларны пассив эшкәртеп кенә калмый, аларны, халык рухын һәм милли колоритны саклаган хәлдә, тарих һәм көнкүреш белән, биографик моментлар белән— кыскасы, реаль чынбарлык белән органик рәвештә бәйләп, халыкның, зәвыгына, рухи ихтыяҗына һәм, ниһаять, шул заманның идея-эстетик таләпләренә җавап бирә торган синтетик характердагы әсәрләр иҗат итә.

Халык әдәбияты белән язма әдәбият арасындагы аерма турында Г. Ибраһимов болай дип яза: «Бу икенең берсен табигый урманга, икенчесен оста караучының дикъкатьле тәрбиясендә эшләнгән бакчага охшатырга мөмкин»[1]. Һәм «Шүрәле» белән «Су анасы»н ул моның иң гүзәл үрнәкләре итеп саный. «Тукаевның бу шигырьләре шулкадәр ачык вә табигый чыккан ки, — дип яза Г. Ибраһимов «Йолдыз» газетасында (1910 ел, 547, 549 саннар) басылган «Халык мосәннәфаты» (иҗат ителгән әсәр — Л. Ж.) дигән мәкаләсендә, — чи гавамның авызыннан да шулкадәр генә чыгар иде... Әдип вә шагыйрьләребездән Тукаевның «Су анасы» вә «Шүрәле»се кебек шигырь вә хикәячекләрнең чыгуын теләргә тиешлебез»[2].

Г. Тукай әкиятләренең тагын бер күркәм сыйфаты турында әйтми мөмкин түгел. Ул да булса, аларның теле. Ф. Әмирхан шагыйрьнең «Шүрәле» әсәре урнаштырылган беренче җыентыгы («Габдулла Тукаев шигырьләре. Өченче дәфтәр», 1907 ел) чыгу уңае белән, «Әльислах» газетасында (1907 ел, 3 декабрь саны) басылган рецензиясендә поэманың теленә махсус туктала. Ул мисал рәвешендә әсәрдән пейзаж һәм шүрәленең портреты сурәтләнгән өзекләрне китерә. Шул ук вакытта әдип җыентыктагы күп кенә шигырьләрнең теле чуар булуын билгеләп үтә («иске төрек теле белән язылып, гарәпчә, фарсыча, әзербәйҗанча, тагын әллә нәрсәчә телләреннән корылган шигырьләре дә күптер»[3]).

Күренә ки, Г. Тукай әсәрләре ул чорда әле иске корама телдән арынып җитмәгән була. Инде шагыйрьнең 1908 ел башында дөнья күргән икенче җыентыгына («Г. Тукаев шигырьләре. Дүртенче дәфтәр») язылган рецензиясендә Ф. Әмирхан Г. Тукайның күп шигырьләрен «матур тасвирлы, садә татар телендә язылган» дип бәяли[4]. Ә бу җыентыктагы шигырьләрнең күпчелеген исә «Шүрәле» поэмасыннан соң туган әсәрләр тәшкил итә.

Галимнәр дә шагыйрьнең киң массага аңлаешлы саф татар телендә эзлекле рәвештә яза башлавы «Шүрәле» әсәреннән башланып киткән дип саныйлар[5]. Димәк, Г. Тукайның әкиятләр иҗат итүе, тел җәһәтеннән карaганда, аның үз-үзен тәрбияләү чарасы да булган дип әйтергә мөмкин.

Г. Тукайның әкиятләр өлкәсендәге эшчәнлеге балалар әдәбиятына хезмәт итү белән бәйле дидек. Ләкин әлеге мәсьәләнең икенче ягы да бар. Бу урында без Г. Халитның «Тукай үткән юл» дигән китабыннан бер өземтә китерү белән чикл-

---

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият дәресләре. Казан, 1916 ел, 62 бит.
[2] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан, 1960 ел, 40, 41, 42 битләр.
[3] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр, II том, 184 бит.
[4] Шунда ук, 206 бит.
[5] Х. Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты, 54 бит.

нергә уйлыйбыз: «Искергән мәгънәсендәге дидактик һәм риторик поэзия басымыннан тиз арада котылу юлларын эзләгәндә, — ди ул, — Тукай боларны, бер яктан, рус классик поэзиясе традицияләрендә — аеруча Пушкин һәм Лермонтов мирасында күрсә, икенче яктан, татар халык иҗатында тапты. Соңгысын ул, һичшиксез, милли әдәбиятның үзенчәлекле **халыкчан җирлеген ныгыту өчен** (ассызык безнеке — Л. Җ.) көрәш коралы дип аңлады»[1].

Шагыйрьнең әкиятләре дә әнә шушы максатка хезмәт иткән.

Чыннан да, Г. Тукай әкиятләренең халыкчанлыгы, поэтик яктан камил эшләнеше аларның гаять популяр булуына ярдәм итте. Бу әсәрләрне яратып укыйлар, яттан сөйлиләр. «Шүрәле» һәм «Су анасы» әкиятләре композиторларны опера һәм балетлар язарга рухландырды. «Шүрәле» поэмасы СССР һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә ителде. Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты Казанда гына түгел, Мәскәү, Ленинград һәм башка күп кенә шәһәрләрдә, шулай ук чит ил сәхнәләрендә зур уңыш казанды. Шушы уңайдан М. И. Калининның түбәндәге сүзләре искә төшә: «Иң сәләтле шагыйрьләр, иң талантлы композиторлар бары тик халык иҗатына якын торганда, аның чыганакларына мөрәҗәгать иткәндә генә үз иҗатларында даһи була алганнар»[2].

Г. Тукай иҗаты безнең өчен торган саен тирәнрәк ачыла бара дибез икән, бу аның әкиятләренә дә кагыла. Төрле яклап һәм тирәнрәк төшенә барган саен, әлеге әкиятләр үзләре турында күбрәк һәм яңачарак сөйли башлыйлар. Ләкин алар әлегә үзләренең тикшеренүчеләрен көтә. Мәсәлән, Г. Тукай әкиятләренең мифологик нигезен билгеләү, бу әсәрләрне тарихи-этнографик яктан тикшерү, яисә шагыйрьнең бу өлкәдеге традициялелеге һәм новаторлыгы мәсьәләсен киңрәк ачыклау кызыклы нәтиҗәләр бирер иде.

Илленче еллар башында ук инде Ә. Фәйзи болай дип язган иде: «Тукай иҗатының һичшиксез өйрәнелергә тиеш иң әһәмиятле якларының берсе — әсәр өстендә эшләү ысуллары, шагыйрьнең осталыгы, аның әсәрләрендәге форманың идея эчтәлегенә органик рәвештә бәйләнгән булуы... Классикларыбызның, беренче чиратта Тукаебызның, иҗатын өйрәнү, алар турында монографияләр язу-булдыру яшь язучыларның игътибарын әдәби осталык ягына юнәлдерер иде[3].

Бу бурыч бүген дә актуаль булып кала. Аерым алганда, Г. Тукайның әкият иҗат итү осталыгын өйрәнү нигезендә барлыкка килгән күләмле хезмәтләр язучыларыбызга, бигрәк тә яшь әдипләргә, зур мәктәп булып хезмәт итә ала.

---

[1] Г. Халит. Тукай узган юл, 126 бит.
[2] М. И. Калинин. О литературе. Ленинград, 1949 ел, 194—195 битләр.
[3] Ә. Фәйзи. Күрсәтелгән хезмәт, 71 бит.

## Илгиз Кадыйров

# СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ МУЗЫКАСЫ

Көнбатыш Себер татарлары Көнбатыш Себернең урманлы-далалы көньяк өлешендә урнашкан. Авыллары башлыча Иртыш, Тура, Тара, Ом, Исәт, Тубыл һәм башка елгалар буена утырган. Бу елгалар калын урманнар һәм үтә алмаслык сазлыклар аша бердәнбер аралашу юлы да булган.

Татарлар, нигездә, авылларда, азрак санда Төмән, Тубыл, Том, Тара, Барабинск, Новосибирск, Омск һ. б. шәһәрләрдә яшиләр.

Хәзерге Себер татарларының иң якын борынгы бабалары булып XII—XIII гасырларда Көнбатыш Себер далаларыннан алып, Иделнең түбән өлешенә кадәрге киң мәйданда яшәүче төрки телле кыпчак кабиләләре санала.

Көнбатыш Себер территориясендә монгол империясенең Җучи улусы җирендә Төмән ханлыгы барлыкка килә. Бу Себер татарларының беренче берләшмәсе була [1]. Соңыннан Себер ханлыгы оеша. Аның башында XVI йөзнең алтмышынчы елларында Күчем хан (күчмә үзбәклләрдән килгән шейбанлы) тора. [2]

Себер ханлыгында яши торган төрки телле кабиләләр билгеле бер дәрәҗәдә казакъларга, күчмә үзбәкләргә һәм, күрәсең, нугайларга да кардәш булган [3].

Ханлык озак яшәми. 1582 елда Күчем хан җиңелә һәм аның территориясе Рус дәүләтенә кушыла. Шушы вакыттан башлап интенсив рәвештә Себерне үзләштерү башланып китә.

«...Беренче рус утраклылары татарларда күргән чагыштырмача югары культурага Себер төркиләре күптәннән ирешкән булган» [4]. Татарлар экономик үсеш ягыннан да югарырак торганнар. Даладагы районнарда, бигрәк тә Бараба даласында, терлек асраучылык алга киткән. Руслар килгәнчегә кадәр үк инде, гади булса да, игенчелек белән дә шөгыльләнгәннәр. Тиз өлгерүче үсемлекләр — арпа, борай һәм солы чәчкәннәр [5].

В. П. Левашева Себер ханлыгы территориясенә кергән җирләрдә үткәрелгән казылмалардан чыккан табылдыклар җыелмасын җентекләп тикшергәннән соң түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Монда игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, металлургия, туку һәм тегү эшләре, тире иләү-эшкәртү кораллары бар... Бизәнү һәм башка тормыш-көнкүреш әйберләре шактый югары культура дәрәҗәсе турында сөйлиләр» [6].

---

[1] Очерки истории СССР. Период феодализма. IX—XV йөзләр, II кисәк, СССР Фәннәр академиясе нәшрияты, 1953 ел, 464 бит.
[2] Л. П. Потапов. Этнический состав и происхождение алтайцев. «Наука», Ленинград, 1969 ел, 81 бит.
[3] Л. П. Потапов. Күрсәтелгән хезмәт, 82 бит.
[4] Россия. Полное географическое описание нашего Отечества. XVI том. Көнбатыш Себер. СПб., 1907 ел, 265—266 битләр.
[5] История Сибири. I том. «Борынгы Себер». «Наука», Мәскәү, 1968 ел, 363 бит.
[6] В. П. Левашева. О городищах Сибирского юрта. «Советская археология», XIII том, Мәскәү-Ленинград, 1950 ел, 347 бит.

Бараба даласында яшәгән татарларны руслар бараба дип йөрткәннәр. Алар инде XVII гасырда даими утрак тормышта яшәгәннәр. Радлов күргән картлар үзләренең ата-бабаларының, алтайлылар кебек үк, мәҗүси корбаннар чалуларын һәм мөселманнар кебек киенгәнлекләрен сөйләгәннәр.

«Ул халыкның холкы яхшы — алар ялганламыйлар һәм разбой салмыйлар. Георги аларны яссы йөзле, азрак сузылып киткән күзле, зур колаклы һәм кара чәчле итеп сурәтли»,— дип яза рус галиме Н. М. Ядринцев.[1]

«Бохаралылар... Себер татарлары белән русларга караганда шактый алданрак элемтәгә керәләр. Бохаралылар үзләренә хатыннарны, гадәттә, татарлар арасыннан алганнар... Мондый туганлык элемтәләре аларны Себер татарлары белән тагын да якынайткан».[2]

Бохаралылар уку-укыту, культура эшләренә дә билгеле күләмдә өлеш кертәләр. Җирле халык алардан күн эшләп чыгару, келәм сугу кебек кайбер һөнәрләрне үзләштерә.[3]

Себер татарлары формалашуда Казан, Самара, Сембер, Пенза һәм Россиянең башка губерналарыннан күчеп килгән татарлар да катнаша. Төрле җирләрдән килүләренә карамастан, Себердә аларның барысы да Казан татарлары дип йөртелә. Россиядән татарларның күчеп килүләре XX йөзгәчә дәвам итә. Алар арасында кайчандыр сөрелеп шунда яшәп калганнары да һәм Үзәк Россиядә җир җитешмәү сәбәпле ирекле рәвештә күчеп утырганнары да бар.

Көнбатыш Себер татарлары халкыбызның шактый зур этник төркемен тәшкил итсә дә, аларның музыка культурасы озак кына еллар белгечләребез игътибарыннан читтәрәк кала килде. Моңа, әлбәттә, бу төбәкнең татар халкының төп политик һәм культура үзәге булган Казаннан ераклыгы да комачаулык итте. Музыкаль фольклорны, бигрәк тә Татарстаннан читтәге өлкәләрдә яшәүче татарларның көй-җырларын чын-чыннан фәнни нигездә җыйнау һәм тикшерү эшләре 1960 еллар тирәсендә генә ныклы рәвештә юлга салынды.

Революциягә кадәрге чорда басылган хезмәтләрдә бу төбәкнең тарихын, этнографиясен, телен һәм фольклорын чагылдырган материаллар бик аз санда булып, аерым өзекләр рәвешендә генә очрый. Тик академик В. В. Радловның «Төрки кабиләләренең халык әдәбияты үрнәкләре» хезмәте генә үзенең зур күләмлелеге белән аерылып тора һәм әлегә кадәр Себер татарларының телен һәм халык авыз иҗатын өйрәнү өчен кыйммәтле чыганак булып хезмәт итә[4].

Себер татарларының җырлары турында беренче мәгълүматлар үткән йөзнең алтмышынчы елларында күренә башлый. Шул чор матбугаты битләрендә Себер татарларының тормыш-көнкүреше белән бергә, аз гына күләмдә булса да, аларның ничек җырлаулары турында да әйтелеп узыла[5]. 1864 елда «Тобольские губернские ведомости»да Тубыл татарлары җырлары басылып чыга[6]. Аларны җыюда Тубыл татары Нияз Урмаев булышкан. Укымышлы бу кеше булдыра алган кадәр диалекталь үзенчәлекләрен саклап, сигез дистә чамасы дүртьюллык язып алган һәм русчага тәрҗемә иткән.

Себер татарларының музыкаль фольклор үрнәкләрен беренче булып шагыйрь Мөхәммәт Садри җыя. Ул 1940 елда Көнбатыш Себергә оештырылган фәнни экспедиция[7] вакытында фонографка Омск һәм Новосибирск өлкәләрендә яшәүче татарлардан күп санда җырлар һәм көйләр язып ала. Соңрак композитор А. С. Ключарев бу язмаларны нотага сала һәм кырыктан артык җыр-көйне «Татар халык көйләре» җыентыгына кертә[8]. Алар арасында инде хәзер гомумтатар музыка хәзинәсенең энҗеләренә әверелгән «Каръят батыр», «Сәрвиназ», «Илчебага», «Зәңгәр күз»

[1] Н. М. Ядринцев. Сибирские инородцы, их быт и современное положение. СПб., 1891 ел, 52—54 битләр.
[2] Н. М. Ядринцев. Күрсәтелгән хезмәт, 34—35 битләр.
[3] Д. Г. Тумашева. Көнбатыш Себер татарлары теле, 14 бит.
[4] В. В. Радлов. Образцы народной литературы тюркских племен. СПб., 1872 ел.
[5] «Тобольские губернские ведомости», 1861 ел, 35—45 битләр.
[6] «Тобольские губернские ведомости», 1864 ел, 34—35 битләр.
[7] Экспедиция Татарстан Халык Комиссариаты карамагындагы Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты һәм Казан музыка кабинеты тарафыннан Х. Ярми, С. Әмиров, В. Хаҗиев, М. Садри составында оештырыла.
[8] Татар халык көйләре. Төзүче һәм җыючы А. С. Ключарев. Казан, 1955 ел.

жырлары бар. Җыентыкның ахырында бу көйләрнең лад һәм жанр үзенчәлекләре турында кыскача аңлатма бирелә.

Соңгы елларда Себер татарларының берничә җырын композитор Җәүдәт Фәйзи язып алды. «Халык җәүһәрләре» дип аталган җыентыгына ул 1965 елны Төмән һәм Тубыл шәһәрләрендә язып алган берничә җырны керткән. Шулардан «Сахралар» һәм «Усакайлар» җырлары Татарстан радиосы концертларында да яңгырый.

Себер татарлары җырлары турында Х. Ярми, М. Госманов, М. Мәһдиев, Ф. Әхмәтова, Ф. Урманчеев хезмәтләрендә байтак мәгълүматлар табарга мөмкин [1].

СССР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты секторы 1967 елның җәендә Көнбатыш Себер татарларының авыз иҗатын җыюга керешә. Бер елдан соң бу эшкә яңа оешкан сәнгать секторы кушылды.

Көнбатыш Себер татарларының музыкаль-поэтик иҗаты — гаять бай һәм күп кырлы хәзинә. Халыкның тарихи үткән юлы, үзенчәлекле тормыш-көнкүреше һәм гореф-гадәтләре санап бетергесез җыр-көйләрдә чагылыш тапкан. Шулар арасында үзләренең идея-художество эчтәлеге белән киң халык массаларының эстетик таләпләрен канәгатьләндергән һәм аның өмет-хыялларына тәңгәл килгәннәре безнең көннәргәчә килеп җиткән.

Җыр-көйләр Себер татарлары тормышында гаҗәеп зур урын тота. Алар туй мәҗлесләренең аерылгысыз һәм мәҗбүри шартына әйләнгән: җыр белән кыз атаанасы өеннән аерылып китә, кияүне дә кыз куенына җыр белән озаталар; җыр хезмәт процессында да мөһим роль уйный. Ә әкият һәм дастан геройлары исә бер-берсе белән көйләп аңлаша. Җыр аша аерым шәхеснең дә, бөтен бер халыкның да эчке рухи дөньясы ачыла. «Җырын алалмадың — серен алалмадың!» Тормыш-көнкүреш һәм эчке дөньяларының җыр-көйләрдән аерылгысыз икәнлеген алар әнә шундый тапкыр сүз белән белдергәннәр.

1968—1975 еллардагы экспедицияләр вакытында җыелган музыкаль фольклор материаллары Себер татарлары иҗатының гаять катлаулы һәм составы ягыннан чуар да булуын күрсәтте. Монда Көнбатыш Себер татарларының җирле диалекталь фольклоры, Казан ягы, ягъни Казан, керәшен һәм мишәр татарлары белән килгән фольклор, татар халкының күпчелек этник төркемнәренә уртак үрнәкләр — гомумтатар классик фольклоры, бохаралы, башкорт, казакъ һәм рус халыкларының гаҗәеп себерләшкән фольклоры барысы бергә яши һәм үзенчәлекле гаҗәеп мозаика тәшкил итә.

Халыкның шигъри-музыкаль иҗаты формалашуы һәм үсүе Себер татарларының халык булып оешу процессы белән тыгыз бәйләнештә барган дип карарга кирәк. Тарихи эзлеклелекне нигез итеп алып, аны гомуми рәвештә генә дүрт чорга аерып карарга була: иң борынгы, борынгы, яңа һәм бүгенге чор.

Иң борынгы чордагы музыкаль фольклорны без гомумтөрки фольклоры дип, ягъни Себер татарларының бабалары Алтай йортыннан аерылып чыкканда үзләре белән алып киткән хәзинә дип фикер йөртәбез.

Борынгы фольклор нигездә XVII гасырга кадәр, ягъни Себер ханлыгы чорында формалашкан дип санарга мөмкин. Бу чорда музыкаль фольклор аерым вак этник төркемнәрнең җыр-көйләре җыелмасы рәвешендә генә яши, чөнки Себер татарлары бердәм халык булып формалашырга өлгермәгәннәр.

Борынгы фольклорга бохаралы, казакъ һәм башка төрки телле халыкларның, шулай ук ханти-мансиларның өлешчә йогынтысы булырга тиеш. Беренчеләре Себер йортының таркалуына кадәр үк килеп утыра башласалар, калганнары алар белән озак гасырлар янәшә яшәгәннәр.

Яңа фольклор чоры исә XVII гасырда Идел буе өлкәләреннән күчеп килүче татарларның халык иҗаты белән тыгыз элемтә башлану нәтиҗәсендә туа башлый. «Кү-

[1] Х. Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты. Казан, 1967 ел, 194—196 битләр; М. Госманов. «Бараба татарлары фольклоры». «Казан утлары», 1962 ел, 6 сан; М. Мәһдиев. «Себер татарлары иҗаты». «Казан утлары», 1968 ел, 10 сан; Ф. Әхмәтова. «Әйтүкә һәм Батыш турында тарихи җыр», «Азат хатын», 1970 ел, 8 сан; Ф. Урманчеев. «Тарихи җырлар», «Казан утлары», 1969 ел, 3 сан; Халык авазы. Казан, 1974 ел; «Мәхәббәт дастаны» («Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу»). «Татар әдәбияты мәсьәләләре». КДПИның гыйльми язмалары, № 133. Казан, 1974 ел, Алтынчы җыентык.

чеп утыручылар аерым авыллар булып та, шул ук вакытта Себер татарлары белән бергә дә утыралар».[1] Шушы чордан алып, Себер татарлары тормышында яңа дәвер башлана. Кайчандыр Алтай йортында бергә булып, соңыннан төрле тарихи сәбәпләр аркасында шактый гасырлар аерылып яшәгән һәм шул дәвер эчендә һәрберсе үзенчәлекле музыкаль фольклор үрнәкләре тудырып өлгергән кардәш халыклар XVII гасырда бер-берсенә яңадан якыная башлыйлар. Моңа кадәр дә аларның рухи бәйләнеше бервакытта да өзелеп тормаган. Чөнки Себер ханлыгы Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы белән даими политик һәм экономик бәйләнештә торган.

Казан татарлары үзләре белән башлыча ангемитоник пентатоника ладына корылган җыр-көйләр һәм бәетләр алып киләләр. Җирле халыкның музыкаль фикерләве пентатониканың көчле йогынтысын кичерә. Себер татарлары арасына акрынлап ислам

дине керә башлый. Бу хәл, үз чиратында, мөнәҗәтләрнең таралуына китерә.

Мишәр татарлары исә ангемитоника һәм диатоникага бай катнаш көйләр алып киләләр. Алар җирле фольклорга органик рәвештә кушылып китәләр. Чөнки диатоник көй агышы өчен Себер татарларында күптәннән җирлек була. .

Тулаем алганда, Казан татарлары музыкаль иҗатының Себер татарларына тәэсире гаять киң, һәм ул әле аерым бәет-мөнәҗәт һәм җыр-көйләрне турыдан-туры күчереп алуга гына кайтып калмый. Экспедиция материаллары шуны күрсәтә: Себер төбәгендә татар музыкаль фольклоры тулы яңгыраш алган һәм аның барлык жанрлары да диярлек иҗади файдаланыла. Монда сүз шулай итеп, Себер татарларының музыкаль фикерләвенә тирәнтен үтеп керү турында бара. Әлбәттә, иҗади ярдәмләшү төрле чорда төрле дәрәҗәдә булган һәм торган саен катлаулырак төс алган. Мондый тыгыз һәм нәтиҗәле иҗади бәйләнеш ике халыкның да музыкаль һәм шигъри фикерләвендә уртак сыйфатлар булганда гына мөмкин.

Икенче бер төбәктән килгән җыр-көйләр җирле татарларның традицион фольклоры белән янәшә «тыныч кына» яшәми, әлбәттә. Алар, кагыйдә буларак, җирле музыка стиле белән тыгыз элемтәгә керә, «уртак тел» табарга тырыша, аның кай өлешен булса да үзенә муафыйк килерлек итеп үзгәртә. Һәм шул ук вакытта алар үзләре дә акрынлап ассимиляциягә дучар була — «себерләшәләр». Күп очракта хәтта ул җырларның кайсысы җирле, ә кайсысы күчеп килгән булуын билгеләү ифрат читенләшә. Бу, үз чиратында, яңа үзләштерелгән фольклор үрнәкләренең җирле төбәктә тоткан ролен билгеләүгә комачаулый.

Җирле һәм читтән килгән фольклорның күп гасырлар дәвамында бер-берсе белән шулай тыгыз элемтәгә кереп, аерып ала алмаслык дәрәҗәдә «чорналып» үсүе Себер татарлары музыкасының катлаулы стиль комплексы тууына китергән.

Себер татарларының бүгенге көндәге музыкаль фольклоры гаять катлаулы күренеш ул. Традицион мирас әле дә булса яши бирә, урта һәм олы буын вәкилләре арасында һаман да сөеп башкарыла һәм яратып тыңлана. Әлбәттә, алар яшәгәндә традицион фольклор да яшәячәк. Ләкин шул ук вакытта традицион фольклор үрнәкләренең кимүе дә нык сизелә. Бу, беренче чиратта, йола белән бәйләнгән җыр-көйләргә һәм әкият-дастан назымнарына кагыла.

Себер төбәгендә җыеп алынган музыкаль-шигъри хәзинәне башкарылу рәвешенә карап өч төргә бүләргә була: көйләүләр, көйләр, җырлар.

Көйләүләрнең нинди дә булса бер йола белән бәйләнгәннәре һәм мөстәкыйль башкарыла торганнары бар. Йола көйләүләренең бүгенге көндә бары тик калдыклары гына сакланып калган, ул да булса — «Яңгыр теләү». Бары тик ике тавышлы гына булган бу гади көйләү, һичшиксез, Себер татарларының гына түгел, ә гомумтатар фольклорының иң борынгы үрнәкләреннән берсе булырга тиеш[2]. Себер вариантына охшаш көйне күрше казакъ халык иҗатында да очратырга мөмкин.

Мөстәкыйль көйләүләрдән дастан һәм әкият назымнарын, бәет, мөнәҗәтләрне күрсәтә алабыз.

[1] В. В. Храмова. Көнбатыш Себер татарлары. «Себер халыклары» исемле этнографик очерклар китабында. СССР Фәннәр академиясе басмасы, Мәскәү-Ленинград, 1956 ел, 474 бит.

[2] Ике тавышлы яңгыр теләү көйләрен кара: А. Абдуллин. Тематика и жанры татарской дореволюционной народной песни. «Вопросы татарской музыки» җыентыгында. Казан, 1967 ел. 15 бит; М. Нигмедзянов. Олиготонные лады в татарской народной музыке. «Советская музыка» журналы, 1974 ел, 1 сан.

Көйләрнең шулай ук тормыш-көнкүреш йоласы белән бәйләнгәннәре (аларны могам дип йөртәләр, мәсәлән, «Шайтан могам», «Ат могам») һәм мөстәкыйль башкарыла торганнары бар. Соңгыларына бию көйләре, инструменталь маршлар һәм пьесалар керә.

Җырлар — Себер татарлары музыкасында иң зур төркем. Алар шулай ук йола җырлары һәм мөстәкыйль җырлар (лирик җырлар) төркеменә аерылалар. Йола җырлары арасында туй җырлары иң күренекле урынны алып тора. Болар: кияүне кыз куенына озату җырлары («Кияү типсәү»), ишек бавы җыры, кызның чәчен икегә аерып үргәндә башкарылган җырлар («Яр-яр», «Үләң таш»), кызны егет өенә озату, туй мәҗлесендә кода-кодагыйларның бер-берсен макташу җырлары, кара-каршы башкарыла торган күңелле туй уены җырлары («Хан кызы», «Башмак» һ. б.), сатып яки көчләп бирелгән кызларның ата-анасын, туган авылын каргап китү җырлары.

Гаилә тормышында туйлар зур вакыйга рәвешендә бик күңелле һәм шау-шулы үткән. Туйга авыл халкы белән беррәттән алыстан да кода-кодагыйлар һәм кардәшләр килгән. Кагыйдә буларак, килен читтән алынган. Чөнки ыруглык калдыклары озак сакланып калган Себер татарларында бер авыл кешеләре бер-берсе белән туган-тумача саналган һәм алар арасында өйләнешү тыелган.

Туй ул яңа семья төзү тантанасы, кыз белән егетнең җитлегүен мактау тантанасы. Яучылау һәм фатиха бирүдән алып, туйдан кунаклар таралган вакытка кадәр булган һәрбер адым тирән этник мәгънәгә ия. Ул берничә гасырлар элек шушы этник төркемгә хас тормыш-көнкүреш һәм семья-әхлак кагыйдәләреннән чыгып төзелгән.

Туйларга махсус рәвештә җырчылар һәм музыкантлар чакырылган һәм туйның җыр-музыка белән үткән өлешенең уңышлы чыгуы музыкантлар, җырчылар осталыгына турыдан-туры бәйләнгән. Мондый кадер-хөрмәт, күрәсең, җыр-музыка туй вакытында үзенә күрә ниндидер магик көчкә ия була дигән ышануга нигезләнгән. Бу ышану Себер татарларында XX гасыр башларына кадәр дәвам итә. Туй йоласы җырлары да шул чоргача актив рәвештә башкарылып килә. Һәм ул җырлар өлкән яшьтәге кешеләр хәтерендә әле дә саклана. Күпләренең өйләнү-кияүгә барулары шул җырлар белән үткән.

Туй йоласы җырларын туйның өч моментында башкару мәҗбүри булган: кияүне урам буйлап тип сугып кыз өенә озата барганда «Кияү типсәү» («Күч җыры», «Кияү сүзе», «Ялтыр-талалтир»), кыз өенең капка төбендә «Ишек бавы» җыры, егет өенә китәр алдыннан кызның чәчен икегә аерып үргәндә «Яр-яр!» яки «Үләң таш» җырларын җырлаганнар.

«Яр-яр» җырларына тукталып үтик.

Себер татарларында, кайбер башка халыклардагы кебек, кыз белән яшь киленне чәч толымына карап аерганнар. Кызлар чәчне бер толымга үреп йөртсә, яшь киленнәр исә аны икегә аерып үрергә тиеш булганнар. Шуңа күрә чәч аеру ритуалы кыз озатканда иң изге, иң җаваплы йолаларның берсе саналган.[1] Ул болай үтәлгән. Кияү егетләре белән кызны алырга килгәч, кызның җиңгәләре чыбылдык эчендә кызның чәчен махсус тарак белән елый-елый икегә аерып үрә башлыйлар. Һәм шул вакытта кызның туган-үскән йорты, ата-анасы, дус-ишләре, туган-тумачалары белән саубуллашу сәгате җиткәнне аңлатып, «Яр-яр» әйтелә башлый.

«Яр-яр» җырлары гаять зур территориядә яшәүче төрки телле халыкларның кыпчак төркеменә кергәннәренә хас. Күрше казакъларда ул — «Җар-җар», үзбәкләрдә — «Ёр-ёр», нугайларда — «Хей-җар», каракалпакларда — «Хауҗар», Башкортстандагы Ык буе татарларында — «Яр-яр».

«Яр-яр»ның шигъри тексты Курмашиның «Кыйссаи бүз егет» дастанына да кертелгән. Бу очраклымы? Күрәсең, юк. Һәрхәлдә, XVII гасырга караган «Яр-яр» текстының безнең Идел төбәгендә табылуы бу йола җырының Идел буенда яшәүче татарларга да ят нәрсә булмаганлыгын әйтеп тора.[2] Драматург М. Фәйзинең

---

[1] Ф. Әхматова, Р. Гайнанов. Себер юлларында. «Социалистик Татарстан» газетасы, 1967 ел, 13 август саны.

[2] М. Усманов. Об археографических экспедициях Казанского университета. «Тихомировские чтения 1970 года», Мәскәү, 1970 ел, 122 бит.

дә «Кызыл йолдыз» пьесасына бу куплетларны кертүе, һичшиксез, халык иҗатына таянудан килә. Соңгы елларда гына өйрәнелгән Ык буе татарлары иҗаты да — моның ачык мисалы [1].

«Кияү типсәү». Төмән өлкәсе авылларында шушы җыр белән кияүне кыз куенына озатканнар. Бу болай булган. Башка авылдан килгән кияү иң элек дусларына яки туган-тумачаларына туктый. Нугәрләр (кияү егетләре) кияүне ике яктан култыклап алып, шушы җыр белән кыз өенә алып киләләр. Әгәр дә кияү буласы егет күңеленә хуш килгән кеше булса, кыз түшәк җәеп көтеп торган, ошамаса — чыгып качкан. Бу очракта аны беркем дә көчләп бирергә батырчылык итмәгән. Шунысы кызык: кайвакытта олы яшькә җиткән картлар да, шаярып һәм дә гомер иткән карчыгын сынарга теләп, үзләрен шулай «иңдертеп» йөргәннәр.

Төмән өлкәсе Вагай районы Күләт авылында Халиков Хәйдәр бабай (1889 елгы) бу турыда менә нәрсәләр сөйли: «Моны ялтир әйтү тиләр. Җегетне көнтес алып кереп таныштырып алатылар. Ваклар җиснә дип килгәч, ул аларга косык (эрбет чикләвеге) өләшә. Кич белән ялтир әйтеп ай әллерләп алып киләләр биччгә. Йегет пелән кысга аерым чатыр коратылар. Кысны анта саклап утыратылар туслары, җиңгәләре».

Лирик җырлар — Себер татарлары шигъри-музыкаль иҗатының иң зур тармагы. Музыкаль тасвирлау чараларының байлыгы, шигъри нәфислеге белән аерылып торган бу җырларны халыкның эстетик кичерешләре көзгесе дип әйтергә мөмкин. Лирик җырларга киң колачлы аһәң хас. Төрле йола һәм гореф-гадәтләр белән бәйле әсәрләр зур иҗтимагый политик үзгәрешләр аркасында онытылуга таба барган вакытта алар урынын лирик җырлар биләп ала. Жанрлар төрлелеге кимесә дә, җыр-көйнең халык өчен әһәмияте кимеми. Киресенчә, безнең көннәрдә Себер татарлары музыка хәзинәсенең баюы турында сүз алып барырга мөмкин. Лирик җырлар халык тормыш-көнкүрешенең барлык тармакларына үтеп керә, аның тематикасы киңәя.

Лирик җырларны якынча дүрт төркемгә: сузып җырлана торган иректе метроритмдагы эпик яңгырашлы озын көйләргә, иректе метро-ритмдагы лирик озын көйләргә, төгәл метро-ритмдагы квадрат структуралы җыйнак, кыска көйләргә, иректе метро-ритмдагы баш өлештән һәм төгәл метро-ритмдагы җыйнак кушымтадан торган озынча салмак җырларга бүләргә була.

Беренче төркемгә Омск өлкәсе Ишемтамак районы Зур Тибенде авылында Абтюкова Сәлимә (1925 елгы), Саургач авылында Разулев Шәфикъ (1913 елгы), Төмән өлкәсе Тубыл районы Лайтамак авылында Таҗетдинова Җәмилә (1906 елгы), Новосибирск өлкәсе Чаны районы Кошкүл авылында Хәбибуллин Кәримулладан (1928 елгы) язып алынган «Борынгы җыр», «Туктасын качкы», «Мәхмүт мәргән», «Кара да гына елан» һәм башка җырларны алырга була. Киң эпик яңгырашлы бу җырлар Себер татарлары иҗатына иң хас үрнәкләрдән.

Бигрәк тә Бараба татарларының иң күркәм һәм киң таралган «Кара да гына елан» һәм «Асыл кошлар» җырларын һәр җырчы белә диярлек. Ә Казан ягыннан килгәннәре исә «бу инде чын барабалар көе» дип искәртеп куярга онытмыйлар.

Озын лирик көйләр (икенче төркем) — иң күп санлы. Аларны йөзләп санарга була. һәм үзенчәлекләрен дә бер-ике үрнәк белән күзаллау һич мөмкин түгел. «Туп-туп баскан туры ат», «Аргамагым», «Агавын» (Бараба татарлары), «Иске пасхуд», «Җиктем күк юрга» (Омск өлкәсе), «Димен лә», «Бадъян баскыч», «Моңлы көй» (Төм татарлары) җырлары халык телендә бүген дә яши.

Калган ике төркемгә кергән җырлар Себер татарларының һәр этник төбәгенә дә бердәй хас.

Шунысы кызыклы, лирик озын көйләргә «Йосыф-Зөләйха», «Вүз егет», «Таһир-Зөһрә», «Сәйфелмөлек» кебек мәгълүм дастаннарның аерым өзекләре дә җырлана. Алар күптән инде мөстәкыйль җыр булып таралып киткәннәр.

---

[1] Р. М. Мөхәммәтҗанов. Башкортстанның Ык буе татарлары йола иҗаты. Автореферат. Уфа, 1973 ел.

Себер татарларының музыка сәнгате тамырлары белән тарих тирәнлегенә китә. Аның нигезләре борынгы төрки телле кабиләләрнең шигъри-музыкаль хәзинәсеннән аерылгысыз. Югарыда әйтелгәнчә, ул гаять катлаулы шартларда барлыкка килгән. Себер татарларының үз арасындагы төрле этник төркемнәрнең, бөтен татар халкының, Казагыстан һәм Урта Азия халыкларының музыкаль культурасы Көнбатыш Себер төбәгендә даими бәйләнешкә керәләр. Бу бәйләнеш — иҗади процесс. Совет фольклористикасы фәне вәкилләре мондый бәйләнешне төпле өйрәнү өчен яңа методлар эзлиләр.

Кайбер гомумтөрки бәйләнешләрен карап үтик.

Менә Бараба татарларының тиңдәшсез «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастаны[1]. «Шигъри хәзинәсендә «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастаны булган һәр бер халык аны үз әсәре дип исәпли, туган телендә сөйли, милли моңы белән җырлый... Безнеңчә, дастанның һәрбер милли версиясе һәм барлык вариантлары бер тамырдан үсеп чыккан, бер тамырдан таралган», дип яза Ф. Урманчеев. Бу гаҗәеп әсәр халык тормышының үткәнен зур панорама итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Дастанның төп эчтәлеге сөйләп, кайбер диалоглары көйләп әйтелә. Ләкин аның әле күптән түгел уен коралына (мәсәлән, «Җатыган» дип йөртелә торган кыллы уен коралына) кушылып, көйләп әйтелүендә безнең шигебез юк.

«Хан кызы» җыры, фольклорчыларның билгеләве буенча, бәетләргә керә[2]. Шуңа карамастан, «эчтәлеге белән дә, формасы ягыннан да әсәр бәет жанрының башка үрнәкләреннән аерылып тора»[3] икән. Менә шул аерымлыкларын исәпкә алып та, кайбер фольклорчылар «Хан кызы» бәет түгел, җыр дип исәплиләр. Себер татарлары, мәсәлән, Төмән өлкәсе Тубыл районы Лайтамак авылында яшәүче Исәнярова Зинникамал (1927 елгы) «Хан кызы»н җыр дип атый. Аның әйтүенчә, туй мәҗлесләрендә, яшьләрнең аулак өендә ул кара-каршы башкарылган күңелле, шаян җыр икән. Аны кунакларның кәефен күтәрү, китәсе кызның туган өйдән аерылу хәсрәтен җиңеләйтү өчен җырлаганнар.

Фольклорчыларның билгеләве буенча, бәетләр бары тик безнең татар халык иҗатына гына хас жанр. «Башка халыкларда безнең бәетләргә тәңгәл килердәй әсәрләр юк. Дөрес, бәетләр башкорт халык иҗатында да бар. Ләкин, башкорт галимнәренең фикеренчә, алар татар фольклоры йогынтысы нәтиҗәсендә барлыкка килгән»[4].

Ә менә Ф. Н. Катановның хакасларда язып алынган фольклор үрнәкләре арасында «Хан кызы» җырының шигъри юлларына тәңгәл килә торган әсәр бар[5].

Үзбәк халкында да шуңа охшаш җырны очратабыз.

Йигит:

**Сочинги узун дейдилар,**
**Доно укам, ёр-ёр,**
**Кора соч укам, ёр-ёр,**
**Курсат сочингни бир курайин,**
**Жоним укам, ёр-ёр!**

Киз:

**Сочимни куриб нима киласиз,**
**Сиз акажоним, ёр-ёр,**
**Жон акажоним, ёр-ёр,**
**Бозордаги сочпапукни**
**Курмабмидингиз, ёр-ёр!**

---

[1] Күрсәтелгән хезмәт, 126 бит.
[2] Х. Бадигый. Халык әдәбияты. Бәетләр. Казан, 1913 ел; Х. Ярминең күрсәтелгән хезмәте.
[3] Ф. Урманчеев. Халык авазы. Татар халык бәетләре тарихыннан очерклар. Казан, 1974 ел, 83 бит.
[4] Ф. Урманчеев. Халык авазы, 83 бит.
[5] Ф. Н. Катанов. Хакасский фольклор. Абакан, 1963 ел, 20, 98 битләр.

«Хан кызы» Себер татарларында гына таралган җыр түгел.[1] Мәсәлән, ул Г. Тукайның җырлар дәфтәрендә дә бар (кызганычка каршы, бу көйнең җырлары дәфтәрдән ертып алынган)[2]. Г. Тукай аны җырлар арасына кертә, бәетләр белән бутамый. Әлбәттә, бу кызыклы факт. Менә шуңа күрә дә «Хан кызы»ның яңа вариантларын язып алырга кирәк. Күп вариантларның көй һәм сүзләрен чагыштырып карагач кына җырның төп функциясе турында катгый фикер йөртергә мөмкин булачак.

Себер татарлары иҗатын өйрәнгәндә кайбер бәхәсле җырлар да очрый. Мәсәлән, «Тамчы тама» шундыйлардан. Аның көе С. Габәши, В. Виноградов һәм Г. Әлмөхәммәтовның мәгълүм «Эшче» операсындагы Нигъмәт ариясе белән тәңгәл килә. Новосибирск өлкәсе Чаны районы Белекте авылында Йосыпова Шәмсинур (1900 елгы) әйтүенә караганда, көй бу авылда бик күптәннән, «бабайлар заманыннан» билгеле.

Көйнең Себердә бик популяр булуын төп Себер татары Таминдаров Сәгыйр (1888—1975) дә раслады. Аның әйтүенчә, Кемерово өлкәсендә яшәүче халыкларда бу җырны нугәр егетләре кызны егет өенә озатыр алдыннан җырлаганнар. Җыйналган барлык кеше елаган. 1969 елның көзендә бу җырны ачыклау өчен махсус рәвештә Кемерово өлкәсе Юрга районы Кышлау авылына керелде (С. Таминдаров исә күрше Эскәтем авылында туган). Авылның иң олы кешесе — 87 яшьлек Шулаяков Гафур бабай бу җырны «Кыз озату җыры» дип яздырды. Яшь вакытта ул аны нугәр егете булып җырлап йөргән. Димәк, җырның ким дигәндә алтмыш еллык гомере бар. «Эшче» операсы исә 1930 елны сәхнәгә куела.

Солтан Габәшинең Нигъмәт ариясе турында язмалары күренми (һәрхәлдә, әлегә табылмаган). Шуңа күрә бу көйне Себер татарларыныкы дип өзеп әйтергә ашыкмыйк. С. Габәши — халык җырларын җыючы һәм өйрәнүче, музыкаль фольклорны гаять тирәннән белүче. Әгәр дә композитор үзе белгән һәм җыйган йөзләгән көйләрнең берәрсен операда файдалана икән, бу профессиональ музыка өлкәсендә табигый хәл санала. Күп вакытта автор көйнең кайдан алынуын да әйтеп тормый. Мәсәлән, Җ. Фәйзи 1952 елда Әлмәт шәһәрендә язып алган «Сагынам» җырының көен «Тапшырылмаган хатлар» операсында Галия ариясендә генә файдаланып калмый, операның төп музыкаль лейтмотивы итә.

Теге яки бу җыр-көйнең таралып китүен алдан әйтү кыен. Алар, иң беренче чиратта, фән өчен әһәмиятле. Теләсә кайсы халыкның музыкаль-поэтик хәзинәсе — зур культура кыйммәте булган, илебез музыкантлары һәм галимнәренең игътибарын көннән-көн үзенә җәлеп итә торган тиңдәшсез дәүләт милке. Аны мөмкин кадәр югалтмыйча җыю һәм саклау — дәүләт эше.

Себер татарлары җыр-көйләрен магнитофон тасмасына яздыруда йөзләрчә җырчылар катнашты. Шулар арасында Нургалиева Вәйдә, Абитов Биктимер, Уразов Зәйнулла, Разулев Шәфикъ, Хәбибуллин Кәримулла, Сөләйманов Имаметдин, Таҗетдинова Җәмилә, Корманов Шәриф, Шулаяков Гафур, Таминдаров Сәгыйр кебек кабатланмас иҗади шәхесләр белән очрашулар күңелдә тирән эз калдырды. Аларның һәрберсе — халык иҗатындагы коллектив башлангычның һәм шул ук вакытта башка җырчыларга караганда чагыштырмача индивидуальләшүнең гүзәл гәүдәләнеше. Үз авылларында гына түгел, ә тирә-якта дан тоткан бу җырчы-музыкантлар социаль әһәмияткә ия булган вазифа үтиләр. Алар — халыкның кадерле мирасы, иң әһәмиятле милли үзенчәлекләреннән берсе булган музыкасын һәм аны башкару традициясен саклаучы, яшьләрнең тәрбиячесе һәм акыллы киңәшчесе. Музыкантлар һәр вакытта да иҗтимагый тормышның уртасында яши.

---

[1] Бер вариант Н. Мөштәриева тарафыннан Пермь өлкәсендә язып алынган.
[2] Г. Тукай. Әсәрләр. 2 том, Казан, 1955 ел, 295 бит.

Омск өлкәсе Ишемтамак районы Зур Тибенде авылында яшәүче Абитов Биктимер абый татар халык җырларын күп белүе белән безне таң калдырды. Аның башкаруында магнитофон тасмасына кырыктан артык җыр язып алынды.[1] Авторы билгеле булмаган «Җиктем күк юрга», «Ямщикәй», «Иске пасхуд», «Сәвә» (кыз исеме), «Уракчы», «Милай Мәхмүзә», «Исәт» һәм башка бик күп җыр-көйләр үзенчәлекле интонацион-лад төзелешләре белән аерылып торалар иде.

Биктимер абыйдан язып алынган җырлар тематик яктан гаҗәеп күп төрле: арада тормыш-көнкүреш җырлары да, ямщиклар моң-зары, бәет-мөнәҗәтләр дә бар. Иң күбесе — мәхәббәт җырлары. Аларга эпик яңгыраш, тирән фәлсәфи мәгънә хас.

Биктимер абый бу зур мирасның күп өлешен әтисеннән өйрәнгән. Әтисе, Мәлик бабай, әйләнә-тирәдә дан тоткан җырчы-ямщик булган. Безне таң калдырганы тагын шул булды: үлем түшәгендә ятканда да Мәлик бабай җырларын Биктимер абыйга өйрәтеп яткан. Менә кайда музыкаль традициянең көче, менә кайда саекмас чишмәләр!

Себер татарлары музыканы бик яраталар, сабан туйлары, бәйрәмнәр һәм туйлар оста җырчы, скрипкачы һәм гармунчысыз үтми. Биредә «Тәфтиләү», «Кара урман», «Уел», «Зиләйлүк», «Сарман» һәм башка бик күп җырларыбызны да бик яратып җырлыйлар.

Бөек Октябрь социалистик революциясе Себер татарлары тормышын тамырыннан үзгәртте, хуҗалык һәм культура үсеше өчен гаять зур мөмкинлекләр тудырды. Патша хөкүмәтенең рәхимсез колониаль политикасы аркасында сан ягыннан кимүгә таба барган җирле татарларга бөек совет семьясындагы барлык тигез хокуклы халыклар кебек һәрьяклап үсү өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр ачылды.

[1] Мондый феноменнар әкият сөйләүчеләр арасында да бар. Мәсәлән, шул ук районның Эбаргунь авылында 78 яшьлек Хамматов Әхмәт бабай егерме әкият яздырды.

# КҮҢЕЛЕМӘ АЛАМ ЯКТЫЛЫК...

Төрле-төрле табышлар, төрле-төрле нәкышләр... Шуларның өчесе мәктәпкәчә яшьтәге балаларга адресланган (Җ. Дәрзаманов. «Солдат булдым»; Р. Миңнуллин. «Акбай цирк карый»; Р. Хәлиуллина. «Чүкеч — нәни булышчы»), ә Н. Мадьяровның «Утлы кыя» китабы кече яшьтәге мәктәп балаларына багышланган.

Дүрт автор, дүртесе дүрт төрле. Нәҗип Мадьяров шигырьләреннән туган җир җылысы бөркелеп торса, Җәүдәт Дәрзаманов нәни дусларының эчке психологик дөньясын ачуга нык игътибар итә. Роберт — лирик шагыйрь. Яшьләр поэзиясендә лирик булган кебек, балалар шигъриятендә дә лирик булып кала. Ә Роза шигырьләрендә туган җир җылысы да, романтика да, хезмәт тәрбиясе дә бар.

Балалар шигыренең һәр юлы рәсем булырга тиеш, төгәлрәк әйткәндә, хәрәкәтле рәсем. Моны белмәгән авторның балалар өчен шигырь язуга алынмавы хәерле.

Болыт-малайлар туп уйный,
Уйный бездән күрепме?
Әй тибәләр кызып-кызып
Күктә мамык бүрекне!

(Җ. Дәрзаманов. «Җәйге яңгыр».)

Сузылып бар буена
Чәчәкләр су коена.
Зур тамчы китсә тиеп,
Куялар биеп-биеп.

(Җ. Дәрзаманов. «Наза йөри бакчада».)

Кыздырасы килми бер дә,
Кояш та сабырланган.
Сабыр булганга микәнни,
Кояш та сарыланган.

(Р. Миңнуллин. «Сары көз».)

Роберт гадәти генә детальләрдә табыш күрә һәм аларны балалар аңларлык телдә сурәтли дә белә.

Дөнья яшел микән әллә
Яшел яңгыр яуганга,
Урман-кырларны ямь-яшел
Тамчы белән юганга?

Яшел дулкын чаба кырда,
Җил иссә дә чак кына...

Шагыйрь нәниләрне рәхәт бер дулкынга көйли, яшел яңгыр, яшел дулкын, яшел, сары җилләр булуга ышандыра. Балалар өчен шигырьнең көче дә нәкъ менә шунда: күрсәтә һәм ышандыра белүдә.

Ясадым мин дәфтәремә
Бүренең бик явызын.
Озын иттердем тешләрен,
Зур иттердем авызын...

Шуннан соң ул миңа таба
Карап тора башлады.
Курыктым да бүрене мин
Тизрәк ертып ташладым.

Хәрәкәтле рәсем Робертның «Елмаючы бүреләр» шигырендә бигрәк тә ачык чагыла. Вакыйгалар мультфильмдагы кебек тиз алышына. Шигырь сабый күңеленә сеңеп кала, һәм ул аны такмаклап йөри башлый.

Бала һәрчак шатлык көтеп яши. Үзен әйләндереп алган дөньяга, кешеләргә дә шатлык тели. Бу фикер Җәүдәтнең «Күкеле сәгать» шигырендә матур чагылыш тапкан.

Аларның озын гомерләр
Юравын теләр идем:

Әтиемә, әниемә,
Әбиемә, бабайга,
Миңа, сиңа, әнә теге
Соры күзле малайга.

Бераз олыларчарак әйтелгән кебек. Әмма якты фикер. Изге фикер.

Балалар шигъриятендә хезмәт темасы үзәк темаларның берсе булып кала бирә.

Шул күзлектән Роза Хәлиуллинаның «Чүкеч — нәни булышчы»сы күпне вәгъдә итә.

Чүкеч — нәни булышчы,
Син булышсаң,
Мин көчле.
Кулга чүкеч алганнар
Зур эшләргә
Бурычлы.

Шагыйрәнең нияте изге. «Хезмәт кадерен белгәннәр бәхетләрен таба», — ди ул. Роза әлеге фикерне шигырьдән шигырьгә үстерә. «Синлек, минлек, анлык», «Тегермән» кебек шигырьләр шуның ачык мисалы. «Без дә киттек» шигыре сабыйның күз аядына рәсем булып килеп басарлык:

Диңгезчеләр чыгып китте
Диңгезгә,
Космонавтлар очып китте
Йолдызга.
Без дә киттек бакчабызга,

— кебек гадәти юллардан башлана ул. Ә бакча сабыйның эш урыны, ягъни ул аңа диңгез дә, йолдыз да. Ул ясаган кораб хыялда гына булса да еракка йөзеп китә. Бала хыялы яңа утраулар ача.

Җәүдәт Дәрзамановның нәни герое әтисенең көченә соклана:

Әти сукса, нык суга,
Кадактан да ут чыга.

Үзе дә, биленә каеш буып, йолдызлы бүрек киеп, әтисе каршына килеп баса. Солдат кеше сынатырга тиеш түгел инде ул: бәтиләргә печән ашата, утын яра, суга бара... («Солдат булдым.»)

Нәҗип . Мадьяров геройлары зурраклар. Алар сугыш кырында ятып калган Нур абыйлары кебек тырышлар.

Авылыбызда
Күп юкәләр
Утырттык.
Урамнарны
Матурладык,
Балкыттык.
Бу эштә без
Ару-талу
Белмәдек.
Сугышчылар
Һәйкәлен дә
Бияадек.
(«Юкәләр».)

Авторның фикере һәркемгә аңлаешлы. Әмма вакыйгаларны шул рәвешле коры гына сөйләп чыгу күңелдә канәгатьсезлек тойгысы калдыра. Шигырьләр балага гади генә информация бирә, әмма эстетик ләззәт бирми. Хәтердә уелып калырлык образ-детальләр булмау шигырьләрнең кирәксез озынга сузылуына китерә. «Җил тегермәнә», «Чишмәбез», «Бураннан соң», «Учак» исемле шигырьләр нәкъ менә шундыйлар.

Авылны белеп яза Н. Мадьяров, яратып яза. Укучылар кулына килеп ирешкән шигырь җыентыклары шул турыда сөйли. «Утлы кыя»сында да автор үзенә хыянәт итмәгән. «Туган җир», «Офык өсте куя яктырып», «Дулкын-дулкын булып», «Ромашкалар илендә» кебек шигырьләр шуны раслый. Бу урында «Күзгә урман» исемле шигырьгә аерым тукталып үтәсе килә. Гаҗәеп талгын шигырь, сагышлы шигырь. «... сентябрь иртәсен тәбрикләп тиеннәр шаяра, яфраклар көчләрен җуялар саргая, саргая, саргая». Инде былбыллар концерты да тынган, кошларга еракка, еракка китәргә хәбәр килгән. «Дулкыннар йоклый җәй җилләрен сагына, сагына, сагына». Шигырь күзгә матурлыкның халәтне искиткеч төгәл бирүче юллар белән тәмамлана:

Кып-кызыл тәлгәшле миләшләр
Таң нуры астында коена.
Яфраклар соңгы кат тирбәлеп
Коела,
коела,
коела,

Ләкин урынсыз кулланылган бер сүз җанны әрнетеп куя. «...миләшләр таң нуры астында коена», — ди шагыйрь. «Астында» сүзе үз урынында түгел. «Таң нурларында коена» дию дөресрәк, татарчарак булыр иде.

Роза Хәлиуллина җыентыгында да шигъри камиллеккә ирешмәгән әсәрләргә урын калдырылган. «Ни чаклы?», «Бер бишектә биш бәби», «Таш койрык», «Давылдан соң», «Матур күлмәкле кунаклар» кебек кайбер шигырьләр сабый күңелен җәлеп итә алмастыр.

Чага торгач, ура! Җиңү!
Гөлт итеп очкын кабынды.
Ташка кадак та кагар бу,
Әз генә үссен тагын да.
(«Җиңү».)

Һәр балалар шагыйре шушы рәвешле яза башласа, укучыбы[illegible] ни әйтер?

Шагыйрәгә сүзләр кулланышына да игътибар итү кирәк. «Туктап калган чана — бик алама юлдаш», — ди ул. Ничек инде алама? «Тау шуу» шигырендә исә: «Чанасында эт тартып тауга йөгерә малай!»...— дип яза. Бәлки чанага эт утыртып йөгерәдер малай?

Розада «Тәкыялы Нәкыя» исемле шигырь бар. Нәкыя, тәкыя үреп, башына кия һәм үзе дә чәчкәгә охшап кала. Җ. Дәр-

замановта да «Тәкыя» исемле шигырь белән очрашабыз.

Мондый очрашулардан соң азрак эзләнәбез бугай дип әйтәсе килә.

Китапларның полиграфик эшләнеше турында берничә сүз. Соңгы елларда нәшрият бу мөһим мәсьәләгә игътибар итә башлады. Т. Хаҗиәхмәтов, И. Әхмәдиев, Р. Төхфәтуллин кебек талантлы рәссамнарның балалар китабын бизәргә алынуы сөенечле хәл. Балалар китабы рәсемсез яши алмый. Яңа китап кулга эләккәч, бала иң элек аның рәсемнәрен карап чыга. Шуннан соң гына шигырьләрне укый башлый, яки өлкәннәрдән укыта. Ә менә Роза Хәлиуллина китабында күңелне иркәләрлек ник бер рәсем булсын. 26 шигырьне эченә алган, күләме ике табак чамасы булган китапның рәсемсез чыгуы гаҗәп хәл. Ярый әле, тышлыкта рәсеме бар.

Һәр әйбәт шигырь җыентыгы — бала өчен бәйрәм. Без алар өчен язабыз, кечкенә гражданнарыбыз гүзәл кеше булып формалашсын өчен язабыз. Максатыбыз да, кыйблабыз да шул. Безгә начар язу хокукы бирелмәгән. Һәр шигырь, шагыйрь әйтмешли, күңелләргә яктылык алып килсен.

**РӘШИТ БӘШӘРОВ.**

# МАТБУГАТЫБЫЗНЫҢ ҮСЕШ ЮЛЛАРЫ

КПСС тарихының состав өлеше булган партия-совет матбугаты тарихы белән кызыксыну елдан-ел үсә бара. Мәгълүм булганча, В. И. Ленин матбугат тарихы белән партия тарихы аерылгысыз бәйләнештә торуын, матбугатта «гыйбрәтле материал» табу мөмкинлеген билгеләп узган.

В. И. Ленинның «Матбугат социалистик төзелеш коралы булырга тиеш» дигән күрсәтмәсенә нигезләнеп, партия коммунистик төзелеш бурычларын хәл иткәндә партия-совет матбугатына таяна. КПСС Үзәк Комитетының XXV съездындагы отчет докладында иптәш Л. И. Брежнев массовый информация һәм пропаганда чараларының экономиканы, фәнне һәм культураны үстерүгә йогынтысы үсә баруын билгеләп үтте. Матбугат эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү, аның сугышчанлыгын арттыру — хәзер иң мөһим бурычларның берсе. Әлеге бурычны хәл иткәндә матбугатыбыз узгандагы бай тәҗрибәгә дә мөрәҗәгать итә, заман сынавын узган формаларны яңа эчтәлек белән баетып бүген дә куллана.

Совет матбугаты реакцион көчләр, аларның матбугаты белән рәхимсез көрәштә барлыкка килде һәм ныгыды, аңа ялкынлы полемик рух, буржуаз идеологиягә карата килешмәүчәнлек хас иде. Капма-каршы ике система арасында идеологик көрәш кызганнан-кыза барган шартларда совет матбугатының әнә шул тәҗрибәсе бәяләп бетергесез әһәмияткә ия. һәм ул тәҗрибәне гомумиләштерү — матбугат тарихчыларының изге эше.

Икенчедән, партия-совет матбугаты тарихын өйрәнү Октябрь революциясенең данлы тарихын, партиянең узган юлын тирәнрәк төшенергә ярдәм итә, партия кадрларын, журналистларны матбугатка партия җитәкчелеге тәҗрибәсе белән коралландыра.

Большевистик матбугатның Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорындагы эшчәнлеге гаять бай һәм кызыклы. Социалистик революция казанышларын саклау, сыйнфый дошманны тар-мар итүгә массаларны туплауда партиянең актив булышчысы булып әверелгән чын халык матбугаты нәкъ шул чорда туды, беренче адымнарын ясады, авыр сынаулар үтеп ныгыды, үсте.

Милли телләрдә партия матбугаты барлыкка килү тәҗрибәсен өйрәнү зур әһәмияткә ия. Бу — ленинчыл милли политиканы тормышка ашыруның калку бер мисалы.

Матбугат тарихына караган күп санлы тикшеренүләрдә ул тема теге яки бу дәрәҗәдә, әлбәттә, яктыртыла килә. Әмма шул ук вакытта татар телендәге партия-совет матбугатының бөтенлекле бер система буларак формалашуын ачып биргән хезмәтләрнең әлегә бик аз икәнлеген икърар итәргә мәҗбүрбез. Шуңа күрә Р. М. Нуруллинаның 1978 елда Казан дәүләт университеты нәшриятында дөнья күргән

«Татар телендә партия-совет матбугатының аякка басуы (1917—1925 еллар)» исемле китабы безнең өчен көтеп алынган хезмәтләрнең берсе булды.

Автор теманың актуальлеген ышандырырлык итеп дәлилли. Ул татар телендәге партия-совет матбугатының барлыкка килү үзенчәлекләрен, публицистик жанрларның формалашуын, журналистлык осталыгы мәсьәләләрен журналистика фәне күзлегеннән өйрәнүгә игътибарны юнәлтә. Һәм менә шушы хәл авторның тикшерену предметының яңалыгын билгели дә. Хикмәт шунда, журналистика тарихын өйрәнүгә багышланган байтак хезмәтләрдә нәкъ менә әлеге фәннең предметы, эчке закончалыклары тиешенчә исәпкә алынмый иде.

Автор, бүтән тикшеренүчеләрнең хезмәтләренә таянып, революциягә кадәрге алдынгы татар матбугатының торышына туктала, беренче большевистик татар газетасы «Урал», революцион-демократик юнәлештәге «Азат», «Азат халык» газеталарын искә ала, революциягә кадәр үк туган алдынгы традицияләрнең дәвамчанлыгын күрсәтергә омтыла.

Монографиядә Бөек Октябрь социалистик революциясенә әзерлек һәм аны тормышка ашыру чорында аерым матбугат органнары эшчәнлеген яктыртуга шактый зур урын бирелә, татар һәм башкорт хезмәт ияләрен политик яктан тәрбияләүдә «Кызыл байрак», «Ирек», «Аваз» газеталарының җитди роль уйнавы күрсәтелә.

Чыннан да, революцион татар журналистикасы үсешендә әлеге басмалар зур урын тота. Аларда М. Вахитов, Г. Ибраһимов кебек ялкынлы каләм ияләре хезмәттәшлек итә, газеталарның битләрендә яңа тормыш өчен көрәшнең иң үткен мәсьәләләре чагылыш таба, социализм һәм интернационализм идеяләре пропагандалана, империалистик сугышның асылы, милли буржуазия һәм аның милләтчелек идеологиясе фаш ителә, хатын-кызлар азатлыгы, завод-фабрикаларда эшче контроле урнаштыру мәсьәләләре куела. Газеталар редакцияләрендә Вәли Шәфигуллин, Шәһит Әхмәдиев, Борһан Мансуров, Хәсият Гайнуллин кебек беренче партияле татар журналистлары буыны чыныгу ала.

Газеталарның идея юнәлешләрен өйрәнү, алардагы материалларны җентекләп анализлау нигезендә автор, татар совет матбугаты революциягә кадәрге большевистик һәм революцион-демократик матбугат традицияләренә таянып аякка басты, дигән ышандыргыч нәтиҗә ясый.

Автор, алда әйткәнебезчә, татар телендә партия-совет матбугаты барлыкка килү закончалыкларын, матбугатның җаны булган публицистиканың формалашуын, төп тематик юнәлешләрне һәм журналистлык алымнарын тикшерә. Матбугатта партия җитәкчелегенең ул чордагы үзенчәлекле форма һәм алымнарын анализлый.

Монографиянең күпчелек өлеше совет властеның беренче айларыннан чыга башлаган газеталарны анализлауга багышланган.

Автор күренекле татар революционеры, интернационалист Мулланур Вахитов җитәкләгән Үзәк татар-башкорт комиссариаты органы «Чулпан», шулай ук «Кызыл Армия», «Эш», «Эшче» газеталары эшчәнлеген җентекләп тикшерә, материалларның идея юнәлешен, язылыш һәм бирелеш формаларын күзәтә. Октябрь революциясеннән алып гражданнар сугышы ахырына кадәрге чорны автор икегә бүлеп карый. Беренчесе — совет властеның тәүге айлары матбугаты. Бу чорда матбугатның күмәк пропагандистлык вазифасы алгы планга чыга. Бу хәл совет власте идеяләрен, аның декретларын һәм күрсәтмәләрен төшендерү, пропагандалау, хезмәт ияләрен яңа властьның асылы, структурасы белән таныштыру зарурлыгы белән аңлатыла. Икенче чор — гражданнар сугышы еллары, Коммунистлар партиясе һәм совет дәүләте бөтен хезмәт халкын эчке һәм тышкы дошманнарны тар-мар итүгә туплаган бер вакытта матбугат органнарының пропагандистлык эшчәнлеге, автор фикеренчә, тиз үзгәреп тора торган тормыш вакыйгаларын публицистик анализ аркылы үткәрү формасында бара. Автор газеталарда басылган материалларның сыйфаты яхшыру, хәбәрчеләрнең һәм журналистларның профессиональ осталыгы үсү процессын күзәтә, бу процесста Галимҗан Ибраһимовның ролен ачып бирә, аның катлаулы һәм киеренке иҗтимагый тормыш мәсьәләләрен аңлауда яшь журналистларга һәм язучыларга ярдәм итүен күрсәтә.

Хезмәттә аерым төбәкләрдә чыга торган газеталар үзәк газеталар белән чагыштырылып өйрәнелә. Гражданнар сугышы чоры газеталарын барыннан да элек тема һәм максат уртаклыгы берләштергән. Алар арасындагы аерма — вакыйгаларны

яктыртуның оперативлыгында, журналистлык осталыгында, жанрлар составында гына диярлек.

Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә яшь Совет дәүләтенең тыныч төзелешкә, җимерелгән халык хуҗалыгын аякка бастыру чорына керүе һәм бу чорда матбугат органнарының эшчәнлеге аерым бүлектә карала. Анализдан күренгәнчә, татар матбугаты бу елларда экономик төзелеш проблемаларына йөз белән борыла, массаларны экономик яктан тәрбияләү, иҗади хезмәткә туплау, төрле милләт һәм халыкларның мәнфәгатьләре уртаклыгы, сыйнфый бердәмлек, пролетар интернационализм һәм халыклар дуслыгы темалары үзәк урынны ала.

Монографиядә газеталарның эшче-крестьян массалары белән элемтәсе, елдан-ел киңәя барган эшче һәм хәбәрчеләре хәрәкәте өйрәнелә. Совет матбугатын үстерүдә, аның халыкчанлыгын тәэмин итүдә әлеге хәрәкәт гаять зур урын тота. Матбугат халык массалары тормышына торган саен тирәнрәк үтеп керә, хезмәт ияләрен җәмәгать эшләренә, дәүләт белән идарә итүгә тарта. Бу эштә партия оешмалары һәм газета редакцияләре күп төрле алымнар һәм формалар кулланды. Автор әнә шул форма һәм алымнарны барлый, кайберләренең бүгенге көндә дә яшәргә хаклы икәнлеген исбатлый.

Хезмәттә журналистлык осталыгы мәсьәләләренә, газета материалларының жанр үзенчәлекләрен тикшерүгә зур урын бирелә. Конкрет мисаллар җирлегендә автор татар совет публицистикасының газеталардагы барлык жанрларны — һәм аналитик, һәм художестволы-публицистик төрләрне — беренче чордан ук уңышлы үзләштергәнлеген күрсәтә. Әлеге еллар публицистикасының дәрәҗәсен аның Ленин темасына мөрәҗәгать итүе һәм бу өлкәдә беренче уңышлы адымнар ясавы да раслап тора. В. И. Ленинга илле яшь тулу уңае белән, аннары ул вафат булгач, газеталарда аналитик материаллар белән беррәттән, художестволы-публицистик жанрларда иҗат ителгән әсәрләр дөнья күрә. Татар телендәге лениниананы тудыру һәм үстерүгә «Кызыл Армия», «Эшче», «Эш» газеталарында Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи-Казанлы, И. Кулиев, К. Әмири һәм башкалар зур хезмәт куялар. Монографиядә бу эш конкрет мисалларда бәян ителгән.

Рецензияләнә торган хезмәтнең яңа бер әйбәт сыйфатын — аның тиешле белешмәләр белән тәэмин ителүен әйтеп үтәргә кирәк. Белешмәләрдә теге яки бу вакыйга, шул заманның матбугат органнары, күренекле журналист һәм культура эшлеклеләре турында өстәмә мәгълүматлар бирелә.

Әлбәттә, бер монографиядә матбугат кебек катлаулы һәм бай идеология эшенең барлык якларын да колачлап бетерү мөмкин түгел. Шулай да автор, татар матбугаты белән беррәттән, рус һәм башка телләрдәге матбугатның барлыкка килү юлларына да күз салып, уртак һәм аермалы якларны чагыштырып өйрәнсә, әлеге процесс янә дә тулырак, колачлырак булып алга килеп баскан булыр иде дигән фикер туа. Эш шунда ки, безнең якта, рус һәм татар телләрендәге матбугат белән бергә, башкорт, чуваш, мари, удмурт телләрендә дә совет матбугаты барлыкка килгән бит. РКП (б) ның Үзәк һәм Казан губерна комитетлары бер үк мәсьәләләрне хәл иткәндә төрле телләрдәге матбугат органнарыннан да оста файдаланганнар. Милли матбугат системасын булдыру һәм үстерү культура революциясен тормышка ашыру һәм милли политиканы үткәрүнең бер нәтиҗәсе һәм чарасы да ул.

Китапны укыганда анда тупланган бай материалны теоретик яктан тагын да киңрәк гомумиләштерү, тирәнәйтү кирәклеге дә сизелә.

Тулаем алганда, Р. Нуруллина матбугатыбыз тарихын өйрәнүгә җитди өлеш булырлык хезмәт язган.

**РИНАТ НӘБИЕВ,**
**Казан дәүләт университеты аспиранты.**

Туфан Миңнуллин

# ВӘХШИЛӘР

ЭТЮД

„Ижминводы» санаториенда ял итәм. Шифалы су эчәм, дәваланам, Кама ярында табигать матурлыгына сокланып йөрим. Сул ягымда — исеме риваятьләрдә еш телгә алынган елга, елга аръягында — болын, уң ягымда — текә яр, яр өстендә— агачлар. Кайбер урыннарда яр кырт киселгән — таш стена. Төрле төстәге ташның үз матурлыгы бар. Ләкин кемнәрдер бу матурлыкны язу тактасы иткәннәр. Акбур белән дә, буяу белән дә үзләренең исемнәрен язганнар, ике исем уртасына + билгеләре куйганнар. Шактый ук оятсыз сүзләр дә язылган ул ташка. Вәхшилек!

Көрсенеп, авыр сулап, арырак атладым һәм вәхшиләрнең үзләренә тап булдым. Ике егет, бер кыз. Төс-кыяфәтләрен сурәтләмим, чөнки синнән-миннән әллә ни аерылып тормыйлар.

Бер егет икенчесенең җилкәсенә баскан да, сул кулындагы буяу банкасына уң кулындагы пумаланы манып, кызыл ташка ак буяу белән исемнәр яза. Кыз читтән карап ләззәтләнеп көлә. Каян буявын тапканнар да, ничек пумаласын юнәткәннәр. Югыйсә, кибетләрдә дә алар еш булмый бит!

Менә, ниһаять, язу әзер:

«Юра—Аля+Фарид= от Юры алименты».

Беренче егет икенчесенең җилкәсеннән сикереп төште дә, беравык үзенең иҗатына сокланып карап торды. Аннан буш банканы пумаласы белән бергә Камага ыргытты. Өчәүләшеп көлештеләр.

Курка-курка гына яннарына килдем. Курыкмаслык та түгел: егетләрнең икесе дә дага сындырырлыклар. Буяу банкасын ыргыткан кебек, мине дә Камага тондырулары бик мөмкин. Чөнки алар вәхшиләр, кыргыйлар. Ә вәхшиләр уйлап-нитеп тормый.

Шулай да тәвәккәлләдем, беткән баш беткән, мәйтәм.

— Сез, егетләр, ни эшләгәнегезне белеп эшлисезме?

Өчесе дә аптырап, гаҗәпләнеп миңа карадылар. Янәсе, каян килеп төште бу бөҗәк?!

— Сез матурлыкны пычратуыгызны аңлыйсызмы? Юк, мин сезне гаепләп әйтмим, сорыйм гына, беләсем килә. Бәлки сез, чынлап та, аңламыйсыздыр, сезне аңа өйрәтмәгәннәрдер. Алайса, мин сезгә аңлатыйм...

Мин аларга табигать матурлыгы, кешенең матурлыгы турында озаграк сөйләдем бугай, баштарак гаҗәпсенеп тыңласалар да, соңрак ялыктылар. Егетләрнең берсе икенчесенә:

— Бу картлач эстетика укыта, ахры, — диде.

Икенчесе:

— Юк, минемчә, ул психиатрия больницасыннан качкан, — дип куйды.

Кыз көлде. Минем ачуым чыкты.

— Сез, сез беләсезме кемнәр? Сез — кыргыйлар, сез — вәхшиләр! — дип кычкырдым.

Тагын өчәүләшеп көлделәр.

Берсе:

— Фәрит, аңлат әле шуңа вәхшиләрнең кем икәнлеген, — дигәч, куырылып килдем, сугып егуын көттем.

Әмма ул сукмады, теле белән аңлатты:

— Без сезне тыңладык, картлач, инде безне тыңлагыз, — диде.— Борын-борын заманнарда, сезнең бабаларыгызның бабалары ыштансыз-күлмәксез шыр ялангач йөргән вакытта, Аристотель, Конфуций, Гераклит, Демокрит, Платоннар булмаган чакта җир өстендә кыргыйлар, вәхшиләр яшәгән. Алар кыяларга, ташларга хайван, кош һәм кеше сурәтләре ясаганнар. Бүгенге көн галимнәре хәзер ул кыргыйларга рәхмәт укыйлар, чөнки шуларга карап алар борын-борын-борын заманнарны өйрәнәләр. Үтәр йөз, мең еллар, сезнең кебек матурлыкны аңлаучы цивилизацияле кешеләрнең кәгазьгә язган сүзләре юкка чыгар, чөнки кәгазьнең гомере кыска, ә менә без язган бу язу — калыр! Шуңа карап киләчәк галимнәре бүгенге җәмгыять тормышын өйрәнерләр. Әһә, диярләр, әгәр дә Юра белән Аля өйләнешсәләр, балалары булса, аннан Аля Юрадан аерылып Фәриткә кияүгә чыкса, Юра барыбер алимент түләргә тиеш булган икән, диярләр. Тарихмы бу? Фәнме? Төшендегезме вәхшилекнең бик кирәк нәрсә икәнен? Кем өйрәтте дип сорасалар, дүртенче курс студентлары өйрәтте дип әйтегез.

Ике егет, бер кыз көлешә-көлешә китеп бардылар. Нишләргә, ни әйтергә белми басып калдым.

— Эх, вәхшилекнең ни икәнен тел белән әйтмичә, йодрык белән аңлатсалар, сугып ексалар, Камага тотып атсалар, җиңелрәк булган булыр иде!

## Кәшфелзадә

### Йокысыз төн

Тышта буран акылыннан язган,
Атна була бугай кимендә...
Авылымнан китә алмый ятам...

**Роберт Миңнуллин.**

Буран йөрде Сөн буенда —
авылда;
Тәрәзәмә кар куллары
кагыла...
Бер юл язалмаган моңсыз
чагымда
Кешнәү тавышы ишеттем мин
урамда.
...Әллә Пегас калган бүген
буранда?
Әллә аранын ватып ул
чыкканмы?
Күктә Ай күренми — шуннан
куркамы?

Кешнәү тынды, ни өркетте
Пегасны?
...Кем сызгыра? Ул аны урлап
суймасмы?
Атның ал канымы тышта? —
...Таң атты.
Әнкәй торып бик иртәдән
мич якты.
Өшәнгәндер, алып керик
Пегасны!

### Урта кеше фәлсәфәсе

Юаш булсаң басарлар,
Усал булсаң асарлар.
Урта гына кеше булсаң,
Ил агасы ясарлар.

**Халык җыры.**

Әллү, дөнья, бәллү, дөнья,
Тирбәт мине, яшәт...
Әлегә мин риза синнән:
Биргәнеңә —
Рәхмәт!

Әйтә алмыйм кан койдым дип,
Тир түктем дип рәтләп.
Даным да, медалем дә юк,
(Салкында туңганым да юк!)
Ә бик рәхәт... Рәхмәт!

Кем керәште — көне узды
Ыгы-зыгы белән яшәп:
Тапты шан, я нәфрәт...
Акыл белән гомер кичтем —
Алдым бары рәхмәт.
Янды берәү, батты берәү...
Мөхәммәт я Әхмәт.
Минем хәл шәп: тапкан анам,
Рәхмәт сиңа, рәхмәт!

...Әллү, дөнья, бәллү, дөнья,
Тирбәт, озак яшәт.
Бар да матур, бар да әйбәт:
Җылы, бәхет, рәхәт.
Рәхмәт! Рәхмәт!

## Йокла

Йоклыйсыңмы, ә, илһамым?
Син, шигырем?
Йокла!
Тирә-юнең тып-тын ласа,
Шау-шу, тавыш юк ла. —
Йокла!

Йокы — иске, изге бер эш,
Бабайлардан йола.
Шагыйребез кабатлаган:
«Йокы, йокы...»
— Йокла!

Дөньясында ни бар, анда
Кемнәр ялкын-утта,
Сизмә берни, белмә, каләм,
Кыймылдама, йокла!
Бул бөек бер битараф син,
Борчу, гамең юк ла.
Төшең матур: кызлар иле,
Гөлләр туе...
Йокла!

Йокла, илһам!
...Әй, карәле,
Мәрткә үк син китмәдеңме?
Исәнме син, тукта!
...Тәнкыйтьтән соң ял итәмсең?!
Алай гына булса
Ярый, туган, йокла!
Йокла!

## Идрис Туктар

### ЕГЕТ БЕЛӘН КЫЗ

Егет, кызның уң битеннән үбеп:
— Уң колагыңа бер сүз әйттем, ишеттеңме? — диде.
— Юк,— диде кыз.
Егет, аның сул битеннән үбеп:
— Сул колагыңа бер сүз әйттем, ишеттеңме? — диде.
— Юк, — диде кыз.
Егет, аның иреннәреннән үбеп:
— Ишеттеңме инде, сандугачым? — диде.
— Күптән шулай диләр аны, карлыгачым! — диде кыз.

### ПЕНСИОНЕРЛАР СӨЙЛӘШӘЛӘР

— Доктор, мин нилектән авырый белмим икән?
— Яши белгәнгә күрә.

●

— Күрше, нихәл! Ни дип болай бер үзең генә балтаңны суга төшереп утырасың?

— Соң ни, гомер уза, кием туза, ә тунны сакларга кирәк.

●

— Былтыр кысканга быел эчемнән генә сине гаепләп йөримен. Ниһаять, хәзер синнән гафу үтенмәкче булдым. Дустым, зинһар гафу ит мине!

— Тапкансың эш! Эчеңнән генә гаепләвеңдә синең белән миңа — ни файда, ни зарар?

— Файдасы юкның зарары күп: күңелеңдә җыела-җыела килгән ачулар, тышка ташып чыгып, һичбер гаепсез кешеләргә барып тия.

●

— Мин көненә 5—6 стакан гына эчәм.
— Китче?!. 70 кә җитсәң дәме?
— Мин сиңа чәй турында сөйлим лә!..

●

— Егет чагымда мин кызлардан кача идем, хәзер кызлар миннән качалар.

●

— Сине өйләнергә җыена дип сөйлиләр, дөресме? Акылыңнан шашмыйсыңдыр ич?

— Бик шашар идем дә бит, башта шашарлык акылның үзен булдырасы бар шу-у-л!..

●

— Бер япь-яшь кызга өйләндем, малай, котла үземне!

— Әйтәм җирле бик боек күренәсең!.. Туфрагың җиңел булсын!..

## Җөмләләр

●

Кешеләр үлсәләр дә яшиләр, үлмәсәләр дә яшәмиләр.

●

Кешене тактсызлыкта гаепләгәндә дә тактсызланма.

●

Егет кешегә җитмеш җиде уй да аз, бер туй да җиткән.

●

Яраткан эшең, кайгырткан кешең булмаса — үл генә!

●

— «Жигули»ем җигүле, — ди-ди торгач, үзең тугарылып калма.

●

Тырнаклары кып-кызыл, күңелләре кап-кара: һич кайгыртмый уңны-сулны — упкынга төшеп бара.

●

Комың коелып беткәндә дә комсызланма.

# КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИН



Әдәбиятта вакыйга дип әйтерлек хәлләр була. Кадыйр Сибгатуллин безнең әдәбиятка гадәти хәл булып кына түгел, вакыйга буларак килеп керде. Күтмәгәндә-уйламаганда аның үзенә түгел, газеталардагы шигырьләренә очрадым. Иң беренче сүзләрендә үк миндә: «Менә бу шагыйрь, тумыштан шагыйрь!» — дигән шатлык туды. Утызынчы еллар ахырында Мостай миндә шундый ук гаҗәп шатлык һәм кабатланмас соклану тудырган иде. Кадыйр, Г. Бәшир һәм М. Әмир кебек үк, сүзнең җанын, бәгырен, аһәңен, мелодия мәгънәсендәге моңын бик үткер сизә. Кадыйрның бу хасиятенә шигырьнең ритмик сүз булуы да катнаша. Аның шигырьләре безнең телнең менә нинди потенциаль мөмкинлекләре бар икән дигән хис тудыра.

Такташ:

**Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә,**
**һәрбер йөрәк аны яңарта...**

— дип әйтеп киткән иде. Кадыйр исә Такташны кабатламый гына бу канатлы шигырьнең дәвамын әйтеп бирде:

**Кама ярларында эзлим сине,**
**Дулкын өсләрендә — куләгәң.**
**Мәхәббәтне юк дию че булса,**
**Андый кеше сине күрмәгән!**

Бу да мәхәббәт дигән бөек хис турындагы канатлы сүз бит (мәхәббәт — любовь кына, сөю-ярату гына түгел ул!).

Кадыйр чын мәгънәсендә Татарстан шагыйре:

**...Кырларым күмелгән рәшәгә.**
**Җырчы да, шагыйрь дә булма дн,**
**Монда ту, монда үс — яшә дә!**

Туган телнең серләрен сизү шундый нечкә ки бу шагыйрьдә, аны башка телләргә күчереп тә булмый кебек; Тукай әйтмешли, туган телдәге алтыннары коелып калыр кебек тоела.

Егерме-утыз җыентык чыгарып та бер генә чын шигъри сүз әйтә алмаган шагыйрьләр байтак. Бер генә җөмләсе белән гадәттән тыш шагыйрь икәнен раслаган

яшьләр бар. Кадыйр — шундыйларның берсе. Аның тыгыз, киң мәгънәле шигырьләрен укып, үтеп кенә китеп булмый, ул туктата, уйландыра:

**Киләчәк барын бар,**
**Бу көннәр юк анда.**

(Беренче юлдан соң «ләкин» сүзе дә булырга тиеш иде. Автор аны төшереп калдыра, чөнки ул сүздән башка да бу ике юлдагы тирән мәгънә бик ачык аңлашыла). Бу бит асылда диалектик фәлсәфәнең — «бер кергән агым суга икенче кабат кереп булмый» дигән фикернең, вакыт һәм пространство — материянең яшәү формасы ул дигән фәлсәфи фикернең шигъри әйтелеше бит!

Кадыйр Сибгатуллин башкалардан аерылып торган чын шагыйрь буларак та, зирәк, акыллы шәхес буларак та безнең Равил Фәйзуллинны хәтерләтә. Поэзиягә килү адымнарын мәктәптә үк бергә башлаганнар алар. Безнең әдәби дөньябызда да аларның бергә булуларын, кулга-кул тотынышып яшәүләрен күрәсем килә.

ХӘСӘН ТУФАН

# ФӘННУР САФИН



Фәннур Сафин әдәбиятыбызга 1970 нче елларда килде. Ул чагында әле яшь шагыйрь Казан университеты студенты иде. «Казан утлары» журналы редакциясендә шигърият бүлеге мөдире булып эшләгән чагымда Фәннур беренче тапкыр редакциябезгә аяк басучылардан берсе булды.

Яшь авторның шигырьләре инде шул вакытта ук игътибарга лаек иде. Соңгарак ул активрак яза, редакциягә ешрак һәм кыюрак килә башлады.

Аның шигырьләре, хәзерге яшь шагыйрьләребез иҗатына хас булганча, үзенчәлеге, оригиналлыгы белән шатландырды. Икмәк һәм игенчеләр турындагы хезмәт батырлары образларын чагылдырган шигырьләре янында яшьлек романтикасы белән канатланган интим һәм гражданлык лирикасы шигырьләре дә, тирән кичерешләр, фәлсәфи уйланулар да яшь шагыйрь иҗатында күзгә ташланалар иде инде.

Аның: «Кайт», «Яшь тай», «Нинди озын юл бу — гомер!..», «Бер адым», «Кеше юлга чыкса» дигән шигырьләре белән бергә, шулар кебек үк тагын бик күп уңышлы әсәрләрен санап китәргә мөмкин булыр иде.

Фәннур Сафинның үз талантын тагы да үстерүдәге, шигъри осталыкка ирешүгә омтылудагы тырышлыгы анык күренеп тора. Ул һәр вакыт әзләнә һәм хадисәләрне шигырьдә сәнгатьчә тасвирлап бирү чараларын, формаларын табуны, үзләштерүне үзенә таләп итеп куя. Төрле темаларны бәянлап бирүдә еш кына кызыклы, ә кайчакта көтелмәгән ачышлар ясый. Моны дәлилләп, Татарстан китап нәшрияты тарафыннан 1976 елда чыгарылган аның беренче китабы «Кеше юлга чыкса»ны күрсәтергә мөмкин.

Фәннур Сафин үсә торган, өметле, талантлы шагыйрь. Аңа яңадан-яңа уңышлар, иҗат шатлыгы, ак юл телибез.

НУРИ АРСЛАН

# ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ



Фатих Урманчеев — галим-язучы. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре буенча аны актив тәнкыйтьче диярга була. Ләкин хезмәтләренең эченә тирәнрәк кергән саен, аның төп өлкәсе халык иҗаты икәнлеге ачыла бара. Төп өлкәсе, яратып эшләгән, иң нык өйрәнгән өлкәсе. Бу темага диссертация язганы өчен генә түгел, хезмәтләренең характерыннан, рухыннан чыгып әйтәм бу фикерне.

Фатих Урманчеевка кадәр бу өлкәдә эшләүчеләр элек тә булган. Элек тә дигәнем революциягә хәтле үк. Бөек Ватан сугышы алдыннан һәм аннан соң, кимендә утыз-кырык ел буена Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Хәмит Ярми, Афзал Шамов кебек язучылар, галимнәр татар халык иҗатын җыюда, туплауда, дөньяга чыгаруда зур эш эшләделәр. Яшьләргә шулар әйбәт җирлек тудырдылар. Фатих Урманчеевның таланты язучы буларак, галим буларак шул нигез-җирлектә үсеп китте, җәелеп китте. Хәзер аның ике зур хезмәте бар: «Бәетләр турында монография» (8 табак), «Татар халык эпосы» (17 табак). Болар арасында бигрәк тә «Легендалар әзеннән» (бәет жанрының туу һәм формалашу тарихына карата), «Халыкның күңел көзгесе», «Тарихи җырлар», «Совет чоры бәетләре» кызык. Галим Болгар чорыннан алып хәзерге көнгә чаклы сузылган юлны күздән кичереп, дөнья хәтле материалны тарихи-фәнни анализлап, тикшереп, яңадан безгә бербөтен хәлендә, гомумиләштерелгән хәлендә күрсәтүне үз алдына максат итеп куя шикелле. Хезмәтләрен укыгач шундый фикер туа, шундый хис туа. Шушы тирәнлеккә үтеп керү өчен, колачлау һәм җыеп әйтү өчен белем һәм эрудиция өстенә тагын бер сыйфат кирәк дип уйлыйм. Ул үз халкының тарихына, культурасына булган зур мәхәббәт, аның иксез-чиксез рухи байлыгы белән горурлану хисе. Фатих Урманчеевның халык иҗаты турындагы мәкалә, монографияләре күңелдә менә тагын нинди хис уята. Язучының осталыгы турында сүз барганда иң шәп критерий шушы.

СИБГАТ ХӘКИМ.

# САИМӘ ИБРАҺИМОВА



Саимә Ибраһимова хезмәт юлын Татарстан китап нәшриятында редактор булып башлаган кеше. Шул елларда ук, балалар өчен язылган китапларны редакцияләү белән бергә, русчадан тәрҗемәләр дә иткәли иде.

Соңыннан, тора-бара, аның бу мавыгуы иҗат эшенә әйләнде.

Нәшрияттан, «Яшь ленинчы» газетасына килеп, анда җаваплы секретарь булып эшли башлагач, Саимә балаларга тагын да якынайды. Балаларның үзләренә генә хас тормышы белән бергә, аларның холыкларын, сөйләү үзенчәлекләрен зур сизгерлек белән өйрәнә башлады.

Әмма тәрҗемәчегә болар гына җитми иде. Ул алган китапларның авторлары төрле чор әдәбия-

тыннан, характерлары төрле-тарихи, тарихи революцион, фәнни-популяр, мажаралы әсәрләр булганлыктан, аңа иҗтимагый һәм фәнни белемен үстерүдә туктаусыз эшләргә туры килде. Мәсәлән, С. Григорьевның «Александр Суворов» китабын шул чорның тарихи шартларын, этнографиясен, хәрби терминнарны һ. б. яхшылап белми торып тәрҗемә итү һич мөмкин түгел иде. Китапның укучылар тарафыннан яхшы кабул ителгән тәрҗемәсе Саимә Ибраһимованың зур тырышлыгы хакында сөйли.

**ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА.**

# РАВИЛ БОХАРАЕВ



Соңгы 3—4 елда Равил Бохараев исеме Татарстанның (һәм Татарстанның гына түгел) әдәби җәмәгатьчелеге һәм шигырь сөючеләре игътибарын үзенә җәлеп итте. Дөрес, аның шигырьләре матбугатта элегрәк тә күренә башлаган иде, ләкин Равил шагыйрь буларак нәкъ менә соңгы 3—4 елда өлгерде. Моның үз сәбәпләре бар. Беренчедән, Равил бу елларда тәмам балигъ булып җитте — Казан дәүләт университетын математик буларак тәмамлап чыкты, инде менә шул ук белгечлек буенча Мәскәү дәүләт университеты каршындагы аспирантураны тәмамлый. Димәк, Равил инде хәзер тормышка һәм шигърияткә җитди карый торган олы кеше һәм менә шушы җитдилек Равилнең нык тырышлыгы белән кушылып, аның шигырьләрен дә җитлеккәнрәк, профессиональрәк итә барды. Һәм, чыннан да, нәкъ шушы елларда аның шигырьләре үзәк матбугат битләрендә торган саен еш күренә башлады, ә 1977 елда Татарстан китап нәшрияты аның беренче шигырь җыентыгын бастырып чыгарды.

Равилнең беренче китабы ук укучы арасында зур кызыксыну уятты. Минем төрле яшьләрдәге, төрле профессия кешеләре булган шигырь сөючеләр авызыннан Равилнең бу китабы турында мактау сүзләре ишеткәнем бар. Алар шагыйрьнең иҗаты җитди булуын, шигырьләренең гади һәм буш булмавын, гражданлык хисләренең тирән шигъри образлар ярдәмендә бирелүен, гомумән, шигырьләрнең үзенчәлекле, яңа төр шагыйрь тарафыннан язылганлыгын әйтәләр. Шунысы кызык, күп кенә яшь шагыйрьләрнең иҗатын теге яки бу дәрәҗәдә, теге яки бу классик шагыйрь иҗатына якынлаштырып, чагыштырып була. Ә менә Р. Бохараев иҗатын бер шагыйрь белән дә чагыштырып булмый — ул үзенчә бер шагыйрь.

Инде рус телендә язучы шагыйрь буларак, Равил Бохараев иҗатының тагын бер ягын, безнең Татарстан өчен әһәмиятле булган бер эшчәнлеген дә әйтеп китәргә кирәк — ул татар поэзиясен оригиналдан тәрҗемә итүче дә. Аның тәрҗемә иҗаты шулай ук игътибарга лаек. Г. Тукай, М. Җәлил кебек классикларыбызның һәм байтак кына бүгенге шагыйрьләребез әсәрләренең Равил тәрҗемәсендә үзәк матбугатларда басылып чыгуы әнә шул турыда сөйли.

**ГӘРӘЙ РӘХИМ.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ — ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ

КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросы һәм ТАССР Министрлар Советы карары белән Г. Тукай исемендәге республика премиясе Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе дип үзгәртелде. Комитетның түбәндәге яңартылган составы расланды:

М. Х. Хәсәнов (председатель), И. Н. Алиев (председатель урынбасары), Г. С. Сабиржанов (секретарь), Ш. Р. Агеев, С. С. Айдаров, И. Н. Алексеев, М. М. Әмиров, Г. А. Ахунов, Ш. Х. Биктимеров, Ю. М. Воронин, Н. К. Даутов, Н. Г. Жиһанов, Р. А. Жиһаншина, А. Г. Кадыйрова, А. С. Миндубаев, М. М. Мусин, М. К. Мөхәррәмов, Ф. Г. Надиров, З. Ш. Нуретдинов (Зәки Нури), Г. А. Паушкин, М. М. Танишев, Ә. И. Тумашев, Ю. С. Федотов, И. Ш. Хәкимова, Ш. Х. Хамматов, Р. А. Шәмсетдинова, Ю. Б. Щелыванов, Х. А. Якупов, М. З. Яруллин.

## Г. КАМАЛНЫҢ 100 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ ХӨРМӘТЕНӘ

Шушы елның 5 январенда Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрында татар әдәбияты классигы, драматург, шагыйрь, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Галиәсгар Камалның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Кичәне кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Гариф Ахунов ачты. Галиәсгар Камалның тормышы һәм иҗаты турында ТАССР культура министры И. Н. Алиев сөйләде.

Тантаналы кичәдә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, КПССның өлкә комитеты икенче секретаре В. С. Дергунов, КПССның өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре Р. М. Мусин, профсоюзларның Татарстан өлкә советы председателе С. Г. Сафин, ВЛКСМның өлкә комитеты беренче секретаре Ш. Р. Агеев, КПССның өлкә комитеты бюросы членлыгына кандидат Социалистик Хезмәт Герое Г. Ә. Әсхәдуллин катнашты.

Соңыннан Татарстан сәнгать осталары катнашында зур концерт булды, Г. Камал әсәрләреннән өзекләр күрсәтелде.

* * *

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының конференц-залында фәнни конференция булды. Анда галимнәр, язучылар, сәнгать эшлеклеләре катнашты. Юбилярның күп кырлы иҗади эшчәнлеге турында профессор М. К. Мөхәррәмов, өлкән фәнни хезмәткәрләр А. Г. Әхмәдуллин, Б. Гыйззәт, профессор И. Г. Нигъмәтуллина һәм Казанның башка галимнәре докладлар ясады.

Фәнни конференциядә КПССның өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

* * *

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрында Галиәсгар Камалның «Банкрот» исемле музыкаль комедиясе буенча эшләнгән яңа спектакль премьерасы күрсәтелде. Әсәрне сәхнәгә ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Празат Исәнбәт куйган, рәссамы — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай премиясе лауреаты Энәс Тумашев. Спектакльгә музыканы Фуат Әбүбәкеров язган, биюләрне Татарстанның атказанган артисткасы Анна Гацулина әзерләгән.

* * *

Казан театр училищесы студентлары драматургның «Беренче театр» пьесасы буенча спектакль куйдылар. Әсәрне Празат Исәнбәт сәхнәләштергән. Спектакль юбилей көннәрендә — данлы датага багышланган тантаналы кичәдә күрсәтелде. Кичәдә шулай ук Г. Камалның шигырьләре дә яңгырады. Драматургның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турында сәнгать фәннәре кандидаты Х. Кумысников сөйләде.

## ШАМИЛ УСМАНОВНЫ ХӨРМӘТЛӘҮ КИЧӘСЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында танылган татар совет язучысы, күренекле хәрбиполитик эшлекле Шамил Усмановның тууына 80 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Анда партия, совет, җәмәгать оешмалары, хезмәт коллективлары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлекләләре, сугыш һәм Совет Армиясе ветераннары, әдәбият сөючеләр катнашты.

Кичәне кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты. Ш. Усмановның тормышы һәм иҗаты турында филология фәннәре кандидаты Альберт Яхин сөйләде.

Тантаналы кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

### ЯЗУЧЫ ТУГАН АВЫЛДА

Күренекле дәүләт эшлеклесе, ялкынлы публицист һәм язучы Шәһит Әхмәдиевнең тууына 90 ел тулуны республикабыз җәмәгатьчелеге киң билгеләп үтте. Чистай районы, Татар Ялтаны авылында ул аерүча зур җанлылык белән узды. Чөнки Ш. Әхмәдиев шунда туып-үскән, мәктәп салдыруда башлап йөргән. Олы юбилей уңае белән язучы туган авылда зур кичә булды. Анда Ш. Әхмәдиевнең тормыш һәм иҗат юлы турында доклад сөйләнде. Аннары укучылар язучының әсәрләреннән өзекләр укыдылар.

### ЯҢА ГАЗЕТА

Яңа елның беренче көнендә рус телендә «Кичке Казан» («Вечерняя Казань») газетасының беренче саны чыкты. Ул казанлыларны һәм Казан кунакларын башкалабыз тормышы белән даими таныштырып барачак.

### ЕГЕРМЕ ЕЛЛЫККА БАГЫШЛАП

Мәскәүнең П. И. Чайковский исемендәге концерт залында РСФСР Язучылар союзының пленумы булып узды. РСФСР Язучылар союзы оештырылуга 20 ел тулуга багышланган пленумга күп милләтле Россия әдәбиятының күренекле вәкилләре җыелды. Татарстаннан Сибгат Хәким, Афзал Шамов, Зәки Нури, Атилла Расих, Әдип Маликов, Равил Фәйзуллин һәм Лирон Хәмидуллин катнашты. Бу форумда КПССның XXV съезды карарлары яктылыгында әдәбият һәм тормыш дигән темага С. Михалков доклады буенча фикер алышулар үткәрелде. Анда берничә ел РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре булып эшләгән шагыйрь С. Хәким чыгыш ясады.

### КОНКУРСЛАР

* * *

ВЛКСМның өлкә комитеты һәм «Ялкын» журналы, Татарстан комсомолының 60 еллыгына багышлап, иң яхшы шигъри әсәрләргә ябык конкурс игълан итте. Конкурсның девизы — «Комсомолда туганнар».

Конкурска җибәрелгән әсәрләр (шигырьләр, шигырь бәйләмнәре, поэмалар һ. б.) Татарстан комсомолының бай тарихын, бүгенгесен, данлы эшләрен күпьяклап тасвирларга, үсеп килүче яшь буында пролетар интернационализм, патриотизм, Коммунистлар партиясе эшенә чын күңелдән бирелгәнлек хисләре тәрбияләргә тиеш.

Конкурс 1979 елның ахырына кадәр дәвам итәчәк.

Җиңүчеләрне түбәндәге премияләр көтә: беренче (бер) — 100 сум, икенче (бер) — 75 сум, өченче (бер) — 50 сум.

* * *

ВЛКСМ өлкә комитеты, Республиканың тынычлыкны яклау комитеты һәм «Яшь ленинчы» газетасы редакциясе балалар өчен иң яхшы хикәяләргә һәм пьесаларга ачык **конкурс** башлап җибәрде. Конкурста катнашучыларның әсәрләре түбәндәге темаларга багышланырга тиеш: пионер отрядлары, кызыл эзтабарлар, тимурчылар, «Аҗаган» уены, табигатьне саклау, укучыларның хезмәт бригадалары, тынычлык өчен көрәш, малайлар белән кызлар арасындагы дуслык, интернациональ дуслык, социалистик җәмгыять тәртипләрен бозучыларга каршы көрәш һ. б.

Хикәяләрнең һәм бер пәрдәле пьесаларның күләме — машинкада басылган 7 биттән алып 17 биткә кадәр. Күп пәрдәле пьесаларның күләме 10 биттән алып 30 биткә кадәр.

Конкурс 1979 елның 20 нче октябренә кадәр дәвам итә.

Җиңүчеләргә түбәндәге бүләкләр биреләчәк:

Иң яхшы хикәяләр өчен: беренче бүләк — 250 сум, икенче бүләк — 100 сум, өченче бүләк — 75 сум.

Иң яхшы пьесалар өчен: беренче бүләк — 250 сум, икенче бүләк — 150 сум, өченче бүләк — 100 сум.

### МОНГОЛИЯ КУНАГЫ КАЗАНДА

Монголия Халык Республикасының Мәскәүдә «Тәрҗемә өлкәсендә яңа уңышлар» дигән халыкара симпозиумда катнашкан язучысы Шугэр Цэрэндуламын Казанда булып китте. Беренче тапкыр ул Казанда 1976 елның көзендә булган иде.

Шугэр монгол укучысының татар әдәбияты белән таныш булуы турында сөйләде. Герой-шагыйрь Муса Җәлил әсәрләре әдипнең тууына 70 ел тулу уңае белән монгол телендә басылып чыккан, хәзер аның икенче тулырак басмасы чыгачак. Монголия Язучылар союзы тәкъдиме белән күренекле татар әдибе Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повесте монгол теленә тәрҗемә ителә.

Шугэр — филология фәннәре кандидаты. Хәзерге көндә «Иске язулы монгол китабы» дигән темага докторлык диссертациясе өстендә эшли. Аның Казанга килүенең төп максаты да үзенең гыйльми эшчәнлегенә бәйләнгән иде. Монгол галиме Казан университетында XIX йөздә монголистика фәненең үсеше, монгол теле буенча эшләгән профессор О. М. Ковалевский, А. В. Попов хезмәтләре белән, Казанда монгол телендә басылып чыккан китаплар белән, Казан матбагачылыгы тарихы белән танышты, татар галимнәре белән очрашты, театрларда булды.

### ЕЛЛЫК ПРЕМИЯЛӘР

Шагыйрь Равил Фәйзуллинга 1978 елда «Литературная Россия» газетасында басылып чыккан «Күкләр биек» исемле шигырьләр циклы өчен редакция бүләге бирелде.

* * *

Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин «Литературная газета»да басылып чыккан тәнкыйть мәкаләләре өчен шулай ук газетаның еллык премиясенә лаек булды.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

* * *

Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы ачык җыелышы шагыйрь Ренат Харис иҗатын тикшерүгә багышланды. Филология фәннәре докторы Н. Г. Юзиев докладында Р. Харисның татар совет поэзиясенә алтмышынчы елларның уртасында аяк басуын һәм җитмешенче еллар поэзиясендә төпкә җигелеп тартучы шагыйрьләрнең берсе булып өлгерүен билгеләп үтте. Җыелышта Ренат Харис үзенең иҗат планнары турында язучылар алдында хисап бирде, рус һәм татар телләрендә шигырьләрен укыды. Фикер алышуларда Гариф Ахунов, Сибгат Хәким, Риза Ишморат, Нәби Дәүли, Ринат Мөхәммәдиев катнашты.

* * *

Проза секциясенең отчет-сайлау җыелышында ике еллык эш турында отчетны секция бюросы секретаре Марсель Галиев ясады. Фикер алышуларда Гариф Ахунов, Фарваз Миңнуллин, Фатих Хөсни, Гәрәй Рәхим, Мөхәммәт Мәһдиев, Атилла Расих, Әмирхан Еники һ. б. язучылар катнашты. Секция бюросының председателе итеп язучы Атилла Расих, секретаре итеп Марсель Галиев, бюро членнары итеп М. Мәһдиев, Р. Мостафин, Г. Рәхим, К. Тимбикова һәм Ә. Гаффар сайланды.

* * *

Балалар әдәбияты секциясенең эшләгән эшләре турында секция бюросы җитәкчесе Адлер Тимергалин сөйләде. Җыелышта катнашучылардан Шәүкәт Галиев, Фарваз Миңнуллин, Шамил Рәкыйпов, Ләбибә Ихсанова, Роза Хафизова, Госман Бакиров, шагыйрьләр Хәкимҗан Халиков, Мәрзия Фәйзуллина һ. б. әдипләр секция бюросының эшенә уңай бәя бирделәр. Секция бюросының председателе итеп язучы Адлер Тимергалин, бюро секретаре итеп шагыйрь Роберт Миңнуллин, бюро членнары итеп Шәүкәт Галиев, Ләбибә Ихсанова, Шамил Рәкыйпов, Разил Вәлиев һәм Равил Кукушкин сайланды.

* * *

Язучыларның 1978 елгы проза әсәрләрен, шулай ук очеркларны һәм публицистик язмаларны тикшерүгә багышланган гомуми җыелышын филология фәннәре кандидаты тәнкыйтьче Флүн Мусин ачып җибәрде. Узган елгы роман, повестьлар, хикәяләр турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Рифат Свиригин сөйләде. Язучы Диләрә Зөбәерованың чыгышы очеркларга һәм публицистик әсәрләргә багышланды. Рифат Свиригин докладың нигездә, 1978 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләргә анализ бирүгә корылган иде. Докладчы Габдрахман Әпсәләмовның «Агыла болыт» романына тукталды, шулай ук Фатих Хөснинең — «Картая белмәс картлык», Шәйхи Маннурның — «Чын сөю бармы?», Гәрәй Рәхимнең — «Саргаймагыз, каштаннар!», Әхмәт Сәйфетдиновның — «Җырла, иркәм», Рафкат Кәраминең — «Очар кошлар белән янәшә», Кояш Тимбикованың — «Агым уртасында», Мөхәммәт Мәһдиевнең — «Кеше китә — җыры кала», Тәүфикъ Әйдинең — «Бөҗра», Барлас Камаловның — «Ярсөяр әрәмәсе» повестьларына җентекле бәя бирде, әлеге әсәрләрдәге уңай һәм кимчелекле якларны күрсәтеп үтте. Ул шулай ук М. Хәбибуллин, Р. Мингалимов, М. Маликова, Ф. Хуҗиәхмәтова, Н. Гыйматдинова һ. б. авторларның хикәяләрен тикшереп, хикәя жанрында мәгълүм алга китеш барлыгын билгеләде. Фикер алышуларда катнашкан Фатих Хөсни, Мирсәй Әмир, Марсель Зарипов, Рафаэль Мостафин, Атилла Расих, Шәйхи Маннур, Гариф Ахунов әсәрләрне идея-художество эшләнешләре ягыннан җентекләп тикшерделәр, әдәби осталыкны арттыруга игътибар өзлексез көчәя барырга тиешлеккә басым ясап әйттеләр.

Публицистикада җылылык, самимилек җитмәү зур кимчелекләрнең берсе булуы искәртеп үтелде. Очерклар һәм публицистик язмаларының авторлары, уңай якларны калку итеп күрсәтү белән бергә, кимчелекләргә каршы да аяусыз булырга тиешләр, диелде.

* * *

Союзның яшь язучылар белән эшләү комиссиясе яшь авторларга практик ярдәм күрсәтүнең төрле формаларыннан файдалана. Шундый эшләрнең берсе — индивидуаль семинарлар уздыру. Соңгы вакытта уздырылган семинарларның чираттагысы яшь шагыйрьләр Ркаил Зәйдуллин (Чувашстан) һәм Ләис Зөлкарнәев (Башкортстан) иҗатына багышланды. Тикшерүдә шагыйрьләр һәм язучылар Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Фарваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Вакыйф Нуруллин, Адлер Тимергалин, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, Роберт Миңнуллин, Фәннур Сафин, Мансур Вәлиев катнашты. Алар әле урта мәктәптә генә укучы яшь шагыйрьләрнең әсәрләрен җентекләп тикшерделәр, анализ ясадылар, киңәшләр бирделәр, әсәрләрен вакытлы матбугатта чыгарырга тәкъдим иттеләр.

### ЯШЬЛЕК БӘЙРӘМЕ

Күптән түгел Түбән Кама җәмәгатьчелеге «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенең унъеллыгын билгеләп үтте. Яшьләрчә дәрт белән эшләп килүче бу берләшмә бик хаклы рәвештә түбәнкамалыларның мәхәббәтен казанды. Ул — культура чараларын үткәрүдә җирле партия һәм совет оешмаларының якын булышчысы. Берләшмә үзенең эшләү дәверендә Разил Вәлиев, Фәннур Сафин, Айдар Хәлим һәм Әхмәт Гадел кебек шагыйрьләрне үстереп чыгарды. Берләшмә эшендә (башлыгы Рахмай Хисматуллин) яшь иҗатчылардан Мөхәммәт Шәйхи, Рифкат Имаев, Кави Зиннәтуллин, Нәфисә Гафиятова, Фәтхулла Абдуллин, Камил Гыйльмуллин, Мизхәт Хәбибуллин актив катнашалар, актив иҗат итәләр. Берләшмәнең иҗат бәйрәме кичәсендә Казаннан шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Фәннур Сафин, Әхмәт Гадел, Госман Садә, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев, Чаллыдан шагыйрь Хәниф Хөснуллин катнашты. Кичәдә берләшмәгә актив булышучы һәм аның эшендә турыдан-туры катнашучы иптәшләргә Татарстан Язучылар союзы идарәсенең, ВЛКСМ

өлкә комитетының Почет грамоталары тапшырылды. Кичә «Яшьлек» жыр һәм бию ансамбле, татар халык театры артистлары, үзешчән сәнгать осталары чыгышы белән тәмамланды. Түбән Каманың 44 нче профессиональ-техник училищесында, 5 нче урта мәктәптә, «Татэнергострой» идарәсендә, 2 нче шәһәр больницасында да шулай ук әдәби-музыкаль очрашулар уздырылды.

## ШАГЫЙРЬ — ПОЧЕТЛЫ КОЛХОЗЧЫ

Шагыйрь Шәүкәт Галиев хезмәт юлын туган колхозында башлый. Ул монда, бигрәк тә Бөек Ватан сугышы елларында аруталуны белми иген игә, Олы Бакырчы басуларыннан фронтка олау-олау ашлык озата. Шагыйрьнең 50 еллыгы уңае белән якташлары аңа Мулланур Вахитов исемендәге колхозның Почетлы колхозчысы дигән мактаулы исем бирделәр.

* * *

Язучы Шамил Рәкыйпов Белоруссия ССР һәм Белоруссия Коммунистлар партиясе оештырылуга 60 ел тулу уңае белән Минскида үткәрелгән тантанада катнашты, Барановичи шәһәрендә булды. Ул шәһәрнең төрле мәктәпләрендә очрашулар уздырды, белорус радиосы буенча чыгыш ясады, Бөек Ватан сугышы каһарманы Иван Кабушкин музеенда элекке партизаннар белән очрашып, легендар Жан турындагы повестена өстәмә мәгълүматлар туплады.

## СТУДЕНТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Казан педагогия институтында татар шагыйрьләре белән очрашу кичәсе уздырылды. Очрашуга шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Разил Вәлиев, Фәннур Сафин һәм Роберт Миңнуллин килгән иде. Кичәне Рәдиф Гатауллин алып барды. Шагыйрьләр үзләренең шигырьләрен укыдылар, сорауларга җаваплар бирделәр, автографлы китаплар сатылды.

## ИҖАДИ ДУСЛЫК

Арча культура йорты каршында эшләүче халык университетының театр факультеты үзенең беренче занятиесен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары белән очрашуга багышлады. Анда СССРның халык артисты Ш. Биктимеров, ТАССРның халык артистлары Һ. Солтанов, М. Миңлебаева, Г. Камалова, Г. Фәтхуллин, ТАССРның атказанган артистлары Г. Исәнгулова, Н. Ихсанова, И. Баһманов, ТАССРның атказанган культура работнигы Р. Сафиуллин һәм башка артистлар катнашты. Театр директоры Ә. Хөсәенов тыңлаучыларны коллективның эшчәнлеге, иҗат планнары белән таныштырды. Соңыннан тамашачыларга төрле спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде.

* * *

Казан дәүләт университеты каршындагы татар театры үзешчәннәре, театр музее белән танышканнан соң, театрның баш режиссеры, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай премиясе лауреаты Марсель Сәлимҗанов белән очраштылар. Әңгәмә вакытында М. Сәлимҗанов режиссер профессиясе һәм аның үзенчәлекле яклары, театрның иҗат планнары турында сөйләде, студентларны кызыксындырган сорауларга җаваплар бирде. Аннары театр сәхнәсендә Василий Шукшинның «Әшнәләр» исемле сатирик комедиясе буенча эшләнгән спектакль күрсәтелде. Соңыннан спектакль турында фикер алышу булды.

## «ОЛЫ ЮЛНЫҢ МАЯКЛАРЫ»

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге һәм сәхнә ветераннары советы Актерлар йортында татар әдәбияты һәм сәнгате тарихы турында сөйләүче «Олы юлның маяклары» исемле әдәби-музыкаль кичәләр оештырып килә. Шул кичәләрнең чираттагысы 1930 нчы еллардагы татар культурасына багышланган иде.

Кичәдә Татарстанның халык артисты Хәким Сәлимҗанов утызынчы елларда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә барган спектакльләр һәм шул чорда иҗат иткән артистлар турында кызыклы истәлекләре белән уртаклашты. Ә язучы Габдрахман Минский драматург, театр һәм тамашачы арасындагы мөнәсәбәтләр турында сөйләде. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык художнигы, Г. Тукай премиясе лауреаты Бакый Урманченың театр декорациясе сәнгате, утызынчы елларда ачылган Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсенең Татарстан павильонын салуда һәм бизәүдә катнашкан архитекторлар, художниклар иҗаты турындагы истәлекләрен тамашачылар бик яратып тыңладылар. Музыка белгече Зәйнәп Хәйруллинаның чыгышы 30 нчы еллардагы музыка сәнгате үсешенә, Татарстанда иҗат оешмалары һәм коллективлары барлыкка килү тарихына багышланган иде.

* * *

Әлмәт татар дәүләт драма театры коллективы ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург Туфан Миңнуллинның «Яшьлегем-юләрлегем» исемле пьесасы буенча эшләнгән спектакль күрсәтте. Соңыннан тамашачылар конференциясе үткәрелде. Чыгып сөйләүчеләр әсәр һәм артистларның уены турында төпле фикерләр әйттеләр, әхлак темасына багышланган бу спектакльне уңай яктан бәяләделәр. Конференциядә Әлмәт язучылары да катнашты.

* * *

Баулы эшчеләр поселогының 14 нче авыл урта профессиональ-техник училищесында әдәби кичә уздырылды. Кичәдә драматург Сәет Кальметов, әдәбият берләшмәсе членнары яшь әдипләр Факил Зәйнагытдинов һәм Сәгадәт Әхмәтшин үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен РСФСР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 6 февраль Указы белән язучы **Нурихан Садрилман улы Фәттаховка (Нурихан Фәттахка) РСФСРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Журналның май аенда чыгачак 5 нче саны өлкән шагыйребез Нури Арслановның яңа әсәрләре белән ачыла. Алар арасында әдипнең туган илгә багышланган шигырьләре дә, лирикасыннан яңа үрнәкләр дә бар.

Монда сез язучы Вакыйф Нуруллинның үткән санда башланган «Аккан су юлын табар» исемле повестеның ахырын укый алачаксыз.

Журналда яңа язылган шигырьләр аеруча күп итеп бирелгән. Шагыйрь Зәки Нуриның «Яз дәфтәреннән» циклы, Рәшит Әхмәтҗановның кыска шигырьләре, Роберт Миңнуллинның «Мәңгелек сәфәр» циклы сезнең күңелгә, мөгаен, хуш килер.

Хикәяләрнең дә төрледән-төрлесен сайлап алып укырга мөмкин. Шамил Маннапов журналга хәрби темага багышланган «Чехолдагы ракеталар» исемле хикәясе белән катнаша. Фоат Садриев хикәясе «Замандаш» конкурсына бирелгән. Яшь язучы Мансур Шәһимәрдәновның «Югалган кыз» исемле хикәясе дә кызыксынып укырлык.

Очерклар шулай ук укучы игътибарын җәлеп итәчәк. Д. Сирайның «Элемтәгә чыгам» очеркы разведчиклар язмышына карый, ә С. Шакир исә язмасында гимнастика буенча Европа чемпионы Галимә Шөгерованың тормышын сурәтли.

Әдәби тәнкыйть материаллары Татарстан язучыларының IX нчы съездын каршылау уңаеннан бирелә. Бу бүлек бүгенге поэзия турында журнал битләрендә алып барылган дискуссиянең йомгаклау утырышы турындагы язма белән башланып китә, «Түгәрәк өстәл янында» фикер алышуда катнашкан әдипләрнең чыгышлары урнаштырыла.

Өлкән буын язучыбыз Фатих Хөсни бу санда үзенең әдәби осталык турындагы уйлануларын язып чыккан. Мәкалә «Орлыклар кая төшә» дип атала.

«Әдәбият тарихына материаллар», «Безнең календарь», «Китап күзәтү», «Төрлесеннән» рубрикаларына да шактый мәгълүмат тупланган.

Юмор яратучы укучылар «Мәсәлчеләр мәҗлесе» һәм «Елмаеп та, көлеп тә...» рубрикаларына карата бирелгән язмаларны кызыксынып укырлар дип ышанабыз.

Журналның 5 нче саны, гадәттәгечә, әдәбият һәм сәнгать яңалыкларын эченә алган язма белән тәмамлана.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210